Академия наук Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова

# ТАТАРОВЕДЕНИЕ В СИТУАЦИИ СМЕНЫ ПАРАДИГМ: ТЕОРИЯ, МЕТОДОЛОГИЯ, ПРАКТИКА

МАТЕРИАЛЫ
МЕЖДУНАРОДНОГО НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОГО СЕМИНАРА, ПОСВЯЩЕННОГО 145-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ КЛАССИКА ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ Г. ИСХАКИ

24–25 апреля 2023 года. Казань

# ПАРАДИГМАЛАР АЛМАШЫНУ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР БЕЛЕМЕ: ТЕОРИЯ, МЕТОДОЛОГИЯ, ПРАКТИКА

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ Г. ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 145 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН
ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ СЕМИНАР МАТЕРИАЛЛАРЫ

2023 елның 24–25 апреле. Казан

# TATAR STUDIES IN THE PARADIGM CHANGING: THEORY, METHODOLOGY, PRACTICE

PROCEEDINGS OF THE INTERNATIONAL SCIENTIFIC AND PRACTICAL SEMINAR DEDICATED TO THE 145TH ANNIVERSARY OF A CLASSIC OF TATAR LITERATURE GAYAZ ISKHAKI

April 24–25, 2023. Kazan

КАЗАНЬ
2023

УДК 323.1+82.091
ББК 83.3(2=632.3)
Т 23

*Печатается по решению Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ в рамках реализии*
*государственной программы Республики Татарстан*
*«Сохранение национальной идентичности татарского народа»*

**Редакционная коллегия:**
*Э.М. Галимзянова, А.М. Закирзянов,*
*М.И. Ибрагимов, А.С. Шарипова*

**Составитель:**
*Л.Р. Надыршина*

**Т 23 Татароведение в ситуации смены парадигм:** теория, методология, практика: материалы международного научно-практического семинара, посвященного 145-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки / сост. Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2023. – 320 с.
ISBN 978-5-93091-449-8

В сборнике представлены материалы международного научно-практического семинара «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика», посвященного 145-летию со дня рождения классика татарской литературы, публициста, общественного деятеля Гаяза Исхаки.

В статьях сборника освещается широкий круг вопросов, имеющих отношение к творчеству Г. Исхаки, его роли в интеллектуальной, политической, общественной жизни татар в первой половине XX века; проблематизируются вопросы о культурном пограничье и татарском зарубежье.

Издание адресовано ученым-гуманитариям, а также читателям, интересующимся творчеством Г. Исхаки, татарской литературой, историей, культурой.

**ISBN 978-5-93091-449-8**

© Оформление. Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2023

## СҮЗ БАШЫ

«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» дигән өченче халыкара семинар мәшһүр татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Гаяз Исхакыйның (1878–1954) тууына 145 ел тулуга багышлана. Узган гасырның беренче яртысында Г. Исхакыйның татар әдәби, мәдәни, иҗтимагый тормышындагы роле бәяләп бетергесез зур.

Аның XX гасыр башы татар сүз сәнгатендәге иң мөһим күренешләрнең берсен хасил иткән әдәби иҗаты тематик һәм жанрлар төрлелеге, мәгърифәтчел, реалистик, публицистик дискурсларга мөрәҗәгать итүе белән аерылып тора. Язучының башлангыч, мәгърифәтчелек чоры әсәрләрендә үк («Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясе, «Бай угълы», «Кәләпүшче кыз» повестьлары, «Өч хатын берлән тормыш» пьесасы) иҗатының әйдәп баручы темасы буларак милләт язмышы калкулана. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) повесть-антиутопиясендә үз халкын юкка чыгу куркынычы турында кисәткән язучы татар дөньясында милләткә хезмәт итү идеалының тере гәүдәләнешенә әверелә. Беренче рус революциясе чорында Г. Исхакыйның актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге (Г. Исхакый татар эсерлары оешмасы «Таң»чылар әйдаманнарының берсе, «Таң йолдызы», «Тавыш» газеталарының мөхәррире булып танылa, Россия мөселманнары партиясе «Иттифак әл-мөслимин» съездларында катнаша. Ул күп тапкырлар кулга алына, Чистай, Казан төрмәләрендә утыра, Архангельск губернасына сөргенгә озатыла) публицист буларак формалашуына ярдәм итә. Аның публицистик чыгышлары, нигездә, милли мәсьәләләргә кагыла: Россиянең сәяси тарихында татарларның урыны һәм роле, аларның төрки дөньядагы урыны, татар мәдәниятен Европа цивилизациясе кыйммәтләренә якынайту һ.б. Г. Исхакый тел, мәгариф, татарларның милли үзтәңгәллеге мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Ул күп мәкаләләрен танылган язучыларга һәм җәмәгать эшлеклеләренә – Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, И. Гаспринский, Р. Фәхреддин, Г. Тукай, Й. Акчура кебек татар милләте әйдаманнары эшчәнлегенә багышлый.

1919 елны Россиядән китәргә мәҗбүр булган Г. Исхакый 1954 елда вафат булганчы татар мөһаҗирлегенең иң абруйлы эшлеклеләреннән берсе булып кала. Кайда гына яшәсә дә (Харбин, Франция, Германия, Польша, Төркия), Г. Исхакый чит илләргә чәчелгән татарларны берләштерү өчен тырыша: милли оешмалар төзи, газета һәм журналлар чыгару белән шөгыльләнә («Милли юл», «Яңа милли юл», «Милли байрак»), ялкынлы чыгышлар ясый. Мөһаҗирлек чоры иҗатында публицистика өстенлек итә, әмма язучы матур әдәбиятны да читкә куймый: «Өйгә таба», «Көз» повестьлары, «Локман Хәким» әкият-антиутопиясе, «Җан Баевич» комедиясе ватаннан читтә языла.

XX гасыр башы татар укучысына бик яхшы мәгълүм булган Гаяз Исхакый исеме революциядән соң (дөресрәге, 1920 еллар башында) татар әдәбияты тарихыннан сызып ташлана. Россия татар матбугатында телгә алынганда, ул бары тик тискәре яктан: буржуаз милләтче, пантюркист дип бәяләнә. Г. Исхакыйның татар әдәбияты тарихына әйләнеп кайтуы 1990 еллар башына,

татарларның милли үзаңы күтәрелеш кичергән чорга туры килә. Шунысы да мөһим: әдипнең эшчәнлеге, иҗаты күп еллар дәвамында ватандагы һәм чит илләрдәге галимнәрнең – тарихчыларның, әдәбият, тел белгечләренең – фәнни кызыксынулары үзәгендә тора.

Хөрмәтле укучы! Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән җыентыкка Төркия, Казакъстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Татарстан һәм Россия галимнәренең Г. Исхакый тормышын һәм иҗатын төрле яклап ача һәм ачыклый торган мәкаләләре тупланды.

Г. Исхакыйның язмышы һәм хезмәтләре турындагы язмалар белән беррәттән, җыентыкта татар мөһаҗирлегенә багышланган мәкаләләр дә урын алды. Күп кенә татар зыялылары, Г. Исхакый кебек үк, татарларга тугандаш төрки телле халыкларның әдәбиятын, фәнен, сәнгатен үстерүдә зур роль уйнаганнар. Аларның мирасын, төрки халыклар алгарышына керткән өлешен өйрәнү хәзерге татар гыйлеменең әһәмиятле бурычы булып кала.

Татар мәдәниятен (тел, әдәбият, сәнгать) башка милли мәдәниятләр белән бәйләнешләр яссылыгында тикшерү дә мөһимлеген югалтмый. Г. Исхакыйның иҗаты үзе дә – әдәби, мәдәниятара сөйләшүнең матур бер үрнәге ул. Мәсәлән, әдипнең революциягә кадәр М. Горький белән хат алышуы, Л. Толстойның әдәби иҗатын махсус бәяләве, яшүсмер вакытта ук төрек тәрҗемәләре ярдәмендә Европа әдәбияты белән танышуы, гомере буе аннан аерылмавы мәгълүм. Мәдәни бәйләнешләр мәсьәләсенә кагылышлы, җыентыкка кертелгән мәкаләләр бу мәдәни феноменны өйрәнүнең теоретик-методологик юнәлешләрен дә билгели.

«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» проектының нигезендә татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен башка халыкларның телләре, әдәбиятлары, мәдәниятләре белән теоретик-методологик күпьяклы һәм чагыштырма өйрәнүгә юнәлдерелгән ачык фәнни мәйданчык булдыру фикере дә ята. Төрле илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган гуманитар галимнәрне берләштерүче дискуссия мәйданчыгы татар белеме өлкәсендә яңа юллар һәм сукмаклар табуга да ярдәм итәр дип өметләнәбез.

*«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме:*
*теория, методология, практика» проекты җитәкчесе,*
*филология фәннәре кандидаты*
***Марсель Ибраһимов***

## ПРЕДИСЛОВИЕ

Третий международный семинар «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика» приурочен к 145-летию татарского писателя, общественного и политического деятеля Гаяза Исхаки (1878–1954). Трудно переоценить роль Г. Исхаки в литературной, культурной, общественной жизни татарской нации в первой половине прошлого столетия.

Его литературное творчество – одно из ярких явлений в литературе начала XX века – отличалось тематической и жанровой многоплановостью, множественностью дискурсов (просветительский, реалистический, публицистический). Уже в ранних, просветительских, произведениях писателя (рассказе «Счастье в знании», повестях «Байский сынок», «Тюбетейщица», пьесе «Жизнь с тремя женами») обозначилась тематическая доминанта его творчества – судьба татарской нации. Писатель, который предрек ее исчезновение в повести-антиутопии «Исчезновение через двести лет» (1904), стал в татарском мире живым воплощением идеала служения нации. Активная общественно-политическая деятельность Г. Исхаки в период первой русской революции (Г. Исхаки был одним из лидеров организации татарских эсеров «Тангисты», был фактическим редактором газет «Тан юлдызы», «Тавыш», принимал участие на съездах партии российских мусульман «Иттифак аль-муслимин». Он многократно подвергался арестам, сидел в тюрьмах Чистополя, Казани, находился в ссылке в Архангельской губернии) во многом способствовала его становлению как публициста. Его публицистические выступления посвящены, преимущественно, национальным вопросам: месту и роли татар в политической истории России, их положению в тюркском мире, приобщению татарской культуры к ценностям европейской цивилизации и др. Значительное внимание Г. Исхаки уделял вопросам татарского языка, образования, национальной идентичности татар. Много статей Г. Исхаки посвятил известным литературным и общественным деятелям – лидерам татарской нации: Ш. Марджани, К. Насыри, И. Гаспринскому, Р. Фахретдину, Г. Тукаю, Ю. Акчуре и др.

Вынужденный в 1919 году покинуть Россию, Г. Исхаки до самый своей смерти в 1954 году оставался одним из самых авторитетных деятелей татарской эмиграции. Везде, где бы он ни жил (Харбине, Франции, Германии, Польше, Турции), Г. Исхаки работал для объединения живущих за рубежом татар: создавал национальные организации, занимался выпуском газет и журналов («Милли юл», «Янга милли юл», «Милли байрак»), делал публичные выступления. В годы эмиграции у Г. Исхаки преобладает публицистика, впрочем, писатель не оставляет и литературного творчества: повести «Өйгә таба» («Домой»), «Көз» («Осень»), сказка-антиутопия «Лукман Хаким», комедия «Джан Баевич» и др.

Имя Гаяза Исхаки, хорошо известное татарскому читателю в начале XX века, после революции (точнее – в начале 1920-х гг.) вычеркивается из истории татарской литературы. Если его и упоминали в российской татарской печати, то исключительно с негативными оценками: как буржуазного националиста, пантюркиста. Возвращение Г. Исхаки в татарскую литературу

состоялось в начале 1990-х гг., в период роста национального самосознания татар. Важно и другое: деятельность Г. Исхаки, его творчество на протяжении многих лет остаются в орбите научных интересов как отечественных, так и зарубежных ученых: историков, литературоведов, лингвистов. В предлагаемый вашему вниманию сборник включены статьи, проблематизирующие различные аспекты его жизни и творчества, ученых из Турции, Казахстана, Азербайджана, Кыргызстана, Татарстана, городов Российской Федерации.

Наряду с публикациями о жизни и творчестве Г. Исхаки в сборник вошли статьи, посвященные татарскому зарубежью. Многие татарские интеллектуалы, как и Г. Исхаки, играли весомую роль в развитии литературы, науки, искусства у родственных татарам тюркоязычных народов. Изучение их наследия, вклада в просвещение тюркских народов – актуальная задача современного татароведения.

Не менее значимым вопросом является исследование татарской культуры (языка, литературы, искусства) в зонах контактов с другими национальными культурами. Само творчество Г. Исхаки – яркий образец включенности в орбиту межлитературных, межкультурных диалогов. Известно, например, что Г. Исхаки до революции вел переписку с М. Горьким, высоко ценил литературное творчество Л. Толстого, благодаря турецким переводам, хорошо знал европейскую литературу. Включенные в сборник статьи по проблеме культурного пограничья определяют теоретико-методологические векторы изучения этого культурного феномена.

Проект «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика» в основе своей содержит идею открытого татароведения, ориентированного на максимальную теоретико-методологическую плюралистичность и сопоставление татарского языка, татарской литературы и культуры с языками, литературами, культурами других народов. Создание дискуссионной площадки, объединяющей ученых-гуманитариев из разных стран и регионов России, надеемся, будет содействовать поиску проективных смыслов в области татароведения.

*Руководитель проекта «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика», кандидат филологических наук*
***Марсель Ибрагимов***

# ЛИТЕРАТУРНОЕ ТВОРЧЕСТВО ГАЯЗА ИСХАКИ: ПОЭТИКА, РЕЦЕПЦИЯ, ИНТЕРПРЕТАЦИЯ / ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ӘДӘБИ ИҖАТЫ: ПОЭТИКА, РЕЦЕПЦИЯ, ИНТЕРПРЕТАЦИЯ / GAYAZ ISKHAKIE'S WRITINGS: POETICS, RECEPTION (RECEIVING), INTERPRETATION

УДК 821.512.145

## АМИРХАН ЕНИКИ О ЛИЧНОСТИ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

Классик татарской литературы Амирхан Еники (1909–2000) в научном и творческом сообществе известен тем, что в свое время среди интеллигенции первым встал на защиту доброго имени Г. Ибрагимова, Г. Исхаки, Г. Тукая. Стало известно, что А. Еники планировал написать произведения о Г. Ибрагимове и Г. Исхаки. В статье анализируются публицистические труды писателя относительно личности Гаяза Исхаки.
**Ключевые слова:** Амирхан Еники, Гаяз Исхаки, творчество, публицистика.

The classic of Tatar literature Amirkhan Eniki (1909–2000) in the scientific and creative community is known for being the first among the intelligentsia to defend the good name of G. Ibragimov, G. Iskhaki, G. Tukay. It became known that A. Eniki planned to write works about G. Ibragimov and G. Iskhaki. The article analyzes the journalistic works of the writer regarding the personality of Gayaz Iskhaki.
**Key words:** Amirkhan Eniki, Gayaz Iskhaki, creativity, journalism.

## ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ШӘХЕСЕНӘ БӘЯСЕ

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Татар әдәбиятының классик язучысы Әмирхан Еникинең (1909–2000) публицистик эшчәнлеге, аеруча милләт хадимнәренә мөнәсәбәтле фикер-карашлары, гамәлләре даими өйрәнелә килә [1]. Әдәбият галиме Фоат Галимуллин: «Без Әмирхан Еникине милләт хадиме, сәясәтче дип тә атыйбыз. Аның «Татар мәсьәләсе», «Кояш баер алдыннан» хезмәтләре Гаяз Исхакыйның мәгълүм «Идел-Урал» дигән хезмәтенең дәвамы буларак каралырга мөмкин. Боларның һәммәсе Әмирхан Еникине һәм шәхес, һәм әдип, һәм фикер иясе буларак халкыбызның горурлыгы дип расларга мөмкинлек бирә», – дип яза [2: 3].

Ә. Еники үз заманында Г. Исхакый исемен җәмәгатьчелек алдында кыю рәвештә беренчеләрдән булып яклап чыга алган әдипләрнең берсе. Дипломат-галим Йолдыз Хәлиуллин Ә. Еникинең Гаяз Исхакый һәм Галимҗан Ибраһимов турында аерым әсәр язу нияте белән йөрүен әйтә [6: 109]. Ә. Еникинең Г. Исхакый иҗатына һәрчак аерым игътибарлы булуын галим Ф. Галимуллин да ассызыклый [2: 3]. КФУ профессоры фикеренчә, Ә. Еники Г. Исхакый шәхесенең үз иҗатына йогынтысын һәрдаим әйтә килә [2: 3].

Ә. Еники Г. Исхакый хакында төрле каршылыклы фикерләр йөргән елларда «Казан утлары» журналында басылган «Көтелмәгән хат» (1989) дип исемләнгән мәкаләсендә Әнкарадан үзе исеменә килгән хатларны укып, язучыны яклап чыга: «Безнең өчен тагы да мөһимрәге – ул хатларның Гаяз Исхакыйга кагылган юллары. Монда шунысы игътибарга лаек: алар бездә Гаяз Исхакый турында кызу бәхәс

барганын ничектер ишетеп белгәннәр һәм шушы уңай белән инде Гаяз турында үзләре белгәнне дә хәбәр итәләр. Мәсәлән, Әнкарәдә яшәүче Мәхмүт әфәнде үзенең хатында «Г. Исхакый Гитлер Алманиясе белән эш берлегендә булмады. «Идел-Урал» легионы эшенә дә катнашмады, Икенче дөнья сугышы елларында Алманиядә дә булмады», – дип яза. Минһаҗ әфәнде дә үзенең җавап хатында шуны ук кабатлый: «Гаяз ага Гитлерга катнашмады, ул Гитлерны танымады. Бу хакыйкать, моны беркем инкарь итә алмас!» – ди. Минһаҗ әфәнде, сугыштан соң Төркиягә баргач, Г. Исхакыйның үзен дә күргән, сөйләшеп тә утырган, хәзерге көндә дә Гаязның кызы Сәгадәт ханым белән даими бәйләнеш тота. Берсе Төркиядән, икенчесе Германиядән торып язган бу ике кешенең сүзләренә ышанырга буламы! Минемчә, була. Чөнки алар Г. Исхакый турындагы чын дөреслекне ерактан фараз кылып кына түгел, ә бик якыннан күреп яки ишетеп белүчеләр Бу бер. Икенчедән, алар язганны кире кагарлык бер дәлил дә безнең кулыбызда юк. Бездә кайберәүләр Г. Исхакый сугыш вакытында Германиядә булган, Гитлерга хезмәт иткән дип язып чыксалар да, моны фактлар белән шулай ук исбат иткәннәре юк әле. Мәгәр, кызганычка каршы, дәлилләмәгән шундый сүзләр «Гаяз мәсьәләсен» хәл итүне һаман да булса тоткарлап килә дә» [4: 188].

«Казан утлары» журналының 1994 елгы дүртенче санында Әмирхан Еники «Ялганны яклау» дигән баш астында Тукай клубында 1971 елны ясаган бер чыгышы хакында мәкалә бастыра [3: 692–707]. Әдип язучыларга философия фәннәре кандидаты З.А. Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» дигән китабына мөнәсәбәт белдерү уңае белән мөрәҗәгать итә. «Ялганны яклау» мәкаләсендә Г. Исхакый шәхесен яклаган мондый юллар да бар: «Тукайның «Мөхәрриргә» дигән шигыре турыдан-туры Гаяз Исхакыйга атап язылганын Хәсән абзый Туфан белергә тиеш иде. Чөнки моннан берничә ел элек кенә Ташкенттан Казанга килеп киткән, кайчандыр Гаязга бик якын торган Шакир карт Мөхәммәдьяров Хәсән абзый бүлмәсендә сөйләшеп утырганда (Маяковскийда торган чагында), безнең икебезгә ул шигырьнең махсус Исхакыйга атап язгылганын, һәр юлын укый-укый, бик әйбәт аңлатып биргән иде. Гаҗәеп шигырь!.. Нинди тирән хөрмәт һәм өмет булган Тукайда Гаяз Исхакыйга карата!.. Хәзер инде бу исбат ителгән бәхәссез хакыйкать» [3: 699]. Х. Туфан катнашында булган әлеге сөйләшүне Ә. Еники «Гөмбәгә бару» мәкаләсендә дә кабатлый.

«...Без дә бардык Төркиягә...» дигән баш атында дөнья күргән мәкаләсендә (1996) Ә. Еники Г. Исхакый белән Й. Акчура каберләрен зират итәргә баруы хакында билгеләп үтә. Татар әдибенең Й. Акчура кабере янындагы хисләре болай бирелә: «Бик әйбәт сакланган кабернең ташы безне аеруча гаҗәпләндерде һәм сокландырды. Ул таш – кечерәйтелгән Сөембикә манарасының нәкъ үзе иде!.. Мәрхүмнең васыяте беләнме, әллә кызларының акылы җитепме эшләнгән бу таш Сөембикә манарасы – олы шәхеснең туган иле белән мәңгелек бәйләнешен чагылдырган символы буларак басып торадыр» [3: 277]. Шунда Ә. Еники Кәрим Тинчуринның җәмәгате Заһидә Әхмәрова сөйләгән вакыйганы бәян итә: «1921–1922 ачлык елларын Кәрим абзый белән Заһидә апа Ташкентта уздыралар. Шул чагында аларга Гаязның аылда калган үсмер кызын кемдер китерә (ихтимал, бу алдан хәбәрләшү буенча эшләнгәдер, дип уйлыйм мин). Сәгадәт авыр кышны Заһидә апаларда торып үткәрә. Егерме икенче елның җәендә Ташкенка Галимҗан Идриси (шулай ук бик билгеле шәхес, килеп, Германиядә укытыр өчен шәкертләр җыя. Ул үзе Берлин университетының укытучысы була. Җыйган шәкертләре белән бергә Идриси Тинчуриннардан Сәгадәтне дә алып китә – әлбәттә, кем кызы икәнен яхшы белеп. Менә шул кешеләрнең игелеге аркасында Гаяз Исхакый бердәнбер кызы белән Берлинда очраша» [3: 278].

«Шәхес» дип исемләнгән мәкаләсендә Ә. Еники милләт хадимнәре Б. Урманче белән Г. Исхакый очрашуын тәэсирле сурәтли, әдипнең әсәрләре белән яшьтән таныш булуын билгеләп үтә: «Аннары Бакый абзый инкыйлаб елларында Гаяз Исхакый белән дә очрашырга өлгергән (Кулын үбеп күрештем дип сөйләгән иде). Исхакыйның татар дөньясында даны аеруча нык күтәрелгән чагы, аңа баш июче яшьләр, әлбәттә, күп булгандыр, мәгәр дошманнары да аз булмаган – бигрәк тә большевикларга иярүчеләрдән. Әмма Гаяз Исхакый барысыннан элек бөек әдип – менә шунсы Бакый абзыйны беренче нәүбәттә әсир иткән булырга тиеш... Мин дә Гаяз Исхакый дигән әдип-

не ишетеп кенә түгел, бик яшьтән үк укып та белә идем. Бездә аның кайбер әсәрләре бар иде – егерменче елларның башларында ук миңа шуларны укырга да туры килде. (Соңыннан иң хәтәр елларда да мин аларны үземдә сакладым). Күрәсез, Гаяз Исхакый мәсьәләсе дә безнең өчен уртак тема иде» [3: 778].

Мәгълүм ки, Ә. Еники Г. Исхакый исемен партия өлкә комитеты җитәкчелеге алдында да яклауда катнашуын да әйтә. «Кояш баер алдыннан» исемле җыентыгында ул бу хакта болай теркәп калдыра: «Сүз-бәхәс нәрсәләр турында барды соң? Алдан билгеләп куйган мәсьәләләр юк иде, алар сүз барышында үзеннән-үзе туды. Безне уйландырган, борчыган күп мәсьәләләр кузгатылды, хәтта бик хәтәр Гаяз Исхакый мәсьәләсен дә телгә алдык. Аны Нәкый абзый кузгатты (Гаяздан башка әдәбият тарихыбыз тулы түгел, ул кешенең яхшы эшләрен начар эшләреннән аерып карарга вакыттыр инде, без бит марксистлар дигәнрәк мәгънәдә әйткән иде ул). Ләкин Табиев Исхакый турында сөйләшүне катгый рәвештә кире какты...» [5: 116].

Шул рәвешле, Ә. Еники Г. Исхакый шәхесенә мөнәсәбәтен кыю рәвештә гел белдерә килә. Хәлбуки әдәби әсәр язарга ниятләве дә күңелендә йөрткән тирән уйлануларын киң җәмәгатьчелеккә бербөтен итеп тапшырып калдыру теләге белән бәйле булгандыр.

ӘДӘБИЯТ


1. Гайнуллина Г.Р. Жанрово-тематическое своеобразие публицистики А. Еники 1960–1980-х годов // Филология и культура. – 2015. – № 4 (42). – С. 202–205.

2. Галимуллин Ф.Г. Әдәбияттагы морзабыз // Ватаным Татарстан. – 2019. – № 32. – Б. 3.

3. Еники Ә.Н. Әсәрләр. Биш томда. V т. Публицистик язмалар, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 479 б.

4. Еники Ә.Н. Көтелмәгән хат // Казан утлары. – 1989. – № 1. – Б. 188–190.

5. Еники Ә.Н. Кояш баер алдыннан. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1996. – 192 б.

6. Шәехов Л.М. Дипломат-галим Йолдыз Хәлиуллин. – Казан: «Ак бүре» нәшр., 2021. – 143 б.


УДК 82-821

## ПЯТНАДЦАТИТОМНОЕ ИЗДАНИЕ «СОЧИНЕНИЙ» ГАЯЗА ИСХАКИ


***Э.М. Галимзянова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



В данной статье рассматривается история подготовки 15-ти томника «Сочинений» Г. Исхаки.



**Ключевые слова:** Татарская литература, Гаяз Исхаки, творческое наследие, источниковедение.



This article discusses the history of the preparation of the 15-volume «Works» by G. Iskhaki.



**Key words:** Tatar literature, Gayaz Iskhaki, creative heritage, source studies.


## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ УНБИШ ТОМЛЫ БАСМАСЫ


***Э.М. Галимҗанова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*


Гаяз Исхакыйның ярты гасырдан артык гомерен иңләгән күпкырлы иҗади эшчәнлеге әдәби әсәрләреннән, публицистик язмаларыннан, әдәби тәнкыйть мәкаләреннән гыйбарәт. Заманында әдипнең эшчәнлеге басма китаплары, вакытлы матбугат битләрендә басылган мәкаләләре аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә барган.

Гаяз Исхакый, татарларда милли үзаң тәрбияләү, милли-азатлык, бердәмлек булдыру юнәлешендәге уй-фикерләрен халкына җиткерү максатыннан, үзенең вакытлы матбугат органнарын да булдыра. Инкыйлабка кадәр Казан, Петербург, Мәскәү шәһәрләрендә чыккан «Таң йолдызы» (1906), «Ил» (1913–1915; 1917–1918), «Сүз» (1915–1916), «Безнең ил» (1916–1917) газеталарының оештыручысы һәм фактик мөхәррире була [3: 353–358; 1: 119]. 1918–1919 елларда исә Себердә Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә «Маяк» газетасын нәшер итә [3: 358–360].

«Милләт хезмәтчесе» булып җитешкән Г. Исхакый, 1917 елның октябрь инкыйлабыннан соң илендә хөкем сөргән вазгыятьне кабул итә алмау нәтиҗәсендә,

мөһаҗирлектә яшәргә мәҗбүр була. 1919 елның 24 гыйнварында Версаль солых конференциясенә дип чыгып китә һәм шул китүеннән үз иленә әйләнеп кайтмый. Кытайда (Харбин), Франциядә (Париж), Германиядә (Берлин), Польшада (Варшава) яши; 1939 елның җәеннән Төркиягә күчеп килә. Башта Истанбул шәһәрендә, соңгы көннәрен (ягъни 1954 елның 26 маеннан 22 июленә кадәр) Әнкарада кызы Сәгадәт белән кияве Таһир Шакир (Чагатай) тәрбиясендә үткәрә. Кызганыч ки, үз вакытында әдипнең мөһаҗирлектәге иҗаты татар укучысына барып ирешә алмый.

Г. Исхакый, туган иленнән читтә яшәсә дә, төрки-татар халкын туплаучы, рухи яктан тәрбияләүче бөек шәхес, остаз булып кала. Харбин, Берлин, Варшава шәһәрләрендә яшәгәндә «Милли юл», «Яңа милли юл» [6: 413] журналларын, «Милли байрак» газетасын чыгаруны оештыра. Аларда татар милләтенең язмышы, киләчәге хакында борчуларын белдерә, телне, милли мәдәниятне саклау проблемаларын күтәрә. Мөһаҗирлектә дә әдипнең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге әдәби иҗаты белән тыгыз үрелеп бара.

Туган иленнән киткәч, Исхакыйның иҗатына һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенә совет хакимияте тарафыннан кара тамга салына: исеме әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез тарихыннан сызып ташлана. Бары узган гасырның 90 нчы елларында гына, илдә сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләр башлангач, ватаныннан читтә гомер кичерергә мәҗбүр булган Гаяз Исхакыйның катлаулы тормышын, күпкырлы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген өйрәнергә һәм объектив бәяләргә мөмкинлек туа. Әдипнең бай иҗат мирасын барлау һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү бурычы куела.

1993 елның 26 апрелендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Г. Исхакыйның исемен мәңгеләштерү һәм әсәрләренең тулы басмасын әзерләү буенча карар кабул ителә. 213 нче номерлы әлеге карарда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Язучылар берлеге һәм Мәдәният министрлыгыннан әдипнең унбиш томлы «Әсәрләр» җыелмасын бастырып чыгару тәкъдимнәре хуплана һәм басманың 8 кешедән (М.Х. Хәсәнов – рәис, Ф.М. Мусин – рәис урынбасары, Л.Р. Гайнанова, Ә. Еники, М.М. Таишев, И.З. Нуруллин, Н.Г. Юзиев, Ф.М. Миңнуллин) торган баш редакцион коллегиясе раслана, бастырып чыгару эше Татарстан китап нәшриятына билгеләнә. Карарда әлеге эшне үтәргә тиешле оешма итеп Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе билгеләнә. Шулай итеп, Г. Исхакыйның күптомлы «Әсәрләр»ен әзерләү Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләренә йөкләнә.

Г. Исхакыйның бай иҗатын татар укучысына җиткерү эше бер төркем текстолог-галимнәр (Лена Гайнанова, Зөфәр Рәмиев, Фатыйма Ибраһимова, Зөфәр Мөхәммәтшин, Эльмера Галимҗанова, Фәния Фәйзуллина, Гөлназ Хөснетдинова, Гөлчирә Ханнанова, Рәшит Кадыйров) тарафынннан тормышка ашырылды. Зур эшнең нәтиҗәсе буларак, Гаяз Исхакыйның унбиш томлы «Әсәрләр»е дөнья күрде (1998–2014). Әлеге басма татар әдәбияты тарихында зур күләмдә әзерләнгән беренче унбиштомлык иде. Шуңа күрә дә әлеге басманың басылып чыгуы татар мәдәниятендә зур вакыйга буларак кабул ителде. Әлеге хезмәт 2016 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге иң югары бүләгенә – Дәүләт премиясенә лаек булды.

Г. Исхакый унбиштомлык «Әсәрләр»енең беренче дүрт томында әдипнең 1917 елга кадәрге иҗат мирасы – прозасы һәм драматургиясе бирелде. Аларда милләтне саклау һәм үстерү буенча үзенең программасын чагылдырган «Ике йөз елдан соң инкыйраз», патша самодержавиесенең халыкларны изү сәясәтен фаш иткән «Зиндан», татарларны көчләп чукындыру фаҗигасен чагылдырган «Зөләйха», иҗатында яңа баскычны тәшкил иткән «Мөгаллимә» кебек әсәрләр белән танышырга мөмкин.

5 нче томга мөһаҗирлектә иҗат ителгән «Өйгә таба», «Көз», «Локман Хәким», «Татар кызы», «Тәүбәгә килгән хатын» әсәрләре һәм «Дулкын эчендә», «Җан Баевич», «Хәят юлында», «Олуг Мөхәммәд» кебек сәхнә әсәрләре урнаштырылды.

1902–1935 еллар аралыгын үз эченә алган публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре 6–13 нче томнарда урын алдылар. Төрле архивларда, музейларда, шәхси кулларда сакланып калган автобиографик язмалары («Тәрҗемәи хәлем» һәм «Васыятьнамә») һәм 320 хаты (1902–1954) 14 нче томда бирелделәр [5: 377–380].

Басмага шулай ук Г. Исхакыйның 1898–1917 елларда тормышы һәм иҗаты турында замандашлары тарафыннан язылган мәкаләләр, рецензияләр, Казан губерна жандарм идарәсе документлары (8 нче том), шулай ук иҗади һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турында (1923–1990) СССРда һәм чит илләрдә басылган мәкаләләр, истәлекләр дә (15 нче том) тупланды. Барлык материаллар киң җәмәгатьчелеккә текстологик яктан эшкәртелеп, сүзлекләр, фәнни искәрмә һәм аңлатмалар белән баетылып тәкъдим ителде.

Унбиштомлыкны әзерләү барышында институт галимнәре тарафыннан гаять зур эш башкарылды. Әдипнең иҗаты китапханәләрдән, мирасханә һәм музейлардан барланды. Ул яшәгән чорда нәшер ителгән, үзе оештырган, җитәкчелек һәм хезмәттәшлек иткән барлык вакытлы матбугат битләреннән: «Тәрҗеман», «Шәркы рус», «Таң йолдызы», «Әл-ислах», «Казан мөхбире», «Бәянелхак», «Ил», «Сүз», «Безнең ил», «Маяк», «Милли байрак» газеталарыннан һәм «Әлгасрелҗәдит, «Сыйрател-мөстәкыйм», «Төрек йорты», «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларыннан мәкаләләр туплап бирелде. «Ил», «Сүз», «Безнең ил», «Маяк» газеталарының Казанда булмаган саннарының күчермәләре Мәскәү, Санкт-Петербург китапханәләреннән кайтартылды.

Г. Исхакыйның ярты гомере мөһаҗирлектә узганлыктан, аның тормышына һәм иҗатына караган материалларның күп өлеше чит илләрдә дә калган иде. Көрәшче-әдипнең катлаулы тормышын, күпкырлы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген җентекләп тикшерү, Төркиядә сакланып калган мирасын ватанына кайтару юлында да шактый эшләр башкарылды. 1997 елда Төркиянең Әхмәдвәли Мәңгәр фонды президенты Суфия Имре Г. Исхакый белән бәйле документлар һәм хатларны Татарстан милли архивына тапшырды. 2000 елларда Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелеге тырышлыгы белән Төркиядәге архив һәм китапханәләрдән «Сыйрател мөстәкыйм» газетасының аерым, «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларының күпчелек саннарының күчермәләре кайтартылды.

Кызганыч ки, гомере буе күченеп йөргәнлектән, Г. Исхакыйның мирасы тулысы белән сакланмаган. Аңа, 1919 елда Мәскәүдәге торак йортыннан киткәндә, 1939 елда Варшавадан күченгәндә, кыйммәтле документларын калдырып китәргә туры килә. Өендә тентүләр оештырылган вакытларда да күп кенә кульязмалары югала.

Шулай итеп, авыр һәм катлаулы гомер һәм иҗат юлы үткән көрәшче әдипнең киңкырлы бай мирасы әле дә җыйнала һәм туплана бара. Шул уңайдан, мәсәлән, 2008 елда, Төркиянең «Аяз-Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакый мирасының бер өлешен: документлар, хатлар, көндәлекләренең электрон күчермәләрен, 2018 елда исә төп нөсхәләрен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә бүләк итте [2: 104]. Әлеге материаллар арасында иң кыйммәтлесе – аның үз кулы белән язып барган шәхси көндәлек дәфтәрләре.

Көндәлекләренең әһәмиятен ассызыклап, Г. Исхакый үзе дә васыятьнамәсендә: «…Дәфтәрләремнең кыйммәте – тарихи һәм мәгънәви ягында. Һәм бу дәфтәрләрнең эчтәлеге киләчәктә Идел-Урал төрки-татар мөселманнарының милли хәрәкәтләренең зур әһәмиятен яктыртачак...» – ди [4: 410].

Бүгенге көндә Институтның текстология бүлеге галимнәре тарафыннан әлеге көндәлек дәфтәрләрен өйрәнү һәм басмага әзерләү эшләре алып барыла. 1 нче китабы әзер. Әлеге материаллар Г. Исхакый мирасын тагын да баетыр, әдипнең мөһаҗирлек чорын өйрәнүгә яңа этәргеч бирер дигән өметтә калабыз.

## ӘДӘБИЯТ


1. Галимҗанова Э.М. Гаяз Исхакыйның 1917 елгы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге һәм «Ил» газетасы // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост: Ф.Х. Миннулина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 118–121.

2. Гарипова Л.Ш., Ханнанова Г.М. Гаяз Исхакый Япония турында (1919 елгы көндәлек хатирәләре буенча) // Гасырлар авазы – 2018. – № 3. – Б. 102–112.

3. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 9 т.: публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 415.

4. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст. һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

5. Фәйзуллина Ф.Г. Гаяз Исхакый хатларында яктыртылган кайбер әдәби проблемалар // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост: Ф.Х. Миннулина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 377–380.

6. Хөснетдинова Г.А. «Совет илләрендә ниләр бар?» («Яңа милли юл» журналы материаллары нигезендә) // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост: Ф.Х. Миннулина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 412–415.

УДК 821.512.145.2

## ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ И ТВОРЧЕСТВО ГАЯЗА ИСХАКИ В ОЦЕНКЕ ТАТАРСКИХ ЛИТЕРАТУРОВЕДОВ

***Ф.Г. Галимуллин***

*Казанский федеральный университет (Казань)*

В статье анализируются научные и научно-критические публикации современных литературоведов, благодаря которым было возвращено литературного и социокультурное наследие выдающегося татарского общественного деятеля и писателя – Гаяза Исхаки. В статье особое внимание уделяется исследованиям профессора И.З. Нуруллина, академика АН РТ М.Г. Усманова – первых исследователей творчества писателя, а также рассматриваются публикации литературоведов XXI века.

**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Ибрагим Нуруллин, Миркасим Усманов, литературоведение, современная оценка, традиции.

The article analyzes publications in the press of Tatar literary critics dedicated to the work of Gayaz Iskhaky. Particular attention is paid to the studies of Professor I.Z. Nurullin and Academician of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan M.G. Usmanov. Due to their studies the legacy of the outstanding public figure and writer Gayaz Iskhaky was returned to the cultural context of Russia. The article also presents an analytical review of the other modern Tatar literary critics' publications dedicated to Gayaz Iskhaky.

**Key words:** Gayaz Iskhaky, Ibragim Nurullin, Mirkasim Usmanov, literary criticism, contemporary assessment, traditions.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ИҖАТЫ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМНӘРЕ БӘЯЛӘВЕНДӘ

***Ф.Г. Галимуллин***

*Казан федераль университеты (Казан)*

XX йөз башы татар иҗтимагый фикере формалашуда күренекле әдибебез һәм сәяси эшлеклебез Гаяз Исхакыйның хезмәтләре әһәмиятле урын алып тора. Шул исәптән 1905–1917 еллар арасындагы нибары унике ел эчендә иҗтимагый аңның әһәмиятле өлешен тәшкил итүче сүз сәнгатебезнең тармакланып үсеп китүенә дә аның тәэсире зур булды. Бу җәһәттән әлеге алгарышларга аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902) әсәренең ролен аеруча билгеләп үтү зарур. Ник дигәндә, бу мәсьәләләрдә әлеге әсәр ясаган көчле тәэсирне башка бер генә хезмәтнең йогынтысы белән дә чагыштырып булмыйдыр. Сүз дә юк, 1905 елның 17 октябрендә халык күтәрелешләре нәтиҗәсендә мәгълүм Манифест барлыкка килмәсә, мондый фикер алгарышына ирешү өчен, дәвамлырак вакыт кирәк булыр иде. Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Максуди, Ш. Камал, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Г. Коләхмәтов һәм башка каләм әһелләребезнең әдәбиятыбызда төрле жанрларда берсеннән-берсе иң мөһим мәүзугларга иҗат ителгән әсәрләре гомуми үсешне барлыкка китерде. Татарлар тупланып яшәгән барлык төбәкләрдә дә зур җанлылык, күтәренке рух барлыкка килде. Туган телебездә матбугат барлыкка китерүгә, татарча спектакльләр куюга мөмкинлек алган милләттәшләребезнең кыска гына вакыт аралыгында ирешкән казанышлары шактый сизелерлек булды.

Г. Исхакый бу әсәрендә халкыбызның иҗтимагый-сәяси, дөньяви белем белән коралланууда, мәдәни үсештә артта калуының сәбәпләрен бәйнә-бәйнә тәфтишләп ача. Алар, аның карашынча, түбәндәгеләргә кайтып кала:

Беренчесе: Дин әһелләребезнең алдынгы карашларны якламавы. «Халкыбызның иң курка торган нәрсәләре, – ди ул, – укыган кешедә диннең бетүедер. Хәзер бер эш булдымы, укыган кешеләрдә миллиянең (милли әхлакның) югалуын һәм диннең зәгыйфьләнүен сөйләргә тотыналар. Бу, минемчә, безнең исламиятне белмәвебез». Ул турыдан-туры мәктәп-мәдрәсәләрдә укытыла торган гыйлемнәрнең дөньяви ихтыяҗларга яраксыз булуын күрсәтә. Ул заманда, мондый нәтиҗә чыгару өчен, бик кыю булырга кирәк иде.

Икенчесе: Халык мәнфәгатьләрен кайгырту сәләте булган кешеләрнең, бик фәкыйрь сыйныфтан чыгып, милләткә хезмәт итәр урында, бар көчен тамагын туйдыру, үзенең эш урынын саклар өчен сарыф итәргә мәҗбүр булуы.

Өченчесе: Бик надан булуыбызны танымавыбыз, фәннәрнең мәктәп-мәдрәсәләребездә урын алмавы.

Дүртенчесе: Кылган эшләребезнең нигезле, эзлекле булмавы, башланган гамәлләребезне ахырына кадәр җиткерә алмавыбыз һәм башкалар.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, халкыбызның бу мәсьәләләрдә артта калуының сәбәпләре болар белән генә чикләнмәве XX гасыр башындагы вәзгыятне азмы-күпме белгән кеше өчен болай да ачык. Мондый хезмәтне язарга алынган Г. Исхакыйның да аларны белмәве мөмкин түгел. Бу чорны шактый колачлап өйрәнгән әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин болай дигән иде:

– Повестьны укыганда, укучы күп нокталар белән билгеләнгән урыннарны еш очратыр. Болар цензор сызып ташлаган кисәкләрне аңлата. Моның шулай икәнен без тагын Гаязның русча язылган автобиографиясеннән беләбез. Ул анда цензорның әсәрдән күп урыннарны чыгарып ташлавы, моңа җен ачулары чыкканы, авырып, түшәктә яткан чагында, хәтта, Петербургка барып, мәгълүм Смирновны (цензорны. – *Ф.Г.*) үтерү уе белән янганлыгын яза.

Соң нинди урыннарны сызып ташлаган цензура? Чамаларга мөмкин. Укучы күрер: шул сәбәпләр арасында милли-колониаль изү, шуның бер күренеше булган христианлаштыру, ассимиляцияләү кебек сәбәпләр юк. Г. Исхакыйның бу мәсьәләне күтәрмәве мөмкин түгел. Менә ни өчен без кыскартылган урыннар, һәрхәлдә, аларның күпчелеге, һичшиксез, самодержавиенең милли-колониаль политикасы белән тегеләйме-болаймы бәйле дип әйтә алабыз» [5: 87–88].

Бу фикерләрне укып, без Ибраһим Зиннәт улының никадәр дөрес фаразлавына сокланабыз. Болай әйтү өчен, сүз дә юк, халкыбызның шундый язмышка дучар булуының нигезләрен һәм, әлбәттә инде, Гаяз Исхакыйны шәхес һәм фикер иясе буларак бик яхшы белергә кирәклеге аңлашылып тора. И. Нуруллин нәкъ шундый галим иде.

Билгеле булганча, Ибраһим Зиннәт улы – егерменче йөз башы әдәби хәрәкәтен аркылысын-буйга өйрәнгән, бу чор сүз сәнгатебезнең үсеш нигезләрен белеп яктырткан монографияләр авторы. Шуңа карамастан ул рәсми булмаган аралашуларда үзенең бу хезмәтләреннән канәгать булмавы турында да әйткәли иде. Аның XX йөз башы татар әдәбиятына кагылышлы лекцияләр курсы ике кисәк булып 1962 һәм 1964 елларда басылды. Ә «XX йөз башы татар әдәбияты» монографиясе укучылар кулына 1982 елда килеп керде. Дөресендә бу елларда әле Г. Исхакыйга дошман итеп карау гадәти хәл иде.

Бу хакта әдибебез Әмирхан ага Еники әнә ничек бәян итә. Ничектер көтмәгәндә бер төркем язучыларны Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Ә. Табеев янына чакыралар. Табын яңарта-яңарта озак кына чәй өстәле янында сөйләшеп утыралар. «Хәтта бик хәтәр Гаяз Исхакый мәсьәләсен дә телгә алдык. Аны Нәкый абзый кузгатты (Гаяздан башка әдәбият тарихыбыз тулы түгел, ул кешенең яхшы эшләрен начар эшләреннән аерып карарга вакыттыр инде дигәнрәк мәгънәдә әйткән иде). Ләкин Табеев Исхакый турындагы сөйләшүне катгый рәвештә кире какты)» [4: 218].

Димәк, ул вакыттагы тикшеренүләрдә XX йөз башы әдәби хәрәкәте һәм тарихы турында әлеге классик әдибебез һәм халкыбызның бәхете өчен көрәшкә бөтен барлыгын багышлаган хөрмәтле шәхесебезне искә алмыйча гына язарга ярый иде. Хәзерге вакытта без – бу чорда Г. Исхакыйның никадәр киң колачлы эшчәнлеге турында шактый ук мәгълүматлы буыннар – узган гасырның беренче-икенче дистәләрендәге әдәби һәм иҗтимагый-сәяси мохитне тасвирлауны «Инкыйраз» авторы эшчәнлегеннән башка

күз алдына да китерә алмыйбыз. Егерменче гасырның алтмышынчы-сиксәненче еллары шартларында беренче-икенче инкыйлаблар арасындагы вәзгыятне төбенә төшеп тикшерергә алынган И. Нуруллин моның шулай икәнлеген һичсүзсез күрә. Шуңа да Г. Исхакый эшчәнлеген яктыртудан башка үз язганнарының һич тә тулы була алмавына күңеле әрни. А. Гыйләҗев әйткәнчә, «Маркс-Ленинга таянган тар иман белән генә Гаяз Исхакыйның иҗат тирәнлеген, рухи байлыгын беркем дә ачып бетерә алмый» [3: 72]. Тормыш барышы И. Нуруллинга да бу хакыйкатьне төшендерә бара. Менә ни өчен, Г. Исхакый турында авыз ачып сүз әйтергә беренче мөмкинлек булу белән, Ибраһим Зиннәт улы әлеге бөек шәхесебезнең мирасын, аның ул заманнардагы эшләрен, шул гамәлләренең кылынуына сәбәп булган мохитне максатчан өйрәнә башлый. Бер генә аягы сәламәт булуына карамастан, галим Г. Исхакыйның соңгы дистә елларында гомер иткән һәм каләм тибрәткән Төркия иленә чыгып китә, әдәбият өчен бик күп яңалыклар һәм мәгълүматлар алып кайта. Әдипнең совет хакимияте юкка чыгуының беренче елында ук нәшер ителгән «Зиндан» дип исемләнгән сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре тупланган китапка язган кереш мәкаләсе бу басмада очраклы гына урын алмады.

Сүз дә юк, И. Нуруллин үзе туып-үскән, сугышта кан койган, җиде дистә ел яшәгән һәм хезмәт куйган илнең ул вакыттагы идеологиясендә тәрбияләнгән, максаты кешелекле булып тоелган, әмма чынлыкта шактый томанлы, рәшәле булып чыккан рәсми карашларны үзенә сеңдереп барган, шулар бөтенесе аның хезмәтләрендә дә чагыла килгән. Әмма ихласлылыгы, хакыйкатькә тугрылыгы аңа ул чор догмаларына тәнкыйть белән карарга да комачауламаган. Боларны аеруча Г. Исхакыйга мөнәсәбәтле хезмәтләрендә күрми мөмкин түгел. Димәк, күпләргә хас булганча, сиксәненче елларның икенче яртысында И. Нуруллинны да карашлар үзгәреше һәм үсеше юнәлешендә күрә тордык. Мондый фикер чолганышында күренекле язучы А. Гыйләҗевнең 1993 елда «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсендә әйткән менә бу сүзләре бик үк гадел бәя булып яңгырый: «Соңгы елларда ул Гаяз Исхакый иҗатын татар дөньясына җиткерүдә бик күп көч куйды. Мактау һәм дан аңа!» [3: 72]. Чыннан да, И. Нуруллинның «Зиндан» җыентыгына язган кереш сүзе татар мәнфәгатьләре өчен гомерен багышлаган Г. Исхакыйның төрле яклап алып барган эшчәнлеген гасыр азагындагы буыннарга җиткерүдә гаять әһәмиятле булды. Без үзебез шаһит, исеме яңа заманга кайта башлагач, күпләр безгә – ягъни әдәбиятка, фәнгә, матбугатка мөнәсәбәтле кешеләргә сорау бирәләр иде.

– Кем соң ул Гаяз Исхакый?

– Аның халыкка иткән хезмәтләре ниләрдән гыйбарәт?

– Нигә аның турында бүгенгә кадәр бер дә искә алынмады?

Әлеге кереш мәкаләдә боларның барысы турында да дәлилле итеп сүз алып бара. «Г. Исхакый, – ди И. Нуруллин, – Советлар Союзында урнашкан иҗтимагый строй белән дә, милли мәсьәләнең хәл ителү рәвеше белән дә килешә алмады. «Идел-Урал» байрагы астында бара торган бәйсезлек хәрәкәте лидеры буларак, Г. Исхакый гаять актив һәм күпкырлы эшчәнлек күрсәтте». Килешергә кирәк, болай итеп Маркс-Ленинга таянган кеше яза алмый. Моның өчен татар халкының үткәндәге һәм бүгенге көндәге хәл-әхвәленә чын булганынча караган, Г. Исхакый алып барган көрәшнең асылын тирән төшенгән һәм яклаган каләм әһеле генә әйтә ала.

А. Гыйләҗев хаклы: Г. Исхакый кебек гаять киң колачлы һәм халыкара киңлекләрдә хәрәкәт иткән шәхеснең яшәү мәгънәсен һәм иҗатын намуслы өйрәнү һәм гадел бәяләү пролетариат идеологиясеннән бөтенләй аерылган затлар өчен җиңелрәк биреләчәге бәхәс уятмый. Юк-юкта идеологиядәге мондый иске йөк ничек тә булса чабудан тартмый калмыйдыр. Менә шуңа да, фикерен дәвам иттереп, ул әйтә: «Г. Исхакый иҗатының тирәнге катламнары яңа заман кешеләрен, яңа татарларның милли фикерләвен, олпат ирләрнең җитди йомгакларын көтә» [3: 72].

Менә шундый олпат ирләрнең берсе билгеле тарихчы галимебез Миркасыйм Госманов иде. Ул Г. Исхакыйның беренче булып басылган, һәм, әйтергә кыюлык итәбез, төп әсәре «Инкыйраз»ны тулы килеш бүгенге укучыга кайтаруда, шуның белән егерменче йөз башы даһиеның татарлар язмышына карата булган карашларын бөтен

килеш җиткерүгә ярдәм итәрлек зур егетлек эшләде – хезмәтнең цензор тарафыннан кискәләнгән урыннарын кире кайтаруга, торгызуга иреште. М. Госманов та: «Ике йөз елдан соң инкыйраз» – ул безнең өчен сүзнең чын мәгънәсендәге бөек әсәре. XX гасыр башы татар әдәбиятының эчтәлегенә төп юнәлешләрне, рухына иман эзлеклелеген биргән һәм бөтен пафосы белән уяну чоры сүз сәнгатебезнең лейтмотивын – төп аһәңен тәшкил иткән уникаль әсәр ул. Аның дөньяга чыкканнан соң 70 ел үткәч кенә табылган һәм 85–90 ел узгач укылу, өйрәнелү мөмкинлегенә ирешә алган сәхифәләре дә гыйбрәтле. Безнең узганыбызны үзенчә гәүдәләндерә торган гомум милли аңыбыз, йолкышланган тарихи белемебез, халык сыйфатында танылу дәрәҗәбез кебек үк, алар да имгәтелгән хәлдә өлешләп кенә сакланып калган икән» [2: 152]. Мондагы карашларны, үзе әйткәнчә, «бөтен килеш җиткерүдә» нәкъ менә М. Госманов бик зур эш башарды. Җитмешенче еллар урталарында ул Ленинград архивларының берсендә очраклы рәвештә генә 150 номеры сугылган «эш»кә юлыга. Ул, «өйрәнелеп җитмәгән эш» буларак, кеше кулына бирелми икән. Күренекле иран белгече Е. Бертельсның улы Дмитрий шунда эшли икән. Ул совет чорының хәтәр елларында ирегеннән дә мәхрүм ителгән булган. Менә шул зыялыдан М. Госманов әлеге «эш»не берәр сәгатькә генә булса да карарга бирүен үтенә. Д. Бертельс ана бирүен бирә, әмма бер сәгатьтән аны алып та китә. Аның каравы М. Госманов әлеге «эш»нең Г. Исхакыйга кагылышлы икәнен белеп кала. 1990 елда «Инкыйраз» матбугатта басылып чыккач, бу әсәр белән ныклап шөгыльләнү мөмкинлеге барлыкка килүен күрә һәм әлеге архивка яңадан бара. Ул инде туп-туры 50 нче фондтан 150 нче «эш»не сорап ала. Анда да аны кулга бирергә бик атлыгып тормыйлар. Бик үтенгәч, күңелләренә рәхимлек иңми калмый. Җентекләп тикшереп карагач, бу кәгазьләрнең цензор Смирнов тарафыннан «Инкыйраз»дан кысартылган текстлар икәнен аңлый. Берничә көн дәвамында шушы өзекләрне күчереп ала. Бу очракта аңа, Кытайдагы Өремче-Гөлҗа якларында яшәгәндә, укуны гарәп графикасында башлавы, әлеге язуның аңа балачактан таныш булуы нык ярдәм итә. Шушы табышын ул «Казан утлары»ның инде без алдарак күрсәткән 1995 елдагы 10 нчы санында бастырып чыгара.

Кемдер М. Госманов юлыккан бу табышны очраклылык дип уйларга мөмкин. Ләкин очраклылык кайбер вакытта эзлеклелекнең бер мөһим буыны булып та чыга икән. Әйтик, бер караганда, И. Ньютон башына алма көтмәгәндә, очраклы рәвештә килеп төшә. Алма кешелек тарихында бик күпләрнең башына төшкәндер. Әмма аларның берсенә дә бу хәл галәм тартылышы канунын ачарга этәргеч бирмәгән. Бу ачыш ясалыр өчен, алманың нәкъ менә атаклы физика галиме башына туры килүе кирәк булган. М. Госманов белән дә шулай. Халкыбызның тарихи үткәнен җелегенә төшеп белгән, милләт язмышы өчен борчылып яшәгән зат үзенә якын идеаллар өчен гомерен багышлаган Гаяз Исхакыйга кагылышлы әлеге «эш»кә битараф кала аламы соң? Исән булса, Г. Исхакый аңа нинди генә рәхмәтләр әйтмәс иде икән? Аның урынына без, исәннәр, М. Госмановка үзебезнең арабызда вакытта күңелен кинәндерерлек җылы сүзләребезне ирештерә алдык.

Әгәр Г. Ибраһимов исемендәге институт галимнәре Лена Гайнанова, Флүн Мусин, КФУ профессорлары Резидә Ганиева, Хатыйп Миңнегулов һәм башкаларның хезмәтләрен искә алмасак, бу хактагы сүзебез һич тә тулы булмас иде. Мәсәлән, әле шушы елга чыккач кына да, Л.Р. Гайнанова бик тә мөһим мәсьәләләрне күтәреп матбугатта чыгыш ясады [1: 16]. Г. Исхакыйның исемен һәм мирасын халкыбызга кайтаруга өлеш кертүне һәрберебез изге гамәл итеп карады. Хәзерге вакытта, бүгенге буыннарга әсәрләренең 15 томы да килеп ирешкәч, бу юлдагы эш нәтиҗәләребез күзгә тагын да ныграк күренә башлады. Шулай да әлеге юнәлештәге бурычларыбыз тагын да күбрәк. Бөтен өмет яңа буыннарда инде.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гайнанова Л. Исхакыйның яңа тәхәллүсләре // Мәдәни җомга. – 2023. – 22 февраль. – Б. 16.
2. Госманов М. Гаяз Исхакый: «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм патша цензурасы (Иҗатының яңа сәхифәләре ачылу) // Казан утлары. – 1995. –№ 10. – Б. 152–181.
3. Гыйләҗев А. Йөгез, бер дога // Казан утлары. – 1993. – № 10. – Б. 7–99.
4. Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 5 т.
5. Нуруллин И. Кайту // Казан утлары. – 1990. – № 1. – Б. 87–88.

УДК 821.161.1+821.512.145

# ТЕМА ВОСПИТАНИЯ И ОБРАЗОВАНИЯ В ПУБЛИЦИСТИКЕ И ХУДОЖЕСТВЕННОМ ТВОРЧЕСТВЕ ГАЯЗА ИСХАКИ И В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ РУССКИХ И ТАТАРСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ XVIII – НАЧАЛА XX ВЕКА

***А.Ф. Галимуллина***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

В русской литературе эти идеи наиболее активно проповедовались писателями XVIII века, а в татарской литературе – писателями XIX – начала XX века. Единство темы философских, педагогических трактатов, статей и художественных произведений позволяет выявить случаи типологического сходства и расхождений в философском и художественном осмыслении темы становления личности, воспитания и образования русскими и татарскими писателями-просветителями, относящимся к разным литературам, эпохам и литературным направлениям. В данной статье мы рассмотрим публицистические статьи и художественные произведения известного татарского писателя и общественного деятеля Гаяза Исхаки (Махамметгаяза Гилязетдиновича Исхакова, 1878–1954), татарского общественного деятеля, педагога и писателя Ризы Фахретдина (Ризаитдина Фахретдиновича Фахретдинова, 1859–1936) и учебно-дидактические и художественные произведения русского писателя и общественного деятеля XVIII века Михаила Никитича Муравьева (1757–1807) в контексте имплицитного и эксплицитного диалога татарских писателей с традициями русской просветительской литературы.
**Ключевые слова:** тема воспитания, образования, становления личности, просветительская литература, татарская литература, русская литература, Гаяз Исхаки, Риза Фахретдин, М.Н. Муравьев.

In Russian literature, these ideas were most actively preached by writers of the 18th century, and in Tatar literature – by writers of the 19th – early 20th centuries. The unity of the theme of philosophical, pedagogical treatises, articles and works of art makes it possible to identify cases of typological similarities and discrepancies in the philosophical and artistic understanding of the theme of personality formation, upbringing and education by Russian and Tatar enlightenment writers belonging to different literatures, eras and literary movements. In this article, we will consider journalistic articles and works of art by the famous Tatar writer and public figure Gayaz Iskhaki (Mahammetgayaz Gilyazetdinovich Iskhakov, 1878–1954), Tatar public figure, teacher and writer Riza Fakhretdin (Rizaitdin Fakhretdinovich Fakhretdinov, 1859–1936) and educational and didactic and works of art by the Russian writer and public figure of the 18th century Mikhail Nikitich Muravyov (1757–1807) in the context of the implicit and explicit dialogue of Tatar writers with the traditions of Russian educational literature.
**Key words:** the theme of upbringing, education, personality development, educational literature, Tatar literature, Russian literature, Gayaz Iskhaki, Riza Fakhretdin, M.N. Muravyov.

В конце XX – начале XXI века в трудах казанских литературоведов наметилась тенденция изучения основных этапов развития русской и татарской литератур и отдельных писателей в широком историко-литературном контексте [1; 7; 13]. Так, татарская литература рассматривается в контексте западноевропейской, восточной и русской литератур. Тема становления личности, воспитания и образования является одной из ведущих в русской и татарской литературах XVIII – начала XX века. Это связано прежде всего с распространением просветительской идеологии в России.

Прежде всего следует отметить, что творческое наследие М.Н. Муравьева, Гаяза Исхаки и Ризы Фахретдина объединяет идея внесловной ценности человека, постановка вопроса о необходимости самосовершенствования, культ чтения, образования и воспитания. В связи с временной отдаленностью и неизвестностью широкому кругу татарских читателей произведений М.Н. Муравьева следует снять вопрос о влиянии русских писателей-просветителей XVIII века на формирование просветительских взглядов татарских писателей конца XIX – начала XX века Гаяза Исхаки и Ризы Фахретдина.

В то же время, следует отметить, что к началу XX века татарские писатели не только обращались к традициям русской реалистической и просветительской литературы, но и в осмыслении новых явлений в татарском обществе начала XX века находили свои пути художественного изображения. Имплицитный и эксплицитный диалог татарских писателей с традициями русской литературы усилился с распространением джадидизма, рассматривающего русскую литературу как часть евразийского самосознания. Одними из значительных татарских общественных деятелей и писателей конца XIX – начала XX века были Гаяз Исхаки и Риза Фахретдинов, в художественном и публицистическом творчестве которых большое внимание отводилось вопросам становления личности, воспитания и образования татарской молодежи.

Гаяз Исхаки получил новое джадидское образование в медресе, изучив наряду с теологией естественные и гуманитарные науки, затем учился в Казанской учительской школе (1898–1902), хорошо владел русским языком, что позволило ему познакомиться с произведениями русской и мировой классики, с трудами русских и зарубежных мыслителей по философии, быть в курсе современных для него общественно-политических публикаций в России. По признанию Г. Исхаки, его любимыми русскими писателями были Н.В. Гоголь, И.С. Тургенев, Л.Н. Толстой, Ги де Мопассан, Кнут Гамсун, Оскар Уайльд и другие. В то же время Гаяз Исхаки оставался истинным патриотом своего народа, активно пропагандируя идею национального прогресса, искренне беспокоясь о судьбе татарского народа. В повести «Инкыйраз спустя 200 лет» (1898) Гаяз Исхаки выступил с беспощадной критикой татарского общества, предостерегая своих соплеменников от бездействия. В то же время в повестях, рассказах, романах и пьесах, написанных в этот же период своего творчества, он ведет поиски положительных примеров, достойных для подражания. В этой связи писатель уделял большое внимание в художественных произведениях вопросам становления личности, воспитания и образования татарской молодежи. Наиболее обстоятельно тема становления личности татарской молодежи представлена в романе «Нищенка» (1908) Гаяза Исхаки на примере судеб Сагадат, Габдуллы и Мансура. В центре романа судьба татарской девушки, которая, пройдя через самые страшные испытания – через нищету, насилие, публичный дом, сохранила свою нравственную чистоту, нашла в себе силы, чтобы простить Габдуллу, ставшего причиной всех ее несчастий. Сагадат стремится к знаниям, она изучает татарский и русский языки, много читает, экстерном сдает экзамены за 4 года обучения в гимназии, любит театр, интересуется общественной жизнью (сходила с Мансуром на реферат (т.е., на лекцию). Гаяз Исхаки изобразил просвещенную татарскую девушку Сагадат в романе в соответствии со своими общественно-политическими взглядами, которые были им высказаны в выступлениях и печати начала XX века.

Будучи религиозным (мусульманским) деятелем, Р. Фахретдинов, несмотря на запреты отца, выучил русский язык, чтобы иметь объективные знания о мире. Более того, в необходимом объёме русскому языку обучил своих детей, об этом он подробно пишет в «Автобиографии» [12: 95].

Р. Фахретдинов в 1869–1889 гг. учился и преподавал в медресе. Он считал педагогику одной из главнейших наук, коль скоро «она изучает методы обучения и воспитания учащихся» [12: 100]. Вместо схоластического механического заучивания наизусть больших текстов ему импонировало более сознательное их восприятие: «Изученное на одном уроке заставлял учеников пересказывать на следующем и разъяснять смысл прочитанного. Скоро выяснилось, что это очень полезное правило» [12: 100]. В результате ученики Р. Фахретдинова легко сдавали экзамены в Духовном управлении мусульман. Высоко оценивая роль учителя в образовании, Р. Фахретдинов между тем призывает постоянно пополнять свои знания путём самообразования.: «Я активно занялся изучением таких предметов, как история, география, мусульманское право, тафсир, хадис. Всё это изучал я с большим желанием, самостоятельно, у себя дома, за своим столом» [12: 106–107]. В книге, посвящённой девятому разделу из нравственного учения ислама, Р. Фахретдинов формулирует 13 правил-требований к учителю-наставнику в медресе. Самые важные среди них: 1) высокая нравственность и духовность, сила собственного примера в обучении, неразрывно связанного с воспитанием;

2) эрудиция, глубокие знания предмета преподавания; 3) милосердие, умение расположить к себе; 4) педантичность, проводить занятия строго в одно и то же специально выделенное время [11: 144].

Немаловажно то, что он призывает уважать личность учеников, быть строгим, но справедливым к их поступкам. Учитель должен совершенствовать свои умения, то есть овладевать методикой преподавания предметов, говоря современным языком. Он должен передавать не только знания, но и развивать нравственные и умственные качества учеников, прививать любовь к Богу, умение общаться, взаимодействуя с окружающими. Наконец, обращает внимание Р. Фахретдинов и на речевое мастерство. По его мнению, учитель-наставник должен сам хорошо владеть устной и письменной речью, обладать красивым почерком, вести записи, чтобы потом при случае воспользоваться ими [11: 144].

Ризаэтдин Фахретдин в конце XIX – в начале XX века опубликовал этико-дидактические книги: «Гыйльме әхләк» («Әхләк гыйлеме», «Научная этика») (1898 г.), «Адабе тәгълим» («Академия познания») (1908 г.), «Гаилә» («Семья»), (1902), «Тәрбияле ана» («Воспитанная мать») (1905), «Тәрбияле хатын» («Воспитанная женщина») (1910 г.), в которых изложил свой взгляд на воспитание детей, на взаимоотношения в семье. Важнейшее место в наследии Риза Фахретдинова занимает многотомная историко-биобиблиографическая книга «Асар» («Асар»), посвященная жизни и творчеству ученых, деятелей культуры и просвещения народов Востока, над которой он работал в течение нескольких десятилетий.

Большую роль в воспитании и благополучии семьи просветитель отводил женщине, поэтому уделял этому вопросу особое внимание. В своих нравственно-дидактических книгах о воспитании: «Гаилә» («Семья»), (1902), «Тәрбияле ана» («Воспитанная мать») (1905), «Тәрбияле хатын» («Воспитанная женщина») (1910 г.) он предъявляет высокие требования воспитанию девочки, будущей жены и матери.

Яркий и самобытный представитель русского Просвещения М.Н. Муравьев активно разрабатывал идеи воспитания и образования в учебно-педагогических трудах, письмах и художественных произведениях различных жанров (поэзия, проза, драматургия). В период правления Александра I он был назначен товарищем министра народного просвещения (1802) и попечителем Московского университета (1803), подготовил первый устав Университета, в котором были провозглашены ведущие принципы университетской автономии: содружество преподавания, обучения и научного исследования. Он приглашает в университет ведущих европейских профессоров, добивается увеличения количества командировок для выпускников университета, вводит в практику преподавания в университете публичные лекции профессоров, а также добивается перевода на русский язык учебников по всем специальностям и создание своих учебников университетскими профессорами. Все это существенно повлияло на качество обучения в Московском университете, создав модель российского университетского образования, традиции, которого сохраняются до наших дней.

Учебно-педагогические сочинения М.Н. Муравьев адресовал венценосным ученикам – внукам Екатерины II, великим князьям Александру и Константину, которым он в 1785 году начал преподавать русский язык, историю и нравственную философию. В учебно-педагогических сочинениях: «Тетрадь для сочинений», «Разговоры мертвых», «Опыты истории», «Эпохи Российской империи», «Письма молодому человеку о предметах, касающихся истории и описания России», а также в художественных произведениях таких, как драматическая сказочка «Доброе дитя», художественная проза дидактического содержания «Эмилевы письма», «Обитатель предместья», «Дщице для записывания» М.Н. Муравьев излагал мысли об образовании и воспитании, о межличностных взаимоотношениях в семье и обществе, которые вышли далеко за пределы своего узко учебного значения.

Среди основных педагогических идей М.Н. Муравьева можно назвать «культ добродетели» (или «чувство добродетели» (А.Н. Пашкуров)), а также глубокое убеждение писателя-философа в облагораживающем воздействии красоты на формирование личности человека («нравственное воздействие красоты» (Н.Д. Кочеткова)).

В «Эмилевых письмах» М.Н. Муравьева воплощается просветительский идеал гражданина на службе Отечества, наделенного чувствительным сердцем.

Типологическое сходство взглядов М.Н. Муравьева, Гаяза Исхаки и Ризы Фахретдинова проявляется и в стремлении усовершенствовать преподавание в учебных заведениях. Эти писатели-мыслителя внесли существенный вклад в развитие образовательной системы своих народов.

Прежде всего Гаяз Исхаки был убежден в необходимости просвещения татарской молодежи, особое внимание и акцент делал на обучении татарских девушек. В конце XIX – начале XX веков необходимо было вести систематическую разъяснительную деятельность, чтобы татарские женщины заняли в обществе достойное положение: имели возможность получать образование наравне с мужчинами, были уравнены в правах в семье. Об этом мы можем судить по публицистике Гаяза Исхаки. Так, например. В статье «Хатын-кыз мәсьәләсе» («Женский вопрос», 1914) [6: 233–235] и «Хатын-кыз бурычы» («Долг женщины», 2014) [5: 269–270], вызвавших после публикации их в газете «Ил» большой резонанс, он непосредственно обращается к татарским женщинам с призывом более активно принимать участие в общественной жизни, в борьбе за язык и культуру татарского народа: *«Исторически веками находившейся взаперти татарской женщине, наверное, трудно сразу встать во главе дела...»* (Здесь и далее подстрочный перевод наш. – *А.Г.*) [5: 270]. В то же время писателя удивляет, что некоторые татарские женщины, в своих публикациях, борясь за свои права, всех мужчин обвиняют в угнетении женщин: *«Самым первым этот вопрос самый старый «изверг» – «Тәрҗеман» бабай начал. Затем к этому делу* (примечание А.Г. – под словом «дело» Гаяз Исхаки имеет ввиду «женский вопрос») *присоединился «изверг» под именем Риза казый, придав ему религиозную оценку* (примечание А.Г. – Риза Фахретдинов). *За ними я тоже, «изверг», выйдя на майдан (площадь) поднял этот вопрос. К нам присоединились еще такие «изверги», как Тукай, Сагит, Фатих»* [6: 235]. В полемически острой форме Гаяз Исхаки призывает объединить усилия мужчин и женщин в борьбе за установление в татарской общественной и семейной жизни новых взаимоотношений.

Гаяз Исхаки называет и поприще, где просвещенная татарская женщина – учительница может принести наибольшую пользу. В статье «Мөгаллим вә мөгаллимәләремезнең бу көнге вазифалары нәрсә?» («В чем обязанности учителей и учительниц», 1914) [4: 231–233], посвященной I Всероссийскому учительскому съезду (Петербург, 23 декабря 1913 г.) Гаяз Исхаки делает акцент на роли учительниц в сохранении национальных традиций, языка и культуры татарского народа: *«Ребенок на протяжении 3–4 лет обучения в школе пусть окончательно усовершенствует свой язык. Более того, пусть этим не ограничится, девочки так должны овладеть языком, чтобы потом, полученные в детстве знания передать своим детям»* [4: 232]. Показательно, что Гаяз Исхаки признает за девочками большую по сравнению с мальчиками восприимчивость учебных знаний, способности к обучению: *«Учитывая, что у девочек сильна познавательная способность, то, что они все легче воспринмают, нет никаких сомнений в большой роли учительниц. Девочки готовы перенимать у учительниц их слова, манеру поведения, походку. И перенимают. Слово учительницы на чистом языке проникнет в сознание учеников»* [4: 232]. В то же время писатель-просветитель считает, что в женщине самой природой заложена способность к обучению детей, что существенно повышает эффективность обучения: *«Кроме того, учительница, будучи женщиной, по своей природе обладает во многом првосходящей способностью любить и воспитывать детей, чем мужчина-педагог. Учитель во многих случаях будучи хорошим преподавателем, оказывается плохим воспитателем. У учительниц этого недостатка, можно сказать, нет.*

*Как учительница пробуждает у детей нежные чувства, так и обладая красивым голосом, учительница у детей повышает лювовь к музыке. Поэтому в формировании национального духа роль учительниц, наверное, выше, чем роль учителей»* [4: 232]. По мнению Гаяза Исхаки, именно татарская женщина издреле призвана сохранять лучшие традиции языка и культуры татарского народа, ибо мужчины по роду своей

деятельности путешествуя, общаясь с представителями других культур и традиций, утрачивают традиции своего народа.

Педагогические идеи, высказанные Гаязом Исхаки, во многих случаях звучат актуально для современного учителя: о содержании и форме обучения и воспитания татарской молодежи, вопросы сочетания татарских литературно-культурных традиций и овладения богатствами общероссийской и мировой науки, культуры и литературы: *«В наши дни школьные учителя, воспитатели ломают головы над проблемами: какой должна быть школьная программа, вернее, духовная проблема (рухи) школы. Наши джадидские школы какие они, чьи они, какое они дают воспитание детям, какие чувства возбуждают? Пришло время ставить и решать эти проблемы...»* [4: 231].

Писатель-просветитель чрезвычайно большое внимание уделял вопросам содержания образования, видя в воспитании и образовании один из важнейших путей для сохранения национальной идетичности: *«Однако поскольку на сегодняшний день самая главная проблема состоит в том, чтобы дать детям одинаковое воспитание, в национальном духе, наш пристальный взгляд обращен на школу. Долг современной школы воспитать будущее поколение сознательными, образованными татарами. Этому должны служить язык образования, воспитание, каждая песня и каждая мелодия… (...) Поэтому учительницы, учителя, кем бы они ни были, на занятиях должны говорить в соответствии с казанским произношением и казанскими (Шивәясе) образованием. Если мы сможем это воплотить в жизнь, то наша национальная культурная основа будет основательно усвоена. Наша национальная культура не будет подвержена ни ветрам, ни ураганам (...). Долг учителей и учительниц в этом и заключается! Самая высокая миссия их дела в этом!»* [4: 232].

Темы воспитания и образования, идеи внесословной ценности человека, женской эмансипации актуальны для татарской литературы и философско-общественной мысли конца XIX – начала XX века, в этот период татарские писатели испытали влияние просветительских идей и национально-освободительного движения. Г. Исхаки не был одинок в этом.

В целом, татарская литература переходного от средневекового к типу культуры Нового времени развивается в русле просветительского реализма, критического реализма и даже испытывает влияние модернизма, некоторые черты татарской литературы типологически сходны с русским и западноевропейским классицизмом и сентиментализмом. Писатели-просветители горячо отстаивали идеи Просвещения, ратуя за европеизацию татарского общества и выступая против косности и застоя в национальной жизни татар. Эстетическим идеалом просветительского реализма становится образ деятельного, мыслящего, совершенного человека. Это нашло отражение и в смене жанров татарской литературы: жанры дидактической поэзии и религиозной поэмы во второй половине XIX – начале XX века заменили жанры просветительской литературы: рассказы, повести, романы, драмы, комедии.

Итак, М.Н. Муравьев и Гаяз Исхаки, Р. Фахретдинов как и другие русские и татарские писатели-просветители пропагандировали идеи образования и воспитания, женской эмансипации, выступали за внесословную ценность человека. Однако, если М.Н. Муравьев, один из родоначальников сентиментализма в России, предтеча предромантизма, мыслит исходя из идей государственности, опираясь на опыт воспитания царской семьи, то Гаяз Исхаки и Риза Фахретдинов – на уровне духовно-нравственного воспитания татарского народа, взаимоотношений внутри национальной семьи. К сожалению, публицистическое, педагогическое и художественное наследие этих писателей до сих пор остается неизвестным широкому кругу читателей.

ЛИТЕРАТУРА

1. Габидуллина Ф.И. Гаяз Исхаки – романист (проблематика и художественное воплощение): автореф. ... канд. филол. наук. – Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2004. – 24 с.

2. Исхаки Г. Г. Исхакыйның Татар әдәбияты турындагы доклады // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Т. 6. – С. 190–203.

3. Исхаки Г. Нищенка // Исхаки Г. Нищенка. Мулла Бабай: перевод А.К. Бадюгиной. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – С. 10–172.

4. Исхакый Г. Мөгаллим вә мөгаллимәләремезнең бу көнге вазифалары нәрсә? // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Т. 6. – С. 231–233.
5. Исхакый Г. Хатын-кыз бурычы // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Т. 6. – С. 269–270.
6. Исхакый Г. Хатын-кыз мәсьәләсе // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Т. 6. – С. 233–235.
7. Каримова А.А. Идейно-эстетическая эволюция проблемы феминизма в творчестве Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань: КГУ, 2000. – 27 с.
8. Кочеткова Н.Д. Литература русского сентиментализма. – СПб.: Наука, 1994. – 281 с.
9. Муравьев М.Н. Сочинения. – Т. 1. Издание Александра Смирдина. – СПб.: Типография императорской Академии наук, 1847. – 438 с.
10. Муравьев М.Н. Эмилевы письма // Муравьев М.Н. Сочинения. – СПб., Т. 1. – 1847. – С. 112–171.
11. Фәхреддин Р. Адабе тәгълим. Укыту кагыйдәләре: гыйлем әхлактан тугызынчы кисәк. – Казан: Академия познания, 2006. – 167 б.
12. Фахретдинов Р. Моя биография // Фәхретдин Р. Фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 1999. – С. 81–110.
13. Хайруллина Д.М. Образ женщины в русской и татарской литературе 1890–1917 годов на примере творчества Г. Исхаки и М. Горького: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань: КГУ, 2005. – 24 с.

УДК 811.512.145

## РОЛЬ САТИРЫ В ПУБЛИЦИСТИКЕ ГАЯЗА ИСХАКИ

***В.З. Гарифуллин***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

В творчестве Гаяза Исхаки переплетаются различные жанры литературы и публицистики. Особое место в его творчестве занимает сатира. Памфлеты и фельетоны Исхаки являются острой реакцией на общественно-политические события, происходящие в стране. Его сатира очень яркая и экспрессивная, богата на выразительные средства языка. В статье анализируются способы создания ассоциации в сатирической публицистике Гаяза Исхаки.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, публицистика, сатира, фельетон, памфлет.

In the work of Gayaz Iskhaki, various genres of literature and journalism are intertwined. Satire occupies a special place in his work. Iskhaki's pamphlets and feuilletons are an acute reaction to the socio-political events taking place in the country. His satire is very bright and expressive, rich in expressive means of language. The article analyzes the ways of creating an association in Gayaz Iskhaki's satirical journalism.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, journalism, satire, feuilleton, pamphlet.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА САТИРА

***В.З. Гарифуллин***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Гаяз Исхакый татар журналистикасын актив оештыручы гына түгел, ә үткен телле публицист буларак та танылa. Аның журналистик һәм публицистик әсәрләре XX гасыр дәвамында татарларның гына түгел, башка төрки халыкларның да иҗтимагый аңына зур йогынты ясады һәм бүген дә зур әһәмияткә ия булып кала бирә.

Гаяз Исхакый нинди дә булса форма яки жанрга гына ябышып ятмаган. Аның журналистик-публицистик иҗатында зур күләмле аналитик мәкаләләр дә, төрле чаралардан җентекле хисаплар да, очерк һәм рецензияләр дә, ачык хат рәвешендәге хисси язмалар да күпләп очрый. Шулай ук аның сатирик публицистика остасы булуын да беләбез. Татар сатирик журналистикасын тикшерүче Р.М. Галиева Гаяз Исхакыйның матбугатта сатирик жанрлар системасын формалаштыруда һәм үстерүдә үзенә генә хас аерым бер урын алып торуын билгеләп үтә [3: 53].

Исхакыйның памфлетлары һәм фельетоннары илдә булган вакыйгаларга бик тиз арадагы реакция рәвешендә язылган. Бу яктан аның иҗатында «Бикмулла кода»га адресланган хатлар рәвешендәге сатирик материаллар сериясе бигрәк тә зур әһәмияткә ия булып тора. Әлеге язмалар «Таң йолдызы» газетасының 1906 һәм 1907 елгы саннарында дөнья күргән. Бу сериядәге кайбер әсәрләрне фельетон, кайберләрен памфлет

дип атау гадәткә кергән. Моңа гаҗәпләнәсе юк, чөнки алар бик охшаш жанрлар. Тик шулай да, безнең карашка, әлеге язмалар күбрәк памфлетка тартым. Нәкъ менә памфлет жанры җәмгыятьтәге кимчелекләрне, тискәре социаль күренешләрне кискен тәнкыйть итүгә юнәлдерелгән була һәм көчле сарказм, принципиаль бәхәс рухы белән сугарыла [7: 263].

Әлеге памфлетларда җәмгыятьнең төрле вәкилләренең кимчелекләре ассоциация алымы нигезендә кискен тәнкыйть ителә. Танылган памфлет остасы Марк Виленский сатирик текстның образлылыгын һәм тәэсирен көчәйтүнең иң нәтиҗәле чарасы буларак нәкъ менә шул «ассоциатив элемент» категориясен билгели дә инде [2: 5].

«Ассоциация» (ягъни «охшашлык») терминының ике төрле мәгънәсе бар. Беренчедән, ул бердәмлекне, берләшүне, икенчедән, үткән психологик тәҗрибәне актуальләштерүне, предметлар арасында аларның охшаш яклары нигезендә бәйләнешләр урнаштыруны аңлата. Виленский бу категорияне икенче мәгънәдә кулланган.

Чынлап та, әгәр дә без сатирик характердагы текстларга мөрәҗәгать итсәк, аларның күбесе охшашлык нигезендә төзелгәнлегенә инанырбыз. Гаяз Исхакыйның «Гыйззәтле вә хөрмәтле Бикмулла кода!» исемле памфлетлар циклы да шушы алымга таянып иҗат ителгән.

Охшашлык әсәрләрнең формасына ук салынган. Памфлетлар эпистоляр формага төрелеп бирү белән беррәттән турыдан-туры ике кешенең хат алышуы калыбына да салып иҗат ителгән. Беренче хатның башламы моны бик ачык дәлилли:

*Сезнең 12 июльдә язган хатыңызны алдым. Үземнең ничек торуымны сорыйсыз. Сезнең берлән кода булсам да, минем дөньям берлән сезнең дөньяңыз арасындагы аерма сезгә минем хәлемне аңларга манигъ булмас микән дип уйлыйм* [4: 50].

Памфлетларның азаккы өлеше дә гадәти хат калыбына салынган була:

*Гомер газизләреңезне теләп язгучы кодаңыз Биктимер* [4: 53].

*Күп сөйләлдем, кодакаем, хуш, сау бул. Исәнлектә күрешергә насыйп итсен, дип язгучы кодаң Биктимер* [4: 113].

Гаяз Исхакыйның сатирик публицистикасында эпистоляр стильнең актив кулланылуын журналистикабыз тарихын өйрәнгән күренекле галим Розалина Нуруллина болай дәлилләгән иде: «Билгеле булганча, публицистика чынбарлыкны чагылдыра, күз алдында булып үткән вакыйгаларны теркәп, бәяләп, аларның асылын ачып, үзе дөрес дип белгән юлдан укучыны ияртеп алып бару өчен аның акылын һәм күңелен билгеле бер идеяләр белән баетып кабындырып, шул идеяләрне тормышка ашыру өчен хәрәкәткә аякландыра. Шушы максатка ирешү өчен әле яңа гына үзенең тормышы турында уйлана, аны үзгәртү юлына керү ихтыяҗын сизенгән укучыга үз итеп эндәшү газета тарафыннан дөрес сайланган рәвеш дияргә мөмкин» [6: 96–97].

Охшашлык эффекты булдыру өчен хатларда метонимия алымы киң кулланыла. Әйтик, хатның адресаты булган «Бикмулла» исеме астында автор сатираның очлы уклары юнәлтелгән конкрет кешене генә түгел, җәмгыятьнең аерым бер катламын күздә тота. Шулай итеп, әлеге хатлар «ачык хат» рәвешен ала. «Мулла» сүзе монда дин әһеле буларак түгел, ә бик тәкъва кыланып та, милләт үсешенә һәм мәгърифәтенә һәм, гомумән, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә битараф калган кешеләр синонимы рәвешендә кулланыла. «Таң йолдызы» газетасының 1906 елгы 28 июль санында басылып чыккан «Сезнең 12 июльдә» дип башланган памфлетта Бикмулла образында укучы тирә-юньдәгеләрнең газаплары, кичерешләре белән кызыксынмый торган җәмгыять вәкилләрен җиңел генә танып ала:

*Сез һәрвакытта: «Әхмәтҗаннар янган көнне Миңлесафа килгән иде, Гыйззениса суга баткан көнне углымыз Әхмәтсафа туган иде», – дип йөртәсез* [4: 51].

Гаяз Исхакый җәмгыятьтә зур үзгәрешләр барган вакытта һәм бу вакыйгаларда һәр кешенең актив катнашуы мөһим булган чорда үз вак-төяк проблемаларына бикләнгән кешеләрне тәнкыйтьли:

*Сезнең фатирыңыз яхшы булса, ашарга-эчәргә мул булса, өй җәмәгатеңез авырмаса, сез үзеңезне бик мәсгуд санысыз.*

*Сезнең үзеңез кебек, тагы үзенең эшләрен уйлаудан башы үтми торган дустыңыз яисә карендәшеңез килсә, сезнең бөтен җәмәгатеңезгә бәйрәм була.*

Алга таба автор зур ачыну, әрнү белән бу битарафлыкның нинди сәяси нәтиҗәләргә китерүен аңлатып бирә:

*Сез выбор вакытларында, әллә нинди Акчура угылларына ияреп, әллә нинди бичуралар артыннан йөреп, «Мәшругаи Гавамия» партиясе дип, авызыңны бик тутырып әйтеп йөрсәңез дә, ул «Мәшругаи гавамия» партиясе ат микән, сыер микән, әллә бербер төрле ашамак-эчмәк әйбере микән, дип сорасалар, сез бөтен сөалгә «әйе» дип җавап бирер идеңез. Халыклары тормышыннан бернәрсә белмәгән кебек, сезнең хәзерге сәяси вакыйгалардан да хәбәреңез-ниеңез юктыр. Сез хәзерге вакыйгаларның әһәмиятле икәнлеген, хәзер дә бөтен куәт вә көч берлән халыкның дошманы бюрократияне бетерергә кирәк икәнлеген белмисез* [4: 52].

Хатларны Гаяз Исхакый «Биктимер» исеме белән, автор битлеге киеп иҗат итә. Бу шулай ук символик мәгънә ала: димәк, хатларны үз-үзенә ышанган, ныклы позициясе булган кеше яза. Ул үзенең кодасы Бикмуллага зур хөрмәт белән мөрәҗәгать итә, еш кына аның алдында үзен түбәнсетә. Моның белән Гаяз Исхакый комик эффект тудыра:

*Үземнең наданлыгымнан моңганчыга һич хәбәрем юк икән. Бик надан икәнмен, кодакаем! Шул наданлык берлән, әллә нинди зур кешеләргә тел тидереп, гөнаһлы булганмын икәнмен* [4: 84].

Охшашлык эффекты булдыруның үтемле чарасы буларак памфлетларда чагыштырулар да актив кулланыла. Мәсәлән, «Мөселман иттифакы» партиясе автор тарафыннан буш тегермән белән чагыштырыла:

*Сез әллә нинди шарлатаннарның халыкны алдар өчен ясалган «Мөселман иттифакы» дигән булган хәйлә тегермәннәренә язылган булып йөрисез. Мәкәрҗәгә дә барып, андагы төрле милләт хезмәтчеләре берлән, Фатихлар, Соловьевлар кебек шпионнар, провокаторлар берлән бергә, җәмгыятьләр ясап, милләт тәрәккый итсен өсен, тагы корсагыңыз ярылганча ашамакчы буласыз* [4: 53].

Памфлет – көннең актуаль вакыйгасына оператив һәм кискен реакция. Бик еш кына ул авторның җан кычкыруы, эмоцияләр шартлавы, кайнар хисләр рәвешендә бәреп чыга. Нәкъ менә шундый эмоцияләр аша Гаяз Исхакыйның «Мөселман иттифакы» партиясенә тискәре мөнәсәбәтен ачык күрергә мөмкин. Билгеле булганча, «таңчылар» белән «иттифакчылар» арасындагы иҗтимагый-сәяси каршылыклар Исхакыйның җитди публицистик әсәрләрендә дә ачык чагылып килгән [5: 37].

Памфлет жанрына хас булырга тиешле кискенлек һәм хиссилек кайвакыт автор тарафыннан ахырга кадәр уйланып бетмәгән, тиешенчә дәлилләнмәгән ялгыш фикербәяләргә китерергә мөмкин. Әйтик, «Бикмулла кода»га адреслап язган хатларның берсендә Гаяз Исхакый Фатих Кәримине милләткә хыянәт итүдә һәм шпионлыкта нигезсез гаепләп чыга:

*Колагыңа гына әйтим, кодакаем, ул бөтенләй жандармскига хезмәткә кергән, алардан жалуния ала, диләр. Алар берлән бер сүзле, бер мәсләкле, бер мәзһәбле, диләр* [4: 56].

Әлбәттә, биредә турыдан-туры гаепләү юк, «диләр» гыйбарәсе белән автор бу фактларның гайбәт булу ихтималына да ишарәли. Ләкин мондый алым укучы күңеленә шик салырга сәләтле һәм ул бүгенге медиа өлкәсендә дә ялган-фейк мәгълүмат таратуның үтемле бер чарасы булып санала. Күрәсең, Исхакый үзенең сәяси дошманнарына каршы көрәштә төрледән-төрле, шул исәптән гаять усал чараларны куллanудан да тайчынып тормаган. Шунысын да искәртик: хат жанры өчен имеш-мимеш, гайбәт белән уртаклашу бөтенләй үк ят күренеш тә түгел һәм памфлет автор бу мөмкинлекне оста эшкә җиккән.

Г. Исхакыйның сатирик әсәрләрендә охшашлану алымы аша мәгълүматны тапшыруның яшерен формаларын еш очратабыз:

*Кодакаем, менә гаҗәпкә калмый хәл юк. Озын буйлы, городовой төсле бер милләтче чыкты да: «Дөрхәте ислам, ягъни шәҗәрәи ислам, димәк ки, ислам егачы ике мең сәнә русларның золымында изелде», – дип, сандугач кебек сайрарга тотынды. Үзе Һиндтә укыган, ди* [4: 82].

Текстта геройның исеме турыдан-туры аталмаса да, андагы чагыштырулар һәм «үзе Һиндтә укыган» дигән кечкенә деталь буенча ук замандашлары сүзнең

Минхаҗетдин Кадермәтов исемле кеше турында баруын аңлый. Бу кеше Һиндстанда укыганнан соң Саратов губернасының Хвалын шәһәрендә югары уку йорты төзү өчен иганәләр җыя башлаган була. Ләкин бөтен акчаны үз ихтыяҗларына гына сарыф итә (Шуны әйтергә кирәк: ул Г. Тукай һәм М. Гафури сатираларында да еш кына мыскыллауга дучар була).

Гаяз Исхакыйның фельетоннарында һәм памфлетларында ассоциатив элемент буларак литота һәм гиперболаның еш кулланылуын күзәтә алабыз. Шул ук вакытта әлеге сатирик әсәрләрдә ясалма көлү, кирәкмәгән шаяртулар юк. Аның сатирасы бик якты, экспрессив. Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, Исхакый сатирасы урау юллар, подтекстлар аша, эзоп теле кулланып түгел, киресенчә, башка чүкеч белән суккан кебек усал рәвеш тә ала. Күренекле галимебез Равил ага Әмирхан Гаяз Исхакыйның публицистик мирасына бик гадел бәя биреп калдырды: «Әдипнең әрнегән йөрәк, сыкраган җан, ләкин чатнамас рух белән язылган йөзләгән мәкаләләрен күздән кичергәндә, безнең алдыбызга үз идеалларына, үз кыйбласына һич хыянәт итмәс гаярь шәхеснең үлемсез образы килеп баса.» [1: 312]

Гаяз Исхакый иҗатында әдәбиятның һәм публицистиканың төрле жанрлары бик матур үрелеп бара. Бу бәйләнешнең ачык бер чагылышы буларак, сатира аның иҗатында аерым бер мөһим урынны алып тора.


ӘДӘБИЯТ

1. Әмирхан Р.У. Иманга тугрылык. – Казан, 1997. – 384 б.
2. Виленский М.Э. Как написать фельетон? – М.: Мысль, 1982. – 208 с.
3. Галиева Р.М. Татарские сатирические журналы начала XX века. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2010. – 181 с.
4. Исхакый Г. Әсәрләр. 6 т. – Казан.: Татар. кит. нәшр., 2005. – 447 б.
5. Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.
6. Нуруллина Р.М. Тарих яза каләмем... – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2009. – 336 б.
7. Тертычный А.А. Жанры периодической печати. – М.: Аспект Пресс, 2000. – 312 с.


УДК 82.091

# ТАТАРСКИЕ КОНФЕССИОНАЛЬНЫЕ УЧЕБНЫЕ ЗАВЕДЕНИЯ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ГАЯЗА ИСХАКИ


***Г.Ф. Даутов***

*Елабужский институт К(П)ФУ (Елабуга);*

***А.Д. Ахметшина***

*ГАПОУ «Мамадышский политехнический колледж» (Мамадыш)*



В данной статье рассмотрены татарские конфессиональные учебные заведения. Гаяз Исхаки во многих своих произведениях рассматривает прошлое татарского народа, размышляет о будущем, ищет средства для его сохранения в качестве отдельной нации. Поэтому он подчеркивает необходимость обучения по-новому, и воспитание учеников, идущих к одному идеалу. В произведениях Гаяза Исхаки сохранилось культурное богатство, пришедшее из глубины истории. Поднятые им проблемы – потребность нации в высокообразованном, нравственном духовенстве. Данные проблемы вновь стали актуальной темой в начале XXI века.



**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, конфессиональные учебные заведения, татарский народ, нация, культурное богатство, высокообразованность.



This article discusses Tatar confessional educational institutions. Gayaz Iskhaki in many of his works examines the past of the Tatar people, reflects on the future, and looks for means to preserve it as a separate nation. Therefore, he emphasizes the need for learning in a new way, and the education of students going to the same ideal. In the works of Gayaz Iskhaki, the cultural wealth that came from the depths of history has been preserved. The problems he raised are the nation’s need for a highly educated, moral clergy. These problems have again become an urgent topic at the beginning of the XXI century.



**Key words:** Gayaz Iskhaki, confessional educational institutions, Tatar people, nation, cultural wealth, high education.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТАТАР КОНФЕССИОНАЛЬ УКУ ЙОРТЛАРЫ

***Г.Ф. Даутов***
*Казан федераль университетының Алабуга институты (Алабуга);*
***А.Д. Әхмәтшина***
*Мамадыш политехник көллияте (Мамадыш)*

Бөек фикер иясе, милли юлбашчы үзенең күп кенә әсәрләрендә татар халкының үткәндәге яшәү рәвешенә күзәтү ясый, киләчәге турында уйланып, аның аерым милләт сыйфатында сакланып калуы өчен чараларын эзли. Без Гаяз Исхакыйның *«Тормышмы бу?»* һәм *«Мулла бабай»* әсәрләрендә татар конфессиональ уку йортларының бирелешен күрсәтербез.

Әлбәттә, Гаяз Исхакыйның *«Тормышмы бу?»* әсәре төрле яклап кызыклы. Әлеге әсәр 1909 елда языла, һәм 1911 елда Казанда басылып чыга. Беренчедән, әсәрнең формасы үзенчәлекле. Ул көндәлекләр рәвешендә иҗат ителгән. Билгеле булганча, көндәлектә үзеңә мөһим булган әйберне генә теркәп куясың. Менә шуңа күрә бу рәвешчә язу укучының бәян ителгәннәргә ышанычын арттыра. Әсәрне укуның җиңеллеге дә шуннан килә. Повесть Гаяз Исхакый каләменең сәнгатьчә алымнарга баеп баруын бәян итә.

Автор әлеге әсәрендә, ник ачынып, *«Тормышмы бу?»* дигән сорау куя. Димәк, кемдер тормышыннан канәгать түгел. Автор аны икенче төрле *«Бер шәкертнең хатирәләре»* дип тә атый. *«Әсәрдә хатирәләр 1895 елның 28 маенда башланып, 1908 елның 3 маенда тәмамлана, ягъни үз эченә унөч елны ала. Унөч ел үсмер кеше өчен, бер гомернең зур бер өлеше, бу вакыт эчендә, яшь кеше җенси яктан гына түгел, аң-хис җәһәтеннән дә зур үсеш юлы үтә. 1899 елның 18 сентябрендә язган хатирәләрендә шәкерт үзенә 23 яшь тулганын әйтә, димәк, ул 1876 елда туган. Хатирәләрне яза башлаганда аңа инде 19 яшь булган дигән сүз. Бу яшьтә кешенең әйләнә-тирә, җәмгыять турында шактый ачык фикере, күңелендә туган төгәл тойгылары була. Әгәр хатирәләр язылып беткәндә аңа утыз ике яшь икәнен искә алсак, бу инде аның ир уртасы булып җиткәнлеген күрсәтә. Гомеренең яртысын диярлек узган ир кеше, үзенең яшәешеннән канәгать булмыйча, башкалар белән шул турыда ачыктан-ачык сөйләшергә карар иткән икән, бу инде юкка гына түгел. Димәк, әлеге уйлар аны озак борчыганнар, ахыр чиктә алар кәгазьгә түгелгәннәр»,* – дип яза Җ. Вәлиди [1: 72].

Гаяз Исхакый татар тормышының *«иң җәрәхәтле җирләрен ача»,* язучы буларак, максатын ачык итеп әйтә: *«Үзем хәл кыла алмаган шул мәсьәләне, бәлки, укучыларым хәл кылыр, мин җавап таба алмаган вакыйгага, бәлки, алар табар, дип, шул «Тормышмы бу?»ны китап итеп бастырырга уйладым»* [2: 8].

Гадәти кеше өчен Шәкертнең тормышында бер дә алай җитешмәслек як күренми. Әтисе – авылда абруйлы мулла була. Тормышлары мул, әйбәт. Казандагы Күлбуе мәдрәсәсеннән җәйге ялга кайткач та, әтисе белән аштан ашка йөреп көн уздыра. Киләчәк тормышында мулла булачак үсмер егеткә хәтта авылдагы яшьтәшләре белән уйнарга, күңел ачарга, бергәләп эшләргә дә ярамый, чөнки алар аңа тиң түгел дип исәпләнелә. Бөтен аралашкан кешесе, әти-әнисе дә, мулла җизнәсе, ишан хәзрәт ишеләр генә. Шәкерт мондый хәл белән килешергә теләми, аның авыл кызлары белән танышасы килә. Ләкин, әлегә кадәр кеше белән аралашмаган, әйтергә кирәк, моңа әллә ни омтылмаган егет кызлар белән гади итеп сөйләшеп тә китә белми, киресенчә, аларның килеп сүз кушуларын көтеп йөри.

Гадәттә, үз-үзенә бикләнгән кеше хыялга бай була, гамәлдә булдыра алмаганын уе белән булса да фараз итәргә ярата. Эчми, тартмый, китап кушмаган гамәлләрне кылмый торган Шәкерт хәтта үзенең мондый *«көфер»* уйларыннан да курка, намаздан соң тәүбә кыла. Ихтыярсызлык – Шәкертнең төп бәласе. Нәрсәдер эшләргә булып та, шуны тайпылышсыз тормышка ашыру өчен үзен туплый алмый. Әнә күрше кызы Сәгыйдәгә хат язарга ниятли, язуын яза да, ләкин бирә алмый интегә, чөнки иң курыккан әйберсе – кеше теленә керү, яман сүзнең ата-анасына килеп ирешүе. Әлбәттә, бу – бик яхшы сыйфат. Әмма, яшьлеккә хас матур итеп сөю-сөешү, табигать баласына чит-ят булмаган башка гадәти гамәлләр билгеле бер тәртипләр кысасы эчендә генә буйсынып

яшәргә күнеккән Шәкерткә атлап чыга алмастай киртә булып тоелалар. Аның иң кызыкканы – бер-берләре белән аралашып яшәүче авыл яшьләре. Беркем гаеп итми. Шәкертнең дә бөтен омтылганы – табигый яшәргә тырышу. Әмма, аның хәлендәге кешегә, андый тормышта яшәү мөмкин түгел. Әйтергә кирәк, әсәрнең кызыксындыру көче – анда Шәкертнең күңел каршылыгы сурәтләнүендә. Үзен чолгап алган тирәлек һәм Шәкерт күңелендәге ризасызлык. Шул рәвештәге эчке конфликт *«Тормышмы бу?»* повестеның төп үзенчәлеге булып исәпләнә [4: 90].

Әлбәттә, хәл-әхвәленең болай булуына Шәкерт үзе генә гаепле түгел. Гаяз Исхакый аны яшәү рәвешенең колы итеп сурәтли. Эчке конфликтның икенче катламы белем алу һәм киләчәктә нинди шөгыль белән мәшгуль булу мәсьәләләренә бәйләнгән. Шәкерт мәдрәсәдә укыган еллар – җәдитчеләр белән кадимчеләрнең үзара тартышкан, якалашкан вакыт арасы. Төрле тарихи, фәнни китаплардан азыкланган, өстәмә рәвештә русча да укыган Шәкерт, әлбәттә, җәдитчеләр ягында була. Ә әтисе исә, киресенчә, кадимчеләр тарафдары буларак билгеле. Бу хәл ата белән бала арасындагы аңлашылмаучанлыкны арттыруга бара.

Әгәр әтисе тормыштагы урыныннан бик канәгать булса, малайның исә, киресенчә, авылда мулла булып каласы килми. Чөнки мәхәллә кешеләре аңардан дини китапта язылган кануннардан читкә тайпылмауны таләп итәчәкләр. Әмма белеп тора: болай эшләргә аңа беркем дә мөмкинлек бирмиячәк. Бөртекләп җыйган гыйлеменең авылда беркемгә дә кирәге булмаячак. Менә ни өчен дин әһеле булуны ул үзе өчен мөмкин булмаган эш дип исәпли [5: 88].

Шундый кешеләрне очратабыз: дөрес уйлый, күңеле белән әллә ниләр эшләргә әзер, иксез-чиксез хыяллар белән яши. Тик ул үзенең ниятләрен чынбарлык итү гамәленә керешә алмый. Безнең Шәкерт тә шулар исәбендә. Ник дигәндә, ул – туганнан бирле аркылыны буйга алып салмаган, үзе билгеләгәнчә, *«егерме өч яшенә кадәр, салам селкетмәгән бер әрәмтамак».* Аның тормышы шулкадәр кызыксыз, бертөрле, 1901 елның 24 июленнән алып 1902 елның 28 июленә кадәр, ягъни елдан артык, хәтта көндәлеген дә кулга алмаган. Бервакыт, күңеле кузгалганда, ул үз-үзенә болай мөрәҗәгать итә: *«Уян, күңел! Үзеңнең дөньяларны җиңә торган, тауларны тишә торган, диңгезләрне корыта торган, тарихларның көпчәкләрен теләгән тарафка әйләндерә торган көчеңне, гайрәтеңне сарыф кыл да мине шул куркыныч диңгездән коткар! Уян, күңел, уян!»* [2: 15].

Ни генә әйтмәсен, үз-үзен ничек кенә битәрләмәсен, Шәкертнең яшәү рәвешендә бернинди үзгәреш-фәлән булмаячак. Барысы да элеккечә калачак. Тора-бара ул үз тормышына бөтенләй җайлашачак. Күңелен *«юк-бар»* нәрсәләр белән бимазаламаячак. Башкага ул сәләтле түгел. *«Тормышмы бу?* дигән сорауга тыныч кына: *«Тормыш бу, шулай яшәү – иң кулае»,* – дип җавап бирсә, укучы һич тә гаҗәпләнмәячәк. Роман шундый юллар белән тәмамлана:

*«Тагы иске тормышлар күз алдымнан үтте. Тагы болар минем йоклаган йөрәгемдә зур бер җәрәхәтләр ачты. Мин төн буе йоклый алмыйча уйладым... Бик озак уйлаган, төшенгәннең соңында күңелемә «Шулмы гомер, тормышмы бу?» дигән сүзләр килде... Мин җавап бирә алмадым. Сездән сорыйм: «Тормышмы бу?»* [3: 70].

Гаяз Исхакый әлеге *«Тормышмы бу?»* романы белән әнә шундый гамьсезлеккә, битарафлыкка, йокымсырауга каршы чыгучы буларак билгеле. Әйтергә кирәк, бу яктан ул *«Инкыйраз»* әсәре белән нык аваздаш. Әсәрдән килеп чыккан мәгънә шул: шәхси язмышына шул дәрәҗәдә битараф булган кеше милләтнең бүгенгесе, бигрәк тә киләчәге турында кайгыртуны үз җилкәсенә күтәрә алмый. Романда, мәсәлән, татар мәдрәсәләренең хәле, укыту-тәрбия торышы – аларны үз башыннан кичергән татар зыялыларының язмышы-киләчәге һ. б. проблемалар бер шәкертнең истәлек-уйланулары, күңел хисләре ташкыны аркылы тасвир ителгән. Гомерен авыл мулласы булып үткәргән элекке мәдрәсә шәкерте тормыш шәфәгында уй-фикерләре белән яңадан күңеленнән узган гомеренә әйләнеп кайта, көндәлекләрен актара, тормыш баскычларын күңеленнән үткәрү аркылы дөньяда яшәү мәгънәсе, гомумән татар тормышы хакында тирән уйлана, борчыла, өзгәләнә.

Болай өзгәләнүләрнең сәбәбе, бер яктан, геройның үзенчәлекле характеры була, икенче яктан, һичшиксез, мәдрәсә. Чөнки Шәкерт укыган мәдрәсә кадими, ул чор һәм заман таләпләренә җавап бирми. Ләкин, шул ук вакытта, егетебез теленнән ишетеп, моннан укып, шактый гына мәгълүмат туплаган. Ул олы дөнья барлыгын күрә, үзендә көч тоя, ләкин системалы теоретик әзерлеге юк, чөнки XX йөз башы татар мәдрәсәләре бары бер профессия вәкилләрен – муллаларны гына әзерләгәннәр. Мондый бәргәләнү – тулы бер буынның, XX йөз башы яшьләренең фаҗигасе. Алар вакыт агышына кушылып китә алмыйлар. Монда бер генә котылу юлы – мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп кору кирәк. Мәгърифәтчеләр тарафыннан идея буларак күтәрелгән әлеге мәсьәлә Гаяз Исхакыйның *«Тормышмы бу?»* әсәрендә образлар аркылы конкрет тормышчан гәүдләнеш ала.

Шулай ук, *«Мулла бабай»* романына игътибар итик. Гаяз Исхакый, 1910 елда *«Мулла бабай»* романың яза башлый, хәтта аның өч кисәген бастырып чыгара. Әсәр укучыга үзенең юнәлеше буенча *«Тормышмы бу?»* романын хәтерләтә. Әлбәттә, ул тагын да киңрәк, тормыш күренешләренә, хис-кичерешләргә, җәмгыятьне бәяләүгә баерак булырга тиеш була. Төп герой монда инде исемле – ул Хәлим. Ул, алга таба мулла бабай, ягъни өлкән яшьтәге кеше булганчы, шактый дәвамлы вакыт эчендә сурәтләнергә тиеш дип уйланыла. Әмма укучы аның белән әле яшь чагында ук хушлаша. Әсәр язылып бетмәгән. Моннан күренгәнчә, бу тема Гаяз Исхакыйны нык дулкынландырган булса кирәк.

Гаяз Исхакыйның гаилә тәрбиясе, уку-белеме нигезендә мөселман традицияләре ята. Дини тормышны тирәнтен ачкан әсәренә әдип *«Мулла бабай»* дип исем бирә. Анда дин әһеленең гомер юлы балачактан үсеп җиткәнчегә хәтле яктыртыла, дөрес, роман мулланың бабай яшенә җитүенә хәтле үк тәмамлана. Төп персонаж – авылда гади мужик гаиләсендә туган Хәлим, башта авыл мәдрәсәсендә, аннан соң янәшәдә урнашкан шәһәрдә (исеме әйтелми), алга таба исә Казан мәдрәсәсендә белем ала. Әлбәттә, язучы мәдрәсә тормышын уңай һәм тискәре яклары белән күз алдына китереп бастыра. Ул үзе кичергән бу тормышны, шәкерт язмышын яратып та, көлеп тә хикәяли [4: 92].

Хәлим, башта авыл мәдрәсәсендә укып, шәһәрдә укырга ниятли һәм агач бинаны яндырып кача. Шәһәр мәдрәсәсеннән ул бик күпне көтә. Ә эти-әнисе, абый-җиңгәләре аны, мулла булыр, галим булыр, дип шатланалар, төрлечә ярдәм итеп торалар. Гади мужик гаиләсе булса да, мөселманнарга хас булганча, аң-белемгә аларның ихлас ихтирамы көчле булып күзаллана. Артык бай булмасалар да, сарык, каз түшкәләре, баллар, майлар хәзрәткә, хәлфәләргә күчтәнәчкә килеп тора. Хәлимнең үзен дә азык-төлек белән тәэмин итеп кенә торалар.

*«Мулла бабай»* әсәрендә дини тәрбия системасы ачык булып күз алдына килеп баса. Биредәге остаз-хәзрәтләр, хәлфәләр зур ихтирам тәртип-тәрбияне ныклы кысаларда тоталар. Һичшиксез, намазлар үтәлә. Яңа килгән балаларга (Хәлимгә дә) мәдрәсә тәртипләренә күнү бик авыр була. Авылы, әнисе, апалары, өе бик сагындыра үзен. Бер урынга җыелган күп малайлар арасында шуклык та, уен, мендәр сугышлары да җитәрлек. Әмма зурга китү, угрылык, имгәтүләр юк. Казый да чыбыгы белән сакта тора, эләктереп тә алгалый. Шуны да әйтергә кирәк, цивилизацияле инглиз мәктәпләрендә дә соң заманнарга хәтле суктыру гадәте саклана [4: 54].

Шактый авырлыклар белән Хәлимнең укулары алга китә – *«Тәфсирне», «Шәрхе Габдулла»*ны үтә. Уңышлары булгач, аны *«мужик баласы»* дип үртәү дә бетә. Авылга кайткач, аны бик хөрмәтлиләр. Авылның хәзрәте ашка килеп, аның белем дәрәҗәсен тикшереп, мактап та китә. Хәлимнең мәдрәсәдә укыган еллары шулай үтә. Мәдрәсә тормышының, шәкертләрнең кайбер ямьсез гамәлләре дә ачыктан-ачык күрсәтелә. Байның әнисе үлемен түземсезләнеп көтүләре, анда барып сәдака алулары, шуннан ул акчаларга тәм-том алып ашаулар – барысы да бәйнә-бәйнә тасвирлана. Бу күренешләр бик җанлы, сәнгатьчә булып, шактый шаянлык белән язылган, әлбәттә.

Хәлим, мәдрәсә елларында уку программасын үтәп, дин мәсьәләләрендә шактый мәгълүматлы була, белем ныгыта. Берзаман 3 шәкерт моназарәгә чит мәдрәсәләргә барырга җыеналар. Алар белән хәлфәләр шөгыльләнә, бәхәсләргә җаваплар әзерләнә.

Хәлим дә алар белән китә. *«Казый», «Гакаид», «Шәмсия», «Габделхәлим»* дигән китапларны алып, ат-арбага утырып юлга чыгалар.

Иң беренче барып кергән хәзрәт – мул тормышлы, нык яшәүче, йорты бай, кунакчыл. Икенче авылда, моназарә кылып чыккач, тагын бер хәзрәткә тап булалар. Аның сөйләгәне китап түгел, ул кош-корт, нәсел айгырлары белән мактанып, бай гошерләрне хуплап утыра. Әмма намазга азан ишетелми. Шәкертләр ат мәсьәләләреннән туеп, чыгып китәләр. Әлеге образны Гаяз Исхакый Гогольнең Собакевичена охшатып яза шикелле [4: 24].

Күрше авылдагы Саттар хәзрәтнең, киресенчә, йорт-җире начар, балалары тәрбиясез. Ач хәзрәт үзе укымышлы, китаплары да бар, аларны аңлата да белә. Ләкин гамәле юк, авыл халкы аннан разый түгел. Чөнки ул йорт тота белми, никах укырга, исем кушарга йөрми. Авылда мәдрәсә салына, әмма ул укыта белми. Авыл халкы аны – үзе белемле, әмма аның файдасы юк, дип әйтә. Ул Гогольның хыялый Маниловы сыман сурәтләнә. Шәкертләр, абыстайның *«ашка ит юк»,* дигәнен ишеткәч, чыгып китү ягын карыйлар.

Тагын бер хәзрәткә барып керәләр. Ул дин сабаклары укытмыйча, әкияти китаплар гына укый. Салсал, Сәетбаттал турындагы кыйссаларны укып, күңел ача. Теләсә нинди хикәятләр белән көлдереп, мәгънәсез уен көлке ясап утыруы белән ул Ноздревны хәтерләтә.

Бу чагыштырулар, билгеле, бик якынча, чөнки рус алпавытлары татар муллаларыннан яшәү рәвешләре, гореф-гадәтләре белән нык аерыла. Әмма, типик образлар буларак, охшашлыклары да бар, әлбәттә.

Хәлим өенә кайткач, этисе үлеп китә. Ул ярдәмсез кала. Ул Казандагы мәдрәсәгә күчеп, укуын дәвам итә, өч ел ачлы-туклы торып укый. Хәлим Казанда үзенең идеалына ирешә – пишкадәм була. Хәлим ихлас күңеленнннән ислам диненә инанган, ул кушканны гына үтәүче булып формалаша. Әйтергә кирәк, Хәлим Гаяз Исхакыйның 1908 елда язган *«Тормышмы бу?»* дигән әсәрендәге каһарманнан шактый нык аерылып тора. Яшь язучы анда мулланы шактый гөнаһлы уйлар, гөнаһлы эшләр иясе итеп тасвирлый.

Әйтергә кирәк, *«Мулла бабай»* романында, *«Тормышмы бу»* дигән әсәреннән аермалы буларак, Гаяз Исхакый мулланы алай ук соң дәрәҗәдә кире сыйфатта күрсәтми. Чөнки, ул инде шактый тормыш юлы үткән һәм дөнья күргән язучы, динне бөтенләй бетереп ташларга теләми [4: 50].

Романда Хәлим авылга кайта, авырлыклар аша, талаш-орышларга үзе катнашмаса да, элекккеге мулла тарафыннан шуларга тартылып, авылының бер мәхәлләсенә мулла булып хезмәт куя. Күрше авылның Габдерәхим хәзрәт исемле галим бер мулланың Зөһрә исемле кызына өйләнә. Гаяз Исхакый әлеге хәзрәт образын яратып, идеаллаштырып яза. Аңынча (Габдерәхимчә), мулла булган кеше мәхәлләнең тәмам атасы кебек шуның эше белән генә шөгыльләнергә тиеш, аның кайгысы белән генә яшәргә, әллә никадәр байлык, дәүләт артыннан кумыйча, барына да канәгать булырга тиеш. Ул намазларын үти, мәдрәсәдә укыта, авыруларны өшкерә, ясин укый, ашларга да йөри. Йортына артык игътибар итмәсә дә, аны таза тота. Алар бай түгел, әмма мохтаҗ да түгел. Җәе-кышы анда кунак өзелми, аларны бик ачык йөз белән каршы ала. Баен да, ярлысын да тигез күрә. Хәлим менә шушы хәзрәтнең кызына өйләнә. Зөһрә белән матур итеп, бер-берсен аңлап, яши башлыйлар. Дөнья мәшәкатьләре артып китә.

Әйтергә кирәк, Хәлим дәрес бирә, сабак укыта башлый. Зөһрә, хатыннарны җыеп, Коръән сөйли, гарәпчә сүзләрне аңлата. Хәлим хатынына да сарыф, нәхү укыта башлый. Яңа мәдрәсә салу турында авыл халкы белән сүз алып бара. Аңа ихтирам арта, *«хәзрәт»* дип, аны олысы-кечесе зурлый, хөрмәт күрсәтә башлый. Хәлим дә, буш вакытын гыйлем арттыруга багышлыйм, ди. Әмма Зөһрә балага уза, өй салу кирәклеге белене. Бу мәшәкатьләр белән мәдрәсә салу онытыла. Бала туа, тормыш тагын җайга салына.

Шуның белән роман тәмамлана. Бала туу тормышның дәвам итүен белдерә. *«Тормышмы бу?»* дигән әсәрдәге кебек бәргәләнү, мулла тормышын мәгънәсез дип табу биредә юк.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгене әйтергә кирәк, Гаяз Исхакыйның инкыйлаб чорындагы кискен карашлары шактый үзгәргән, ул бу әсәрләрендә яшәешнең матди ягы зур роль уйнаганың аңлаган, муллаларның элеккеге, борынгыларын идеаллаштырган хәлдә, заман таләпләре үзгәргәнен дә искәртә. Шуңа күрә ул яңача укыту зарурлыгын һәм дә, шәкертләргә бер мәсләк, бер идеалга бара торган тәрбия бирергә кирәклеген ассызыклый. Гаяз Исхакый әсәрләрендә инде тарих тирәнлегеннән килгән мәдәни байлык сакланып калган. Ул күтәргән проблемалар – милләткә югары белемле, әхлаклы руханилар кирәклеге XXI гасыр башында яңадан иң актуаль тема булып калкып чыкты.

ӘДӘБИЯТ

1. Вәлиди Ш. Гаяз әфәнде // Мирас. – 1996. – № 7–8. – Б. 69–76.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: публицистика: 15 томда. 7 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1915 – 1916. – 366 б.
3. Исхакый Г. Әсәрләр: романнар: 15 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1918. – 448 б.
4. Мусин Ф. Гаяз Исхакый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.
5. Нуруллин И. Кайту // Казан утлары. – 1990. – № 1. – Б. 85–88.

УДК 82-1+821.161.1“197/201”

## ЗНАЧИМОСТЬ ПЕРЕВОДОВ В ОСВОЕНИИ ПУБЛИЦИСТИЧЕСКОГО НАСЛЕДИЯ Г. ИСХАКИ

***И.А. Еникеев***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье представлен первый перевод двух публицистических статей Гаяза Исхаки на русский язык. Проанализированы два варианта перевода – московский и казанский. Показано значение интертекста и метатекста для адекватного перевода татарского оригинального текста. Раскрыта значимость перевода для полноценного понимания наследия Гаяза Исхаки русскоязычными читателями.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, публицистика, перевод, татарский язык, русский язык, татарская литература.

The article presents the first translation of two journalistic articles by G. Iskhaki into Russian. Two variants of translation are analyzed – Moscow and Kazan. The importance of intertext and metatext for an adequate translation of the Tatar original text is shown. The importance of translation for a full understanding of the heritage of Gayaz Iskhaki by Russian-language readers is revealed.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, journalism, translation, Tatar language, Russian language, Tatar literature.

В 2014 году в Москве был издан сборник исторических документов «Первая мировая война в оценке современников: власть и российское общество. 1914–1918». Редакционная коллегия сборника решила включить в него две статьи Г. Исхаки, до этого ни разу не публиковавшиеся на русском языке, и предложила мне сделать их перевод. После сдачи материала редакторы, для которых татарский язык был родным, особо подчеркнули не только полную смысловую адекватность перевода оригиналу Г. Исхаки, но и абсолютное соответствие перевода языковой личности автора – мироощущению и мировоззрению Г. Исхаки. По словам редактора отдельные фрагменты в русском переводе раскрывали полемические акценты Г. Исхаки даже лучше чем татарский оригинал. Дело в том, что писатель в своей полемике обращался не только к интеллигенции, но и к широкой массе, используя сниженную лексику и даже бранные слова. Оказалось, что средствами русского языка можно не только передать смысл старых и малопонятных сейчас даже для татарского читателя слов, но и выразить во вполне пристойной форме эмоциональный пафос автора, использовавшего ругательства в адрес врагов татарского народа. Однако затем текст прошел правку московского редактора, который изменил короткий татарский синтаксис на длинные сложноподчиненные предложения, сократил синонимичные повторы, снизил эмоциональный пафос Г. Исхаки, заменив обличительную интонацию на нейтрально-повествовательную

и нивелировал религиозный контекст, подменив слово «души» словом «жизни» [3: 428–429]. Тем самым русскоязычный переводчик адаптировал татарский текст к своему мировоззрению. Он сузил интертекстовое поле Г. Исхаки и изменил его метатекстовую инфраструктуру: вместо обличительного памфлета получилась очередная жалоба угнетенного татарина. В итоге изменился жанр публицистической статьи Г. Исхаки и образ автора – был изменен масштаб политической личности и ее формат как национального лидера.

Данную языковую особенность русско-татарских переводов впервые обнаружил писатель Р. Бухараев, когда переводил стихотворения Г. Тукая. Как переводчик он признает, что весь смысл стихов поэта, его контекст и подтекст, понятный только татарам, невозможно полностью выразить на русском языке. «Поэзия Тукая, сокровенная суть ее, непереводима на другие языки. Нельзя перевести ее так, чтобы, как в татарском, отозвалось все собственной болью, родственным восторгом и слезами сострадания. Так же непереводим и Сергей Есенин, с которым Тукай более всего схож золотым певческим даром» [1: 334]. Но переводчик открыл способность русского языка проявлять и вскрывать архитектуру татарского текста – особенно его интертекстовые и метатекстовые компоненты, т.е. скрытое цитирование и авторский нарратив (замысел), образующие своеобразие писательского дискурса. Ученые установили, что «способность вбирать в себя элементы иного (чужого) мироощущения свидетельствуют о гибкости, восприимчивости русской языковой системы, высокой степени ее кодируемости, свидетельствует о возможности выражения художественных образов одной (например, марийской, татарской и др.) культуры на языке другой (русской)» [6: 8]. Оксфордский словарь толкует понятие дискурс как мыслительную посылку, проявляющуюся в тексте через цепь событий. В результате создается связный текст в совокупности с различными жизненными, социокультурными, психологическими и другими факторами. Дискурсивный подход к творчеству Г. Тукая, стремление его интерпретировать, выстроить диалогические отношения наметился у Р. Бухараева в процессе работы над переводами поэзии классика на русский язык. Во-первых, он обнаружил скрытое цитирование Тукаем произведений русских поэтов А.С. Пушкина, В.А. Жуковского, М.Ю. Лермонтова. Столкнувшись с проблемой отсутствия в русском языке адекватного эквивалента сказанного Тукаем, Бухараев использовал фразеологические обороты-аналоги. И эта «вольность переводчика помогла прояснить истоки происхождения стихотворения Тукая «Яз». Оказалось, что это вольный перевод Тукая двух стихотворений В.А. Жуковского «Весеннее чувство» и «Приход весны» с использованием образов стихотворения М.Ю. Лермонтова «Воздушный корабль», написанных в стиле сентиментального романтизма» [2: 83]. На примере этих стихотворений проявляются принципы переводческой деятельности Бухараева как сотворчества с другой национальной культурой или диалога разных культур. А это и является основой дискурсивной коммуникации. Во-вторых, он осознал богатство татарского языка используемого Тукаем и понял, что очень трудно на русском языке адекватно передать смысл, а главное контекст и подтекст его произведений. В-третьих, для понимания смысловых конструкций Г. Тукая Бухараев не только полностью изучил творчество поэта, но и его биографию. Для понимания контекста стихов Тукая он сопоставил творческую и жизненную хронологию писателя и акцентировал внимание на самых драматических и поворотных моментах жизни Тукая. Перед ним раскрылся дискурс Тукая в аспекте событийного и функционального текста. Р. Бухараев открыл важную особенность русско-татарского переводческого дискурса – разоблачение говорящего через взаимодействие разных историко-временных контекстов. Писатель не только сумел выразить проблемы отчуждения татар от национальной культуры, языка, но и увидеть причины этого в разрушении национальной среды (мили мохит). Если человек живёт по образу и подобию другого народа, то по-родному думать и говорить он не сможет. С другой стороны дискурсивный метод Р. Бухараева показал судьбу Тукая, в том числе и татарам, с неожиданной стороны. Он сумел показать психологическую глубину этой личности, снять покровы с образа-памятника и раскрыл его как живого человека, близкого по духу и чувствам современникам нового тысячелетия.

Методика выявления интертекстовой составляющей татарского оригинала подразумевает вскрытие и проявление скрытой полемики разных этнокультурных и философских контекстов вплоть до пародирования используемых переводимым автором первоисточников. Это происходит в тех случаях, когда переводчик не может найти адекватных аналогов татарским фразеологизмам. Однако в случае Г. Исхаки обнаруживается связь его фразеологизмов с метатекстовым замыслом писателя – включить в публицистический текст драматическую интригу. Следует также учитывать, что казанский перевод статьи Г. Исхаки был дословным и буквальным, т. к. редакторы категорически не принимали идею вольного перевода. Тем не менее контекстная методология перевода прекрасно себя зарекомендовала и в этом случае, образовав взаимодополняющее друг друга, билингвальное единство двух этнических культур – татарской и русской. Национальный интертекст Г. Исхаки, спрятанный в подтексте и понятный татарам-современникам, но плохо считываемый в начале XXI века, заключался в наличии скрытых гипертекстовых отсылок к текстам татарской религиозной и сказочной литературы. Данные татарские стилевые маркеры (мифологизированные образы врагов ислама и тюркских народов) образуют смысловой слой, который В. фон Гумбольдт назвал «Дух народа» и объяснял как непроговариваемый и невидимый общекультурный фон. Чтобы раскрыть этот фон переводчику приходится расшифровывать скрытые прецедентные интексты в тексте оригинала и заложенные в них смыслы, одновременно вызывая у читателя определенные ассоциации и генерируя дополнительные смыслы. Благодаря данной методике писатель-переводчик Р. Бухараев увидел религиозно-суфийский контекст, объединяющий творчество средневековых татарских поэтов Золотой Орды. Показательно, что религиозный контекст постоянно присутствует в политической публицистике Г. Исхаки, когда он пишет о пожертвованных бесценных жизнях и о проклятых душах «миллионов наших сыновей, которые ушли из жизни негодяями и подлецами, стреляя по исламскому единству…и не пропадут ли в будущем наши души во благо каких-либо очередных шарлатанов и авантюристов» [5: 211].

Как продолжение этого религиозного дискурса Г. Исхаки создал конспирологический нарратив о заговоре империалистических государств против ислама и тюркских народов, облекая его в сказочно-сатирические образы врагов татарского народа. Как опытный оратор Г. Исхаки развивает этот метатекстовый сюжет, основанный на зловещей драматической интриге, используя риторические вопросы и полемизируя с подразумеваемыми оппонентами, разрушая их аргументы с помощью фактов, цифровых данных, сочетающихся с едкой иронией и высмеиванием. Чтобы поразить внимание татарского читателя он визуализирует запредельные 100 миллиардные расходы на войну в виде 5 тысяч вагонов, заполненных золотом [4: 272]. Статья Г. Исхаки «Тайные соглашения» была опубликована в газете «Ил» 15 ноября 1917 года за подписью «Гаяз». Её метатекстовая драматургия выстроена на четырех денотатах (свернутых мыслях), обнаруженных в процессе перевода. Первый денотат звучит, как **«нас обманывали».** Он подразумевает максимальный охват и объединение читательской аудитории как единого мнемонического сообщества вокруг этого тезиса. «Каждому известно, что с началом войны и в период ее продолжения общественная мысль и периодическая печать наших союзников, а вслед за ними и пресса России морочили всем голову заявлениями – мол «Мы сражаемся за сохранение прав малых народов»; После каждой победы, воюющих против нас, государств, после каждого сражения, они истошно вопили, что «Это война против вашей культуры. Это варварство». Сами же, как кот, наевшийся масла, старались выглядеть очень благочестиво. Будто бы господа англичане и французы категорически против пролития человеческой крови, но только ради спасения беспомощных наций, они были вынуждены взять в руки оружие. Будто бы только ради восстановления попранных прав малых наций они подняли свое оружие! Будто бы у них нет никакой материальной заинтересованности в войне; будто бы они не желают ни пяди земли, территории Турции, Германии, Австрии, они из снисхождения желают оказать милость малым народам, угнетаемым в этих государствах. Мы нисколько не поверили подобному великодушию и благородству Англии и Франции, на протяжении всей своей истории, погрязших в алчности и корысти, вся

политика которых в последние века заключалась в притеснении, подавлении, выжимании крови малых наций. Мы знали, что за этими красивыми словами скрываются [...] удила, узда английской политики, змеиный язык плутовских козней французов» [5: 210]. Второй денотат **«причина заговора»** выявляет для читателя основных субъектов и участников происходившего обмана. «Главной причиной всех войн является стремление расколоть исламское сообщество, отнять независимость Турции – единственного оставшегося мусульманского государства, о чем мы постоянно писали. С первого появления газета «Иль» постоянно выходили статьи на эту тему. Газета «Сүз» таким образом за подобную статью была погублена неверными. Теперь открыто и ясно показана причина войны, направленной против всего мира, об этом заявлено устами английских, французских, русских дипломатов. Откровенно заявлено и всем стало известно, что главной причиной этих кровопролитных войн является не стремление англичан, французов и русских спасти и защитить различные малые нации, а всего лишь разделить между собой в первую очередь – Турцию, во вторую очередь – Австрию, в третью очередь – Германию» [5: 211]. Третий денотат **«мы – жертвы»** представляет мусульман и тюрко-татар главным объектом манипуляций заговорщиков. «В итоге получается, что свыше миллиона мусульман из армии России пожертвовали своими бесценными жизнями ради того, чтобы святыни Арза оказались попраны ногами французов, а Иран стал жалким рабом англичан и русских, они ушли из жизни негодяями и подлецами, стреляя из пушек и оружия, по исламскому единству, обнажив сабли против исламского флага! В итоге, этот многомиллионный народ был обманут шарлатанами; эти миллионы истинных мусульман превратились в орудие в руках английских, французских и русских авантюристов!.. Теперь об этом стало известно. Теперь это преступление из преступлений явилось на глазах у всех, доступно всеобщему обозрению. Но ведь обо всем стало известно уже после того, как дело было сделано и все уже разбито! Стало известно, когда мусульманские войска понесли сотни тысяч жертв, когда сотни тысяч мусульманских воинов остались хромыми, безрукими, слепыми и изуродованными…Стало известно, когда все уже было кончено» [5: 212]. Четвертый денотат **«спасение от врагов»** четко обозначает врагов созданного автором мнемонического сообщества и намечает пути выхода из кризисной ситуации. «Тайные соглашения стали известны. Теперь стала явной степень нашего обмана во время произошедшей войны. Но защищены ли мы от подобного обмана во время будущих войн, не пропадут ли напрасно наши души во благо каких-либо очередных шарлатанов? Гарантировано ли в будущем одному миллиону мусульманских воинов право: применять оружие только за свои права, по собственному усмотрению? Без этого обман и самообман не исчезнут. Без этого мы и дальше, подобно продажному скоту, без конца будем проливать кровь во имя счастья английского вора и ублажения французской проститутки» [5: 213].

Значимость статьи Г. Исхаки состоит в том, что она представляет взгляд на события 1914–1917 годов глазами живых современников и потому еще не деформированного коммунистической пропагандой XX века. Указанный перевод историко-политического текста поднимает важную научно-методологическую проблему статуса двуязычия в национальной культуре. Оказалось, что в данном случае разные языки не искажают трансляцию национального дискурса иноязычной аудитории. Перевод на русский язык помог усилить акценты оригинального текста и показать его скрытую интертекстуальную и метатекстовую архитектуру. Например, религиозный дискурс, драматический сюжет, конспирология заговора, сказочные образы врагов-злодеев, риторические приемы. В процессе перевода было выявлено, что Г. Исхаки использует в публицистике приемы драматургии – находит интригу, чтобы через нее раскрыть и показать крупный исторический конфликт разных политических сил.

## ЛИТЕРАТУРА

1. Бухараев Р.Р. Избранные произведения: Книга историй. – Казань: Магариф – Вакыт, 2011. – 415 с.

2. Еникеев И.А. Русскоязычные писатели в национальном культурном пространстве-переводы Р. Бухараева // Международная научно-практическая конфиренция «Восток-Запад: литература и художественная культура» (19–21 октября 2017 года. Казань). – Казань, 2017. – С. 81–84.

3. Исхаки Г. Тайные соглашения // Первая мировая война в оценке современников: власть и российское общество.1914–1918: Т. 4. Демократия «страны нарушенного равновесия». – М.: Политическая энциклопедия, 2014. – 591 с.
4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. 7 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 366 б.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 т. 9 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 415 б.
6. Набиуллина А.Н. Феномен транскультурации в современной русскоязычной прозе: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2023. – 24 с.

УДК 821.512.145

## ЭПОХА И ЛИЧНОСТЬ В ДРАМАХ Г. ИСХАКИ «УЛУГ МУХАММЕД» И Р. ЗАЙДУЛЛЫ «ПОСЛЕДНИЙ ТАТАРИН» (сравнительный анализ)

***А.М. Закирзянов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье исследуется особенности эпохи и исторические личности в драмах Г. Исхаки «Улуг Мухаммед» и Р. Зайдуллы «Последний татарин». В пьесе Г. Исхаки в центре внимания сложный, противоречивый период середины XV века, в котором показан образ Улуг Мухаммад-хана. Он опытный, умелый вождь, военачальник. В пьесе Р. Зайдуллы раскрывается сложная ситуация середины XVI века в Казанском ханстве и анализируется поучительный образ Кул Шарифа. Сравнительный анализ позволяет оценить особенности двух эпох, а также исторических личностей, раскрыть их отдельные черты и сделать выводы, связанные с современностью.
**Ключевые слова**: татарская драматургия, Г. Исхаки, Р. Зайдулла, сюжет, эпоха, личность, сравнительный анализ.

The article examines the features of the epoch and historical figures in the dramas of G. Iskhaki «Ulug Muhammad» and R. Zaidulla «The Last Tatar». The play by G. Iskhaki focuses on the complex, contradictory period of the middle of the XV century, in which the image of Ulugh Muhammad Khan is shown. He is an experienced, skillful leader, a military commander. The play by R. Zaidulla reveals the difficult situation of the middle of the XVI century in the Kazan Khanate and analyzes the instructive image of Kul Sharif. Comparative analysis allows us to evaluate the features of two epochs, as well as historical figures, to reveal their individual features and draw conclusions related to modernity.
**Key words:** Tatar drama, G. Iskhaki, R. Zaidulla, plot, epoch, personality, comparative analysis.

## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «ОЛУГ МӨХӘММӘД» ҺӘМ Р. ЗӘЙДУЛЛАНЫҢ «СОҢГЫ ТАТАР» ДРАМАЛАРЫНДА ЧОР ҺӘМ ШӘХЕС (чагыштырма анализ)

***Ә.М. Закирҗанов***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар халкының фаҗигале тарихы дәүләтчелек белән тыгыз бәйле. Бабаларыбыз IX гасырда Идел буендагы Болгар дәүләтенә нигез салып, аның шул чорда Евразиядә киң танылуына ирешә. XIII гасыр урталарында Алтын Урда дәүләтенә көчләп кертелгәч тә, болгар иле үзенең йогынтысын саклый. Җирле халык буыннан буынга тапшырылып килгән дәүләтчелеккә омтылу идеясе белән яши. Шуңа да Алтын Урда таркалганнан соң, элекке Болгар илендә беренчеләрдән булып Казан ханлыгы оеша. XVI гасыр уртасында Казан ханлыгының рус дәүләте составына кертелүе белән татар халкы дәүләтчелеген югалта. Әмма ирекккә, мөстәкыйльлеккә омтылу, үз дәүләтен булдыру идеясеннән халык бервакытта да баш тартмый. Дәүләтне югалту фаҗигасенең сәбәпләрен ачу, шуннан чыгып бүгенгебезгә бәя бирү, халыкны берләштерүгә нигез булган милли идеяне булдыру һәм аны тормышка ашыру мәсьәләсе һәр чорда да актуаль булып кала. Шуңа да әлеге гаять җитди мәсьәлә XVI гасырдан башлап халык авыз иҗатында, аеруча дастан, риваять һәм легендаларда чагылыш таба. Ә инде XX гасыр башында яңарыш дәвере кичергән татар әдәбиятында дәүләтчелек белән бәйле

мәсьәләләр алгы планга чыга. Сүз сәнгатендә бу тема-проблемага беренчеләрдән булып «яңа заман әдәбиятының, шул исәптән дарамтургиясенең нигез ташларын салуда гаять зур өлеш керткән» [1: 36] Г. Исхакый мөрәҗәгать итә («Ике йөз елдан соң инкыйраз») һәм алга таба Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал, Дәрдмәнд, Н. Думави һ.б. иҗатында теге яисә бу аспектта чагылыш таба. Совет чорында автономия кысаларында яшәгән Татарстан һәм татар халкының дәүләтчелеге мәсьәләсен кузгатуны күз алдына да китереп булмый. 1920–1930 елларда моңа омтылыш ясаган татар зыялылары бик тиз эзәрлекләнә башлап, күбесе репрессияләр корбаны була (М. Солтангалиев, Г. Ибраһимов һ.б.). Алай гына да түгел, ВКП(б) ҮК 1944 ел 25 августында кабул иткән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары нигезендә татар халкы тарихыннан Алтын Урда дәвере алып ташлана. Шул чор белән бәйле дастан-кыйссаларны өйрәнүгә дә киртә салына. Совет хөкүмәтенең әлеге гаделсез эшгамәленә символик җавап-мөнәсәбәт рәвешендә Г. Исхакый «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасын яза [6: 55]. Дөрес, 1960–1980 елларда әдипләр үткән тарихка мөрәҗәгать итеп, дәүләтчелек чорларын сурәтләргә алына. Татарның дәүләт тоткан халык булуы, аның, Тукай әйтмешли, бу илдә хокуклары зур булу мәсьәләсе эзлекле үстерелмәсә дә, тарихи әсәрләр халыкның үзаңын уятуга зур йогынты ясый.

XX гасырның 80 нче еллары ахырында, илдә иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни шартлар үзгәргәч, ерактагы һәм якындагы тарих, атаклы шәхесләр тормышы әдәбиятта төп темаларның берсе булып китә. Тарихны заман белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү, чор куйган сорауларга тарихтан җавап эзләү омтылышы белән М. Хәбибуллин, Н. Фәттах, Р. Мөхәммәдиев, М. Хәсәнов, Ә. Рәшит, А. Хәлим, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, М. Әмирханов һ.б. иҗатында очрашабыз. Шул рухтагы әсәрләр арасында Р. Зәйдулланың «Соңгы татар» драмасы да бар. Әлеге мәкаләдә Г. Исхакыйның 1947 елда тәмамланган «Олуг Мөхәммәд» һәм Р. Зәйдулланың яңа гасыр башында язылган «Соңгы татар» драмаларында чор һәм шәхесләр бирелешен ил-халык язмышы белән бәйләнештә тикшерү максатыбыз булып тора.

Г. Исхакыйның биш пәрдәлек тарихи драмасында XV гасыр урталарында Казан ханлыгы оешу вакыйгалары сурәтләнә. Сюжетка нигез итеп Р. Фәхретдиннең «Шура» журналында чыккан «Олуг Мөхәммәд хан» язмасы алынган дигән фикер бар [6: 56]. Автор аны Болгар, Алтын Урда кебек дәүләтләрнең табигый дәвамчысы итеп карый һәм гаять зур тарихи әһәмияткә ия булуын кат-кат искәртә. Шуңа да алгы планга катлаулы, каршылыклы чор һәм шунда дөрес юлны таба алган тарихи шәхес чыга. Р. Зәйдулланың «Соңгы татар» драмасында Казан ханлыгың соңгы көннәре сурәтләнә. Ил-халыкка сугыш, дәүләт мөстәкыйльлеген югалту куркынычы яный. Тирә-якта дан тоткан дәүләт ни өчен шундый хәлгә калган, аны яклап-саклап калырдай шәхес-юлбашчы табылырмы? Сорауга җавап эзләү йөз еллык тарихы булган ил-дәүләтнең юкка чыгуына китергән эчке һәм тышкы сәбәпләрне ачу да булып тора. Бу исә ике чор, ике дәүләтне һәм, билгеле инде, тарихи шәхесләрне чагыштырып караганда ачык күренә.

Г. Исхакый әсәрендә вакыйга Алтын Урдадан куылган Олуг Мөхәммәднең рус җиренә килеп, Белев шәһәрендә кышны үткәрү теләгән белдерүе белән башлана. Рус патшасы Василий моның белән килешми һәм, 40 меңлек гаскәр туплап, сугыш белән килә. Олуг Мөхәммәдкә башка юл калмый, ул 4–5 меңлек гаскәре белән каршы чыга. Шул рәвешле, безнең каршыда гаять катлаулы тарихи чор ачыла. Тарихтан билгеле булганча, татар ханы ун тапкыр зур булган яуны тар-мар итүгә ирешә [9: 21–31]. Г. Исхакый вакыйга барышында әлеге җиңүнең сәбәпләрен ачуга зур игътибар бирә. Берсе – дошманның гаделсез булуын аңлау. Илчеләр рус җирендә сыену табарга теләгән татарларны ике гасыр буе рус җирен талауда, зур салым түләп торуда, шәһәрләрне юк итүдә, хатын-кызларны кол итеп алып китүдә һ.б. гаепләсә дә, моның ике арада дошманлык уятуны максат иткән чиркәү әһелләре сөйләгән сүзләр булуы аңлашыла. Илчеләр Василий Собакин белән Андрей Галитаевның ике төрле караштა булуы да шуны күрсәтә. Шуңа җавап буларак, Олуг Мөхәммәд янындагы җыенда татар-рус мөнәсәбәтләренә бәйле тарихи документларда теркәлгән фактлар яңгырый: Алтын Урда составына кертелгәннән соң, рус җирендә таркаулыкка чик куелу, илне Мәскәү

князьлеге тирәсенә җыю; рус җирендә дин ирегe игълан ителеп, чиркәү әһелләрен эзәрлекләү катгый тыелу, аларны салымнан азат итү һәм Мәскәү патриархына буйсындыру; юллар салу, сәүдә эшен көйләп җибәрү, төрле өлкәләрне үзара якынайту максатында почта эшен тәртипкә салу һ.б.

Белев янындагы сугышта җиңүгә икенче сәбәп булып, сугышчыларның һәм төрле сословиедәге халыкның Олуг Мөхәммәд тирәсенә бер йодрык булып туплануы, уртак максат белән эш итүе тора. Тагын бер сәбәп – халыкның төрле катлавын берләштерүгә ярдәм иткән дингә таяну. Изге сугышка һәм башка эшләргә хан Аллаһы ярдәменә таянып алынган кебек, хан башлаган эшнең изгелегенә, Аллаһы ризалыгы белән башкарылуга инану гаскәр башлыгыннан алып хан тирәсендәге барча хезмәтчедә күзәтелә. Олуг Мөхәммәдне сан ягыннан күпкә өстен дошманга каршы ханбикә Гөлбикә мондый сүзләр белән озата: «*...Меңнәрчә бикәләр, кызларыбыз мәсхәрә булганчы, шул карлар астында тәннәребез чересен, намусыбыз югалсын, җаныбыз чыксын. Тәңре ярдәм бирсен, солтаным!*» [5: 451]

Р. Зәйдулланың «Соңгы татар» драмасында тагы да катлаулы һәм каршылыклы чор сурәтләнә [3: 15]. Вакыйгалар Казан ханлыгында, төгәлрәге Кол Шәриф өендә һәм шәһәр мәйданында бара. «Башлам» өлешендә сәед белән яңарак кына дошманнары тарафыннан үтерелгән хан Сафа Гәрәйнең улы Үтәмеш арасындагы сөйләшү ил-көннең авыр, каршылыклы яшәешенә ишарә итә. Пьесадагы вакыйгалар татар-рус каршылыгына бәйле үстерелә. Аның бер ягында, бөтен көчен, талантын халкы мәнфәгатен яклауга, аның азатлыгы өчен мөмкин булганның барын да эшләргә әзер Кол Шәриф булса, икенче якта рус дәүләте алып барган басып алу сәясәтен яклаучылар төркеме тора. Автор төп игътибарны ханлыкның эчке каршылыкларын, таркаулык сәбәпләрен ачуга юнәлтә. Тарихтан билгеле булганча, XVI гасыр урталарында Казан ханлыгы гаять каршылыклы чорга керә. Ханнарның бер-бер артлы алмашынып торуы, ханлыкның үзендә көчле ил башлыгы табылмавы, шулай ук татар ханлыклары арасында үзара ярдәмләшү булмау һ.б. сәбәпләр аны эчке таркаулыкка китерә. Кырым ханнары династиясенең бер вәкиле булган Сафа Гәрәй Казан ханы булып күтәрелгәч, илне берләштерү буенча җитди адымнар ясала. Ә инде аның Ногай ханы Йосыф бәк кызы Сөембикә белән никахлашуы моңа тагы да киңрәк юл ача. Әмма илнең эчке һәм тышкы дошманнары тарафыннан Сафа Гәрәй үтерелә. Рус дәүләте алып барган астыртын сәясәт нәтиҗәсендә ханлыклар арасындагы бәйләнешләр нык кими. Морзаларның бер өлеше, таяныч эзләп, Мәскәү патшасы ягына авыша. Әнә шундый шартларда илне берләштерерлек, Мәскәү басымына каршы торырлык кеше бармы, дөресрәге булганмы? Р. Зәйдулла бу сорауга җавап рәвешендә Кол Шәриф шәхесенә мөрәҗәгать итә.

Г. Исхакый драмасында Олуг Мөхәммәднең Казанга килүе һәм аны халыкның каршы алуы күренешнә җитди игътибар бирелә. Бер караганда, Казан кешеләренең Олуг Мөхәммәдне хан итеп күтәрүе шактый җиңел, гади күренеш кебек. Әмма асылда ул гаять җитди вакыйга булып, автор аның сәбәпләрен тулы ача. Төп сәбәп, билгеле инде, Олуг Мөхәммәднең чыңгызлылар нәселеннән булып, хан булырга тулы хокукы булу, икенчесе, Белев янындагы сугышта җиңү яулау, ул ханның көчен, осталыгын, акылын күрсәтә. Казанлылар руслар алып барган сугышлардан иза чиккән вакытта, көчле хан бу михнәттән саклаучы, азат итүче буларак кабул ителә. Олуг Мөхәммәд ханның башка төбәккә түгел, нәкъ менә Казанга килүе дә мөһим факт, чөнки монда элекке Болгар дәүләте дәвамчанлыгы саклана һәм атаклы хан ярдәмендә дәүләтчелекне торгызу, аны ныгыту барча халыкның теләге буларак кабул ителә. Моның шулай икәнен ачу өчен Г. Исхакый Казан кешеләренең ханны каршы алырга килүләренә аерым игътибар бирә. Башта Казан башлыгы Үлмәс хан улы Галимбәк һәм якыннары килеп баш ора, аннары казанлылар исеменнән аксакаллар килә. Болар ил-халыкка зур йогынты ясаучы катлам, шуңа да алар белән әңгәмәдә хан тарафыннан гаять гыйбрәтле сүзләр әйтелә: «*Ил – барыбызның уртак малы. Дошманнарыбызга дошманлык безне бүген ничек берләштерсә, арамыздагы дустлык, кардәшлек тә шулай берләштерсен!*» [5: 462]. Соңыннан исә хан каршына кара халык вәкилләре килә. Монысы да бик мөһим булып, Олуг Мөхәммәднең бөтен ил халкына тигез каравы, һәрбер катламның мәнфәгатен кайгыртырга әзерлеген аңлата. «Әсәрдә Олуг Мөхәммәд зирәк, алдан

күреп эш итүче идарәче буларак ачыла» [7: 262]. Бу урында Г. Исхакый ассызыклаган тагын бер мәсьәлә – ул төрле төбәкләргә таралып яшәгән татарларның үзара дуслыгы, бердәмлеге. Халкы, гаскәре белән Казан тирәсенә килеп туктаган Олуг Мөхәммәд үзен ничек каршы алырлар дип борчыла. Әгәр аларны кабул итмәсәләр, кайдан килдең шунда кит, дисәләр, нишләргә? Ханның бу сорауга җавабы ачык: *«Әгәр Казан кабул итмәсә, күтәрелеп сахрага китәмез, казак буламыз. Илдәшләр арасы сугышларга мин сәбәп тә була алмыйм, бу сугышларда башлык та итә алмыйм»* [5: 459]. Игътибар итик, ул һич тә көч белән, гаскәр белән Казанны яулап алабыз дими, кардәшләрнең каны түгелмәячәген ачык итеп әйтә.

Әнә шул рәвешле, Г. Исхакый драмада көчле шәхесне алгы планга чыгара, ил өчен кыен, хәлиткеч мизгелләрдә шундый кешеләр җитәкчелекне үз кулына алырга тиеш дип фикерне яклый. Олуг Мөхәммәд гаять катлаулы шартларда тыныч юл белән властька килә һәм Казан ханлыгын оештыра. Оешу бер хәл, аның белән идарә итәргә, якларга һәм сакларга да кирәк бит әле. Хан ил белән идарә итүдә дә осталык, акыл һәм тәҗрибә күрсәтә. Драмада ул «Казан ханлыгын төзүче итеп кенә түгел, ә бәлки таркау ханлыкны бергә туплый алган милли юлбашчы, талантлы полководец, киләчәккә карап эш йөртүче дәүләт җитәкчесе итеп тә тасвирлана» [8: 60]. Моның нигезендә, идарә итүнең югарыда әйтелгәннәрдән тыш, гаять мөһим мәсҗәләләре ята. Берсе – ил өчен әһәмиятле мәсьәләне киңәшеп хәл итү. Хан үзенә яраклашуны түгел, бәлки мәсьәләгә ачык карап, аны төрле яклап тикшерүне, бәяләүне тели. Шуңа да ул үзенә ошап бетмәгән фикерләрне дә игътибар белән тыңлый белә. Икенчесе – вәзирләр һәм түрәләрнең тугры булуына ирешү. Моның өчен гадел булып, һәркемнең эшенә дөрес бәя бирүне яклый хан. Өченчесе – башка халыкларга һәм диннәргә тигез карау. Текстта чуваш һәм чирмеш аксакаллары белән очрашып сөйләшү күренешләре бирелә. Аларда ханның толерантлыгы, төрле халыкларны үзенә сыендырган, бүгенге терминалогия белән әйткәндә, «полиэтник, полимәдәни җәмгыять төзү идеясе» [8: 71] һәм шуңа омтылышы ачык күренә. Дүртенчесе – ханның идарә итү ысулына күпчелекнең теләкләшлек күрсәтүе, яклавы. Бу мәсьәләдә Г. Исхакый хатын-кызларның зур роль уйнавын яхшы белә, шуңа да туй мәҗлесе күренешендә Болгар иле традицияләре саклану, җәмгыятьне берләштерүдә хатын-кызлар йогынтысы турында җитди дә, гыйбрәтле дә сөйләшү бара. Ханбикә Гөлбикәнең хан фикерен җиткерүе дә махсус кертелгән кебек: *«Туган илләр дустлык, кардәшлек берлә берләшсен, ди. Кардәшкә кардәш кылыч күтәргәч, дәүләтемез Сарай ханлыгы кебек булачак, моннан дошманнарымыз файдаланачак, ди»* [5: 482]. Бишенчесе – халыкның аң-акылын үстерү, мәгърифәтле итү, киң планда мәдәнияткә игътибар итү кирәклеге. Мәчетләр каршында мәктәп-мәдрәсәләр оешу да шуңа хезмәт итә. Драмада ханның дәрвиш Әбүлмөхсин белән әңгәмәсендә яңгыраган сүзләре шуның ачык мисалы: *«Дәүләт корыр өчен белем кирәк, бер-береңә ышаныч кирәк, халык арасында дустлык кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк. Ул да шигырь белән, китап берлә, тарих берлә ясала»* [5: 474].

Р. Зәйдулла «Соңгы татар» пьесасында алгы планга Кол Шәриф шәхесен чыгара. Пьесада ул белеме, акылы белән халык арасында танылу алган, үзе артыннан ияртеп барырга әзер дини җитәкче – сәед – буларак сурәтләнә. Кол Шәриф ил өстенә янаган куркынычны бөтен тирәнлегендә аңлап, җаны-тәне белән тетрәнү кичерә. Иле-халкы өчен үзенең гомерен дә бирергә әзер шәхес булып ачыла. Сөембикә ханбикәнең, рус патшасы таләбе буенча, үзара тыныч яшәү шарты буларак, «иректә» тоткын итеп Мәскәүгә җибәрелүен дә сәед бик авыр кабул итә. Кол Шәриф, Р. Зәйдулла сурәтләвендә, Сөембикәне ярата. Кадерле кешесен үз кулы белән диярлек чит-ят илгә җибәрергә мәҗбүр булу, Кол Шәрифкә әйтеп бетергесез күңел газабы китерә. Йөрәге моңа каршы килсә дә, акылы белән ул бу хәл белән килешергә мәҗбүр. Сөембикәне тоткын итеп җибәреп, Кол Шәриф илнең ирегең саклап калуга өмет итә. *«Казан йортын без бүтәнчә исән калдыра алмыйбыз»* [5: 254], – ди ул, ханлыкны ныгыту, илне берләштереп, азатлыгын саклап калу өчен вакыт оту максатында. Әмма аның теләге тормышка ашмый. Рус дәүләте Казан ханлыгын юк итү, аның җирләрен басып алу өчен теләсә нинди мәкергә бара. Сафа Гәрәй ханның үтерелүендә дә патша кешеләренең кулы уйнавы сизелә, Сөембикәне тоткын буларак Мәскәүгә җибәрүне таләп итү

дә, ханлыкны җитәкчесез калдыру, көчсезләндерү өчен эшләнә. Ә инде ханлыктагы морзаларның кайсын куркытып, кайсын юмалап сатып алып, илне эчтән таркатуга ирешә [2: 211–213].

Р. Зәйдулланың шәхес концепциясен хәл итүдә алгы планга Казан ханын түгел, бәлки сәедне чыгаруы мөһим факт булып тора. Димәк, бу чорда Казан ханлыгында Олуг Мөхәммәдкә тиң олы хан юк. Тарихтан да без моның шулай булуын беләбез. Автор сәнгати уйлануында «Әлеге вазифаны дин башлыгы үти алмас идеме?» дигән сорауга җавап эзли. Аңлашылганча, юк. Биләгән вазифасы һәм шәхси сыйфатлары аңа юлбашчы булу мөмкинлеге бирми. Вакыйгаларда Кол Шәриф характер сыйфатларына һәм эш-гамәлләренә бәйле бөтенлекле образ булып ачылмый. Ул ил эчендәге хәлләргә бәя биреп баручы буларак бирелә. Бөтен нәрсәне килештереп хәл итү теләге белән йөри, әмма конкрет эш-гамәл кылмый, диярлек: хатынының хыянәтен дә иң соңыннан белә, кызы Айсолтанның качып китүен дә сизми кала, нигәдер кызы бик җиңел аның йогынтысыннан чыга, үги әнисе теләге белән генә яши һ.б. Р. Зәйдулла текстыннан күренгәнчә, ханлык җиңелүнең тагын бер сәбәбе булып, ил халкын уртак идеягә, максатка берләштерә алмау тора. Нәтиҗәдә рус кешеләре аерым морзаларны, түрәләрне сатып алып, хыянәткә этәрә, таркаулыкны котылгысыз итә. Шәхси мәнфәгатьләре өчен илен-халкын сатарга әзер торучылар башында Кол Шәриф хатыны Хөршидә тора. Кол Шәрифнең беренче хатыны бала тапканда вафат була һәм, кабул ителгән гадәт буенча, сәед аның сеңлесе Хөршидәгә өйләнә. Чибәр, усал һәм акыллы хатын, астыртын эш йөртеп, мәскәүлеләр белән якыная, иренең һәм иленең серләрен сатып, һәртөр хыянәткә бара. Автор аны күрәзәче дә итеп сурәтли. Ул ханлыкның фаҗигасен алдан күрә, шуңа да тәрбияләп үстергән үги кызы Айсолтанны әтисе Кол Шәрифкә сиздерми генә Воеводага кияүгә биреп, Мәскәүгә озата, үзенә дә качу юлы әзерли. Бик күп нәрсәне алдан күреп торса да, Хөршидә үз язмышын билгели алмый. Ханлык җимерелгәч, рус патшасына да, Воеводага да аның кирәге калмый.

Шул рәвешле, Г. Исхакыйның Казан ханлыгы оешуга бәйле вакыйгалар сурәтләнгән «Олуг Мөхәммәд» һәм Р. Зәйдулланың Казан ханлыгының соңгы көннәре чагылыш тапкан «Соңгы татар» драмаларын чагыштырма планда өйрәнү, ханлыкның оешуын һәм йөз елдан соң таркалуы вакыйгаларын бәяләү, билгеле бер нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә. Һәр икесендә гаять катлаулы чорлар булуга карамастан, беренче очракта Олуг Мөхәммәд хан олпат ир, оста җитәкче буларак сурәтләнеп, яңа дәүләткә нигез сала, икенчесендә исә, көчле хан булмау сәбәпле, җитәкчелекне үз кулына алырга омтылган сәед Кол Шәриф олы җитәкче, оештыручы дәрәҗәсенә үсеп җитә алмый, илен саклап, һәлак була. Ике автор да гыйбрәтле язмышлар аша, берәүләрнең бөеклеген, икенчеләрнең түбәнлек гамәлләрен сурәтләп, татар халкының каршылыклы тарихыннан үзенчәлекле сәхифәләрне ача, үткәннән гыйбрәт алып, бүгенгебезгә бәя бирергә һәм киләчәк турында уйланырга этәрә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәдуллин А. Гаяз Исхакый һәм татар драматургиясе // Мирас. – 1995. – № 1–2. – Б. 34–39.

2. Закирҗанов Ә. Дөньяны ярату (Ркаил Зәйдулла) // Иҗат тылсымы: әдәби портретлар, күзәтү мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2022. – Б. 195–226.

3. Закирзянов А. Р. Зәйдулла драматургиясендә дини-әхлакый башлангыч // Роль ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов VII Международной научно-практической конференции, посвященной 1100-летию официального принятия Ислама в Волжской Булгарии. – Набережные Челны: Ак мечеть, 2022. – С. 12–17.

4. Зәйдулла Р. Саташкан сандугач һәм башка пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 232–268.

5. Исхакый Г. Олуг Мөхәммәд // Гаяз Исхакый, 15 томда. 5 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Б. 441–519.

6. Миңнегулов Х.Й. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 367 б.

7. Миңнуллина Ф. Г. Исхакый драматургиясендә фаҗигалелек («Зөләйха», «Дулкын эчендә», «Олуг Мөхәммәд» әсәрләре мисалында) // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 260–263.

8. Сәхапов Ә. Исхакый иҗаты. – Казан: Татар «Мирас» кит. нәшр., 1997. – 336 б.

9. Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное воспроизведение издания 1923 г. – Казань, 1990. – 310 с.

УДК 82.091

# ТВОРЧЕСТВО Г. ИСХАКИ В РЕЦЕНЗИЯХ ФАТИХА АМИРХАНА (1907–1912)

***Г.Н. Зайнеева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Фатих Амирхан и Гаяз Исхакый были сторонниками просветительских идей в образовании начала XX века. Каждый поднимал в своем творчестве вопросы, касаемые реформы в системе образования, равноправия женщин и мужчин, обучения женщин. В публицистике Фатиха Амирхана имеются статьи, посвященные творчеству Г. Исхаки в целом, или же о конкретном его литературном произведении. В статье дается информация о данных рецензиях.
**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, Гаяз Исхаки, татарская литература, рецензии, публицистика.

Fatih Amirkhan and Gayaz Iskhaky were supporters of educational ideas in education at the beginning of the XX century. Everyone raised in his work issues related to reform in the education system, equality of women and men, women's education. In the journalism of Fatih Amirkhan there are articles devoted to the work of G. Iskhaki in general, or about any of his literary works. The article provides information about these reviews.
**Key words:** Fatih Amirkhan, Gayaz Iskhaki, Tatar literature, reviews, journalism.

# ФАТИХ ӘМИРХАН БӘЯЛӘМӘЛӘРЕНДӘ Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫ (1907–1912)

***Г.Н. Зәйниева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар әдәбияты классигы, журналист, танылган публицист Фатих Әмирхан (1886–1926) – XX гасыр татар милли тормышында тирән эз калдырган, аның мәгарифе, рухи үсешенә көчле йогынты ясаган күренекле шәхес. Ул җаны-тәне белән татар милләте, аның киләчәге, язмышы, үсеше өчен борчылып яши һәм җитди мәсьәләләрне күтәргән мәкаләләре белән үткен журналист, кыю публицист буларак танылa.

Фатих Әмирханның әдәби, тәнкыйди эшчәнлеге газета-журнал редакцияләре белән тыгыз бәйле. Мәгълүм булганча, ул «Әлислах», «Кояш», «Кызыл армия» газеталарында, «Тәрбияи этфаль», «Ялт-Йолт» журналларында җаваплы вазифалар башкарган. Татар вакытлы матбугаты битләрендә аның тарафыннан басылган күпсанлы мәкалә, фельетон, рецензияләр урын алган. Шунысын да әйтергә кирәк: вакытлы матбугатта ул шул чор татар җәмгыяте өчен актуаль булган мәсьәләләрне күтәргән публицистик мәкаләләрен күп очракта төрле тәхәллүсләр белән, кайчакта хәтта имзасыз-аноним итеп тә бастырган. Мәсәлән, аның бик актив язышкан чоры 1907–1909 елларга туры килә – «Әлислах» газетасы оешканнан алып, соңгы санына кадәр фактик редактор буларак, һәр санда мәкаләләре урнаштырылган була. «Әлислах»ның баш мәкаләләре авторы булып та Ф. Әмирхан санала, алар имзасыз басылган булсалар да, үзенең Ризван Алушига язган хатында (1907, 25 ноябрь) ул әлеге мәкаләләрнең анықы булуын ассызыклап әйтеп уза.

«Тәрбияи этфаль» («Балалар тәрбиясе») журналын да Фатих Әмирхан исеменнән башка күз алдына китереп булмый, анда да язучының язмалары урын алган. Әлеге журнал 1907 елның гыйнвар-март айларында Мәскәүдә татар телендә чыккан беренче балалар журналы буларак санала. Журналның титул битендә: «Унбиш көндә бер чыга торган сабак балаларына махсус әдәби, фәнни вә рәсемле мәҗәллә» дип язылган.

Г. Исхакый Әмирхан хакында «...мөхәррир булып китү юлына, шул юлда үлү юлына аяк баскан» [3: 19], дип, әдипнең мөхәррирлек эшен югары бәяли.

Фатих Әмирхан публицистикасында аерым шәхесләр исемнәренә, иҗатларына багышланган, аларның татар әдәбияты тарихында рольләрен күрсәткән язмалары шактый. Андый шәхесләрдән Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Риза Фәхреддин, Ярулла Вәлине һ.б атап китәргә мөмкин.

Фатих Әмирханның 1907–1912 еллар аралыгында Гаяз Исхакый иҗаты белән бәйле булган өч мәкаләсе билгеле. Беренчесе «Тәрбияи этфаль» журналының 1907 елгы 1 нче (1 гыйнвар) санында «Бу көннәрдә улган вакыйга» бүлегендә исемсез һәм имзасыз басылган. Әлеге мәкаләнең үзенеке икәнлеген ул дусты Ризван Алуши-Ибраһимовка 1907 елның 8 апрелендә язган хатында әйтеп уза: «Фәрхәнә ханым минем мәкаләләрне укый икән, ләкин мин мәкаләләремне күбрәк имзасыз җибәрәм, шунлыктан монда кайсылар минем мәкалә булдыгыны сөйләмәкче булам. Беренче номеруда – "Идарәдән", "Истамбул шәһәре", "Күктә күренә торган нәрсәләр", "Гаяз"» [2: 239]. «Тәрбияи этфаль» балаларга багышланган журнал булганга, биредә Ф. Әмирханның язу стиле җиңел, җиткерәсе фикерләре теләк-киңәш буларак яңгырый, укучыларда Гаяз Исхакый иҗатына кызыксыну уяту, аның иҗаты белән тирәнрәк таныштыруны теләп тә тәкъдим ителә. Мәкалә Гаяз Исхакыйны хөрмәт итеп, олылап язылган, биредә әдип сүзенә дә аңлатма бирелеп, әдип сүзен кем йөртергә хаклы икәнлеге хакында да ассызыклап үтелә: «Мин Гаяз әфәндене әдип дидем, бу сүз, сезнең белгәнегезчә, һәрбер китап язып чыгарган кешегә әйтелә торган сүзме? Юк, әдип дип бары язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгата, күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирә вә мәгыйшәтнең начар вә яхшы якларыны ачык күрсәтә торган мөхәррирләргә генә әйтеләдер» [1: 28]. Аннан соң язучы «Өч хатын берлә тормыш» һәм «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләренә тукталып уза. «Өч хатын берлә тормыш» пьесасында Гаяз Исхакыйның надан, әхлаксыз, тәкәббер бай кешеләрне аның капма-каршы булган зыялы, әхлаклы, тәрбияле геройларны оста тасвир итүе хакында, һәр эш-гамәлнең нәтиҗәсе булуын Ф. Әмирхан аерып күрсәтә. «Гаяз әфәнденең башка әсәрләре дә шулай тәэсирле язылган вә шулай ук еглата вә көлдертәләр» [1: 29] дип бәясен бирә. Ахырдан Ф. Әмирхан укучыларга әлеге әсәрләрне укып чыгып, журнал редакциясенә үз тәэсирләрен язып җибәрергә, аннан соң язучыларның исемнәрен журнал битләрендә күрсәтергә вәгъдә итеп, мәкаләсен тәмамлый. Шул рәвешле, язучы бала күңеленә ачкыч та таба белгән, кызыксындырып, китапка якынайтырга, әдипләр тормышы, иҗаты белән таныштырырга, гомумән, әдәбиятка тартуда зур көч куйган.

Ф. Әмирханның «Әлислах» газетасында (1908, 26 октябрь) «Яңа китаплар» бүлегендә «Дамелла» имзасы белән басылган «Солдат» мәкаләсе билгеле. Бәяләмә Гаяз Исхакыйның «Солдат» исемле повестеның басылып чыгу уңаеннан язылган. Газетаның алдарак басылган санында («Әлислах», 1908, 13 октябрь) «Солдат» әсәре хакында «Яңа китаплар» рубрикасында белдерү басылган була: «Солдат» (Гаяз Исхаков әсәре. Хөсәен Әбүзәрев нәшере). Гаяз әфәнденең иң соңгы әсәре «Солдат» бу көннәрдә табгы ителеп *(басылып)* тәмам булды. Киләчәк номерда мөфассал *(җентекле)* тәнкыйть дәрҗ ителәчәктер *(теркәләчәктер)*». Югарыда телгә алынган бәяләмә күләм ягыннан зур түгел. Повестьның әүвәлге җөзьәсе *(бүлеге)* басылып чыгу уңаеннан таныштыру рәвешендә генә язылган дигән фикер туа. Ләкин Ф. Әмирхан «Хода насыйп итеп, бервакыт һавалар алмашынса, йөрәкләрне катырган, җансызландырган суыклар урынына ачык йөзле, җылысы белән бөтен нәрсәгә рух өрә торган «яз кояшы» чыкса, калганы да нәшер ителер вә мин дә тәнкыйдемне язармын. ...бу әсәр – Гаяз әфәнденең хәзерге чын мәсләкен күрсәтә алырлык әүвәлге әсәредер» [1: 141] диеп, киләчәктә бу әсәргә киңрәк тукталырга өмет итә, аңа зур өметләр баглый.

Ф. Әмирханның «Әлислах» газетасында (1907, 19 ноябрь) «Китаплар хакында мөхакәмә» бүлегендә «Дамелла» имзасы белән басылган «Алдым-бирдем» мәкаләсе дә игътибарга лаек. Ул – Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем» (1907) исемле пьесасына бәяләмә. Ф. Әмирхан мәкаләләренең күпчелегендә яңалыкка омтылу, искелектән арыну, белем бирү системасындагы үзгәртүләрне таләп итү, хатын-кызларның ирләр белән бертигез хокукта булу фикерләре алгы планга куелган була һәм ул Г. Исхакыйның бу пьесасында да нәкъ шушы темалар үзәккә куела, ди ул мәкаләсендә. Пьеса геройлары, вакыйгалары «бик дөрест вә халис *(чын)* татар мәгыйшәтеннән алып тасвир итәдер» [1: 71], диелә мәкаләдә. Мәсәлән, Хәлил бай Шакиров тибына характеристикасында: «Бу фирка *(төркем)* халык телләре вә фикерләре белән никадәр яңалыкка тәүҗиһ *(мөрәҗәгать)* иткән күренсәләр дә, фигыльләрендә һаман искелектән аерылып җитә алмау, искелекнең аларга биргән имтияз *(өстенлек)* вә хосусиятләреннән

файдаланырга тырышу вә билахирәдә *(ахырда)* бик тиз үзен чолгап алган искелек хамиләренең *(яклаучыларының)* тәэсирләренә төшү кеби сыйфатларын изһар итмәктәдер *(күрсәтәдер)*» [1: 71], диелә. Шулай ук бәяләмәдә Әхмәди бай, мулла типлары тормышчан тасвирлана, дигән фикер үткәрелә. Ф. Әмирхан күзлегеннән әсәрдә хатын-кыз типлары ирләр типларыннан яхшырак тасвирланган. Мәсәлән, Галия исемле героиняга «...бер нәрсәгә дә карамый теләгәнен итәргә тырыша торган вә бөтенләй бирелеп берәүне сөя ала торган кыз булып, табигате белән хөррият вә киң мәгыйшәткә касд иткән *(омтылган)* татар кызының дөрест тибыдыр» [1: 72] дигән характеристика бирелә. Пьесаның уңай якларына гына түгел, кимчелекле якларына да игътибар ителә: мәхәббәтнең аз бирелүе, әсәрдә романтизмның «саран» булуы. Ахырдан нәтиҗә буларак: «Яңа мәгыйшәт үз каһарманнарыны икенче төрлерәк каршыларга тиеш! Бу – минем фикерем, бәлки әдәбият белән күбрәк белеш кешеләр башка төрле тәкъдир итәрләр» [1: 73] дигән сүзләр белән пьесаны һәр шәкерткә укып чыгарга киңәш итә.

Фатих Әмирханның Г. Исхакый белән дустанә мөнәсәбәттә булулары хатларында ачык күзәтелә, алар бер-берсенә ихтирам хисе белән сугарылган, бер-берсе белән киңәшләшеп язган юллар очрый. Мәсәлән, Г. Исхакыйның 1912 елның июнь-сентябрь аралыгында Мезень шәһәрендә (Архангель губернасындагы шәһәрчек) сөргендә булган чагында язган хатында татарларның тормышы, яшәеше, татар әдәбиятында аның чагылышы хакында фикерләре аеруча мөһим (1912, 5 август): «Безнең тормышымызда (минем күрүемчә) мескинлек, булдыксызлык хәятның үзәге түгел. Ара-тирә очрый торган бәхетсезлек кенә. Шуның өчен, шул ноктага иң зур нокта иттереп тотып, бөтен тормышны шуннан ага торган зәһәрле буяуга буярга тырышу, минемчә, зур хата. Татар халкының истикъбали карашыннан җинаять! ... мин татар әдәбиятының аерынгы бер галәмәте, аның егъламавы, ныклыгы, тазалыгы, тормышның начарларына, зәһәрләренә каршы чыгуына ышанып, күкрәкне киереп, йырлый-йырлый сугышуы дип, рефератымны бетергән идем. Шул сүзләрне мин тәмам ышанып әйткән идем» [3: 19]. Әдип Ф. Әмирхан әсәрләре белән яхшы таныш булган, фикерен җиткерә барган: «Тагы синең әсәрләренең «минеке»леге күренеп тора торганы, минемчә, ... «Хәят» [3: 21].

Хатларыннан күренгәнчә, Г. Исхакый: «Син, мин, Габдулла, Сәгыйдләрнең татар әдәбиятындагы урыннарын күрсәтә торган берме, берничәме мәкаләләр. ...Габдулланың кыйммәте үз урынында никадәр зур булса, Сәгыйднең дә бәһасе үз базарында Габдулланыкыннан ким түгел», – дип яза [3: 22]. Г. Исхакый үзен, Фатих Әмирханны, Габдулла Тукайны, Сәгыйть Рәмиевне – шул чорда ук инде татар әдәбиятында мөһим роль уйнаган лидерларыннан санаганлыгы күренә. Бу, әлбәттә, шулай.

«Русиядә руслардан кала иң зур милләт без булганга, шуңарга безнең хакымыз бар. Русиядә еврейлардан кала иң тырыш милләт без булганга, көпчәкләрне майларга май чыгара алырлык көчемез бар. Май атларга егерме биш миллионлы сөтле савым халкымыз бар. Шуның өчен аның сөтен бозмау, каймагын ачытмас өчен күпер янында йөри торганнар безләр, сезләр, әминләр, диниләр бик сакланып, кулны-башны юып, ни эшләгәнемезне төшенеп, һәр хәрәкәтне уйлап, үземезнең мәсьүлиятемезне аңлап, селкенмәскә кирәк. Вә шул күпер янына килә башлаган һәр кешегә вазифасының зурлыгын аңлатырга вә тегендә ятып тора торган көченең куәтен белдерергә вә шул куәтенең эч кайнавыннан гына үзенең кәпрәп-күпрәп чыккан бер комчык кына икәнен хәтереннән чыгармаска кирәк. Мин менә хәзер бөтен эшемезне шулай карыйм» [3:22], – дип яза Г. Исхакый Ф. Әмирханга хатында. Ике зур публицистның әдәби мирасы искиткеч бай. Татарлар, милли тигезлек, иҗтимагый гаделлек һ.б. проблемалар Русия иҗтимагый-сәяси контекстында каралып, яктыртылып, аларга җәмәгатьнең игътибарын да юнәлтеп, әдипләр үз фикер-мөнәсәбәтләрен белдереп баралар, икесе дә каләмнәрен соңгы көннәренә кадәр кулларыннан төшермичә, халкы өчен, аның киләчәге өчен янып-көеп яшиләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. 3 т.: публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 512 б.

2. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.

3. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 479 б.

УДК 82.091

# ВОСПРИЯТИЕ Г. ИСХАКИ В ТУРЦИИ

***А.И. Кабирова***
*Университет изящных искусств им. Мимара Синана (Стамбул, Турция)*

Гаяз Исхаки – журналист, писатель и человек идеи, который был вынужден жить в разных странах. Последний период своей жизни в эмиграции (1940–1954) он провел в Турции. В работе сделана попытка определить, что значит личность и творчество Г. Исхаки в Турции. Для этого изучены научные работы и печатная продукция, посвященные его жизни и деятельности. А также дана информация о мероприятиях, которые были приурочены к 145-летию со дня его рождения.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Иделле, Турция, 145-летие.

M. Ayaz Ishaki is journalist, writer and idea man, which was forced to live in different countries. He spent the last period of life in exile (1940–1954) in Türkiye. The paper attempts to determine what the personality and work of G. Iskhaki means in Türkiye. For this, there were studied the scientific works and printed materials devoted to his life and works. Also, there were analyzed the events dedicated to the 145th anniversary of his birth.
**Keywords:** Ayaz Ishaki, Idilli, Türkiye, 145th anniversary.

# ТӨРКИЯДӘ Г. ИСХАКЫЙГА БИРЕЛГӘН ИГЪТИБАР

***А.И. Кәбирова***
*Мимар Синан исем. Нәфис сәнгать университеты (Истанбул, Төркия)*

Бүгенге көндә Төркия Җөмһүриятенең Фәнни эшләр мәркәзендә (YÖK: https://tez.yok.gov.tr) Гаяз Исхакый белән бәйле барлыгы җиде эш бар: дүрт эш тел һәм әдәбиятка кагылышлы бүлемнәргә карый (Төрек теле һәм әдәбияты – 2, Яңа төрек әдәбияты – 1, Заманча төрек телләре – 1), өч эш тарих бүлеменнән чыккан. Бу хезмәтләрнең якланган еллары һәм җитәкче белән авторлары түбәндәгечә:

1994: Prof. Dr. Nadir Devlet – Şule Güngör,
1999: Prof. Dr. Alemdar Mustafa Yalçın – Alsu Kamalieva,
2006: Doç. Dr. Mustafa Öner – Arife Gülsün,
2016: Yrd. Doç. Dr. Saime Selenga Gökgöz – Derya Hamiye Erbirsin,
2019: Doç. Dr. Ahmet Karaçavuş – Selda Şahin,
2020: Prof. Dr. Adnan Rüştü Karabeyoğlu – Murat Uzun,
2020: Prof. Dr. Varis Çakan – Mert Can Baba.

Güngör Ş. «Яңа милли юл» журналын тикшерә һәм М. Гаяз Исхаки-Иделленең сәяси карашларын анализлый. Kamalieva A. хезмәтендә Гаяз Исхакыйның пьесаларында социаль һәм сәяси темалар ачыклана. Ул аның турында шулай яза: «Г. Исхакый – әдәби тармакларның һәр өлкәсендә әсәр биргән шәхес. Ләкин ул үзенең көрәшче характеры аркасында сәнгать өчен сәнгать белән шөгыльләнә алмый. Сәнгатьне халыкны агарту, милли үзаңын үстерү, фикерләрен җиткерү өчен изге корал итеп күргән Исхакый – 1918 елга кадәр 29 әсәр биргән әдип. (...) Сәнгатьне корал буларак кулланса да, Гаяз Исхакыйның иҗат көче куәтле, һәм бу көчле сәнгатьче кемлегенең нәтиҗәләрен табу кыен түгел. Исхакыйның әсәрләрендә социаль темаларга зур әһәмият бирүе күренә» [5: аннотация, 6: VIII]. «Аның пьесаларында хатын-кыз алгы планда» [5: аннотация]. Чөнки ул, әнисе остазбикә булу сәбәпле, татар хатын-кызының барлык мәсьәләләрен күреп үсә [9: 19: 56–20: 33]. Шулай ук, әсәрләрендә мәгърифәт, гореф-гадәтләр, дин мөһим урын алып тора. Шул ук вакытта, ул каршы булган һәм мәгънәсез тапкан гореф-гадәтләр дә бар. Ул эчкерсез, мәгърифәтле яшәеш яклы һәм надан, фанатик дин кешеләреннән көлә [5: аннотация].

Гаяз Исхакыйның көндәлек журналистикасы белән сугарылган сәяси тормышы бар. Бу сәясәт белән үзара бәйлелек һәм аның көрәшче характеры пьесаларында сәяси интенсивлыкның төп сәбәбе дип санарга була [5: аннотация]. Г. Исхакый әсәрләренең нигезендә популизм һәм төрекчелек ята [8: 33: 38, 6: VIII]. Анталиядә Г. Исхакыйның тууына 145 ел туу уңаеннан үткәрелгән чарада «Төрекчеләр берләшә» хәрәкәте башлыгы Юҗел Өндәр (Yücel Önder) аның әсәрләре турында болай әйтә: «46 әсәрен

бу ике принципка *(популизм һәм төрекчелек принципларына)* нигезләнеп язган. Басылмаган ике әсәре бар... 12 газетасы бар. Барлыгы 60 әсәр. Әгәр 60 әсәр 100 әр бит дисәк, аркадашлар, 600 бит булыр. 200 әр бит булган очракта – 12 мең бит! Әсәрләре бик беленми яки аз тикшерелгән. 12 мең битне укырга бер гомер аз, аркадашлар. «Зөләйха»ны укыганда елый-елый укыйсың – китап бетми. Шундый әсәрләр турында сүз бара – беркем дә битараф кала алмый торган әсәрләр дип әйтәсем килә [8: 33:55–34.40].




Akış A. Aklımda Kalanlar (Ayaz İshaki, Zeki Velidi ve Mehmet Emin Resulzade ile ilgili Hatıralar). – Ankara: Neyir Matbaacılık, 2002. – 214 с.

Шул ук уңайдан Истанбулда оештырылган сөйләшүдә Мимар Синан исем. Нәфис сәнгать университетының тарих профессоры Исмаил Түркоглу (Prof. Dr. İsmail Türkoğlu) да: «Гаяз Исхаки Төркиядә бик беленми», – дип әйтә [9: 11:41–11:49]. Моны ул: «Чөнки көрәш елларының күп өлешен Европа, Ерак Көнчыгышта, Россиядә үткәргән», – дип аңлата [9: 11:49–11:56]. Ул – тормышының мөһим өлешен сөргеннәрдә, төрмәләрдә үткәргән кеше [9: 22:12–22:38]. Төркиягә дә килеп киткәли. Аның Sırat-ı Müstakim (1908) журналында Казанлы Аяз (Kazanlı Ayaz) исеме белән мәкаләләре бар [9: 26:23–26:35].

Г. Исхакыйны Икенче дөнья сугышыннан соң таный башлыйлар: кызы һәм кияве (Saadet Çağatay-İshaki һәм Tahir Çağatay) Әнкара университетында Социология бүлемен булдыруга, гомумән, Төркиянең фәнни тормышына зур өлеш керткәннәр [9: 12:03–12:56].




Çağatay T., Akış A., Çağatay-İshaki S., Agay H. Muhammed Ayaz İshaki Hayatı ve Faaliyeti. 100. Doğum Yılı Dolayısıyla. – Ayyıldız Matbası, 1979. – XXIV + 351 с.

Г. Исхакыйның кызы профессор-тюрколог Сәгадәт Чагатай туган ягы, этисе һәм тормыш иптәшенең дә исемнәреннән торган Идел-Урал Гаяз Таһир Төркстан фондын (İdil Ural Ayaz Tahir Türkistan Vakfı) оештыра. Соңгы ун ел эчендә фонд җитәкчесе Түлай Дуран Исхакыйларның шәхси әйберләрен, досьеларын һәм сирәк фотоларын Татарстанга кайтарды. Шулай ук Сәгадәт ханым мирасының бер өлешен профессор Надир Дәүләткә дә биргән булган. Ул үз чиратында профессор Исмаил Түркоглуна биреп калдырган [9: 38: 17–40:55].

Гаяз Исхакыйның Төркиядә иң билгеле әсәре – «Өйгә таба» (1922) романы. Бу роман, төрек теленә тәрҗемә ителеп, басып чыгару өчен 1927 елда Төрек учакларына бирелгән булса да, 1941 елда гына дөнья күрә [8: 1:00:44–1:01:40].




1941




1967




1998

Романның Төркиядә өч басмасы чыккан. Алар түбәндәгеләр:

1. İshaki M.A. Üyge Taba / Eve Doğru. – İstanbul: Sertel Matbaası, 1941. – 125 с.

2. İshaki M.A. Üyge Taba. – İstanbul: Ötüken Yayinevi, 1967. – 120 с.

3. İshaki M.A. Üyge Taba / Eve Doğru. – Ötüken Neşriyat, 1998.

Uzun M. үзенең фәнни хезмәтендә Гаяз Исхакыйны хәзерге татар әдәбиятына нигез салучы шәхесләрнең берсе буларак таныта һәм «Өйгә таба» романының тел һәм стиль үзенчәлекләрен тикшерә [10: XXI]. Gülsün A. язучының «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм «Зиндан» әсәрләренең, лексик үзенчәлекләрен ачыклап, төрек теленә тәрҗемә итә [3: аннотация].

Baba M.C. Россия мөселманнарының бәйсезлек өчен көрәш чорында Г. Исхакыйның эшчәнлеген [1: IV], Erbirsin D.H. аның «Милли юл» һәм «Яңа милли юл» журналларын [2: 2] өйрәнә.

Г. Исхакый турында соңгы ун ел эчендә дөнья күргән, тормышын һәм иҗатын яктырткан китаплар дип түбәндәге өч китапны әйтеп була:

1. Kamalieva A. Romantik Milliyetçi Ayaz İshakî. – Ankara: Grafiker Yayınları, 2009. – 248 с.

2. Zaripova-Çetin Ç., Yılmaz H. Ayaz İshaki: Hikayeler (Seçmeler). – Muğla Üniversitesi Yayınları, 2009. – 182 с.

3. Kanlıdere A. Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İsaki. – Ötüken Neşriyat, 2019. – 318 с.










Күргәнебезчә, Гаяз Исхакыйны танучыларның барысы да аны татар әдәбиятының иң мөһим язучыларыннан берсе дип атый. Хәтта проф. Исмаил Түркоглу: «Безнең өчен Мехмет Акиф (Mehmet Akif), Мехмет Әмин Юрдакул (Mehmet Emin Yurdakul), Хәлит Зия (Halit Ziya) нинди әһәмияткә ия исә, татар әдәбиятында да Гаяз Исхакый шундый», – дип әйтә [9: 13:35–13:49]. Быел тууына 145 ел туу уңаеннан Төрки дөнья тикшеренү фондында «Гаяз Исхакый – төреклекнең сүнмәс йолдызы» исемле конференция [7] һәм, алда әйтеп үткәнчә, Төрек учакларының ике филиалында сөйләшү булды [8, 9]. Төрки дөнья тарихы һәм мәдәнияте журналында (Türk Dünyası Tarih Kültür Dergisi) Г. Исхакыйга багышланган мәкалә чыкты.




Türk Dünyası Tarih Kültür Dergisi, Şubat 2023 – Sayı 433

ӘДӘБИЯТ

1. Baba M.C. Rusya Müslümanlarının bağımsızlık mücadelesinde Ayaz İshaki'nin faaliyetleri / Деятельность Гаяза Исхаки в движении российских мусульман за независимость: ВКР магистра. – Анкара, 2020. – 115 с.

2. Erbirsin D.H. İdil-Ural muhacir siyasî edebiyatında Yaŋa Millî Yul ve Ayaz İshakî'nin siyasî söylemi / «Яңа милли юл» в политической литературе иммигрантов из Волго-Уральского региона и политический дискурс Гаяза Исхаки: ВКР магистра. – Анкара, 2016. – 177 с.

3. Gülsün A. Ayaz İshaki'nin iki hikayesinde söz varlığı: İke Yöz Yıldan Son İnkraz ve Zindan / Лексические особенности произведений Гаяза Исхаки «Ике йөз елдан соң инкыйраз» и «Зиндан»: ВКР магистра. – Измир, 2006. – 1421 с.
4. Güngör Ş. Yana Milli Yul (Yeni Milli Yol) dergisi ve tatar aydınlarından M. Ayaz İshaki (İdilli)'nin siyasi görüşleri / Журнал «Яңа милли юл» и политические взгляды татарского интеллектуала М. Гаяза Исхаки-Иделле: ВКР магистра. – Стамбул, 1994. – 110 с.
5. Kamalieva A. Ayaz İshaki'nin piyeslerinde sosyal ve siyasi konular / Социально-политические темы в пьесах Гаяза Исхаки: дис. – Анкара, 1999. – 357 с.
6. Şahin S. Ayaz Ishakî hayatı ve fikirleri / Жизнь и идеи Гаяза Исхаки: ВКР магистра. – Трабзон, 2019. – 115 с.
7. TDAV (Фонд исследований тюркского мира). Türklüğün Sönmeyen Yıldızı Ayaz İshaki / Гаяз Исхаки – неугасающая звезда тюркости. [Электронный ресурс]. – URL: https://turan.org/turklugun-sonmeyen-yildizi-ayaz-ishaki-2/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 17.03.2023).
8. Türk Ocakları Antalya. Doğumunun 145. Yılında Tatar Ayaz İshaki / Төрек учаклары-Анталия. Туусына 145 нче елда татар Гаяз Исхакый. [Электронный ресурс]. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=7MYoGH6PLQY (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.03.2023).
9. Türk Ocakları İstanbul. Doğumunun 145. Yılında Ayaz İshaki / Төрек учаклары-Стамбул. Тууына 145 елда Гаяз Исхакый. [Электронный ресурс]. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=Y50i24nAEvU (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.03.2023).
10. Uzun M. Muhammed Ayaz İshakî'nin «Öyge Taba» adlı romanı üzerinde dil ve üslûp incelemesi / Языковой и стилистический анализ романа «Өйгә таба» Мухаммада Гаяза Исхаки: дис. – Коджаэли, 2020. – 837 с.

УДК 82.091

## ЭКЗИСТЕНЦИАЛЬНАЯ ИРОНИЯ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ИСХАКИ

***В.Ф. Макарова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматривается философско-эстетическая природа смеха в повести Г. Исхаки «Тормышмы бу?». Иллюзорность происходящего, игра в качестве модели абсурдного бытия выступают основой экзистенциальной иронии. Анализ произведения дает возможность проследить, как культура в начале XX века подверглась трансформации.
**Ключевые слова:** игра, экзистенциальный смех, метафизическая ирония, иллюзорность, самоирония, мениппея, пародия.

The article examines the philosophical and aesthetic nature of laughter in the story of G. Iskhaki «Tormyshmy bu?»The illusory nature of what is happening, the game as a model of absurd existence are the basis of existential irony. The analysis of the work makes it possible to trace how culture underwent transformation at the beginning of the twentieth century.
**Key words:** game, existential laughter, metaphysical irony, illusory, self-irony, menippea, parody.

## Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА ЭКЗИСТЕНЦИАЛЬ ИРОНИЯ

***В.Ф. Макарова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX гасыр башында кеше турындагы яңа күзаллаулар аның Аллага һәм дөньяга карашын үзгәртә, кеше яшәүнең чикле, үлемнең котылгысыз булуын аңлый. Хакыйкатькә төшенгән кешенең тормышы яңа дөньяда трагик-пессимистик тонда, экзистенциаль чикләрдә сурәтләнә башлый. «Уен» хаос һәм абсурдлыкка корылган көнкүрешнең, кешенең һәм мәдәниятнең асылын билгеләүче категория буларак чыгыш ясый. Кеше фаҗигасе язмыш көлүе фонында бара.

Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» (1909) [4] психологик повестенда шушы чордагы метафизик иронияның фәлсәфи-эстетик табигате яхшы чагыла.

Әсәрдә башта ислам фәннәрен үзләштергән, аннан рус, Европа мәдәнияте белән танышкан һәм үзен ислахчы булып халыкка хезмәткә багышлау турында хыялланган геройның табигый ихтыяҗларын өстен кую нәтиҗәсендә, тормыш ваклыклары белән мәшгуль уртакул авыл мулласы булып калуы сурәтләнә. Мәхдүмнең хыялый чынбарлыгы, рухи бушлыгы, мәгънәсез яшәеше автор кинаясенең нигезен тәшкил итә.

Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» повесте беренче затта шәкерт көндәлеге формасында язылган. Анда геройның тормышы, шәхес буларак формалашу процессы күрсәтелә. Менә ул – яшь чагында мулла улы, кызлар белән танышырга тәвәккәлли, әмма беренче адымны ясарга батырчылык итми. Егетнең психик халәте тасвирлана – ул кызга омтыла, сүз дәшәргә, кагылырга тели, үзен бу гамәлләрне башкарырга мәҗбүр итәргә тырыша, ә үзе аннан кача, моның өчен үзен сүгә, әмма шул ук вакытта үзенең тотышын акларга сәбәпләр эзли. Егетлеген югалткан очрактан соң да аның хисләре каршылыклы.

Яки башка эпизод: шәкерт каникул вакытында авылына кайта. Халык кырда эшли, ул гына – мулла улы, берни белән дә шөгыльләнми («Без инде өч көннән бирле иртәдән кичкә кадәр ашка йөримез (...) Бүген тагы сигез җиргә ашка барырга. Корсак кына чыдасын инде. Акчасы күпме булыр икән?» [4: 83–84]).

«Атналар буе бер нәрсәгә дә өйрәтми» торган мәдрәсәдә ел уздырып, «авылда көч җыярга» карар иткән герой үзен әрәмтамак ди, шул ук вакытта гамәлләрен акларга сәбәп эзли.

Геройның халыкны аңлы, белемле итәсе килү кебек югары максатлары вак теләкләре белән каршылыкка килүен тасвирлау аша Г. Исхакый яшь интеллигентның рухи драмасын күрсәтә. Геройның үз тормышын үзгәртәсе килә, тик аның ихтыяр көче дә, кадими мәдрәсәдә уку сәбәпле, белеме дә юк. Шунлыктан ул үзен ялгыз, бәхетсез хис итә («Шул авылларны, шуларның кешеләрен, Яхъя мулла пәриләре кебек, бер төн эчендә яңадан төзисем, яңадан ясыйсым килә. Ләкин кай төшеннән тотарга белмим». «Егерме өч яшенә кадәр салам селкетмәгән бер әрәмтамак булып бушка ашап ятудан башка ни эшли алам?» [4: 134]).

Көндәлек авторы үзирония куллана: ул рус, төрек, гарәп, татар телләрен бераз белә. Ул тарих, география, биология, педагогика, дин, Коръәнне аңлату, логика буенча «кайбер» мәгълүматларга ия («Мин хәзер аз гына русча, аз гына төрекчә, аз гына гарәпчә, фарсыча, аз гына үз телем татарча беләм (...) Минем фикерем дә мәгълүматым кеби. Анда да аз гына вөҗдан, аз гына шәфкать, аз гына эшкә мәхәббәт, аз гына халкыны сөю, аз гына үзен үзе сөю, аз гына тормыш сөю, аз гына ялкаулык, аз гына эш яратмау бар (...) Шулар белән тормышны мәгънәле үткәрергә кирәк, тормышның буш җирләрене тутырырга кирәк» [4: 131]. «Тагы иң авыр җире – һәр нәрсәне сөйләгән вакытта дин ноктаи нәзарыннан сөйләү (...) Ләкин русча укырга кирәк, хатыннарны качырмаска кирәк, динне дөньядан аерырга кирәк мәсьәләләрендә ничек итеп дин куша диерсең? Дөньядагы бөтен эшләрне, мәсьәләләрне ничек иттереп кагып-сугып дин эченә тутырырсың? (...) Шуның өстенә, мин тагы, дингә ул кадәр ышанмыйм да (...) шуның өчен мин мулла булмаска тиеш һәм булмыйм» [4: 125–126]).

Герой күңеленә курку һәм шик салына. Ул итекче дә, сәүдәгәр дә була алмый – куллары эшкә өйрәнмәгән. Ялганчы да буласы килми. Чарасызлыктан ул болай ди: «...миннән көлмәгез! Мин егълыйм, сез дә егълагыз! (...) Үзеңезне чолгаган дөньяңызның шул егетнең башы кеби идеке өчен егълаңыз!» [4: 133].

М. Рюмина фикеренчә, «ирония биеклек – түбәнлек, тирәнлек – өслек һ.б. каршылыклар булганда туа» [5: 279]. Ирония күтәрә һәм төшерә: эчке рухи көрәш вакытында хатын-кызларның һәм табигатьнең матурлыгы һәм бөеклеге геройда капма-каршы хисләр уята – соклану (бала имезүче анага карата), көчсезлек, ерткыч хисләр (фахишәгә карата). Аның хатын-кызлары я фәрештә, я шайтан белән бәйле. «Мин аларны хайван кеби уасым, изәсем килә», «...әллә нигә шул матурлыкны җимерәсе килә» [4: 128], – ди ул фахишәләр йортыннан чыкканда. Бу – аның әхлак кануннарына колларча буйсынасы килмәү инстинкты, протест белдерүе.

Шәкерт ошаган кызлар белән бер каршылыксыз танышкан һәм алар белән дус булган рус студентларыннан көнләшә. Дини күрсәтмәләргә буйсыну кирәклеге һәм аң төпкелендә яткан иреккә омтылышы геройның күңелендә эчке конфликт китереп чыгара. Вакыйгаларның иллюзор булуы, яшәешнең абсурдлыгы, психологик тотрыксызлык ироник көлке өчен нигез булдыра.

Геройның үз халкы турындагы идеяләре иллюзор. Ул, модалы пәлтә киеп, хушбуй сөртенгәч, европача алдынгы карашлы кешегә әйләндем дип уйлый. («Мин хәзер

фикерле шәкерт. Мин хәзер милләт кайгыртам, дин кайгыртам. Үземезнең татарларны шул романнарда укыган кеби итәргә тырышам (...) Мин романнарда киенгәнчә киенәм» [4: 119, 121]. «Безнең халык надан әле. Ул Альфредларны-ниләрне белми (...) Әлбәттә, ул хатыннар теге романнарны укыган булсалар, андагы Катрин кеби, безнең сүзгә катышып китәргә тиеш иде. Менә шунысы начар шул, алар берни укымаганнар» [4: 118, 119]). Герой халкын үзе укыган француз романнарындагы кебек итеп күрәсе килә, ләкин һәр адымында ярлылыкка, наданлыкка, соры төссезлеккә, аңсыз массага абына.

Мәхәббәт өлкәсендә дә аның иллюзияләре җимерелә («Әндәлес гарәпләренең мәдәниятене белгән бер егет берлә ник сөешмәскә? (...) Иртәдән кичкә кадәр бакчада йөрүдән арып беттем» [4: 118, 120]). Баксаң, тормыш герой көткән китаптагычадан нык аерыла икән.

Хикәяләүченең зур өметләр баглаган укуыннан да күңеле кайта. Мәдрәсәдә алынган белемнәрнең файдасыз булуына аерым ироник басым ясала. Дини китаплар, «мәгънәле итеп пошкырып куя гына белүче» кадими мулла ирония һәм пародия алымнары ярдәмендә тәнкыйть ителә. Шул рәвешле, иллюзия җимерелүгә ирония туа.

Финалда үз-үзеннән канәгатьсез герой, әтисенә буйсынып, авыл мулласына әверелә. Менә яшь хәзрәт үзен Дон Кихот итеп күрәсе килә, тик күрше Миңлесафа белән уйнаудан ерак китә алмый. Яшь мулланың хезмәтче хатын белән шаярулары, берничә йомырка, бер кочак утын, салам өчен ызгышып йөргән хатыннар эше буенча казый булуы турындагы эпизодлар геройның югары идеалларына параллель фарс күренешләре буларак кабул ителә.

Планнары җимерелеп, яшьлеге заяга узганга, идеаллары рәшә генә булып тормышка ашмый калганга герой үкенә, җаны бәргәләнә: «Уян, күңел, уян!»

Сюжет канвасына сәяхәт мотивы аша француз романнарына аллюзияләр, Европа тормышы образлары кертүдә карнавал көлүгә бәйле мениппея жанры традициясе күренә. Ул, Бахтин әйткәнчә, еш кына үз эченә сәяхәтләр яки төш формасында бирелгән социаль утопия элементларын ала («она часто включает в себя элементы социальной утопии, которые вводятся в форме сновидений или путешествий в разные страны» [1: 135]).

«Тормышмы бу?» әсәрендә мөселман Андалузиясе тасвирламасы утопия идеясен үзен пародияләүгә бәйле. Европа әдәбиятына гашыйк шәкерт мәдрәсәне һәм башка мәгърифәтле мөселман халыкларының тормышын контрастлар белән тасвирлаганда, ирония тагы да көчәя. Ул Испания гарәпләренең тормыш дәрәҗәсенә [4: 94–95], Европаның азат хатын-кызларына [4: 118] соклана. Андалузия аңа искиткеч бай, демократик, әкияти серле ил кебек тоела. Бу – социаль утопия, ирешеп булмый торган якты киләчәк (әсәрдәге «Нигә бездә барысы да алай түгел?» дигән риторик сорау Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902) дистопия повестендагы мотивлар белән дә аваздаш).

«Тормышмы бу?» әсәрендә табигый экстатик башлангычның акыл хисе культурасыннан өстенлек итүен күзәтергә мөмкин. Үз вакытында повесть матбугатта шул уңайдан дискуссияләр уята. Интим мөнәсәбәтләр һәм эпизодларның күплеге аркасында Г. Ибраһимов бу повестьны, Г. Исхакыйның кайбер башка әсәрләре белән беррәттән, «порнография» дип атый [3]. Ә күп кенә тәнкыйтьчеләр, М. Горький, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин повестька югары бәя бирә. И. Бикташев «Тормышмы бу?» әсәрен Купринның «Яма», М. Горькийның «Трое» әсәрләре белән бер рәткә куя [2].

XX гасыр башында кешенең чын табигате хакындагы Фрейд өйрәтмәләре сәнгатькә дә йогынты ясамый калмый. Кешенең беренчел дәрт-инстинкт буларак табигате дини традициядән мирас итеп алынган рухи башлангычта үскән культура белән каршылыкта иде. «Алла үлгәннән соң» һәм традицион кыйммәтләр җимерелгәннән соң, яшәеш моделе буларак беренче планга «уен» чыга: герой алдынгы карашлы Европа кешесе, киң карашлы шәкерт, яхшы ир, гадел мулла рольләрен башкара. Иллюзия җимерелгәч, эчтәлекнең формага туры килмәве нәтиҗәсендә яшь аралаш көлү барлыкка килә. Ул көлү драматизм белән сугарылган экзистенциаль ирония булып яңгырый.

Шул рәвешле, Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» повесте экзистенциаль ирония чагылышын гына түгел, XX гасыр башында мәдәниятнең яңарышын күзәтергә ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Бахтин М. Проблемы творчества Достоевского. 5-е изд. Киев, 1994. – 512 с.
2. Бикташев И. Тәнкыйть тирәсендә // Кояш. – 1915. – 13, 14 август.
3. Ибраһимов Г. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән // Тормыш. – 1915. – 26 февр.
4. Исхакый Г. Тормышмы бу? Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / Төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авторлары И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б. 78–146.
5. Рюмина М. Эстетика смеха: Смех как виртуальная реальность. – М.: КомКнига, 2006. – 320 с.

УДК 82.091

## ПЬЕСА Г. ИСХАКИ «ЗУЛЕЙХА» В ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКЕ

***Ф.Х. Миннуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассмотрены литературно-критические статьи и теоретические исследования, посвященные пьесе Г. Исхаки «Зулейха». На примере отдельных статей выявлены основные принципы и приемы анализа произведенияя. Раскрываются нравственные и философские поиски писателя.
**Ключевые слова:** критика, татарская драматургия, герой, трагедия.

The article considers literary-critical articles and theoretical studies devoted to the play by G. Iskhaki «Zuleikha». Using the example of individual articles, the basic principles and techniques of analyzing the work are revealed. Moral and philosophical searches of the writer are revealed.
**Key words:** criticism, Tatar drama, hero, tragedy.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬТӘ Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «ЗӨЛӘЙХА» ПЬЕСАСЫ

***Ф.Х. Миңнуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX йөз башы ил тарихында тирән тетрәнүләр, ачы югалтулар, милли үзаңның көчәюе белән сыйфатлана. Бу чорда әдәби әсәрләрнең үзәгендә шәхес язмышы, халык һәм милләт язмышы тора. Татар әдәбияты классигы, прозаик, драматург, публицист, сәясәтче Гаяз Исхакый – халкыбыз тормышында, мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган шәхес. XX гасыр башы татар тормышына гаять зур йогынты ясап, «яңа заман татар Ренессанс әдәбиятының нигез ташларын салучы» [6: 63] һәм халыкның милли азатлык көрәше лидерларыннан берсе. «Ул, халкыбызның киләчәге турында уйлап иҗат иткән әдип тә, милли азатлык хәрәкәтенә үзенең зур өлешен керткән көрәшче дә. Аның иҗаты һәм киң планлы эшчәнлеге иҗтимагый фикеребез тарихында мөһим роль уйнады. Халкыбызның мәнфәгатьләрен күз алдында тоткан хәлдә ул туктаусыз эзләнде һәм бу эзләнүләр аның фәлсәфи карашлары үсешендә үзләренең чагылышларын таптылар» [1: 371]. Ул милләтне инкыйраздан саклап калу максатында, игътибарын халыкның милли яшәешенә, гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, шул ук вакытта фаҗигале язмышына юнәлтә. Әйтергә кирәк, матур әдәбиятның проза, драматургия өлкәләрендә, шулай ук публицистика һәм әдәби тәнкыйтьтә танылган Г. Исхакый иҗаты, эшчәнлеге замандашлары Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Й. Акчура, Г. Кәрам һ.б. тарафыннан югары бәяләнә. Г. Сәгъди, мәсәлән, язучының иҗат юлын өч баскычка бүлеп карый: беренче баскыч – җәдитчелек, тәрәккыйче милләтчелек идеяләре белән сугарылган чор; икенчесе – «аз гына социализмга охшаш бер ис аңкый торган Гаяз»; өченчесе – милли яңгыраш алган «Мөгаллимә»ле, «Зөләйха»лы Гаяз» [13: 138] Р. Ганиева исә Г. Исхакый иҗатын, фәнни концепциягә салып, түбәндәге чорларга бүлә: 1) мәгърифәтчелек чоры (1897–1904); 2) «таң»чылык чоры (1905–1911); 3) милләтчелек чоры (1912–1918); мөһаҗирлек чоры (1919–1954) [6: 64].

Әдипнең бай һәм киңкырлы иҗатында драматургия аерым урын алып тора. Әдәби тәнкыйть тә Г. Исхакыйның сәхнә әсәрләрен зур игътибар белән күзәтеп, бәясен биреп бара. Язучының «Өч хатын берлә тормыш», «Алдым бирдем», «Кыямәт»,

«Җәмгыять», «Мөгаллим», «Зөләйха» һ.б. пьесаларына мөнәсәбәтле мәкаләләр күп языла. «Гаяз Исхакыйнын драматург буларак ижатын ике чорга бүлеп карау мәслихәт булыр. Беренче чор – 1906–1923 еллар. Татар театр сәнгатенең туу көннәреннән алып, Гаяз әфәнде эмиграциягә киткәч, анын әсәре буенча куелган иң соңгы спектакль уйналу еллары бу. Исхакыйның шул вакытта татар сәхнәсенә күтәрелгән иң соңгы әсәре – «Салих хаҗи балалары» («Юлсызлар») 1923 елның 9 ноябрендә уйнала. Икенче чор – Гаяз Исхакый мирасы халкыбызга кире кайту чоры. Театр сәнгатендә ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1992 елның 19 декабрендә «Зөләйха» трагедиясен сәхнәләштерү белән башланды» [2: 37]. Үз чоры татар җәмгыятенең төрле якларын ачу белән бергә, әдип халкыбызның фаҗигале үткәне, көчләп чукындыру вакыйгаларына мөрәҗәгать итә һәм татар драматургиясендә яңа бер юнәлешне башлый. Ул милли-дини рух белән сугарылып иҗат ителгән, колониаль изүне фаш иткән «Зөләйха» әсәрен яза. 1907 елда Чистай төрмәсендә язылa башлаган әсәр 1912 елда тәмамлана. Ш. Мөхәммәдьяров бу әсәрне язу идеясенең инде 1905 елларда тууын, башта «Мәкруһ» («Җәберләнгән») исеме астында язылган өлешенең язучыны эзәрлекләп йөргән жандармнар кулына эләгеп юкка чыгуын, Истанбулда аның кабат языла башлавын һәм Петербургта төгәлләнүен әйтә [10: 138]. Мәгълүм ки, татар халкының тормышы, тарихы фаҗигаләр белән тулы. 1552 елда Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы – шуларның берсе. Г. Исхакыйның мөселман халыкларын, беренче чиратта, татарларны көчләп чукындыру вакыйгалары тасвирланган «Зөләйха» (1912) – иң беренче татар трагедиясенең нигезендә нәкъ менә шул фаҗига ята. Пьесада Коръән тәгълиматы, дини мифологиядән алынган риваятьләр, пәйгамбәрләр тарихына караган мәгълүматлар, шартлы образлар мөселман һәм христиан динендәге кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре белән кушылып китә, катлаулы синтез тәшкил итә [12: 64]. «Зөләйха» пьесасы 1911–1912 елларда язылса да, патша цензурасы аны куярга рөхсәт бирми, ул Февраль инкыйлабыннан соң гына сәхнәгә менә. Трагедия беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан күренекле артист һәм режиссер Габдулла Кариев бенефисында 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. «Зөләйха» Бөтен Русия мөселманнарының Мәскәүдә уздырылган Беренче корылтае (1–14 май) делегатларына тәкъдим ителә. «Зөләйха» драмасын куйган вакытта татар театры тагын бер өр-яңа сурәтләү чарасы белән байый – композитор С. Габәши тарафыннан әсәр өчен махсус музыка языла. Туй һәм Зөләйханың үлеме, сәхнәләрендә яңгыраган милли музыка драманы тагын да тәэсирлерәк итә» [2: 43]. Спектакль куелу уңае белән матбугатта басылган рецензияләрдән аңлашылганча, «Зөләйха» фаҗигасе тамашачыларга көчле тәэсир ясый, киң җәмәгатьчелектә зур вакыйга буларак кабул ителә. Трагедия бигрәк тә татар зыялылары тарафыннан югары бәяләнә. Мәсәлән, Г. Кәрам «Габдулла Кариев бенефисы», «“Зөләйха”ның өченче мәртәбә уйналуы» язмаларында бу әсәрнең театр кануннарына таянып, белеп язылуы хакында әйтелә. Ф. Әмирхан пьесага бәя биреп, болай яза: «Зөләйха» иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте (изгелеге) юлында һичбертөрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә куәтле рухка ия шәхесләре барлыгын күрсәтә вә бөтенлегемезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер дәлилдер» [10: 288]. Рецензентларның берсе Шәһид Әхмәдиев: «Бу әсәрне сәхнәдә күрерлек хөррият дөньясына ирештек микәнни дигән сүз һәрбер кешенең күңеленә килерлектер», – ди [10: 296]. Мәкалә авторы пьесаның сюжетына тукталып, беренче, икенче, дүртенче пәрдәләрнең тарихи хакыйкатькә таянып, осталык белән язылуын ассызыклый, әмма өченче пәрдә алдагы күренешләрдә бирелгән реализмны киметә төшә дигән нәтиҗәгә килә. Автор драмага реалистик әсәрләргә куела торган таләпләрдән чыгып бәя бирә. Әсәрнең сәхнәгә менүен, татар халкы өчен искиткеч зур вакыйга булуын да билгеләп үтә. Г. Кариев «Зөләйха» белән 1918 елның җәендә Идел буе, Кавказ, Төркестанга гастрольләргә чыгарга планлаштыра. Ләкин ил күләмендә башланып киткән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Кариевның бу планы тормышка ашмый, «Зөләйха» русларга каршы юнәлдерелгән һәм ислам динен пропагандалаган пьеса дип репертуардан төшерелә. Матбугат битләрендә дә «Зөләйха»ның тыелуын күрсәткән мәгълүматлар, бәяләмәләр чагылыш

таба. Мәсәлән, «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 ел, 20 март санында түбәндәге хәбәр урнаштырыла: «Зур спектакль – концерт – кабаре кичәсе. Җомга көн, 24 мартта Казандагы бөтен татар артист, җырчы, музыкант, әдип, шагыйрьләре, бөтен сәхнә һәвәскәрләре, педагогия техникумы, партия мәктәбе, хәрби-сәяси курслар, команда курслары каршындагы сәхнә көчләре катнашы белән шәһәрдә салына торган татар театры файдасына тантаналы кичә ясалачак.

Программада:

1. Зөләйха. Г. Исхакый. Туй пәрдәсе.

2. Таһир-Зөһрә. Ф. Бурнаш. Гөлләр бакчасы пәрдәсе.

3. Концерт». 21 мартта исә «Зөләйха»ның программадан төшереп калдырылуы, аның урынына К. Рәхимнең «Бүз егет»е тәкъдим ителүе мәгълүм була [5: 6].

Г. Ибраһимовның аерым бер мәкаләләрендә дә «Зөләйха» пьесасының киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителмәве, читләштерелүе турында билгеләп үтелә. «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» (1923) язмасында, мәсәлән, иҗтимагый-сыйнфый гөрухларның «үз нокталарыннан хаклы уларак, дини, милли зәһәрләр белән сугарылган «Зөләйха»ларны сагыналар, әмма «дингә каршы, имеш» дигән хәбәр буенча, әдәби-шигъри кыйммәте бик югары әсәрләр театрда куелса да, китап булып чыкса да, бик оешып, бер кулдан, беравыздан бойкот ясыйлар», – дип язып чыга [9: 155]. «Пролетариат әдәбиты» (1924) язмасында яңа хөкүмәт тарафыннан тыелган әсәрнең эшче-крестьян массасының, яшь буынның сыйнфый аңнарын оештыра торган әсәрләр рәтенә кертелмиячәк дип билгеләнә. 1930 елда Казанда басылып чыккан «Татар дәүләт Академия театры» исемле китабында Зәки Мөхсинов «Зөләйха»ны Г. Исхакыйның иң кабахәт әсәрләреннән дип атый [5: 7].

Туган иленнән, җиреннән читтә, еракта (1919–1954) яшәргә мәҗбүр булган елларда да Г. Исхакый эшчәнлеген дәвам итә, татар халкының тарихы, иҗтимагый-сәяси фикере, әдәбияты турында фәнни хезмәтләр бирә, әдәби әсәрләр яза. Чит илләрдә «Зөләйха» пьесасы эмигрант татарлар оештырган үзешчән драма коллективлары тарафыннан Кытайда Харбин (1921), Япониядә Токио (1933), Финляндиядә Тампере (1937) шәһәрләрендә уйнала. Бу хакта мөһаҗирләр арасында таралган «Милли юл», «Яңа милли юл» исемле вакылы матбугат битләрендә урын алган мәкаләләрдә дә әйтелә, әдип иҗатына тәфсилле бәя дә бирелә. Мисал итеп, Мәхрүсә Вафаның «Гаяз Исхакый бәй Тамперда», Сания Гыйффәтнең «Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә кырык ел тулу мөнәсәбәте берлә» (1937) не китерергә мөмкин. «Muhammed Ayaz Ishaki» җыентыгында мөһаҗир татар журналисты Б. Мусабай (Әнвәр Галим) «Г. Исхакый әсәрләрендә кеше хокуклары мәсьәләләре» (1979) язмасында «Зөләйха» трагедиясенә тукталып, «Бу әсәрнең төп максаты һәр милләткә һәм һәр шәхескә үз динен тоту һәм аны саклау хокукы танылырга тиешлегеннән, аны бозарга һичберәүнең дә көче җитмәячәген күрсәтергә тырышудан гыйбарәт» [11: 278], – дип язып чыга. Шул рәвешле, туган илендә тыелган, онытылырга мәҗбүр ителгән Г. Исхакый эшчәнлеге, чит илдә яшүче замандашлары тарафыннан бәяләнә. Әйтелгәнчә, 1990 елларга кадәр Г. Исхакый шәхесе һәм аның иҗаты сәяси сәбәпләр белән халыктан читләштерелеп килде. XX гасыр ахырында ил тормышында башланып киткән үзгәрешләр чорында, әдипнең тоткынлыкта яткан зур иҗади мирасы халкыбызга кире кайтарыла башлады. Илдә сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләр башлангач кына, әдипнең мирасы туган илгә кайтарылды [7: 152]. Казанда, Уфада, туган авылында аның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлегенә багышланган фәнни-мәдәни чаралар уздырылды, төрле җыентыкларда, матбугат битләрендә мәкаләләр дөнья күрде. Татар сәхнәсенә иң беренче булып яңадан «Зөләйха» трагедиясе күтәрелде. Празат Исәнбәт Г. Камал исемендәге театр сәхнәсенә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» (1992), «Алдым-бирдем» (1994), «Җан Баевич» (1995) әсәрләрен сәхнәләштерде. Уфадагы «Нур» театрында Б. Ибраһимов белән Ф. Бикчәнтәев Г. Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясен һәм «Көз» повестен киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим иттеләр. Г. Арсланов П. Исәнбәт тарафыннан сәхнәләштерелгән «Зәләйха» әсәренә тукталып, спектакьлдә беренче планга җинаять һәм җәза проблемасы чыгуын билгели. Автор фикеренчә, тамашачы Зөләйханың соңгы газапларын, узган авыр юлын күрми, сабырлыгы өчен хак

Тәгалә тарафыннан ярлыкавын, изге җаннар рәтенә кертелүен, оҗмахка юл алуын да белми [2: 47].

Г. Исхакый пьесасындаә шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. А. Әхмәдуллин фикеренчә, татар сәхнә әдәбиятына Г. Исхакый алып килгән зур яңалыклардан берсе – «Зөләйха» әсәре, аның төп персонажы. Тарихи тематиканы яңа югарылыкта күтәргән, милли проблемасын яңа яссылыкта куйган пьеса. «Динебезгә тугрылык, милләт язмышын хәл итүдә исламның ролен раслап күрсәтү үзәк персонаж язмышын сурәтләү ярдәмендә эшләнә. Бу яктан Г. Исхакый беренче булды» [4: 32–33]. Автор әсәрнең жанрын драма дип билгели, ләкин биредә трагик хата булмаса да, пьесаның сюжеты, төзелеше, фаҗигалелекнең көчлелеге буенча, аны – трагедия дип әйтергә мөмкин. 1991 елда дөнья күргән «Зиндан» китабының кереш мәкаләсендә И. Нуруллин да пьесаның жанрын трагедия дип билгели. А. Әхмәдуллин да «Зөләйха» әсәре милли драматургиядә трагедия жанры формалашу юлында уңышлы тәҗрибә булды, дип яза [3: 41]. Трагедия жанрында иҗат ителгән әсәрләрнең үзәгендә трагик язмышлы герой була. Г. Исхакый Зөләйханы гаиләсеннән аерып, рус кешесенә кияүгә бирүне һәм көчләп чукындыруны милләт тормышында зур фаҗига дип бәяли. Төп геройның хәл итеп булмаслык каршылык эченә кереп, киеренке көрәш нәтиҗәсендә котылгысыз рәвештә һәлакәткә юлыгуы – әлеге жанрның иң мөһим үзенчәлеге. Зөләйха да, үзенең һәлакәткә баруын белгән хәлдә, үз идеяләренә гомеренең соңгы көненә кадәр тугры кала. Үз диненнән, теленнән язмый, трагедия ахырында, мөселман, татар булып, фани дөньядан китә. Әлеге әсәре белән Г. Исхакый, татар әдәбиятында беренче булып, үз милләтенә, үз диненә, үз кыйбла-мәсләгенә, үз гаиләсенә, әби-бабадан калган гореф-гадәтләренә, үзенең ана булу сыйфатларына тугры калган бөек татар хатын-кызы образын гәүдәләндерә [8: 63–64]. Ул трагик герой, көчле шәхес буларак ачыла, авырлыкларга баш имәү, горурлык, икенче яктан, каршылыкны җиңеп чыгарга көче җитмәү аны зур газаплануга һәм, үлемгә китерә, трагик герой итә. Рухи һәм физик изелү кичерүгә карамастан, Зөләйха динен, рухи ныклыгын саклап кала. Христиан динендә тәрбия алган Әхмәтне дә үз диненә кайтаруга ирешә. «Ислам диненең халыкны берләштерүдәге ролен күрсәтүне драматург башка диннәрне түбәнсетү исәбенә эшләми. Һәр халыкның үз диненә ышанычы көчле, аның моңа хакы бар, дип куя ул мәсьәләне». А. Әхмәдуллин сүзләре белән әйткәндә, пьесада: «Зөләйханың рухи бөеклеге динебезгә тугрылыкта сыналып күрсәтелә. Әдәбиятыбыздагы кабатланмас үзенчәлекле татар-хатын кызлары образлары галереясы тагын бер гүзәл образ белән баеды [4: 32, 41]. Югарыда каралган мәкаләләр арасында төрле характердагылар очрый: аларның күбесе хуплау, уңай мөнәсәбәт белдерү характерында язылганнар, тенденциоз рухтагылары да юк түгел. Мәклә авторлары Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасын күзәтү ясап, анализлап, татар драматургиясе яшәешенең бик күп якларына, аеруча аның сәнгати дәрәҗәсенә дә басым ясыйлар, чор әдәби процессын анализлаган җитди күзәтүләрен дә киң җәмәгатьчелеккә җиткерәләр. Әдип-драматургның пьесаның милли драматургиянең үсешен, яңалык алып килүен билгелиләр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. – Казан: Фән, 1999. – 317 б.

2. Арсланов Г. Г. Исхакый һәм татар театры // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы. Әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2000. – Б. 36 –50.

3. Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 239 б.

4. Әхмәдуллин Г. Г. Исхакый һәм мили сәхнә әдәбияты // Гаяз Исхакый иҗаты: Гаяз исхакый тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2008. – Б. 32–33.

5. Гайнанова Л. «Зөләйха фаҗигасе // Г. Исхакый. Зөләйха: пьеса. – Казан, 2019 – 101 б.

6. Ганиева Р. Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. – Казан унив-ты, 2002. – 272 с.

7. Гарипова Л. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Исхакый көндәлекләре // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки. – Казан, ИЯЛИ, 2018. – С. 151–154.

8. Закирҗанов Ә.М. Гаяз Исхакый һәм XX йөз башы татар драматургиясе // Фәнни Татарстан. – 2018. – № 2. – Б. 59–66.

9. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 15 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 8 т. – 431 б.
10. Исхакый Г.. Әсәрләр: 15 томда / төз. Ф. Ибраһимова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 8 т. – Б. 138–145.
11. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда / төз. Г. Ханнанова, Р. Кадыйров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 15 т. – Б. 117–120.
12. Мусин Ф. Гаяз Исхакый // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017 –4 т. – Б. 63–94.
13. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: Татарстан дәүләт нәшр. басмасы. – Казан, 1926. – 138 б.

УДК 82.091

# О ЛИТЕРАТУРНОМ НАСЛЕДИИ Г. ИСХАКИ В РУССКИХ ПЕРЕВОДАХ (1920–1930-е годы)

***Н.М. Мифтахутдинова***
*Национальный музей РТ (Казань)*

В этой статье раскрывается деятельность Г. Шарафа как одного из авторов книги «Сборник татарской литературы», опубликованной в 1931 году под редакцией П. Радимова. Автор предисловия – известный литературовед П.С. Коган. Этот сборник является хрестоматией к книге Дж. Валиди «Очерк истории образованности и литературы татар», изданной в 1923 году под грифом «Татарская литература в переводах на русский язык».
Отдельная глава сборника (1923 г.) посвящена творчеству писателя Г. Исхаки – представителя особого направления общественно-политической мысли среди татар. К сожалению, в хрестоматию 1931 г. не были включены переводы его рассказов, подготовленные Г. Шарафом. Структура и содержание сборника были подвергнуты резкой критике. Авторов обвиняли в увлечении представителями буржуазной литературы за исключением М. Гафури, Ш. Камал, Г. Ибрагимова.
В 1930-х годах политическое давление на литературу усилилось. В 1931 году был арестован Дж. Валиди, преследованию подвергся и Г. Шараф.
**Ключевые слова:** джадидизм, кадимизм, литературные переводы, просвещение, реализм.

This article reveals the activities of G. Sharaf as one of the authors of the book «The Collection of Tatar Literature (pre-revolutionary)», published in 1931 under the editorship of P. Radimov. The author of the preface is the famous literary critic S.P. Kogan. This collection is achrestomathy for the book by J. Validi «An essay on the history of education and the literature of Volga Tatars», published in 1923 under the heading «Tatar literature in translations into Russian».
A separate chapter of the collection is devoted to the work of the writer G.Iskhaki, a representative of a special direction of socio-political thought among the Tatars. Unfortunately, the translations of his stories prepared by G. Sharaf were not included here. The structure and content of the collection were sharply criticized. The authors were accused of being carried away by representatives of bourgeois literature, with the exception of M. Gafuri, Sh. Kamal, G. Ibragimov.
In the 1930s, political pressure on literature intensified. In 1931 J. Validi was arrested. G. Sharaf was also persecuted.
**Key words:** Jadidism, Kadimism, literary translations, enlightenment, realism.

# Г. ИСХАКЫЙ ӘДӘБИ МИРАСЫНЫҢ РУС ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ (1920–1930 еллар)

***Н.М. Мифтахетдинова***
*Татарстан Республикасы Милли музее (Казан)*

Илдә барган үзгәртеп кору елларында татар әдәбияты мәйданыннан бөтенләй төшеп калган һәм укучыга моңарчы таныш булмаган язучыларның исемнәре, әсәрләре кайтты. Бигрәк тә, татар җәмәгатьчелеге өчен зур ачыш –язучы, дәүләт эшлеклесе, сәясәтче Г. Исхакый шәхесе белән бәйле материаллар. Инде Г. Исхакыйның әсәрләре, аның иҗаты һәм тормышы турында материаллар тупланган 15 томлыгы да дөнья

күрде. Шулай ук фәнни әйләнештә эшчәнлеген һәм иҗатын чагылдырган күпсанлы хезмәтләр, монографияләр, мәкаләләр дә бар.

Билгеле булганча, Г. Исхакый Совет властен кабул итми һәм 1920 елда эзәрлекләүләрдән качып, чит илгә китәргә мәҗбүр була. Шушы шартларда совет чоры әдәбият белемендә Г. Исхакый иҗатын өйрәнү булганмы дигән сорау туа. Бу мәсьәләгә 1920–1930 елларда татар әдәбиятының рус телендә тәрҗемә үрнәкләре сериясеннән нәшер ителгән хезмәтләр беркадәр ачыклык кертә.

Татар әдәбияты әсәрләрен башка халык телләренә тәрҗемә ителү мөһимлеге турында Җ. Вәлиди 1913 елда ук күтәреп чыга. Шушы теманы яктырткан «Тәрҗемәләр» мәкаләсе «Вакыт» газетасының 5 май санында басыла [2: 240].

Бу мәкалә Петербургта чыга торган «Современник» журналының апрель номерында Г. Исхакыйның «Шәкерт абый» исемле хикәясе рус телендә басылу уңаеннан языла. Шулай ук Җ. Вәлиди мәкаләсендә «Современник» журнал идарәсенең Г. Исхакый иҗатына югары бәя бирелгән текстының татарча тәрҗемәсен цитата итеп китерә [2: 247]. Шунысы игътибарга лаек: революциягә кадәр татар әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре аерым журнал яисә җыентыкта бер-ике мисал итеп кенә бирелсә, революциядән соң аерым тәрҗемәләр китап булып нәшер ителә, бу өлкәдә җитди эшчәнлек алып барыла. Мәсәлән, Г. Тукайның «Узюлган умид» (1920) шигырьләр җыентыгы, «Коза и баран» (1921), «Шурәле» (1921) әкиятләр китаплары шундыйлардан.

1920–1930 елларда татар әдәбияты үрнәкләре һәм язучылары белән рус һәм башка халыкларны таныштыру юнәлеше киң җәелә. Бу тәрҗемә хезмәтләр татар һәм рус галимнәренең, язучыларның бердәм иҗат үрнәкләре булып тора. Милли халыкларның мәдәнияте, иҗтимагый тормышы белән таныштырып барылган рус телендә журнал һәм газеталар басыла.

Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф, П. Радимов һәм П. Коган тарафыннан дистә еллар бергә эшләү нәтиҗәсендә 1923 елда рус телендә Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» исемле китабы һәм әлеге китапка хрестоматия буларак, 1931 елда нәшер ителгән «Сборник татарской литературы» китабын күрсәтергә мөмкин.

Әлеге җыентыкларны эшләүдә Г. Шәрәфнең эшчәнлегенә аерым тукталасыбыз килә. Г. Шәрәф − күренекле тел белгече, профессор, тарихчы, этнограф, язучы. Аның Г. Тукай белән «Мәктәптә әдәбият дәресләре» китабына материаллар туплауда катнашуы да билгеле. Ул Петроградта укыганда ук рус шагыйрьләре әдәби түгәрәкләренә йөри. Шушы түгәрәктә үзенең беренче тәрҗемәләрен укый.

Г. Шәрәфнең автобиографиясендә мондый юллар бар: «В 1923 г. под редакцией и с комментариями моими и П. Радимова издана в Москве «История татарской образованности и литературы Дж. Валидова»; сданы в печать до 100 печатных листов переводов на русский язык избранных произведений татарских писателей и поэтов, произведённые также под редакцией моей и поэта П. Радимова, каковое издаются Центральным Госиздатом в Москве [10: 279]». Архив материалларында Г. Шәрәф барлыгы 300 битлек тәрҗемә эшләвен күрсәтә, әмма күбесе басылмый калды дип яза [11]. Шуңа да бирелдә язылган 100 басма бит бары аның басылган тәрҗемә текстлары турында сүз бара.

Шулай ук архивында үзе тарафыннан татар язучыларының рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләренең язу машинасында җыелган кульязмалары саклана: Ш. Камал «Давным давно», «На чужбине», Г. Камал «Ради подарка», Ф. Әмирханның «Девушка татарка», Г. Ибрагимовның «Дети природы», Г. Рәхим «От чего соловей стал серым» әкияте, К. Нәҗми шигырьләре.

Хөкүмәт тарафыннан да Г. Шәрәфнең әлеге эшчәнлеге югары бәяләнә. 1921 елда Татарстан Халык Мәгариф Комиссариатының фәнни бүлеге гыйльми хезмәтләрне бүләкләү турында карар кабул итә. Бүләкләнгән хезмәтләр арасында Г. Шәрәфнең «Татар әдәбиятының русча тәрҗемәдәге үрнәкләре» («Образцы татарской литературы в русских переводах» исемле хезмәте дә бар [1: 43]. Г. Шәрәфнең тәрҗемәләре 1931 елда нәшер ителгән «Сборник татарской литературы» дигән җыентыкта да урын ала.

Ж. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» хезмәте әле дә актуальлеген югалтмый. Совет идеологиясе төшереп калдырган әдәби үзенчәлекләр, язучы шәхесләре, иҗатлары белән дә танышырга мөмкинлек бирә. Биредә Ж. Вәлиди татар иҗтимагый фикеренең борынгы заманнардан алып 1917 елга кадәр үсешенең төп этапларына туктала, XIX–XX гасыр татар фәненең, мәдәниятының күп кенә вәкилләре эшчәнлегенә югары бәя бирә. Революциягә кадәрге әдәбият мәгърифәтчелек реализмы кысаларында үсешен күрсәтә, шулай ук татар җәмгыятендә күзәтелгән кадимчелек белән җәдитчелек үзенчәлекләрен дә укучыга җиткерә. Ж. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» китабына Г. Ибраһимов «Безнең байрак» газетасында тәнкыйть мәкаләсе белән чыга. Әлеге хезмәткә пролетар әдәбият күзлегеннән бәя бирә [4: 61]. Әдәбиятчы Т.Ш. Гыйләҗев 1922–1924 елларда Ж. Вәлиди пролетар идеология тарафдарларының революциягә кадәрге татар әдәбиятының буржуаз культура итеп карауга һәм әдәбиятның «пролетар», «буржуаз» бүленешенә курыкмыйча каршы чыгуын билгели [5: 208].

Ж. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» китабына кереш мәкаләне профессор, әдәбиятчы П.С. Коган яза. Аның имзасы куелган кулъязмасы Г. Шәраф архивында саклана [8: 14]. Әмма ни өчен басма китапта әлеге мәкаләнең булмавы ачык сорау булып кала.

1927 елда мәкалә С. Җәлал тәрҗемәсендә «Безнең юл» журналында басыла [8]. Шулай ук журнал редакциясе әлеге мәкаләнең язылу максатына да туктала: «Урыс укучыларын татар матур әдәбияты үсешенең төп моментлары һәм кайбер төп фикерләре белән таныштыру өчен татар әдәби әсәрләреннән 20–25 табаклар нәрсә русчага тәрҗемә ителеп, ике китап рәвешендә (берсе татар әдәбиятының революциягә чаклы булган чорына, икенчесе революциядән соңгы чорына карата мәйданга чыгарырга уйланган иде. «Безнең юл» укучылары алдына куелган түбәндәге мәкаләдә рус әдәбияты, сәнгать дөньясының иң атаклы тәнкыйтьчеләреннән П. Коганның әнә шул ике китапның беренчесенә аталып язылган сүз башыннан гыйбарәт» [8: 22].

Г. Шәрәф фондындагы П.С. Коганның кереш мәкаләсендә Г. Исхакый иҗатына югары бәя бирә. Ж. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» хезмәтендә күрсәтелгән «Кәҗүл читек», «Теләнче кыз» һ.б. әсәрләренә дә туктала.

Журналда С. Җәлал тәрҗемәсендә бирелгән шул ук П.С. Коганның «Татар әдәбияты турында» мәкаләсендә Г. Исхакый турында бөтенләй мәгълүмат юк. Г. Шәрәф архивында сакланган документлар арасында П. Радимовның Г. Шәрәфкә язган хаты бар. Хатта җыентыкны бастыру белән бәйле сораулар күтәрелә. Түбәндәге текст язылган:

«Дорогой Г. Шарафович!

Получил от брата письмо и рукопись. В Госиздате ждут очень наших переводов. Коган напишет предисловие тотчас-же. Как получу “Озтазбике”, он хочет прочитать этот рассказ. За Валидовым пойду сегодня ( корректура ждет меня, а в Казань по моему адресу они не сообразили прислать). Новые рассказы еще не сдавал в Госиздат, они через две недели получают деньги расплачиваются с кредиторами. О Тукаеве Коган напишет, а портреты Вы пришлите, на все это согласие получены.

Жду скорее переводов. Денег вышлю еще через неделю. Привет! П. Радимов. 15 ноября 1922 г.» [12].

Хатның икенче ягында:

«Если получу корректуру сегодня, сейчас иду в Госиздат, пришлю с братом. Или же пришлю с Мишей Коганом дня через три.

Эскизы памятника Тукаева у Сенникова-Спиранского

Художественная мастерская, д. 70, Грузинская улица» [12].

«За Валидовым» дигән сүзне «Очерки образованности и литературы татар» хезмәте турында дип аңларга кирәк. Хатта Г. Шәрәфнең әдәби әсәрләр тәрҗемәләренең авторы булуы турыдан-туры язылa.

1931 елда басылган «Сборник татарской литературы» хрестоматиясендә Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури, Дәрдмәнд, Бабич, Заһидә Гыйффәт, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Әхмәдиев, Г. Гобәйдуллин, Г. Рахим әсәрләренең тәрҗемәләре

бирелә. Заманның сәяси-иҗтимагый шартларына бәйле Г. Исхакый әсәрләре төшереп калдырыла.

Җыентыкта П. Радимовның китап төзүдә һәм тәрҗемәләрдә Г. Шәрәфкә рәхмәтен белдерелгән текст та урнаштырылган. Әлеге хезмәткә П.С. Коганның «Татар әдәбияты тарихы» мәкаләсе кертелә. Мәкалә 1927 елда «Безнең юл» журналында басылган текстны кабатлый. Шулай ук Г. Исхакый турында өлеше төшереп калдырылган.

«Сборник татарской литературы» китабы нәшер ителү белән «На литературном посту» журналында Г. Галиевнең тәнкыйть мәкаләсе басыла [4].

Г. Галиев «О сборнике татарской литературы» мәкаләсендә төп тәнкыйтен Г. Шәрәфкә юнәлтә. Әлеге җыентыкның асылда тәрҗемәчесе һәм төзүче буларак та Г. Шәрәф булуын билгели. П. Радимовның редактор итеп күрсәтелүен бары Г. Шәрәфнең «ширма артына яшеренгән буржуаз элемент буларак» җаваплылыктан качуы итеп күрсәтә. Гиз белән договорда Г. Шәрәфнең имзасы булуын да тәрҗемәче һәм редакторы булуына дәлил итеп китерә.

Автор Г. Шәрәфне турыдан-туры татар-пролетариат әдәбиятының дошманы һәм татар буржуазиясенең ялчысы итеп характерлый. Җ. Вәлиди исә татар буржуазиясенең идеологы, эчке буржуаз эмиграциянең бер вәкиле буларак бәяләнә. Билгеле булганча, Җамал Вәлиди җыентык басылган елны 1931 елның 8 маенда кулга алына.

П.С. Коганның кереш мәкаләсе Г. Шәрәф карашларының тәэсирендә язылган булуын ассызыклый. Җыентыкта революциягә кадәр булган чорда Бубый эшчәнлеген һәм Таңчыларны прогрессив күренеш буларак, ә пролетариат, сыйнфый көрәш тасвирланган әсәрләрнең күләгәдә калуларын да зур кимчелек буларак күрсәтә.

Г. Галиев әлеге җыентыкның 1923 елда Җамал Вәлидинең «Очерки образованности и литературы татар» китабының иллюстратив материалы, ягъни теоретик материалының әдәби әсәрләр белән тулыланышы булуын ассызыклый.

Әлеге җыентыкта Г. Исхакый әсәрләрен төшереп калдырылуын хезмәтнең уңай ягы буларак күрсәтә.

Хәзер исә тәнкыйтьче шул елларда эзәрлекләүгә дучар булган Г. Гобәйдуллин әсәрләренең җыентыкка кертелүен зур кимчелек итеп күрсәтә. 1937 елда исә Г. Шәрәф тә кулга алына.

Шул рәвешле, 1920 нче елларда әле Г. Исхакый әсәрләре җыентыкларга кертелә. Иҗаты югары бәяләнелә. Бу уңайдан П.С. Коганның да мәкаләсе дә игътибарга лаек.

Әйтергә кирәк, Җ. Вәлидинең хезмәте 1920 елларда да тәнкыйтьләнде, әмма 1930 еллардагы тәнкыйть әдәбият өлкәсеннән бигрәк, авторларны совет идеологиясенең шәхси дошманы буларак кабул итү, аларны юк итүгә корылган иде.

## ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917–1973). – Казан: Татар кит. нәшр., 1976. – 476 б.

2. Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917г.). – М.: Госиздат, 1923. – 106 с.

3. Вәлиди Җ. Тәрҗемәләр // Вәлиди Җәмал: әдәби һәм тарихи документаль җыентык / төз. Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – 624 б.

4. Галиев Г. О сборнике татарской литературы // На литературном посту. – 1931. – № 8. – С. 39–42.

5. Гилязов Т.Ш. Вклад Джамала Валиди в историю татарской литературной мысли // Филология и культура. – 2015. – № 4. – С. 206–210.

6. Ибраһимов Г. Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз! // Безнең байрак. – 1923. – 23 апрель, № 11.

7. Коган П.С. О татарской литературе. Предисловие к сборнику произведений татарских писателей // Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, Ф. 20, Оп. 3, Д. 15.

8. Коган П.С. Татар әдәбяты турында // Безнең юл. – 1927. – № 8, 9.

9. Сборник татарской литературы (Дореволюционный). – М.-Л.: ГИХЛ, 1931. – 160 с.

10. Шараф Г. Жизнеописание // Духовное наследие: поиски открытия. Г. Шараф. Сочинения, письма, документы. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 300 б.

11. Шәрәф Г. Үз гомеремдәге әһәмиятлерәк эшләрем // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Музыкаль һәм язма мирас үзәге, 20 ф, 2 тасв., 1 эш.

12. Шәрәфкә хат. Радимовның Г. Шәрәфкә язган хаты // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Музыкаль һәм язма мирас үзәге, 20 ф., 2 тасв., 25 эш.

УДК 821.512.145

# ЖАНР ЛИТЕРАТУРНОЙ СКАЗКИ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЯЗА ИСХАКИ

***А.Р. Мотигуллина***
*Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма (Казань)*

Данная статья посвящена изучению жанрового своеобразия литературной сказки «Лукман хаким» прозаика XX века Гаяза Исхаки. В основе синтеза фольклорной и авторской сказки автор раскрыл исторические события, связанные как с историческим прошлым исламских народов, но в то же время прогнозировал будущее татарского народа.
Также изучая особенности произведения, анализировали национально-религиозные мировоззрения автора, образную систему, попытались выяснить причины обращения писателя к данному жанру.
**Ключевые слова:** литературная сказка, фольклорная сказка, жанр, образ автора, система образов.

This article is devoted to the study of the genre originality of the literary fairy tale «Lukman hakim» by the twentieth-century prose writer Gayaz Iskhaki. Based on the synthesis of folklore and author's fairy tale, the author revealed historical events related both to the historical past of the Islamic peoples, but at the same time predicted the future of the Tatar people.
Also, studying the features of the work, they analyzed the author's national and religious worldviews, the figurative system, tried to find out the reasons for the writer's appeal to this genre.
**Key words:** literary tale, folklore tale, genre, author's image, system of images.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА ӘДӘБИ ӘКИЯТ ЖАНРЫ

***Ә.Р. Мотыйгуллина***
*Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм университеты (Казан)*

Танылган язучы Г. Исхакыйның иҗаты идея-тематик төрлелеге, эстетик кыйммәтләрнең ачылышы һәм жанр хасятләренең күпкырлылыгы белән аерылып тора. Жанрларны сайлау ягыннан әдип аларның киң панорамын бирә. Драма төрендә фаҗига, драмага мөрәҗәгать итсә, эпик әсәрләрендә роман, повесть, хикәя, әкият жанрларына нигезләнә. Әлеге мәкалә кысаларында язучының әдәби әкият жанрын бәяләргә омтылырбыз [6].

Әдәби әкият жанрынының нигезен халык авыз иҗатындагы халык әкиятләре тәшкил итә. Әкиятләрнең поэтик нигезе тора-бара әдәби әсәрләргә дә күчә. Татар әдәбият белемендә һәм фольлорда жанр хасиятләренең барлыкка килүенә тукталып, галиме Л.Х. Мөхәммәтҗанова түбәндәгечә раслый: «У восточных народов созидание и исполнение, подобно творческому процессу, было напрямую связано с личностью импровизатора-сказителя, который опирался на эпические традиции устного характера», – дип раслый [3: 247].

Әдәби әкият жанрына хас үзенчәлекләр рус әдәбиятын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләрендә (М.Н. Липовецкий, Л.В. Овчинникова) шактый тирән ачыла. Тикшеренүчеләр әлеге жанрның идея-эстетик ягын, тематик үзенчәлекләрен һәм аеруча поэтикасын ачуга тукталалар. Тикшеренүче И.В. Цикушева фикеренчә, автор әкиятенең үзенчәлеге түбәндәгечә ачыла: «Опираясь на древнейшие архетипы, авторская сказка ориентирована не только на жанры народной сказки, но и на ассимиляцию элементов предшествующей культурной традиции. В ней также используются идейные принципы и сюжетно-композиционные модели повести, философского романа, утопии, притчи, басни и других литературных жанров» [8].

Шул рәвешле, автор әкияте халык әкияте белән әдәби жанрларның синтезын тәшкил итеп, әкият-новелла, әкият-поэма, әкият-повесть, әкият-притча, әкият-пьеса, әкият-пародия, фәнни-фантастик әкиятләр, абсурда әкияте рәвешендә калыплаша [9]. Шуңа күрә автор әкияте, ягъни әдәби әкият халык әкияте поэтикасына нигезләнеп, әдәби әсәр язу алымнарына һәм үзенчәлекләренә таянып, аерым авторлар тарафыннан үзгәртелеп, әдипнең идея-эстетик позициясе яктылыгында иҗат ителә. Әлеге фикерне шагыйрь Р. Миңнуллин иҗатында «кечкенәкият» жанры турында язылган мәкаләдә дә

ачык күрәбез: «Существует такая разновидность стихотворной сказки, как повесть-сказка. По своим жанровым характеристикам повесть-сказка использует гораздо больший набор средств характеристики героев, чем народная сказка. Внимание автора и читателя в большей степени сосредоточено на событиях, а не на характерах, поэтому повесть-сказка насыщена приключениями, которые происходят с героями» [7: 235].

Прозик Салават Юзеевның «Казанские сказки» җыентыгындагы әсәрләр циклына бәя бирүче Д.Ю. Сырысева, татар тормышын рус телендә тасвирлаган заманча әдәби экиятләрнең үзенчәлегенә тукталып, «продолжают традиции авторской литературной сказки, которая образно, сюжетно и стилистически связана с фольклорной, но модернизирует ее», – дип яза [5: 73].

Г. Исхакыйның иҗатында әкият башка жанрлар белән чагыштырганда, бик аз урын алып тора. Аның 1923–1924 елларда «Локман хәким әкияте» языла. Ул «Идел» журналында галим-тикшеренүче И. Нуруллинның сүз башы белән басылып чыга. Галим әсәрнең жанр хасиятен билгеләргә омтылып, «жанры ягыннан бу хыялый хикәя. Егерменче елларда Европада һәм бездә активлашып китеп, «антиутопия» дип йөртелә торган әсәр җөмләсенә керсә кирәк», – дип белдерә [1]. Шунда ук әсәрне өйрәнәсе барлыгы ассызыклап узыла.

Әдип әсәрнең жанрын әкият дип билгеләп, безне фантастик дөньяга алып кереп китә сыман. Чынлыкта исә, 1920 елларда язылган әсәрнең нигезенә реалистик вакыйгалар салына. Алар, барыннан да бигрәк, ислам дине тарихында XI гасырда булган вакыйгаларны хәтерләтә. Аерым алганда, ислам динендә друз сектасы белән бәйле хәлләргә барып тоташа. Аның башында Мисыр хәлифе Хәким (996–1021) һәм аның фикердәше Дарази тора.

Тарихи чыганакларга караганда, Хәким хәлфә бик сәер һәм серле кеше була. Хәтта аның турында психик яктан сәламәт булмаган дигән фикерләр дә йөри. Ул үзенең көчле идарәче икәнлеген дәлилләп, берсеннән-берсе мәгънәсез боекрыклар чыгара һәм аларны даими алмаштырып тора. Идарәче фикеренчә әлеге фәрманнар каирлыларның шәхси һәм иҗтимагый тормышын көйгә салырга тиеш була. Хәлиф чыгарган шундый боерыклар арасында сәүдә эшен төнлә генә алып барырга, хатын-кызларга аяк киемнәрен текмәскә кебекләре дә була. Әмма әлеге боерыклар бер-берсенә каршы килеп, берсе икенчесен юкка чыгарып бара. Ул еш кына үз тирә-юнендәге кешеләрне бер сәбәпсез җәзага тарткан, соңыннан шуларны мул итеп бүләкләгән.Ул идарә иткән вакытта 18 мең кеше үтерелә. Хәким хәлфәнең дини карашлары да тотрыклы булмый. Ислам диненең ике юнәлеше булган сөнниләр һәм ширгыйлар төркеменә керүен үзгәртеп тора. Гомеренең соңгы көннәрендә ул үзен җиденче имам дип игълан итә (натик дип атый).

Тотрыксыз карашларга ия булган Хәким хәлфә ялгыз булмый. Аның карашларын уртаклашучы Каирдагы төрек исламчысы Дарази була. 1017 нче елда Дарази зур мәчеттә халыкка сөйләгән вәгазе вакытында Хәким хәлифкә Адәм җаны кереп урнашкан дип белдерә. Шул юл белән ул мәчеткә җыелган халыкны үз кулына алырга омтыла. Ләкин гыйбадәт кылучылар аның хакыйкатен аңлау дәрәҗәсендә булмыйлар. Шуңа күрә негрлар, берберләр, төрекләр баш күтәрәләр, Дарази котырынган халык көтүеннән качып котыла. Аңа Хәким хәлиф ярдәме белән Сүриягә качып китү мөмкинлеге туа. Ул үз идеяләрен соңыннан Ливан таулылары арасында тарата.

Хәким хәлфә белән тагын бер хәл була. Ул үзенең ишәгенә атланып кичләрен һава суларга чыга. Көннәрдән бер көнне даладан аның киемнәрен генә табып алалар. Бу исә халык арасында Хәким хәлфәнең «яшеренгән имамга» әверелүе турында хәбәр таратуга сәбәп була. Халык арасында аның әйләнеп кайтып, ил белән идарә итәчәк дигән коткы тараталар. Хәким хәлфә культы Мисырда таралмаса да, Сириядә һәм кайбер башка төбәкләрдә киң тарала, халыкны дулкынланырга мәҗбүр итеп тора [10].

Ислам тарихындагы әлеге вакыйгалардан хәбәрдар булган Г. Исхакый әсәренең нигезен үзгәртеп, автор күзаллавына таянып, әдәби әкият дип аталырга хаклы хыялый әсәр иҗат итә. Ул гыйбрәтле хикәя язып, халык язмышының үткәне, киләчәге турында уйларын, теләк-омтылышларын ачарга омтыла. Шунда ук үзенең ил белән идарә итү, акыл иясе һәм халык, илбашы һәм халык турындагы карашларын әдәбиләштереп тәкъдим итеп, грек фәлсәфәчесе Гераклит фикерләрен дәвам иттерә.

Әдәби әкиятне үзенә килсәк, аны төзелеше ягыннан өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин: 1) халыкның рәхәт тормышта яшәве («Әйе, бәхетле яшәгән бу халык: тормышыннан канәгать, күңеле күтәренке булган. ... Ашаганы-эчкәне бал да май икән. Анда балалар ата-ана сүзеннән чыкмаган, хатын ирен тыңлаган, ир хатынына кул күтәрмәгән...»); 2) бәйрәм көннәре үткәннән соң михнәтле көннәр җиткән («Көннәрдән бер көнне кояш баеганнан соң ай калыкмаган, көчле җил чыгып, давыл купкан, күк күкрәп яшен яшьнәргә тотынган. Аннан соңра бөтен җир йөзен каплап яңгыр ява башлаган»); 3) халыкның уянуы («Көне килгәч, бөтен халык берьюлы уянып киткән. ... Һәм шундый күренешкә тап булып хәйран калган: шәһәр таланган, кая карама ачлык-ялангачлык, юллар эштән чыккан, күперләр ишелгән, арыклар кипкән, бакчалар басуга, басулар болынга әверелгән»). Әлеге вакыйгаларның беренче һәм өченчесендә хәким халык белән бергә, икенче вакыйганы ул бары тик күзәтүче генә. Беренче өлештә үк бәла киләсен белгән Локман хәким, патшаны кисәтеп куя: «Ходай Тәгалә хәзрәтләре безнең җиребезгә бик көчле яңгыр җибәрер. Яңгыр сулары дәрьяларны, диңгезләрне, елгаларны-күлләрне басып китәр. Әлеге суларны эчкән һәрбер адәм акылдан язып, исәп-хисапны бутый башлар, хак юлдан язар, турыны кыектан, акны карадан, хәләлне хәрамнан, дусны дошманнан аера алмас хәлгә килер» [1: 4].

Локман Хәким тарафыннан әйтелгән сүзләрнең хаклыгын раслап, «көннәрдән бер көнне кояш баеганнан соң, күктә ай калыкмаган, көчле җил чыгып, давыл купкан, күк күкрәп, яшенле яңгыр ява башлаган. Болыннар, кырлар көн-төн яуган яңгыр сулары астында калып, зур-зур күлләр хасыйл булган, кечкенә инешләр киң елгаларга әверелгән» [1: 4].

Г. Исхакыйның әсәрендә табигать һәм кеше, табигать һәм җәмгыять кебек якларга игътибар ителә. Һәрдаим идиллия арасында яшәгән кешеләр яуган яңгыр суын эчү нәтиҗәсендә үзгәрәләр: «гүяки җир йөзендә инде кайгы-хәсрәт тә, дошманлык та, бай белән ярлы, чибәр белән ямьсез, кыю белән куркак арасындагы аермалар мәңгегә беткән диярсең...» Шул хәлләрдән соң Локман хәким кисәтүләре күзәтелә. Барлык тереклек куркыныч астында кала. Яңгыр суы эчкән халык бертөрлегә әверелә. Барысы да күңел ача, акны-карадан аермый. Әмма идарәчеләрнең (вәзирнең һәм патшаның) алардан аерылып торганын күрәләр. Шуңа күрә аларны яңгыр суын эчәргә мәҗбүр итәләр.

Әкият жанры хасиятләре нигезендә патшаның акылдан язуы яңгыр суы эчеп үзгәргән халык белән идарә итү ысулларын да үзгәртә. Җәмгыятьтәге кануннар үзгәрү нәтиҗәсендә «тиз арада сүзләрнең мәгънәсен алыштыралар: инде акыллы урынына шыр тиле, галим урынына надан сөйли, закон урынына законсызлык хөкем сөрә, тынлык белән тәртипне шау-шу, ыгы-зыгы алыштыра» [1: 5].

Халык тормышы тамырдан үзгәреш кичерә: әсәр башында сурәтләнгән ачык төсләр капма-каршыга үзгәрә: «халык өстендә сәләмә кием-салым, барысы да ябык, үзләрен бет баскан, мәчет манаралары ауган, мәдрәсә түбәсе җимерелгән, мунчаның фонтаны эшләми, туктаган... барысы да нидер эзли, як-ягына карана, гүя ки бик кадерле нәрсәләре югалган диярсең» [1: 5]. Кешеләр арасында булган җитешсезлек аларны чолгап алган тирә-юньдә дә күзәтелә: «шәһәрләр таланган, кая карама ачлык, ялангачлык, юллар эштән чыккан, күперләр ишелгән, арыклар кипкән, бакчалар басуга, басулар болынга әверелгән» [1: 4].

Әгәр Локман хәким булмаса, бу хәлләрнең, үзгәрешләрнең берсен дә күз алдына да китерә алмаслар иде. Әлеге вакыйгалар башланыр алдыннан ул тау куышына кереп, барлык күргәннәрен бәяләп, теркәп бара. Шуңа күрә әдип тарафыннан ул бары тик акыл иясе, вакыйгаларны күзәтүче, идарәчеләргә киңәш бирүче гомумиләштерүче образ буларак кына тасвирлана.

Г. Исхакыйның «Локман хәким әкияте» – эпик киңлеккә ия әсәр. Әдип кыска гына әсәр эченә бөтен бер дәүләтнең язмышын сыйдырган. Анда сурәтләгән дәүләт дүрт фиркагә бүленгән: «Аңгыралар, ахмаклар, акылдан язганнар һәм камил акыллылар партиясе барлыкка килгән». Әлеге партияләр эчендә власть өчен көрәш тә барган. Илдәге тәртип беткән. Ил халкы шулай фиркаләргә бүленеп беткәч, камил акыллылар үзләрен аңгыра дип күрсәтергә тырышкан, аңгыралар ахмак булып кыланган, ахмаклар акылдан язганнар урынына омтылган һәм шул сәбәпле бар халык хәйләгә керешкән:

тилебәрән орлыгы ашаган, бәкләр, аксөякләр әфьюн белән гашиш кулланган, сәүдәгәр халкы эчәргә сабышкан». Илдә тәртип урнаштыру максаты белән җитмеш җиде мең акыллының башы киселгән, бераздан җитмеш җиде мең аңгыра утта яндырылган, чит мәмләкәттән җитмеш җиде мең акылсызны кайтарып караганнар. Шулай да халык арасында үзара ышаныч беткән, дошманлык арткан. Соңгы исәптә «ил тәмам кыргаксыган, бөлгенлеккә төшкән. Халык арасында кабат ызгыш, суеш башланган» [1: 6].

Шул рәвешле, Г. Исхакый әдәби әкият жанрында тылсым һәм чынбарлык элементларыннан оста файдаланып, халык һәм илбашы мөнәсәбәтләрен бәяләп, дәүләт белән идарә итүдә гаделлек хөкем сөрергә тиешлеген ассызыклый. Шул ук вакытта үткәннән алган сабакларга нигезләнеп, татар халкының киләчәге турындагы фаразларын да белдерә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Исхакый Г. Локман Хәким әкияте. (И. Нуруллинның кереш сүзе белән) // Идел. – 1990. – № 6. – Б. 4–6.
2. Липовецкий М.Н. Поэтика литературной сказки (на материале русской литературы 1920–1980-х годов). – Свердловск: Изд-во Урал. ун-та, 1992. – 184 с.
3. Мухаметзянова Л.Х. Книжный дастан в творчестве казанских татар // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. – 2011. – № 4 (26). – С. 247–249.
4. Овчинникова Л.В. Русская литературная сказка XX века. История, классификация, поэтика. – М., 2003. – 312 с.
5. Сырысева Д.Ю. «Казанские сказки» Салавата Юзеева в контексте литературно-сказочной традиции // Вестник Бурятского государственного университета. Филология. – 2021. Вып. 1. – С. 70–74.
6. Хабутдинова М.М,, Мотигуллина А.Р., Замалиева Л.Ф. Наследие Г. Исхаки в репертуаре современного татарского театра // Филология и культура. – 2018. – № 4 (54). – С. 243–250.
7. Хасанова Ф.Ф., Насибуллина Н.Ш. Жанровые особенности и поэтика произведений «кечкенэкият» Р. Миннуллина // Филология и культура. – 2013. – №4 (34). – С. 234–238.
8. Цикушева И.В. Жанровые особенности литературной сказки (на материале русской и английской литературы) // Вестник Адыгейского государственного университета. – 2008. – Вып. 1 (29) // https://cyberleninka.ru/article/n/zhanrovye-osobennosti-literaturnoy-skazki-na-materiale-russkoy-i-angliyskoy-literatury
9. https://ru.wikipedia.org/wiki/
10. https://ru.wikipedia.org/wiki


УДК 821.512.145

## РЕЗЕДА ГАНИЕВА О ТВОРЧЕСТВЕ ГАЯЗА ИСХАКИ

***З.З. Рамеев***
*(Казань)*

В статье освещается вклад татарского ученого Резеды Кадыровны Ганиевой в изучение творчества Гаяза Исхаки.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхакый, Резеда Кадыровна Ганиева, татарское литературоведение, татарская литература.

The article highlights the contribution of the Tatar scientist Rezeda Kadyrovna Ganieva to the study of the work of Gayaz Iskhaki.
**Key words:** Gayaz Iskhaky, Rezeda Kadyrovna Ganieva, Tatar literary studies, Tatar literature.

## ИСХАКЫЙ ИҖАТЫ ТУРЫНДА РЕЗЕДА ГАНИЕВА

***З.З. Рәмиев***
*(Казан)*

Чыгышымның шулай исемләнгәнен күрү белән, хөрмәтле укучылар күңелендә табигый рәвештә бер сорау туарга мөмкин: бәяләнәме соң бу олы мирас танылган әдәбиятчы галимәнең гыйльми эшчәнлегендә? Моңа җавап бирү өчен, минем уемча, әүвәлән библиографик белешмәләргә мөрәҗәгать итәргә кирәктер. Шулай дигәч тә, атаклы әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга баглы халыкара фәнни-гамәли конференциядәге «Текстологические вопросы изучения творчества Гаяза Исхакый» исемле чыгышымда мин: «На сегодня нет изданной полной на-

учной библиографии писателя», – дип сөйләгәнем [1: 49] исемә төште. Күрәм ки, мондый бик кирәк хезмәт, ниһаять, дөнья күргән: ул – «Шәхесләребез» сериясендә чыккан «Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык»ка (төзүче-авторлары – Сөләйман Рәхимов, Зөфәр Мөхәммәтшин, Айрат Заһидуллин. Казан: Җыен, 2011) урнаштырылган әдипнең «шәхесе һәм иҗаты турында тулылыккка дәгъва кылган библиография» [2: 738–915] (төзүчесе – Айрат Заһидуллин). Ул 2009 елга кадәрге материалларны эченә алган. Әлеге библиографиядә, табигый ки, әдипнең иҗади эшчәнлеге турында сүз алып барган хезмәтләргә библиографик тасвирлар да урын бирелгән. Шунысы да бик мөһим: аларда 1980 елларның икенче яртысында дистәләрчә татар әдәбиятчыларының әдипне халкыбызга кайтару юлында максатчан эш алып барганнары күренә. Моның кыскача тарихын К.М. Миңнуллин моннан биш ел элек узган халыкара конференциядә сөйләгән иде [4: 4–10]. Мине хәзер исә, шәхсән, филология фәннәре докторы, профессор Резеда Ганиеваның ул заманнарда бу эшкә катнашлыгы мәсьәләсе кызыксындырды. Шуңа күрә дә беренче эш итеп А. Заһидуллин төзегән «Библиография»не карап чыгарга булдым. Һәм мин галимәнең 25ләп фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләсенә язылган библиографик тасвир белән «очраштым». Моннан ике-өч ел элек фәкыйрегез «Профессор Резеда Ганиева» исемле китап (җыентык) төзеп бастырган иде (редакторы – И.Р. Рәмиева; бәяләүчеләре – Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов; Казан: ФӘН, 2020. 380 б.). Мин анда галимәнең 55 ел дәвамында басылып килгән хезмәтләренең (китап-монографияләре, мәкаләләре, фәнни докладлары) библиографик тасвирларын урнаштырдым. Шөкер, аларның Г. Исхакыйга нисбәтлеләре (бөтенесе дә диярлек) А. Заһидуллин төзегән «Библиография»дә урын алган икән (аерма дүрт-биш публикациягә генә карый). Г. Исхакыйның 145 еллыгы билгеләп үтелгән вакытка туры килгән бу язманың форматы бүген аларның һәрберсе эченә кереп җентекле фикер әйтергә мөмкинлек бирми, билгеле. Бары тик бер-ике сүз белән генә Резеда Ганиеваның да әдип иҗатына хаслы үз фикере булганлыгын искәртмәкчемен.

Г. Исхакыйны халкыбызга кайтару юлында Татарстаныбызда тәүге адымнар 1988–1989 елларда ясалганы хәтердә. Яңарак кына «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» исемле монографиясен бастырган Р. Ганиева да шул вакытларда ук әдипнең кыйммәтле мирасы турындагы фикерләре белән уртаклаша башлаган иде: 1989 елның 5 маенда «Вечерняя Казань» газетасында «Как долго пугали нас этим именем» мәкаләсен бастырды (аңа кадәр февраль аенда Ф. Бәширов диссертациясе авторефератында Гаяз Исхакыйның сәнгати (художестволы) тәҗрибәсе турында сүз бармауны кимчелек итеп күрсәткән иде) [6: 28]. Ярты ел гына элек шул ук газетада Ибраһим Нуруллинның да «Возвращение Гаяза Исхаки» дигән язмасы чыкканын беләм. Бу урында әле совет идеологиясе хакимлек итүен, З. Нургалин, М. Абдуллин, Ү. Билялов, К. Фәсиевләрнең әдипне кайтаруга ачыктан-ачык каршы торып чыгыш ясауларын да онытмаска тиешбез.

Бу еллардан башлап Резеда Ганиева авторлыгында дөнья күргән төрле характердагы публикацияләрдә, фәнни докладларында, беренче чиратта, әдип иҗатының асыл хасиятьләрен ачарга омтылыш өстенлек итә. Бу як аның «Гаяз Исхакый: югары уку йортларының татар филологиясе студентлары өчен махсус курс программасы»нда (Мирас. 1998. № 5) тулырак чагылыш тапты шикелле. Анда һәм дә «Исхакый идеаллары» мәкаләсендә әдип иҗаты шартлы рәвештә дүрт чорга бүлеп өйрәнелү тәкъдим ителде: мәгърифәтчелек (1897–1904), таңчылык (1905–1911), милләтчелек (1912–1918), мөһаҗирлек (1919–1954). Бу программа 1998 елның 5 февралендә татар әдәбияты кафедрасы утырышында расланган (фәнни редакторы – А. Әхмәдуллин). Дания Заһидуллина фикеренчә, ошбу программа «инкыйлабтан соң өзелеп калган гыйльми бәяне бүгенге көн белән ялгаучы, әдипнең исеме әйтелә генә башланган бер чорда Исхакыйның милли-азатлык хәрәкәте вәкиле буларак дөньяга карашларын һәм иҗат баскычларын бер бөтен итеп өйрәнүгә юл күрсәткән беренче хезмәтләрдән булды» [5: 160].

1992 елда якланган «Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах» исемле докторлык диссертациясендә галимәбез, гыйшык-мәхәббәт хискичерешләрен ренессанс-неоплатоник рухта шәрехләгәндә, татар һәм һәм төрки әдәбияты әсәрләренә таянып яза, аерым алганда, Галимҗан Ибраһимовның «Яшь

йөрәкләре», Габделгазиз Монасыйбның «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романнары белән янәшәдә, Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә» романтик пьесасын, «Теләнче кыз» романын, «Зөләйха» трагедиясен дә шактый җентекләп тикшерә. Аның фикеренчә, «Мөгаллимә»дә мәхәббәт ренессанс кануннары буенча сурәтләнә, платоник мәхәббәт Фатыйманың йөрәген көйдерә. Р. Ганиева реалистик «Теләнче» романында романтик сурәтлелек чагылышын күрсә, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына хас сәнгати алымнар яклы булуын Г. Исхакыйның үзе үк күрсәтүенә дә игътибар итә. Галимә, «Зөләйха» трагедиясендә ренессанс романтизмы һәм неоплатоник эстетика алымнары турында сүз йөрткәндә, әсәрдә азат шәхес, милли тигезлек, гадел җәмгыять турында романтик хыял гәүдәләнүен искәртә. Ул Г. Исхакый әсәрләренең текстологиясенә караган мәсьәләләргә дә үзенең мөнәсәбәтен белдерә килде. Мәсәлән, «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясе (Мирас. 1998, №11), «Бер тоткарның саташуы» повесте (Мирас. 1998. № 12), «Мөгаллимә» пьесасы (Мирас. 2001. №4) текстлары аның катнашында әзерләнеп, кереш мәкалә һәм комментарийлары белән укучыларга тәкъдим ителде.

Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте хакында галимнәребез тарафыннан төрле-төрле фикерләр әйтелүе мәгълүм. Р. Ганиева исә И. Нуруллин, Ә. Сахаповларның әсәрне тәнкыйди реализм үрнәге итеп караулары белән килешмәде, аны «төрки-татар әдәбиятлары тарихында беренче антиутопия» итеп тикшерде. Сигез томлы фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы»ның 4 нче томында Флүн Мусин да бу фикергә кушыла [3: 70]. Фәнни-гамәли конференцияләрдә ясаган докладларында, вакытлы матбугат битләрендәге чыгышларында галимә, Г. Исхакый әсәрләре турында сүз алып барганда, әдип иҗатында халыкчылык мотивлары, культура-тарих мәктәбенә хас традицияләргә мөнәсәбәтлелек, «соңарган классицизм» традицияләре, югары уку йортларында укыту мәсьәләләре кебек бик мөһим нәзари проблемаларга да нисбәтән караш-фикерләре белән таныштыра иде.

Резеда Ганиеваның Казан университетында илле ел эчендә узган фәнни-педагогик эшчәнлегендә студентларга татар әдәбияты буенча ике телдә лекцияләр уку, дистәләгән курс эшләре яздыру, дипломнарга җитәкчелек итү төп урынны биләде. 1980 еллар ахырыннан башлап, илдә барган үзгәртеп корулар тәэсирендә дә, аңа да уй-фикерләрен «яңартырга» туры килде. Исхакый мирасына мөнәсәбәттә бигрәк тә. Университетны тәмамлап чыгу белән, фәнни тикшеренүләргә сәләтләре күренеп торган өч егет-кыз исә аспирантурага кабул ителеп, аның җитәкчелегендә кандидатлык диссертацияләре яздылар һәм уңышлы якладылар. Минемчә, аларның ни дәрәҗәдә актуаль проблемалы, концептуаль эчтәлеклелеген исемнәре үк әйтеп тора: «Гаяз Исхакый иҗатында феминизм проблемасының идея-эстетик эволюциясе» (Алсу Кәримова-Шәмсутова), «Әдәби бәйләнешләр контекстында Гаяза Исхакыйның башлангыч чор прозасы» (Рифа Харрасова), «Гаяз Исхакый драматургиясендә классицизм традицияләре» (Тулкунай Абделбариева). Диссертацион хезмәтләргә язган күпләгән бәяләмәләрдә галимә бүген дә әһәмиятен югалтмаган фикерләр әйтеп калдырды. Бу урында исә икесен генә атап китәргә телим. Алар – Р.Ә. Яруллинаның 1897–1906 еллар әдип иҗатының идея-эстетик үзенчәлеген, Л.М. Гайнанованың язучы прозасында художестволы пространство һәм вакыт чагылышын тикшергән кандидатлык диссертацияләре. Кайбер кимчелекләре дә күрсәтелә: әдәбият фәненә яңа методологик концепцияләр тәкъдим иткән олуг галимә Йолдыз Нигъмәтуллина хезмәтләренә таянмау, әдипнең, мәсәлән, иң әүвәлге әсәрләрен өйрәнчек әсәрләр итеп кенә тикшерү (Р. Яруллина) [6: 53, 56–57] , «Тормышмы бу?» әсәре турында сүз алып барганда, диссертантның «дин герой тарафыннан кирәксез традиция» сыйфатында карала дип язу (Л.М. Гайнанова) [6: 147] һ.б.

Гомеренең соңгы елында Резеда Ганиева, кайбер язмаларының һаман да басылмый калуына бик борчылып, беришеләрен генә булса да нәшер итү фикеренә килгән иде. Һәм мин аның илле елга сузылган фәнни-педагогик эшчәнлегенә замандаш галимнәрнең мөнәсәбәтен белдергән мәкаләләрен, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә рәсми бәяләмәләрен генә булса да җыйнап чыгарырга тәкъдим иттем. Архивы материалларын да җентекләп өйрәнү нәтиҗәдә, шактый күләмле ике җыен-

тык хасил булды (татар һәм рус телләрендә): «Профессор Резеда Ганиева» (төзүче – З.З. Рәмиев, редактор – И.Р. Рәмиева; Казан: Фән, 2020), «Әдәбият һәм әдәбиятчылар турында» (җаваплы редактор – З.З. Рәмиев; шунда ук басылды, 2021). Бүгенге чыгышымны әзерләп утырганда, яшерен-батырын түгел, мин андагы материалларга да таяндым. Сүземне тәмамлар алдыннан, Д. Заһидуллина, К. Миңнуллин, Ә. Закирҗанов, М. Бакиров, А. Шәмсутова, Х. Миңнегулов, Н. Йосыпова һәм башка кайбер татар әдәбиятчыларының фәнни хезмәтләрендә Резеда Ганиеваның Исхакый иҗатына мөнәсәбәтле фикерләре дә искә алынып сүз йөртелүен дә әйтәсем килә.

ӘДӘБИЯТ


1. Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конф. материаллары. – Казан, 2008. – 376 б.

2. Гаяз Исхакый: тарихи документаль җыентык. – Казан: Җыен, 2011. – 954 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр. 2016. – 553 б.

4. Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы межд. конф., посв. 140 летию ... Г. Исхаки. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 450 с.

5. Профессор Резеда Ганиева. – Казань: Фэн, 2020. – 380 с.

6. Ганиева Р. О литературе и литературоведах (отзывы и рецензии).– Казань: Фэн, 2021. – 336 с.

7. Ганиева Р. Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. – Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2014 – 272 с.


УДК 821.512.145

## ОТРАЖЕНИЕ НАРОДНЫХ ТРАДИЦИЙ В РАССКАЗЕ Г. ИСХАКИ «СУННАТЧИ БАБАЙ»


***С.Г. Самитова***

*КНИТУ (Казань)*



В данной статье глубинные психологические переживания «маленького человека» рассказа Г. Исхаки «Суннатчи бабай» проанализированы через народные и религиозные традиции, особенно обряда обрезания, татарского народа. В ходе анализа особое внимание уделялось национальным чертам татар, красочно описанным в произведении, а также символическим образам, которые были интерпретированы с точки зрения психоанализа и религиозных канонов Ислама.



**Ключевые слова:** Г. Исхаки, «Суннатчи бабай», образ «маленького человека», символы, национальные и религиозные традиции.



In this article, the deep psychological experiences of the «little man» of G. Iskhaki’s story «Sunnatche Babai» are analyzed through the national and religious traditions, especially the circumcision rite, of the Tatar people. During the analysis, special attention was paid to the national features of the Tatars, colorfully described in the work, as well as symbolic images that were interpreted from the point of view of psychoanalysis and the religious canons of Islam.



**Key words:** G. Iskhaki, «Sunnatche babai», the image of a «little man», symbols, national and religious traditions.


## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» ХИКӘЯСЕНДӘ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ЧАГЫЛЫШЫ


***С.Г. Сәмитова***

*Казан милли тикшеренү технология университеты (Казан)*


Милли мәдәният һәм әдәбият, сәясәт һәм иҗтимагый тормыш, журналистика һәм публицистика, мәгариф һәм фәлсәфә – милләтебезнең сагында торучы бу өлкәләрнең барысы да Гаяз Исхакый исеме белән бәйле. Аның иҗаты милләт язмышы белән янәшә бара. Әдипнең әдәби иҗаты, публицистикасы һәм тәнкыйди хезмәтләре арасында аерылып торган бер хикәясе бар – бу «Сөннәтче бабай» хикәясе.

«Сөннәтче бабай» (1911) хикәясе – татар әдәбияты тарихында беренче булып татар халкының тормышындагаять ихтирамга ия булган сөннәтче образын тудыра. Гади генә сюжетка корылган бу әсәр кечкенә кеше – Сөннәтче бабайның эчке дөньясын бөтен нечкәлекләре белән ачып сала. Әсәрдә, Ислам дине кабул иткәннән бирле килә

торган сөннәткә утырту йоласы аркылы, татар халкының бөтен тарихы, традицияләре, фаҗигаләре сурәтләнә. Сөннәтче бабай һәм аның гомер иткән хатыны Гөлйөзем әбинең тормыш-көнкүрешен иҗади шәрехләп, татар халкында ир-хатын арасында мөнәсәбәтләр шундый булырга тиешле дигән идеяне дә үткәрә. Бу персонажларны ачканда әдип бай һәм кызыклы образлар системасына мөрәҗәгать итә. Йорт-җир, каралты-кура, өй алдында үскән миләш агачы, кәҗә – болар барысы да әсәр тукымасына урынлы кереп китәләр, тасвирлаган вакыйгаларга аваздаш яңгырыйлар, геройларның психологиясен символик мәгънә тудыралар.

Халкыбызда «Милләт нәрсә ул? Милләт ул – тел, гореф-гадәтләр, тарих һәм дин» дигән гыйбарә яши [3: 36]. Дини кануннарның һәм гореф-гадәтләрнең милләт сагында торуын талантлы язучы яхшы төшенгәнлектән, әдәби иҗатында гадәти генә тоелган тормыш-көнкүреш вакыйгаларына тирән мәгънә сала, халкыбызга хас күркәм сыйфатларны көндәлек мәшәкать-күренешләрдә тасвирлый, ышанычын җуйган кечкенә кеше образларының җан трагедиясен гади генә мисаллар аша гәүдәләндерә. Г. Исхакый халыкның үз йөзен саклауда гореф-гадәтләрнең традицияләрнең ролен юкка игътибар бирми. Бу уңайдан галим, дин белгече Шиһабетдин Мәрҗани фикерен искә алуда урынлы булыр: «Диндә өч әйбер юк, әмма алар аный саклый: тел, милли кием, гореф-гадәт», дигән. Димәк тел һәм дин үзара бәйләнештә булып яшәшә барганда гына халыкның киләчәге өметле. Бу турыда Миссионер Н.И. Ильминскийның әйткән сүзләре дә бар. Ул татар халкының башка милләтләргә иярмичә үз йөзен, үз телен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуын ислам кануннары нигезендә яшәүгә бәйләп аңлата: «Казанские татары, под этим именем я разумею народность, средоточие которого в отношении нравственной силы и своеобразного образования находится в Казани, а народ этого типа распространен далеко за пределами Казанской губернии, во всей восточной полосе России, и любят себя называть мусульманами, а не татарами. Они больше гордятся своей магометанской верой, чем своей народностью; но дело в том, что вообще вера есть крепкая основа народности. В Восточной России татары именно являются как бы образцами исповедниками ислама, так что киргизы, например, и башкиры, усердием начинают содержать магометанскую веру и магометанские обряды, они вместе с тем усваивают и татарский язык и татарский костюм, отказываясь таким образом и от родного своего наречи» [4: 32].

Мөселманнарда сөннәт гомер гомергә изге гамәлләрдән саналган. «Сөннәт» татарга фарсы теле аша кергән, гәрчә гарәпчә ул «сөннәһ» (سنة) булып яңгырый һәм Ислам хокукында Мөхәммәд (гвс) әйткән фикерләрне кабул итү һәм кылган гамәлләрне, мәҗбүри булмауга карамастан, төп-төгәл башкаруны таләп итә.

«Г. Исхакый, беренче карашка, әллә ни зур тоелмаган вакыйгалар аша тормышның иң характерлы якларын күрсәтә. Мәсәлән, «Сөннәтче бабай» хикәясендә сөннәткә утырту йоласы аша шул чор татар авылының, халкының бөтен тарихы, традицияләре, шул юлда килеп чыккан фаҗигаләре тасвирлана», – дип яза Р. Яруллина [1: 14] әсәрнең идея-тематик мәгънәсен ассызыклап.

Бик гади генә тоелган сюжетта әдип ни дәрәҗәдә мөһим проблемалар күтәрә һәм герой кичерешләренең авырлыгын күрсәтә алган.

Хәзер әсәрнең текстына якынрак килик. Төп герой – Корбанколый бабай. Г. Исхакыйның бу исемне төп геройга бирүе юкка гына түгел: ул гарәп теленнән «Сөннәт йоласының колы» дигән мәгънәгә ия. Бу уңайдан, теләсә кемнең сөннәтче була алмавын да күрсәтү кирәктер. Бу кәсепне башкару өчен, нәселдән килгән күңел сафлыгы, тән пакълеге белән беррәттән, башкарган эшеңнең изгелегенә, милләт өчен зарурилыгына инану һәм дә «мирас юлы берлән сөннәтчелеккә хакы барлыгыны исбат итә торган шәҗәрәсе» [1: 72] булуы мәҗбүри. Шуңа күрә геройның «Сәлмән Фәрси»дән мирас булып калган шәҗәрәсе, сөннәтли торган чалгы пәкесе, сөннәткә сибә торган агач череге – болар барсы да изгеләрдән санала һәм йортның иң түрендә саклана, җае чыкканда Сөннәтче бабайга кәсебенең мөһимлеген исбатларга һәм шуңа мөнәсәбәттә горурлык хисе тоярга мөмкинлек бирүче әйберләр. Бергә җыеп әйтсәк, үзенең сөннәтләү әйберләреннән башка Сөннәтче бабай юк; Сөннәтче бабайдан башка, бу әйберләр кирәксез [5:43].

Корбанколый карт үзенең нәсел-нәсәбе тарихын Мөхәммәд (гвс) пәйгамбәрнең сәхәбәсеннән башлап сөннәтләргә хакы барлыгын да исбатлый, шул ук вакытта татарлар дөньясында Ислам диненең нык таралган булуын күрсәтергә омтыла. Бу шәҗәрә хикәядә түбәндәгечә яңгырый: «Корбанколый бинеУразколый, уразколый бине Миңлеколый, Миңлеколый бине Габдулла, Габдулла бине Мөхәммәдсалих, Мөхәммәдсалих бине мулла Морад баба, мулла Морад баба бине Хан Гәрәй, Хан Гәрәй бине хәзрәти Аксак Тимер, Аксак Тимер бине хәзрәти Гали, хәзрәти Гали бине Сәедбаттал, Сәедбаттал бине хәзрәти Хәнәфи, хәзрәти Хәнәфи бине Мөхәммәд, Мөхәммәд бине Габделсәлам, бине Мамай, Мамай бине ибн Габбас, ибн Габбас бине Габделмөталиб, Габделмөталиб бине Һашим, Һашим бине Хәсән, Хәсән бине хәзрәти Билал, хәзрәти Билал бине Сәлман Фарси разый Аллаһе ганһе. Укучы Сәлмән Фарси белән бабай арасындагы шул мең дә өч йөз елның шулкадәр тиз кичеп, биш-алты буында Сәлмән Фарсига барып йитүендә дә, шундагы кергән тарихи исемнәрнең тулылыгына да шөбһәләнми иде [1: 75]. Бу шәҗәрәдә урын алган шәхесләрнең барысының да татар халык һәм дин тарихында билгеле булуы сөннәтче бабайның дәрәҗәсен үстерә һәм аңа халыкның ышанычын арттыра.

Авыл халкы телендә картның исеме дә җуела, ул бары сөннәтче бабай булып кына саклана. Аның татар ир-атлары тормышында мөһим эш башкаруы әсәрдә йола символы булып китә. Билгеле булганча кеше үз гомерендә берничә мәртәбә багышлау яки инициация үтә. Инициация (лат. initiatio), татарча әйтсәк, багышлау – шәхеснең ниндидер иҗтимагый төркем яки мистик җәмгыять кысаларында яңа үсеш баскычына күчүен күрсәтүче йола. Иң тәүгесе булып исем кушу тора. Исемне һәр яңа туган сабыйга бирәләр. Менә сөннәткә утырту исә, кечкенә малайланың ир-ат буларак багышлау үтүе. Сөннәтче бабай бу йолада төп рольне башкаручы зат. Шунлыктан әсәрнең беренче юлларыннан ук язучы бу бабайның авыл, бигрәк тә, ир-атлар тормышында аерым бер урында торуын ассызыклап: «Авылның картлары, ир урталары, яшьләре – һәммәсе дә үзләрен белә башлаганнан бирле аны Сөннәтче бабай дип таныйлар», – дип искәртә. Авыл халкына арасында «метрикасын кәҗә ашаган» кебек шаян сүзләр белән аның исеме югалуны, «Газраил фәрештәнең аны онытуы»на бәйләп яшенең дә билгеле түгеллеген аңлаталар. Сүз гадәти авыл кеше турында баруга кармастан, карт үзе дә сөннәт йоласының символы булып китә.

Шунысы кызык, әдип йорт, каралты-кура, йорт алдында үскән миләш арасында параллель үткәреп, бабайның холык-фигыле, рухияте дөньясын күрсәтә. Аның өе беркемнекенә дә охшамаган, нык аерылып тора: «бунда һәрнәрсә Сөннәтче бабайга охшаган, Сөннәтче бабай үзе дә һәр нәрсәгә охшаган иде. Кем белсен, бәлки, Сөннәтче бабай сынында шул өйнең балчыгы берлә бер балчыктан яралгандыр» [1: 67].

Авыл кырындагы йортында Сөннәтче бабай үзенең Гөлйөзем атлы карчыгы белән гомер кичерә. Төрле сәбәпләр аркасында ятим калган бу карт белән карчык бербер аңлап, хөрмәт итеп яшиләр. Һәркайсының бу йортта үз вазифалары һәм алар тиешенчә башкарыла – әдип шуны әсәр барышында исбатлап килә. Көйгә салынган бу тормышның җимерелүе, яңа килгән затсыз хатынның гаиләдә булган тәртипне бозуы Сөннәтче бабайның әкренләп үлемен якынайта.

Сөннәт вакыты башлану – әби белән бабай өчен бик зур бәйрәм. Бу көнне карт иртәнге намазга алданрак бара, ниятле намаз укый. Мөһим эш башлар алдыннан Корьән укытуы, хәзрәттән хәер-фатиха алу гадәткә кертелгәнлектән, Сөннәтче бабай хәзрәт белән остазбикәне ашка чакыра. Ризалык алганның соңында хатынын шатландыру һәм табын көйләү өчен өенә кайта. Г. Исхакый бу көнне «ул матураеп, яшәеп китә», – дип яза. Бабай кияү булып төшкәндәге киемнәрен, хәзрәт кызының улын сөннәткә утыргач биргән кәләпүшен, урам буйлап йөреп туза башлаган казакийларын киеп, хәзрәтләрне капка төбенә чыгып каршы ала. Бу гамәле белән ул, татар тормышындагы кунак хөрмәтләү йоласын да башкара, дин әһелләренә карата булган хөрмәтне дә күрсәтә.

Халкыбызга хас күркәм гадәт – кунакчыллыкны тасвирлаган күренеш аерым игътибарга лаек. Язучы бу турыда язганда халкы өчен горурлык хисе тоя. Ул бу күренешне юмор белән төреп тәфсилләп шәрыхли. Әйтергә кирәк, Г. Исхакый үзе дә указлы

мулла булган, авыл халкы тарафыннан шулай ук зур ихтирамга ия шәхес, шуның өстенә хикәясендә сурәтләнгән гореф-гадәтләрне Ислам кануннарына туры китереп, хәдисләрне дә күздә тотып иҗат иткән.

Хәзрәт белән остазбикәне сыйлау эпизодына автор зур игътибар биреп, гаять тә нечкә штрихлар ярдәмендә җиңелчә көлеп сурәтли. Бу күренештә хәзрәт белән абыстайга карата ихтирам, ризыкка карата хөрмәт тә, татар халкының ачык йөзлелеге һәм кунакчыллыгы да ачык чагыла. Бер-бер артлы табынга бик күп төрле ризыклар чыга, әллә ничә мәртәбә самавыр куела – кунаклар ни сәбәптәндер һаман да ашыйлар, «тәмле сүзгә кереп китеп, чынаякларны санарга оныталар, самавырда су беткәч кенә: "Туйдык, туйдык инде", – дип тартынсыналар да, Гөлйөзем әби тагы кайнаган су берлән самавырны яңарткач, тагы эчәләр иде. Өченче мәртәбә самавырны яңартырга хәзрәт каршы килә, остазбикә дә разый булмый. Гөлйөзем әби: "Минем хәзрәткәем, эчәсем килә, мин дә сезнең мәҗлесеңез берлән шәриф буласым килә", – дигәч, хәзрәт тә дәшми, остазбикә дә разый була; тагы самавыр килә, тагы Гөлйөзем әби берлән бергәчәй эчелә, тагы су бетерелә. Дүртенче самавырга хәзрәт кенә түгел, абыстай да каршы килә. Гөлйөзем әби дә, чәй урынына җыеп ала иде дә» [1: 78].

Чәй табыны җыелып, кыска аятьләр укып дога кылынгач, Сөннәтче бабай хәзрәттән хәер-фатыйха һәм сөннәт йоласын башкарырга рөхсәт ала. Әдип тәфсилләп бабайның йолага әзерлеген сурәтли: ул һаман да бәйрәмчә киенгән, ягъни үзенең кияү булып кергән чактагы күлмәгеннән. Күлмәк – аның бәхет символы, бу йола – бабай өчен зур бәхет.

Шәригать буенча кешегә хас һәм мактауга лаеклы сыйфатлардан: яхшы сүз әйтү яки эндәшми калу, күп сүз сөйләмәү яки азсүзлелек, күрше һәм туганнарга игътибарлы булу, кунакны хөрмәт итү һәм кунакчыллыкны атап була. Г. Исхакый бу әсәрендә бигрәк тә халкыбызның кунакчыллык сыйфатларына аерым игътибер бирә. Бу хәзрәт белән абыстайны кунак итү, сыйлау эпизодыннан күренә. Бер хәдистә Мөхәммәд (гвс): «Соңгы көнгә ышанучы кеше кунагын хөрмәтләсен», – дип ассызыклый, ислам буенча кунакчыллыкның иң яхшы әдәп сыйфатларыннан булуын искәртеп [6: 93]. Шунысын да аңларга кирәк: яхшы әдәб сыйфаты буларак, кунакчыл булу яхшы гамәлләрдән генә санала, ләкин ул боерык түгел.

Әсәрдә тагын бер милли дәвалау ысулы «мөгез салу» яки «кан алу» күренешен тасвирлауга да урын бирелә. Бу күренештән Г. Исхакыйның халыкның гореф-гадәтләрен яхшы белүен, шул исәптән тыйб (медицина) гыйлеменнән хәбәрдар булуын күрәбез. Сөннәтнең аерым вакыты һәм аның чикле булуына бәйле рәвештә, бабай яз һәм җәй көннәрендә эшсез калмас өчен, бу төр йоланы да үзләштерә. Автор әйткәнчә, «Сәлмән Фарси мирас тарикы берлән сөннәтчелекне алса да, Әбугалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйльме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә (химия, алхимия) иҗаят алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйльменең бу кадәр нечкәлекләрене белми иде. Ләкин исәпсез-хисапсыз еллар хәзрәтләр, муллалар, мәэзиннәр белән катнашу, анларга исәпсез-хисапсыз мәртәбә мөгез утырту, иксез-чиксез анларның каннарыны алу аңар зур тәҗрибә биргән вә шул кагыйдәләргәаны да алыштырган иде» [1: 83]. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, карт канны һичкайчан көз алмас, кышын мөгез салмас, беркайчан да мөгез тулганчы файдаланмас. Шунысы билгеле: бүгенге медицина никадәр алга китмәсен, халык дәваләү ысуллары һаман да актуальлеген югалтмый. Кешенең кан басымы бик югары булганда, кан чыгару мәслихәт. Шулай ук мөселман ысулларыннан саналган хиджама да соңгы елларда бик еш кулланыла.

Безнең халыкта «Ясин» догасын магик көчкә ия дигән фикер яши. Шунлыктан кеше авырып киткәндә я тереп китәр, я җан тәслиф кылырга җиңелрәк булыр дип «Ясин» чыгалар. Сөннәтче бабайның Гөлйөзем карчыгы авырып киткәч, ул хәзрәтне чакыра. Автор әсәр тукымасында берничә кат геройның укый беләмәвенә басым ясый һәм кыска-кыска аятьләр укый дип тә искәртүгә карамастан, «Ясин» укырга хәзрәтне дәшүендә, бәлки, аны дин әһелләренә карата хөрмәт белән аларның ниндидер могҗизага сәләтле дип ышанудан киләдер. Гөлйөзем әби вафат була. Сөннәтче бабай шул көннән җанына урын таба алмый, җитмәсә, йоклаганда аркасы өшегәнне сизә. Бу фактка бәйле рәвештә Г. Тукай «Мәкаләи махсуса» (1912) хезмәтендә болай дип

тәнкыйтьләп: «Әле Гаяз әфәнде рисаләсендәге Сөннәтче бабай, аркасы туңганлыктан гына, арка җылытырга бер хатын алган, ди. Мин ул китапны укымадым, укыган кеше генә сөйләде», – дип яза [2: 110]. Ни кызганыч, кеше сөйләгәннәргә генә таянып, Г. Тукай әлеге әсәргә бик түбән бәя бирә. Чынлыкта исә, гадәти генә шушы тормыш факты артында шәхси проблема – ялгызлык ята. Бер-берсенә терәк, юаныч булып гомер сөргән әби белән бабай портретларын сурәтләгәндә, язучы символлардан һәм образлы чагыштырулардан файдалана. Шулар аркылы геройларының тышкы кыяфәтләрен генә түгел, бәлки хисси дөньяларын, үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтергә тели. Бабайның да бәйрәм вакытларында һәм йола үтәгәндә кияү булып төшкәндәге киемнәрен киеп йөрүе – иң бәхетле чорына ишарәле, шул рәвешле ул «бәхетле вакытны» суза. Чөнки бу хис аны җылыта, яшәргә көч бирә, алдагы көнгә ышаныч уята. Әлбәттә, шәригать кушканча, өч көнлек гомерең калсада, ялгыз яшәмә, дигән гыйбәрәгә таянып, ул үзенә карчык эзли башлый. Тик затлы нәселдән булган тол хатыннар төрле сәбәпләр табып, бабайны кире кага. Ул ахырда риза булган хатынны алырга мәҗбүр була. Г. Исхакый бу образны тасвирлаганда да шул ук чагыштыру ысулына мөрәҗәгать итә. Ул бу очракта әлеге затсыз, пычрак карчык белән Гөлйөзем әби арасында параллель үткәрә, әмма бу чагыштыру карчык файдасына түгел. Бу урында ирексездән рус халык мәкале искә төшә: беренче хатын Алладан, икенчесе шайтаннан. Әсәр дә шуны раслый. Сөннәтче бабайның тормышы ялгыз булганга караганда да авырая: йорт-җир ката, кәҗә сөт бирми башлый, соңгы тамчы – изге пәке дә гадәти эшкә тотыла башлый. Үзен белгәннән бирле изге санап, йортның иң түрендә саклаган сөннәт пәкесен затсыз карчыкның кулында күргәч, бабай башта катып кала, ахырдан җенләнгән кебек кычкырырга, еларга тотына һәм бөтенләй телсез кала, тик пәкене кулыннан ычкындырмый. Шул рәвешле үлем түшәгендә ята, күзләрен белән нидер эзли, кемнедер көтә. Өч көн ятканнан соң, хәзрәт килеп Корьән укып бетергәч, аның улы килеп керә. Малай килеп керү белән Сөннәтче бабайның йөзендә «көләчлек» хасил була. Елмаю аша әдип бабайның көткән үзенең кыйммәтле мирасын һәм кәсебен калдырыр кешесе килде, дигән фикер үткәрә. Бу, үз чиратында, милли традиция дәвам итә, халыкның киләчәге бар дигәнне аңлата.

Хикәядә калку сурәтләнгән миләш образына аңлатма бирү сорала, чөнки ул символик образ буларак әсәрнең башыннан ахырынача кызыл җеп булып сузылып бара.

Миләш агачына карата борыңгы халыкларның аерым урын бирүе инде мәҗүсилек диненнән башлап килә. Мәсәлән, славяннар миләш ботакларын Перун бармагына тиңләп, аның бар нәрсәдән дә саклау көченә ышанганнар. Татарларда да миләш агачы белән бәйле күп кенә ышанулар һәм ырымнар яши. Миләш агачының төрле сихербозымнардан, күз тиюдән саклавы һәркемгә таныш. Бу хикәя тукымасында миләш образы ниндидер мәҗүси ышану символы буларак кулланылмый, әлбәттә. Ул бары Корбанколый карт образын тагын да тулыландыру өчен кирәк. Картның тышкы кыяфәтен, бигрәк тә, йөз торышын, битендәге җыерчыкларне миләш ботаклары белән чагыштыру бу ике образның янәшә картаюы һәм аларның бер берсеннән аерылгысыз булуына ишарә ясый. Күпмедер дәрәҗәдә йола символы дияргә мөмкин, чөнки әсәрнең башында аның шаулап үсеп утыруы традициянең яшәве турында сөйли, ахырда корып китүе – бабай үлеменнән соң сөннәтләү йоласының дә тәмамалану ихтималын күрсәтә, чөнки бабайның турыдан туры нәсел дәвамчысы юк. Ул өметләнә хәзрәтнең улы башкарыр дип, тик хәзрәтнең улы моңа риза булырмы – бусы икенче мәсьәлә?! Шушы фикерне дәлилләп булыр иде, әгәр без миләшнең табигый антисептик булуын да искә алсак, Сөннәтче бабайның миләш агачын йорт алдына утыртуы ук, бабайның кәсебе турында сөйли. Кадерләп кенә саклап торткан сөннәт ярасына сибә торган пычкы чүбе миләш кайрысыннан булган дип фаразлыйбыз. Миләш кайрысының структурасына игътибар итсәк, анда кан туктатуга, җәрәхәтне төзәтүгә ярдәм итә торган матдәләр барлыгын күребез. Шулай булгач, бабайга йола үткәрү өчен кирәк матдәләр өе каршында гына үскән. Сөннәтче үлгәннең соңында бу матдәләргә ихтыяҗ да бетә – миләш корый.

Әсәр «Бер тормыш бетте, икенчесе башланды», дигән юллар белән тәмамлана. Табигать законнары буенча тереклек шулай дәвам итә: киләчәктә башак булсын өчен,

орлык та үзен корбан итә. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: чыннан да, бу традицияне үтәү бүгенге көндә сөннәтче картлар түгел, а профессиональ белеме булган хирурглар тарафыннан башкарыла.

Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясе кечкенә кеше психологиясе аша, халыкны саклап торган йолалар, аларның тормыштагы урыны ачыклана.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002 – 480 б.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 447 б.
3. Милләт ул – тел, гореф-гадәтләр, тарих һәм дин // Казан утлары. – 2017. – № 5. – Б. 36.
4. Ильминский Н.И. В Восточной России татары именно являются как бы образцами исповедниками ислама // Эхо веков – Гасырлар авазы. – 2013. – № 1/2. – Б. 28–35.
5. Сәмитова С.Г. Гаяз Исхакый иҗаты (1914–1917 еллар) – Казан: КДУ нәшр., 2005. – 121 б.
6. 40 хәдис. Имам ән-Нәвәи аңлатмасы – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2004. – 416 б.

УДК 821.512.145

# ОБРАЗ СОБОРА СВЯТОЙ СОФИИ В РОМАНЕ ГАЯЗА ИСХАКИ «ӨЙГӘ ТАБА» («ДОМОЙ»)

***М.У. Узун***
*Центр науки и искусства Измита (Коджаэли, Турция)*

Гаяз Исхаки – один из самых значительных деятелей татарской литературы XX века. Одним из важнейших произведений автора является его роман «Өйгә таба» («Домой»). В произведении, написанном в 1922 году, обсуждается тема возвращения к сущности и национальной идентичности. Одним из факторов, влияющих на дидактический стиль Исхаки в этом романе, является феномен религии. Собор Святой Софии, занимающий центральное место в романе, является храмом особой важности как для русских христиан, так и для турок-мусульман.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, религия, литература, Собор Святой Софии.

Ayaz Ishaki is one of the most important figures of 20th century Tatar literature. One of the most important works of the author is his novel named Oyge Taba. In the novel Oyge Taba, written by İshaki in 1922, the subject of returning to the essence and national identity is discussed. One of the factors affecting Ishaki's didactic style in this novel is the phenomenon of religion. Hagia Sophia, which has a central position in the novel, is a temple of special importance for both Christian Russians and Muslim Turks.
**Key words:** Gayaz Ishaki, religion, literature, Hagia Sophia.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «ӨЙГӘ ТАБА» РОМАНЫНДА АЙЯСОФЬЯ ОБРАЗЫ

***М.У. Узун***
*Измит Белем һәм Сәнгать Үзәге (Коджаэли, Төркия)*

Татар әдәбиятының мөһим шәхесләреннән берсе булган язучы, нәшир һәм сәясәтче Гаяз Исхакый үзеннән соң шактый бай мирас калдыра: илледән артык әсәр яза. XX гасыр башы татар әдәбиятының алтын чорын башлап җибәрүче Исхакыйның әсәрләре 1917 елдан соң да татар әдәбиятының формалашуына һәм үсешенә йогынты ясый. Аның әсәрләре татарларга милли идеологиягә ия булырга һәм бу идеологияне милли азатлык хәрәкәтенә әвереледерергә мөмкинлек бирә [10: 224]. Бу чор әдәбиятында милли фикер белән шәхес иреге төшенчәләрен үзәккә алган романтизмның аерым төрләре һәм формалары шигърияттә – Габдулла Тукай һәм прозада бөек осталар белән берлектә Гаяз Исхакый әсәрләрендә чагылыш таба [13: 41].

Исхакыйны романтик язучы яисә реалист язучы дип кенә кистереп әйтеп булмый, аның үзенә генә хас стиле бар [11: 154]. Әсәрләрен бары тик әдәбият белеме күзлегеннән генә чыгып карау язучы иҗатын аңлап бетермәүгә сәбәп булыр иде. Аның иҗатын иҗтимагый фикер, тарих, фәлсәфә, милли сәясәт, милли фикер тарихы, татар халкы тарихы кебек фәннәр яссылыгында өйрәнү зарур [10: 25].

Г. Ибраһимов һәм Г. Баттал тарафыннан 1914 елда Казанда чыгарылган «Яңа әдәбият» исемле басмада Исхакыйның күп кенә әсәрләренә урын бирелә. Татар әдәбиятының мәшһүр һәм бөек әдипләреннән берсе булган Исхакый шушы әдәбиятның алын дәверен тәшкил иткән реализм, реализм-романтизм чорында әсәрләр иҗат итә, татар прозасы һәм драматургиясен реализмга кертеп җибәрүчеләрнең берсе була [4: 139]. Яңа татар әдәбиятына нигез салган Исхакый патша заманында гел эзәрлекләнеп тора һәм вакыт-вакыт төрмәгә атыла, сөргенгә озатыла; СССР вакытында исә аңа «халык дошманы» дигән тамга тагылып [3: 63], тоталитар режим тарафыннан җитмеш ел буена нахакка «халык дошманы» итеп танытыла; әдәбияттан, сәнгатьтән һәм рухи тормыш өлкәсеннән ераклаштырыла яки бөтенләй чыгарып атыла [15: 3]. Мәсәлән, 1970 елда А. Гыйниятуллина тарафыннан әзерләнгән «Писатели Советского Татарстана» һ.б. кебек хезмәтләрдә Исхакый исеме телгә алынмый.

Р. Яруллина-Йылдырым, тимер пәрдәләр ачылганнан соң, татарларда үткәне белән кызыксыну башлануын һәм Совет идеологиясенә туры килмәгәнгә күрә тыелган әдәби әсәрләрнең кабаттан укучыларга кайтарылуын билдерә [13: 140–141]. Шуның нәтиҗәсендә татарларның борынгы тарихына, үткәндәге «билгесезлекләргә» карата кызыксыну арта, тарихи чынбарлыкка нигезләнгән поэзия, проза һәм драматургия әсәрләре языла.

Гаяз Исхакый 1978 елның 22 февралендә Казан вилаятенең Чистай өязе Яуширмә авылында туа. Башта әтисенең мәдрәсәсендә белем ала, 1890 елда Чистай мәдрәсәсендә укуын дәвам иттерә, 1893 елда исә Казанның Күл буе мәдрәсәсендә укый. 1898–1902 елларда, Татар укытучылар мәктәбендә укуын дәвам иткән Исхакый әсәрләр иҗат итә башлый; пьеса, хикәя һәм романнар яза алу сәләте барлыгын күрсәтә [14: 345; 8: 159]. Татар укытучылар мәктәбендә рус телен үзләштерә, рус классиклары әсәрләрен бирелеп укый [1: 10; 9: 12]. Бу мәктәпне бетергәннән соң, башлангыч сыйныфлар укытучысы хокукына ия була һәм берара мөгаллимлек итә [1: 10].

Киңкырлы шәхес булган Исхакыйның фикри яктан формалашуында Русиядә дөнья күргән һәм Исмәгыйль Гаспралы тарафыннан чыгарылган «Тәрҗеман» газетасының йогынтысы зур була [7: 46]. Азәрбайҗанда чыгучы «Игинчи-Көйлү Газетәси» («İginci-Köylü Gazetesi») һәм Истанбулда нәшер ителгән «Малумат» («Malûmat») журналын да күзәтеп барган Исхакыйда журналистикага да кызыксыну уяна [1: 9].

1905 елгы революцияне Исхакый сөенеп каршы ала [8: 159]. Инкыйлабтан соң ул «Таң йолдызы» исемле газета чыгара башлый. Эшчәнлеге көннән-көн активлашкан Исхакый берничә тапкыр кулга алына, шулай да милли хисләр белән сугарылган әсәрләр иҗат итүен дәвам итә. 1908 елда качып китеп, дүрт ел буе Төркиядә яшәү дәверендә «Мулла бабай» исемле роман белән «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый», «Сөннәтче бабай» һәм «Кияү» дип аталган хикәяләр яза. Соңрак туган иленә кайткан Исхакый кабат кулга алына [14: 345].

1917 елгы февраль революциясен зур канәгатьлек белән каршылаган Исхакый татарларның мөстәкыйльлеген яклаган мәкаләләр яза, Мөселман корылтайларын оештыруда актив катнаша, халыкны милли байрак астында туплау өчен тырышлык куя. Милләт хадиме булып җитешкән шәхес совет идеологиясен кабул итми. 1919 елда Версальдә оештырылган Тынычлык конференциясенә киткән әдип яңадан Россиягә кайтмый. Шушы вакыттан башлап аның мөһаҗирлектәге тормышы башлана һәм Исхакый диаспорадагы милләттәшләрен берләштерү өчен күп көч сарыф итә. 1954 елда Төркиядә вафат булган язучының кабере – Истанбулдагы Әдирнәкапы зиратында [14: 345].

Исхакыйның әдәби эшчәнлегенең беренче өлеше XX гасырның башына туры килә. Аның ватанындагы әдәби эшчәнлеген мәгърифәтчелек чоры (1897–1904), таңчылык дәвере (1905–1911) һәм 10 нчы еллар (Миллиятчелек) дәвере буларак карарга була. Язучының тормышының һәм иҗатының икенче өлешен иленнән читтәге эшчәнлеге – Мөһаҗирлек дәвере (1919–1954) тәшкил итә [4: 144; 3: 63–78]. Исхакый мөһаҗирлектәге милләттәшләре арасында татар әдәбиятын һәм мәдәниятен саклап калуда һәм аның иң матур үрнәкләрен дәвам иттерүдә көчен аямый.

1922 елда Алманиянең Берлин шәһәрендә язылган «Өйгә таба» дип исемләнгән роман шушы шәһәрдә үк басыла. 1927 елда язучының үзе тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителә [5: 7].

Роман аша автор барлык төрки халыкларның бердәмлеге идеясен чагылдыра. «Өйгә таба» исемле роман – рус-төрек, христан-мөселман, тәре-ай кебек каршылык элементларына корылган әсәр. Конфликт элементлары гәүдәләнгән шәһәр – Истанбул, ә урыны – ике як өчен дә зур дини мәгънәгә ия Айясофья.

Айясофьяның беренче бинасы IV гасырда базилика формасында агач түбәле буларак инша ителә. Константин I (324–337) төзетә башлаган дип саналган бу бина аның улы Константин (337–361) идарә иткән вакытта гына төзелеп бетә һәм 360 елның 15 февралендә ачылган. 404 елның 20 июнендә булган күтәрелеш вакытында чыккан янгында чиркәү җимерелә. Мабет, II. Тедосий (408–450) тарафыннан яңадан торгызыла һәм 415 елның 10 октябрендә ачыла. Бу икенче чиркәү дә, 532 елда фетнәдә сарайның һәм башка иҗтимагый биналарның бер өлеше белән бергә янганнан соң, император тарафыннан яңадан торгызыла. Айясофья ике Көнбатыш Анатолия архитекторы Траллестан (Айдын) һәм Милетостан (Милет-Балат) Исидороска тапшырыла; ун мең төзүче җәлеп ителгән төзелеше 537 елның 27 декабрендә тәмамланып, кабатан ачыла. Истанбулны яулап алганнан соң, ул Фатих Солтан Мехмет тарафыннан Айясофья исеме белән мәчеткә әверелә [2: 206–207 ].

Тарихи һәм дини яктан христаннар һәм мөселманнар өчен бердәй әһәмияткә ия булган Айясофья гыйбадәтханәсе төрекләр өчен Истанбулдагы хакимият символы булып тора. Үзләрен Византия варислары итеп күргән руслар өчен дә ул мәгънәгә ия.

Романның герое – рус әркяне хәрбе рәисе полковник Тимергали катнашкан бер җыелышта, союзниклар белән ясалаган аңлашу нигезендә, Византиянең чын варисы булган Русиягә Әрмәнстан, Истанбул һәм бугазларның биреләчәге белгертелә. Соңрак исә Айясофья хакында да шулай аңлатыла: «Төреклер тарафыннан былчыратылган Ая Суфияның пакьләнүе, буннан биш йөз ел элек аның башыннан төшерелгән салибның яңадан тагу шәрәфе безгә тапшырылды. Мин сездән динеңез, милләтеңез, императорыңыз өчен, шул мөкатдәс тарихий хезмәттә бөтен фидакярлекләрне көтәм. Яшәсен император, яшәсен аның каһарман гаскәре, саллансын Истанбулда Русиянең ике башлы кара кошлы байрагы! Ялтырасын бөтен дөньяга Ая Суфия башындагы мөкатдәс салибы!» [6: 51].

Тимергали, Тифлистәге Өлмәзоглу гаиләсенең кызы Фәридә белән бәхәсләшкәндә, Айясофья символы һәм аның ике яклы үзенчәлеген шулай белдерә: «Мин, Айясофьяның башына төрекләр төшергән тәрене тагар өчен, үзем кебек төрек-татар гаскәре берлә бердәнбер төрек илен саклый торган туганнарым төрекләргә каршы сугышырга, аларны үтерергә, артымнан килә торган теге урыс тәресене юл ачарга кирәк» [6: 55].

Романда ике милләт арасындагы конфликт сурәтләнә. Әсәрдә алты тапкыр искә алынган Айясофья, руслар белән төрекләр, христаннар белән мөселманнар өчен изге булган, дан-шөһрәт символы кебек кабул ителгән гыйбадәтханә буларак аңлатыла.

Дини ышанулар һәр дәүләттә олы сәяси корал булып тора. Госманлы төрекләре өчен ислам дине һәм ярымай нинди әһәмияткә ия булса, провославие динендәгеләр өчен хач шундый ук мәгънәгә ия. Истанбулны яулап алучыларның Айясофья гөмбәзенә яңадан хач урнаштыру хыялы шундый сәяси идеал булып аңлашыла.

Сугышны чагылдырган «Өйгә таба» әсәрендә батырлык темасы яктыртыла. Провославлар өчен батырлык – Истанбулны төрекләр кулыннан алып, Айясофьяга изге хачны урнаштыру.

Гыйбадәтханә түбәсенә ярымай яки хач урнаштырылуы ике халык арасындагы каршылыкның кем файдасына хәл ителүен күрсәтә торган күренеш булып тора.

Русларның Госманлыга, төрекләргә һәм Истанбулга мөнәсәбәте Тбилисидагы әркяне хәреб рәисе тарафыннан шушы рәвешле сөйләнә:

«Мәҗлес тәмам булганда, әркяне хәреб рәисе:

– Әфәнделәр, күрәсез, мәсьәлә бик зур. Алдымызда Русиянең иң зур тарихи бер бурычы тора. Бөек Петр заманасыннан бирелеп тә, үтәлмәгән милли, дини вазыйфасы

тора. Русиянең әлегә кадәр бөек Русия булып яшәүе өчен аның юлына каршы чыккан шул Төркияне уртадан калдырырга тиеш! Аның авыру тәне алып ыргытылып, Русиянең теләгәнечә киңәюенә һичбер төрле уңайсызлык ясамаска тиеш! Иттифакчыларымыз берле киңәшләшеп, Төркия тәкъсим ителергә карар ителде. Бизанес императорының чын варисы булган Русиягә Әрмәнстан, Истанбул вә бугазлар вәгъдә ителде. Рус халкының дине, милләте өчен алты йөз елдан бирле алдына чыккан төрек халкы берлә тартышуы соңгы баскычына басты… Төрекләр тарафыннан былчыратылган Ая Суфияның пакъләнүе, буннан биш йөз ел элек аның башыннан төшерелгән салибның яңадан тагу шәрәфе безгә тапшырылды. Мин сездән динеңез, милләтеңез, императорыңыз өчен, шул мөкатдәс тарихи хезмәттә бөтен фидакярлекләрне көтәм. Яшәсен император, яшәсен аның каһарман гаскәре, саллансын Истанбулда Русиянең ике башлы кара кошлы байрагы! Ялтырасын бөтен дөньяга Ая Суфияның башындагы мөкатдәс салибы! – диде» [6: 51].

Дөньяви эчтәлекле булса да, Г. Исхакыйның «Өйгә таба» дип аталган әсәрендә дини сылтамалар бик көчле бирелә. Моның төп сәбәбе – укучыларга тәэсир итү һәм юнәлеш бирү. Чөнки Исхакый, татарлар өчен динне берләштерүче, саклаучы бер алым буларак кабул итсә дә, гомеренең һәр чорында диярлек этноцентрик күзлектән эш итеп, татарлыгын, татар кемлеген – милләтен һәрвакыт беренче урында тота [12: 43].

Шулай итеп, XX гасыр татар әдәбиятның бөек остазларыннан берсе булган Г. Исхакый никадәр генә этноцентрик карашка ия булса да, әсәрләрендә дини төшенчәләргә шактый киң урын бирә.

«Өйгә таба» романындагы конфликт дин һәм этник үзенчәлек төшенчәләренә нигезләнә. Әсәрдә барлык төрки халыклар бердәм булырга тиеш дигән фикер чагылдырыла.

Айясофья христианнар һәм мөселманнар өчен әһәмияткә ия бер урын буларак чагылыш таба. Хрситианнар өчен изге саналып коткарылырга тиеш дип уйланылса, мөселманнар өчен мөкатдәс кабул ителеп, хакимиятнең дәвам иттерелергә тиешлеген аңлата. Бер гыйбадәтханәнең ике тараф өчен төрле мәгънә белдерүе – аларны мотивацияләүче көч хәленә китерә.

Әсәрдә үзәккә куелган Айясофья, Истанбулны яулап алырга тырышкан руслар өчен дә, башкалалары булган бу шәһәрне сакларга тырышкан төрекләр өчен дә ирешергә / сакларга теләгән зур идеалның символын тәшкил итә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Binark N. Ayaz İshakî İdilli (1878–1954) // Kazan. – 1974. – S. 8–17.

2. Eyice S. Ayasofya. İslam ansiklopedisi. – İstanbul: Türkiye diyanet vakfı yayınları, 1991. – S. 4, S. 206–210.

3. Ганиева Р. Искакый ижаты // Мирас. – 1998. – Б. 5, 63–78.

4. Заһидуллина Д. Ф., Закирҗанов Ә. М., Гыйләҗев Т. Ш. Татар әдәбияты – теория тарих. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2004. – 248 б.

5. İshâkî M. A. Üyge taba. – İstanbul: Ötüken Yayınevi. – 120 s.

6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 5 том: Хикәяләр, повестлар, пьесалар (1920–1947) / төзүче: Лена Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 559 б.

7. Kamalieva A. Romantik milliyetçi Ayaz İshakî. – Ankara: Grafiker Yayınları, 2009. – 248 s.

8. Kurban İ. (2014), Yaşlı tarihin yankısı (Bulgar-Tatar tarihi ve medeniyeti). – İstanbul: Bilge Kültür Sanat, 2014. – 224 s.

9. Мусин Ф. Гаяз Исхакый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 192 б.

10. Сәхапов Ә. Исхакый иҗаты. – Казан: Татар «Мирас» китап нәшрияты, 1997. – 368 б.

11. Seydahmet K.C. Kazan edebiyatı ve Ayaz İshaki (төзүчеләр: Tahir Çağatay, Ali Akış, Saadet Çağatay-İshaki, Hasan Agay). Muhammed Ayaz İshaki hayatı ve faaliyeti 100. doğum yılı dolayısıyla. – Ankara: Ayyıldız matbaası. 1979. – S. 150–157.

12. Uzun M. Muhammed Ayaz İshakî'nin «Öyge taba» adlı romanı üzerinde dil ve üslûp incelemesi. Нәшер ителмәгән докторлык диссертациясе. – Kocaeli: Kocaeli üniversitesi sosyal bilimler enstitüsü, 2020. – 809 s.

13. Yarullina Yıldırım R. Tatar nesri ve romantizm estetiği. – İstanbul: Kesit yayınları, 2016. – 191 s.

14. Yuziyev N. h.б. Türkiye Dışındaki Türk Edebiyatları Antolojisi 18 – Tatar Edebiyatı II. – Ankara: T.C. kültür bakanlığı yayınları, 2001. – 480 s.

15. Яруллина Р. Гаяз Исхакый Иҗаты (1897–1906 еллар). – Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000. – 163 б.

УДК 821.512.145

# ПРОБЛЕМА ПОЛОЖИТЕЛЬНОГО ГЕРОЯ В ПРОЗЕ ГАЯЗА ИСХАКИ ПРОСВЕТИТЕЛЬСКОГО ПЕРИОДА

***И.К. Фазлутдинов***
*Уфимский университет науки и технологий (Уфа)*

В данной статье раскрывается характер положительного героя в начальном этапе творчества Гаяза Исхаки в контексте постепенного перехода автора с позиций просветительского реализма к парадигмам критического реализма. Через анализ изменений в социально-политических и общественных взглядах писателя, автор в диахроническом аспекте прослеживает эволюцию созданных им образов. В работе раскрывается индивидуальное своеобразие Гаяза Исхаки в художественном изображении главных героев; подчеркивается противоречивость их внутреннего мира; анализируется концепция человеческого счастья в ранних произведениях писателя. По мнению автора статьи, положительный герой в просветительской прозе Гаяза Исхаки за короткий период претерпевает ряд качественных изменений, эволюционируя из простого сторонника изменений в системе национального образования в борца за самоопределение татарской нации.
**Ключевые слова:** просветительский реализм, критический реализм, произведение, эволюция героя, проблема, концепция счастья.

This article reveals the character of the positive hero in the initial stage of the work of Gayaz Iskhaki in the context of the author's gradual transition from the positions of educational realism to the paradigms of critical realism. Through the analysis of changes in the socio-political and public views of the writer, the author traces the evolution of the images created by him in a diachronic aspect. The work reveals the individual originality of Gayaz Iskhaki in the artistic depiction of the main characters; the inconsistency of their inner world is emphasized; the concept of human happiness in the writer's early works is analyzed. According to the author of the article, the positive hero in Gayaz Iskhaki's educational prose undergoes a number of qualitative changes in a short period, evolving from a simple supporter of changes in the national education system into a fighter for the self-determination of the Tatar nation.
**Key words:** enlightenment realism, critical realism, the work, the evolution of the hero, the problem, the concept of happiness.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЧОРЫ ПРОЗАСЫНДА УҢАЙ ГЕРОЙ ПРОБЛЕМАСЫ

***И.К. Фазлетдинов***
*Уфа Фән һәм технологияләр университеты (Уфа)*

Озак еллар тыелганнар исемлегендә йөртелгәннән соң, XXI йөз башында олуг язучыбыз Гаяз Исхакый иҗатына игътибар бермә-бер артты. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әсәрләренең 15 томлык тулы тупланмасы әзерләнеп 1998–2014 елларда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде; халыкара статустагы гыйльми конференцияләр үткәрелеп, аларда яңгыраган чыгышлар аерым җыентыклар булып нәшер ителде [5, 6, 7]. 2018 елда Уфада Башкорт дәүләт университетында Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулуга багышланган бөтенрусия гыйльми-гамәли конференциясе оештырылды һәм аның материаллары аерым җыентык булып басылып чыкты [1]. Бу үзе үк күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның халкыбыз тарихындагы әһәмияте турында сөйли.

Бүгенге көн әдәбият гыйлемендә язучының 1917 елга кадәрге иҗатын аның «дөньяга карашы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әдәби-эстетик зәвыгы, сәнгатьчә фикерләве, әсәрләренең идея юнәлеше, язу стиле» ягыннан өч чорга бүлеп тикшерү гадәткә кергән:

1. Мәгърифәтчелек дәвере (1897–1904);
2. «Таңчы»лык дәвере (1905–1911);
3. Милләтчелек дәвере (1912–1918) [11: 319].

Аңлашыла ки, һәр чор иҗатының үзәгендә язучының шушы дәвердәге иҗтимагый, әдәби-эстетик карашларын гәүдәләндергән үзенчәлекле герой тора. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның беренче проза әсәрләре авторның мәгърифәтчелек идеалын чагылдырган герой һәм аны борчыган мәсьәләләр тирәсендә формалаша. Шуны әйтергә кирәк, бу герой статик фигура түгел. Әдипнең карашлары үскән саен, ул да сыйфат үзгәрешләре кичерә, аның фикер офыклары киңәя, чынбарлыкка мөнәсәбәте катлаулана. Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897), «Кәләпүшче кыз» (1897), «Бай углы» (1899), «Өч хатын берлән тормыш» (1900), «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) кебек әсәрләре уртак иҗат ысулы – мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылсалар да, алардагы төп каһарманнар үзләренең дөньяга карашлары, күтәргән мәсьәләләренең киңлеге, җәмгыятьне камилләштерү юллары турындагы фикерләре, хәтта ки эстетик идеаллары нисбәтеннән бер-берсеннән шактый аерылалар.

Әдәбият галиме Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «татар әдәбиятында мәгърифәтчелек реализмы агымы укыту ысуллары хакында бәхәсләшеп мәйданга чыкты» [2: 155]. Филология фәннәре докторы Ф.М. Хатипов исә укыту мәсьәләләрен әдәбиятта сурәтләүнең ике юнәлештә баруын ассызыклый: «беренчесе – искечә сабак бирүне, ысулы кадимне тәнкыйтьләү; икенчесе – яңача белем бирүнең, ысулы җәдитнең кирәклеген, зарурлыгын раслау» [12: 273]. Әлеге фикерләрне Гаяз Исхакыйның беренче әсәре – «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897) хикәясенә карата да тулаем кабатларга мөмкин.

Академик М.Х. Хәсәнов күрсәтүенчә, «үзенең темасы белән дә, эчтәлеге ягыннан да бу әсәр әле алда торган сәяси тетрәнүләргә ишарә ясамый, татар тормышында булачак җитди үзгәрешләргә нигез бирми шикелле. <…>. Әсәрдә иҗтимагый тәртипләргә кизәнү дә, социаль проблемалар да, сәяси нәтиҗәләр дә юк. Башлап язучы бары тик аң-белем, тәрбия мәсьәләләрен генә күтәреп чыга» [9: 15].

Хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Хәлим, туган авылында мәдрәсә тәмамлагач, укуын Казанда дәвам итәргә тели. Әнисе Фатыйма һәм укымышлы затлар – Кәрим абзый белән Әсма абыстай ярдәмендә, ул этисе Габдерахманның каршылыгын җиңеп чыгып, аңардан гыйлем эстәргә китәргә рөхсәт ала, хәтта ки этисе улына ун сум акчасын да кызганмый.

Казан мәдрәсәсендә Хәлим яхшы укуы, тәрбиялелеге белән мөгаллимнәре арасында ихтирам казана. Беренче елны ул акча түләп белем алса, икенчесендә түләүдән азат ителә һәм тиздән үзе үк Казанның бер мәктәбенә мөгаллим булып урнаша. Мәдрәсә җитәкчесе Рәшит бай хәйләсе белән аның кызы Маһирәгә өйләнүдән баш тартып, Габдерәхим мөгаллим кызы Галия белән никахка керә һәм бәхетле гаилә кора [9: 31–49].

Шулай итеп, «әсәрнең төп мәгънәсе – кешенең гаиләдә, тормышта бәхетле булуы өчен зарурый шарт – уку, белемле, тәрбияле булу» [9: 15] дигәнгә туры килә. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, биредә «кешенең әхлагы турыдан-туры аның белеменә бәйләп карала» [2: 155].

Хикәядә Гаяз Исхакый «бәхет» төшенчәсен шактый тар – шәхси тормыш һәм гаилә кысаларында гына карый, әлегә гомум милләт, җәмгыять дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Ләкин үзәк герой Хәлимнең, (ә димәк, авторның да), уй-фикерләре шул юнәлештә үсә баруын егетнең Казанга китәр алдыннан этисе белән килеп чыккан бәхәсеннән күрергә мөмкин.

«Дөньяда килүдән мәкъсуд (теләк, омтылыш. – *И.Ф.*) – дөньяда гына ничек җитте шулай көн уздыру түгел, бәлки үземез рәхәт яшәп вә башка мөселман карендәшләремезнең дә рәхәт гомер кичерүләренә тырышып вә гайрәт кылып, ахирәт көнендә әбәди мәсгудиятләр (мәңгелек бәхет. – *И.Ф.*) ирешмәктер, болар өчен тәхсиле гыйлемнән башка бернәрсә берлә хасил була торган түгел, шуның өчен дә мәдрәсәләргә барып гыйлем өйрәнергә кирәк [9: 32]», – ди ул. Димәк, Хәлимнең максаты шәхси бәхеткә ирешү белән генә чикләнми, ул гыйлем-мәгърифәт аша барлык «мөселман карендәшләремезне» дә бәхетле итәргә тели. Ләкин, кызганычка каршы, геройның әлеге максаты аның эш-гамәлләрендә берничек тә ачылмый, коры вәгазь сату булып кына кала.

Шул ук вакытта, автор Рәхимә абыстай авызыннан барлык мәдрәсәләрнең дә, барлык укыту алымнарының да бер түгеллеге, аларда дөньяви белем бирү һәм тәрбия эше бергә алып барылырга тиешлеге хакындагы фикерләре белән дә уртаклаша. «Менә монда Сәгъди хәзрәт шәкертләре бар, – ди ул. – Алар да шул ук мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кыланып бетәләр, берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең, аларны монда көтеп торалар. Ул, шәкерт булгач та, бары да әдәпле булмый, әдәп өйрәтсәләр генә әдәпле була» [9: 41]. Хәлим биредә белем һәм әхлак камиллеге аша рухи гармониягә, ә димәк, шәхси бәхеткә ирешкән идеаль герой дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин фикеренчә, «җәдитчелек шавы әдәбияты Муса Акъегет, Заһир Бигиевлардан башланса, әдәбиятта ысулы җәдит Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән башлана» [3: 211]. Галим шушы хикәядән соң язылган «Бай углы», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын берлән тормыш» әсәрләрен идея-тематика, стиль уртаклыклары ягыннан Исхакый иҗатындагы аерым этап итеп бәяли һәм аның мәшһүр «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестенә кадәр дәвам итүен күрсәтә [3: 211]. Санап үтелгән әсәрләрдә үзәк герой җәһәтеннән язучы иҗаты өчен генә түгел, ә бөтен татар мәгърифәтчелек әдәбияты өчен мөһим булган сыйфат үзгәрешләрен күрергә мөмкин. Мәсгуд Гайнетдин билгеләвенчә, «яңа реалистик проза, мәгърифәтчелек реализмына хас идеал гәүдәләнеше, заманының матур максатларына ирешү юлын күрсәтүче, әдәпле, эшчән, сөйкемле үрнәк мулла абзыйлар, сәүдәгәрләр, әдәпле егетләр, гүзәл кызлар образларын үзәккә куеп, бу «алдакчы дөньяда» аларның ничек <…> әүлиядәй саф яшәүләрен күрсәтергә дә өлгерми, Г. Исхакый тормышның интегүле язмышлы Камәрләрен («Кәләпүшче кыз») әдәбият түренә китереп кертә» [3: 212].

Чынлап та, Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» (1897) хикәясеннән соң язылган әсәрләрендәге үзәк геройлар башка мәгърифәтче язучыларның хикәя-повесть каһарманнарыннан шактый үзгә. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестендагы Хисаметдин менла, Закир Һадинең «Җиһанша хәзрәт» повестындагы Хәсән мулла, Риза Фәхретдиновның «Сәлимә яки гыйффәт», «Әсма яки гамәл вә җәза» әсәрләрендәге Сәлимә, Әсма кебек идеаллаштырылган образлардан аермалы буларак, Гаяз Исхакыйның геройлары реалистик планда сурәтләнә. Кеше язмышына белем, тәрбиянең генә түгел, ә җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый факторларның да хәлиткеч йогынтысы язучы тарафыннан татар әдәбиятында беренчеләрдән булып тасвирлана башлый. Бу сыйфат аның һәр героеның язмышына да хас диярлек.

Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» (1897) повестендә Кәримә, ире үлеп, улы Габделәхәтне мәдрәсә интернатына урнаштыргач, теккән кәләпүшләрен Сәлимовлар кибетенә илтеп тапшыру эшен яшүсмер кызы – Камәргә йөкләтеп, аны бер ялгызын ирләр янына чыгарырга мәҗбүр була. «Чыгармый хәле юк! Чыгармаса, акча юк, башка чыгарга кеше юк. Ай, фәкыйрьлек ниләр күрсәтә?! [9: 55]» – дип яза автор. Димәк, үзәк геройны һәлакәткә илтүче сәбәпләрнең берсе социаль эчтәлекле, ягъни фәкыйрьлек. Нәтиҗәдә, физик яктан да, мораль-әхлак сыйфатлары да ныгып җитмәгән кыз Вафа исемле бозык приказчикның татлы сүзләренә алданып, сафлыгын югалта; Зөһрә карчык «ярдәмендә» кулдан-кулга китеп, фәхешханәгә килеп эләгә, яман чир эләктерә; дәваланып чыкса да, җәмгыятьтә үз урынын табалмыйча, элекке шөгыленә кайта һәм ахырда кабат-кабат җенси авырулар белән чирләп, бала тапканда вафат була. Безнең фикеребезчә, Камәрнең трагедиясен, мәгърифәтчеләргә хас булганча, бары тик ана тәрбиясе һәм белем җитмәүгә генә кайтарып калдыру хакыйкатькә туры килми. Юкса автор: «Камәрнең фатирга акчасы, расхутка акчасы юк иде, һәммәсе кирәк! Фатирга акча сорыйлар! Кибеттә кенәгә тулган! Анда акча кирәк иде. Ни эшләсен?.. Кемгә киңәш итсен?.. Кемнән гакыл сорасын – һичкем юк» [9: 68] яисә «Шулай итеп Камәр больнистан аерылды. Ләкин ничек тамак туйдырсын? Кайда торсын? Ни берлә дөньясын кичерсен? <…>. Ике тәүлек буе ашаган юк [9: 74–75]», – дип, героеның авыр матди хәленә кабат-кабат басым ясамас иде. Димәк, әлеге шәхес фаҗигасен рухи сәбәпләр белән бергә, фәкыйрьлек, акчасызлык кебек социаль факторларга таянып та аңлатып була. Кешенең бәхет-бәхетсезлеген аның социаль хәле, әйләнә-тирәлек,

иҗтимагый тәртипләр белән бәйләү мәгърифәтчелек әдәбияты өчен, чын мәгънәсендә, яңалык иде.

«Теләнче кыз» романының 1901–1907 елларда язылган беренче өлешендә дә үзәк геройның язмышы мәгърифәтчелек реализмына хас традицион схемага сыешмый, вакыйгаларга янә социаль мотивлар килеп керә. Әсәрнең төп каһарманы Сәгадәт (бәхет. – *И.Ф.*) исемле. Димәк, ул дөньяга бәхетле яшәр өчен килгән. Ата-анасы ярлы гына булсалар да, кызларына тиешле тәрбия һәм белем бирәләр. Ул мулла кызы белән әхирәт була, күркәм гадәтләргә өйрәнә. Шулай итеп, мәгърифәтчелек реализмы калыплары буенча, Сәгадәтнең тормышы имин һәм бәхетле булырга тиеш кебек. Ләкин алай килеп чыкмый. 1897 елны иген уңмый һәм кызның алтмыш яшьлек әтисе Шәрип карт, ачлыктан куркып, гаиләсе белән шәһәргә күчәргә карар кыла. Тик калада аларны беркем дә көтеп тормый. Шәрип карт та, Хөсниҗамал карчык та яшәрләренә урын, тамак туйдырырга эш таба алмыйча, ачлыктан һәм авырулардан үлеп китәләр, ә уналты яшьлек Сәгадәт хәер сорашып көн күрергә мәҗбүр була. Бай углы, «потомственный почетный гражданин» Габдулла Әмирханович Сәгадәтне капкадан капкага йөргән чагында хәерчеләр төркеменнән аерып, аулакка алып керә һәм мәсхәрәли. Нәтиҗәдә кыз фәхешханәгә килеп эләгә.

Сәгадәтнең фаҗигасен бары тик рухи сәбәпләр белән генә аңлатып булмый. Ул тиешле тәрбия алган, укыган. Ләкин заманның аяусыз чынбарлыгы, кешегә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен җәмгыятьтә шартлар тудырылмавы аркасында, кыз бәхетсезлеккә дучар була. Фәхешханәгә дә аны җан саклап калу ихтыяҗы өстерәп килә, ул анда ачтан үлмәс өчен бара. Күренүенчә, биредә шәхес трагедиясен социаль-иҗтимагый сәбәпләр белән аңлату инде, гомумән, өстенлек ала һәм бу сыйфат язучының мәгърифәтчелек реализмы кысаларын җимереп чыгып, тәнкыйди реализм позицияләренә басуын билгеләп тора. Профессор М.Җ. Сәхәпов күрсәтүенчә, әлеге әсәрләрдә хатын-кыз язмышы милләт язмышы белән тәңгәл куела һәм җенси тигезсезлек киләчәктә халыкның юкка чыгуының бер сәбәбе булу мөмкинлеге турында кисәтелә. «Хатын-кызны ихтирам итмәгән, аны гаилә учагын саклаучы, балаларга тәрбия бирүче шәхес итеп күрмәгән, рухи үсеше һәм камилләшүе өчен тиешле шартлар тудырмаган милләтнең киләчәге томанлы», – ди галим [10: 74–75].

Димәк, «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән аермалы буларак, автор биредә үзәк геройларының язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерә, аларның рухи сәламәтлеге гомум милләт киләчәген билгели. Шулай итеп, «бәхет» төшенчәсе «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендәге шәхси бәхет кысаларына гына сыймыйча, гомум милләт дәрәҗәсенә күтәрелә. Язучы бары тик гомум милли бәхеткә ирешкәндә генә, ягъни халыкның һәр вәкиленә җәмгыятьтә үз урынын табарга мөмкинлекләр тудырылганда гына, аерым шәхес үзен бәхетле исәпли ала дигән карашка күчә.

Гаяз Исхакыйның мәгърифәтчелек чоры иҗатындагы герой эволюциясен югарыда анализланган әсәрләрне 1904 елда дөнья күргән атаклы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый-публицистик повесте белән чагыштырма планда тикшергәндә аеруча ачык күрергә мөмкин. Әсәр үзәгендәге каһарман язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерү биредә ярылып ята.

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны «геройсыз әсәр» дип атый [4: 161]. Чынлап та, «XXI гасырның соңгы унъеллыгын тасвирлый башлаганчы, автор сүзне гомуми рәвештә, ягъни тулаем милләт хакында алып бара. Бары тик болгарлар тәмам юкка чыгарга берничә ел калгач кына, әсәргә Җәгъфәр исемле аерым бер шәхес – тарихчы, язучы образы килеп керә» [4: 162]. Фоат Галимуллин фикеренчә, «әлеге әсәрдә Җәгъфәр чын мәгънәсендә үзәк образ түгел, бәлки ул – автор күтәргән мәсьәләләрнең олылыгын һәм әһәмиятен тагын да көчәйтү өчен хезмәт итә торган сәнгать чарасы» [4: 162].

Шулай итеп, Җәгъфәр образы повестьта милләт символы булып хезмәт итә. Ул – гомумиләштерелгән образ. «Соңгы болгар»ның Болгар хәрәбәләрендә манара астында калып һәлак булуы да очраклы түгел. Дәүләтсез халыкның киләчәге юк – бу үлемнән килеп чыккан төп нәтиҗә шул. Җәгъфәрнең борынгы Ватанында манара астында калуы да милләтнең һәлакәтенә, беренче чиратта, ул үзе сәбәпче икәнлегенә ишарәли.

Хәер, автор ишарәләп кенә калмый, ә әсәргә керешендә бу сәбәпләрне – биш «манигы тәрәкъкый»ны атап ук уза. Болар исәбенә, беренчедән, тормыш тоткасының иске фикерле руханилар кулында булуы; икенчедән, мәктәп-мәдрәсәләрнең аз санлылыгы, булганнарында да уку-укыту процессының тиешле югарылыкта алып барылмавы; өченчедән, милләткә хезмәт итүчеләрнең фәкыйрь булып, тамак хакына эшләве; дүртенчедән, урыс мәктәпләрендә укымау, ә димәк, дөнья мәдәниятеннән читләшү; бишенчедән, башкарган эшләрнең нәтиҗәсезлеге, башлау-ташлау һ.б. керә [9: 154–159]. Ягъни әсәрдә тасвирланган вакыйгалар язучының иҗтимагый һәм фәлсәфи карашларына иллюстрация вазифасын үти. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның өчтән ике өлеше патша цензурасы тарафыннан киселеп, бары тик 1990нчы елларда гына олуг галимебез Миркасыйм Госманов тарафыннан табылып, яңадан гыйльми әйләнешкә кертелүе дә [8: 200–240] повестьның заман чынбарлыгына, милләт сагында торырга тиешле дин әһелләренә, акчаларын халык файдасына тотар урынга, «курчак туйлары» үткәреп, җилгә очырган татар байларына, Русиянең колониаль сәясәтенә гаепләү акты булып яңгыравын күрсәтә. Язучы милли инкыйразга каршы көрәшкә бар гомерен багышлады.

Шулай итеп, Гаяз Исхакый иҗатындагы мәгърифәтчелек чоры озакка сузылмаса да, андагы үзәк герой катлаулы үсеш, эволюция юлы үтә дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Башта ул «саф» мәгърифәтчеләргә хас булганча, «белем, тәрбия һәм тән камиллеге»нә ия булган идеаль шәхес сыйфатында тасвирланса, соңрак дөньяви, реалистик төс ала һәм әйләнә-тирәлек, социаль- иҗтимагый күренешләр белән бәйләнештә сурәтләнә башлый, кешенең бәхет-бәхетсезлегенең сәбәпләре итеп, аның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе генә түгел, ә җәмгыять тәртипләре дә күрсәтелә; соңга таба исә үзәк герой, гомумән, милләт символына әверелә. Болар һәммәсе дә Гаяз Исхакыйның фикер үсешен, рухи эволюциясен билгеләп тора. Язучы әсәрләрендәге геройлар исә аның белән бергә фикри һәм гамәли үсеш юлын кабатлыйлар һәм үз язмышларын татар халкының язмышыннан аерым карамаучы, бу юлда җаннарын корбан итәргә әзер милләт каһарманнарына әвереләләр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Актуальные проблемы современной татарской филологии: материалы V Всероссийской заочной научно-практической конференции с международным участием, посвященной 140-летию классика татарской литературы и общественного деятеля Гаяза Исхаки (1878–1954) (г. Уфа, 18 мая 2018) / отв. редактор И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2018. – 376 с.

2. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүче-авторлар: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина; фәнни редакторлар Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

3. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 319 б.

4. Галимуллин Ф. Эзләнү вакыты: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.

5. Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2000. – 296 б.

6. Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 11 декабрь, 2008) / төзүче Ф.Х. Миңнуллина. – Казан, 2008. – 376 б.

7. Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 450 с.

8. Госманов М. Гасырдан – гасырга. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 488 б.

9. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда / Беренче томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Лена Гайнанова; фәнни редакторлар: Мансур Хәсәнов, Рамил Исламов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 1 т: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). – 399 б.

10. Сахапов Минахмет. Золотая эпоха татарского ренессанса: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 319 с.

11. Татар әдәбияты: теория, тарих / Төзүчеләре: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

12. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.

УДК 821.512.145+070

# ФАТИХ АМИРХАН О ГАЯЗЕ ИСХАКИ
## (по материалам газеты «Кояш»)

*Г.А. Хуснутдинова, А.Ф. Ганиева*
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются посвященные Г. Исхаки литературно-критические и публицистические статьи Фатиха Амирхана, нашедшие отражение на страницах газеты «Кояш» (1912–1918). Писателем выявляются основные характеристики его общественной и литературной деятельности. Он высоко оценивает место Г. Исхаки в истории татарской литературы и культуры.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Ф. Амирхан, татарская литература, публицистика, рецензия.

The article discusses the literary-critical and journalistic articles of Fatih Amirkhan devoted to G. Iskhaki, which were reflected in the pages of the newspaper «Koyash» (1912–1918). The writer identifies the main characteristics of his social and literary activity. He highly appreciates the place of G. Iskhaks in the history of Tatar literature and culture.
**Key words:** G. Iskhaki, F. Amirkhan, Tatar literature, journalism, review.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАКЫНДА ФАТИХ ӘМИРХАН
## («Кояш» газетасы материаллары буенча)

*Г.А. Хөснетдинова, А.Ф. Ганиева*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX йөз башы әдәби хәрәкәтенә һәм мәдәни-иҗтимагый мәсьәләләргә һәрдаим үз карашын, мөнәсәбәтен җиткерүче язучы, публицист Фатих Әмирханның язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый иҗатына, шәхесенә карата әйтелгән фикерләре, язылган мәкаләләре, бәяләмәләре бар. Дөрес, алар күп түгел, әмма аларда күтәрелгән фикерләрнең әһәмияте игътибарга лаек.

Фатих Әмирханның актив язышкан чоры аның «Кояш» газетасы нәшер ителгән елларга карый. Иҗтимагый-сәяси, әдәби, либераль-демократик юнәлешле «Кояш» газетасының беренче саны бертуган Кәримовлар ярдәме белән 1912 елның 10 декабрендә чыга. Мөхәррир итеп журналист, педагог Зәкәрия Садретдин улы Садретдинов (1880–1930) билгеләнә, ә сәркәтиблеккә Фатих Әмирхан чакырыла. Газетаның исеме астында мондый сүзләр языла: «Мөгайян (*ачык, анык*) бер партия программасына иярми торган көндәлек тәрәккыйпәрвәр татарча газетадыр», ягъни газета бер нинди агымнарга да иярми, бары тик дөреслек хакында гына язачагын белдерә. Газетаның беренче битендә көн кадагына суккан баш мәкалә, икенче, өченче битләрдә «Хариҗи хәбәрләр», «Дахили хәбәрләр», «Казан хәбәрләре» һәм игъланнар урын ала. Үзен көндәлек газета дип белдергән «Кояш» баштарак көн саен чыга алмаса да, тора-бара көндәлеккә әйләнә. 1913 елның июньнәреннән башлап кайбер саннары хәтта алты битле булып басыла.

Ф. Әмирханның газета битләрендә басылган мәкаләләре аның язучылыктан кала публицистика да яраткан жанры икәнлеген дәлилли. Коляскасына бәйләнгән булуына карамастан, ул үзен җәмәгать эшлеклесе итеп саный. Чөнки ул җанын әрнеткән, кайгыга салган хәлләр, вакыйгалар хакында дәшми кала алмый, үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Дәүләт Думасы эшчәнлеге, милли мәсьәлә, дини һәм милли оешмалар, Харитоновның Коръәнне бозып бастыруы, Казан мәдрәсәләре, хатын-кызларга белем, ирләр белән тигез хокук бирү мәсьәләләре һ.б. шундыйлар хакында төрле имзалар белән (Ф., Ф. Ә., Ф. Әмирхан, Фатих Әмирхан, Фатих, Т-д, Ташмөхәммәд) актуаль, үткен телле мәкаләләрен бастыра.

Беренче мәртәбә «Кояш» газетасында Г. Исхакый хакында Ф. Әмирхан «1913 нче ел. Милли эшләр» дип аталган хисап-күзәтү мәкаләсендә яза. «Кояш»ның 1914 елгы 1 гыйнвар (302 нче) санында «Ф. Әмирхан» имзасы белән басылган язмасында ул 1913 елгы татар дөньясына, татар әдәбияты һәм вакытлы матбугатына күзәтү ясый һәм аны болай дип тасвирлый: «Үткән сәнә безнең өчен, үзенең сәләфләре

*(үткәндәгеләре)* шикелле үк, шатландырырлык бәхетләргә караганда, күбрәк кайгылар вә муаффәкыятьсезлекләр бирде. Бу ел эчендә без әллә никадәр матур сүзләр сөйләдек, әллә никадәр аллы-гөлле хыял кордык, ләкин шул сөйләнгән вә хыял ителгән нәрсәләрнең уннан берсен дә эшкә чыгара алмадык, сүзләр сүз көе, хыяллар хыял көе калдылар» [1]. Язучының елның файдасыз, уңышсыз үтүенә эче поша. Фикерен дәвам итеп гимназияләр, приютлар, татарлар яшәгән урыннарда мәктәпләр ачарга сүз биреп тә берсен дә булдыра алмауга үкенечен белдерә. Хәтта Думада да хәрәкәт туктап, пыскып калуына борчыла.

Әдәбиятта да шул хәл күзәтелә. Ф. Әмирхан 1913 елны «әдәбиятымыз өчен ачлык елы» дип характерлый. Әдипләрнең яңа, матур әсәрләр иҗат итмәве, бары элек елларда язылганнар белән канәгать булулары бәян итә. «Тукаемыз үлеп китте, Сәгыйд Рәмиевнең бер шигырен булса да күрер ирешә алмадык, Г. Камал ел буе авырып уздырды. Гаязымыз сөргеннән азат ителсә дә, бер җирдә тыныч тора алмый торган булып кына азат ителде. Ул быел бик аз язды....» [1] – дип, борчыла, югалтуларны саный. (1912 елның гыйнварыннан Архангель губернасының Мезень шәһәрчегенә сөргенгә озатылган Г. Исхакый Романовлар Йортының тәхеткә утыруына 300 ел тулу уңае белән 1913 елның апрелендә игълан ителгән амнистия карары нигезендә тоткынлыктан чыгарыла, әмма аңарга Казанда яшәргә рөхсәт ителми.)

Әмма җәмгыятьтә, әдәбиятта уңышлар булмаса да, татар вакытлы матбугатының тәрәккый итүе, язучыны шатландыра. Ул күп газеталарның көндәлеккә әйләнүен, Гаяз Исхакыйның Петербургта «Ил» газетасын оештырып, нәшер итүен, башка өлкәләрдә газета-журналларның чыга башлавын шатланып сөйли.

Публицистның Казан байлары тормышын, аларның урысларга хезмәт итүләрен, куштанлыкларын тәнкыйтьләп язылган «Тормыш валчыклары» (1914, 14 гыйнвар, «Ташмөхәммәд» имзасы белән) мәкаләсендә дә Г. Исхакый исеме телгә алына. Ул аның әсәрләре хакында «дингә зарарлыларның да бигрәк зарарлысы» дип язган «Вакыт» газетасыннан көлеп, анда «татар халкының Гаяз Исхаков, Габдулла Тукай яки Йосыф Акчура углының сурәтенә табына башлавыннан куркып» басылган мәкаләләрнең ахмаклык күренеше дип атый.

Ф. Әмирханның «Мөгаллим» дигән мәкалә-рецензиясе 1913 елда әсәрнең «Шәрык клубы» залы сәхнәсендә куелу уңае белән «Кояш»ның 1914 елгы 27 гыйнвар (322 нче) санында «Ф. Ә.» имзасы белән басылган. Бәяләмәне тәнкыйтьче Г. Исхакый иҗатына бәя бирүдән башлый, аны «зур мөхәррир, зур талант» дип атый һәм «Татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы безнең алда авыр, фаҗигале вә өмидсез булып басып торадыр. Моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә, рухани трагедиягә әйләнә», [3] – дип, әсәргә югары бәясен бирә. Моңа өстәп драманың бишенче пәрдәсе турында тәнкыйть фикерләрен, аның алдагы пәрдәләргә ябышмавын, артык булуын, артистлар тарафыннан төшерелеп калдырылуын хуплый. Артистларның уйнаулары да Ф. Әмирхан игътибарыннан читтә калмый. В. Мортазин-Иманский (1885–1938), Г. Болгарская (1891–1968) һәм Г. Болгарский (1884–1927), Үзбәк Тинчуриннарның (1887–1938) рольләрен оста, табигый, дөньяви башкарулары тәнкыйтьче тарафыннан уңай бәяләнә. Пьесаны уйнаучы артистлар да «шундый бер иттифак вә шундый бер мәһарәт белән уйнадылар ки, караучыларда эзе җуялмаслык авыр, ләкин дөрест тәэсир калдырдылар», [3] – ди. Бу исә, язучы фикеренчә «әгәр яхшы пьесалар булса, артистларымызның да бик яхшы тәрәккый итә алачакларын күрсәтүче» факторның берсе.

1916 елда татар вакытлы матбугатына ун ел тулу датасы зур итеп билгеләп үтелә. Г. Исхакый шул уңай белән, юбилей дип тормастан, 1916 елгы «Сүз» газетасының 20 гыйнвар (12 нче) санында басылган «Йолдыз» юбилейсы» фельетонында газетаның мөхәррире Һ. Максудины милли иман юклыкта, мәсләксезлектә, сәясәткә ярашып эш итәргә тырышуында гаепли.

Ф. Әмирханның «Кояш» газетасының 1916 елгы 3 һәм 4 март (926, 927 нче) саннарында «Ф. Ә.» имзасы белән басылган «Йолдыз» һәм Гаяз Исхаков» мәкаләсе Гаяз Исхакый белән «Йолдыз» газетасы мөхәррире Һади Максуди арасында булган шушы полемика-бәхәсне яктыртуга багышланган.

Ф. Әмирхан Г. Исхакыйның җәмгыятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең, проблемаларның нинди булуына карамастан каләмен дөрес куллануына, һичбер нәрсә белән дә хисаплашмастан әйтеп бирүенә, шул юлда армый-талмый эшләвенә, фикер киңлегенә, курку белмәвенә сокланып «Менә шунда Гаязлык!» – дип, фикерен тәгаенләп куя.

Ул Һади Максудиның Г. Исхакыйны «милләтчелеге бер битлек кенә» дип гаепләвенә каршы чыга. Аның каләменә югары бәя бирә, көчле, дөреслек юлында хезмәт итүче мөхәррир һәм язучы булуын раслый. Аңарга шөһрәт тә, байлык та кирәк түгеллегенә ышанып әйтә. Максудиның шарлатан дип Исхакыйга таккан исемнең хакыйкатькә туры килмәвен дәлилләп, «милләтебез хадимнәре арасында Г. Исхакый кебек шарлатаннар күбрәк булсын иде дип Ходайдан соравын» белдерә. Аны «сүнә белми торган бер ялкыннан ... гыйбарәт бер мөхәррир» итеп таный һәм каләм көченә соклана.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң матбугатта цензура бетерелгәч Г. Исхакыйның моңа кадәр рәсми тыелып килгән «Зөләйха» пьесасын да сәхнәгә кую рөхсәт ителә. Ул беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан аның җитәкчесе – күренекле артист һәм режиссер Габдулла Кариев (1886–1920) бенефисы рәвешендә 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Беренчеләрдән булып бу хакта матбугатта Фатих Әмирхан чыгыш ясый. «Кояш»ның 1917 ел, 19 март санында дөнья күргән бәяләмәдә ул, беренче чиратта, әсәрнең киң иҗтимагый-милли әһәмияткә ия булуына басым ясый: «Бу иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте *(изге)* юлында һичбертөрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә куәтле рухка малик фәрдләре *(ия шәхесләре)* барлыгын күрсәтә вә бөтенлегемезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер вәсикадыр *(нигезле дәлилдер)*» [4]. Моннан соң Ф. Әмирхан пьесаның һәм аның буенча куелган спектакльнең сәнгати сыйфатына да игътибар итә. Һәм «мәүҗүд *(булган)* пьесаларымызның 99 фаизыннан *(процентыннан)* өстен тора вә урыны-урыны белән гүзәллекнең югары дәрәҗәсенә» [4] ирешә дип бәяләнгән бу әсәрнең сәхнәдә Г. Кариев, Г. Болгарская, Камал II (1896–1948) кебек танылган артистлар тарафыннан «гаять иҗтиһат белән» уйналуын күрсәтә.

Әлеге бенефиста татар театрының йортын оештыру мәсьәләсе күтәрелә, чөнки үз биналары булмау сәбәпле, татар театр труппалары моңа кадәр үз спектакльләрен рус театрларында аренда өчен күп акчалар түләп һәм тамашачы өчен уңайсыз вакытта күрсәтергә мәҗбүр булалар. Татар театрының киләчәге өчен аның үз бинасы булу мөһим икәнен яхшы аңлаган Кариев аны хәл итүдә беренче адымнарны ясый һәм бенефисыннан килгән акчаны татар театры бинасын төзү фондына бирергә карар кыла. Аның «Ирек йорты» дип аталачак милли театр һәм гомумән сәнгать бинасын төзү башлангычы ул вакытта татар җәмәгатьчелегедә киң яклау таба [2: 102]. «Ирек йорты» оештыру фикерен Г. Исхакый да хуплый. 1917 елда Казанга килүе уңаеннан оештырылган кичәдә ул үзенең «Тартышу» спектакленнән киләчәк бөтен гонорарын «Ирек йорты» төзү фондына бүләк итәчәген игълан итә.

Ләкин ни кызганыч, 1917 елда илдә барган сәяси үзгәрешләр сәбәпле, бу матур башлангыч тормышка ашмый кала, бина төзелми.

Ф. Әмирханның «Гаяз әфәнде шәрәфенә» (Кояш, 1917, 11 һәм 13 апрель) исеме белән басылган мәкаләсе Г. Исхакыйның Казанга килүе хакында бәян итә. Казан җәмәгатьчелеге әдипкә зур хөрмәт күрсәтә. Аның килүенә багышлап күпсанлы очрашулар, митинглар үткәрелә, банкетлар бирелә. Шулар арасында аеруча әһәмиятлесе 7 апрельдә «Новый клуб» залында киң җәмәгатьчелек катнашында үткәрелгән банкет була. Бу мәҗлестә унбиштән артык татар оешмасыннан 160 тан артык кеше катнаша. Мәҗлестә рәислек иткән Ф. Әмирхан билгеләвенчә җәмәгатьчелек «иске хөкүмәт вакытында Казанда ачыктан йөри дә алмый торган «куркыныч» мөхәррирен бу көн ачыктан җыелышып сәламли һәм алкышлый» [5].

Г. Исхакый беренче чыгышы белән үк җыелышка эшлекле төс бирә. Күпсанлы чыгыш ясаучылар ул вакыттагы татар дөньясының мөһим мәсьәләләре турында

сөйлиләр. Шул ук вакытта чыгышларның һәркайсында Ф. Әмирханның мәкаләсендә әйтелгәнчә, «Гаяз әфәнденең милләт күңелендә бәлэнд *(зур)* хисләр уяткан вә уята торган , бөтен кысылган вә изелгәннәрнең хокукларын химая итә *(яклый)* торган, демократ милләтнең иң бөек демократ мөхәррире булучылыгы хәтергә төшерелә вә шул мөхәрриргә төрле-төрле бер-берсенә охшашмый торган – сыйныфларның һәммәсе тарафыннан самими ихтирам гарыз ителә *(тәкъдим ителә)* иде» [5]. Мәҗлестә Гаяз Исхакыйны котлап адреслар, төрле бүләкләр тапшырыла, «Зөләйха» әсәрен бастырып чыгару өчен мөхәрриреннән рөхсәт алына. Чыгышлар һәм котлаулардан соң Г. Исхакый тагын сүз ала. Аның бер сәгатькә якын дәвам иткән нотыгы бөтен мәҗлескә нык тәэсир итә. Аны озаклап алкышлыйлар.

Шулай итеп, телгә алынып үтелгән мәкаләләр аша без Гаяз Исхакыйның үз заманы татар зыялыларының хөрмәтен казанган шәхес икәнлеген күрәбез. Ф. Әмирхан аның иҗатын, иҗтимагый эшчәнлеген тормыш вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә сурәтли, югары бәясен бирә.

ӘДӘБИЯТ


1. Әмирхан Ф. 1913 нче ел. Милли эшләр // Кояш. – 1914. – 1 гыйнвар.
2. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.
3. Ф. Ә. «Мөгаллим» // Кояш. – 1914. – 27 гыйнвар.
4. Ф. «Зөләйха» // Кояш. – 1917. – 19 март.
5. Ф. Гаяз әфәнде шәрәфенә // Кояш. – 1917. – 11, 13 апрель.



УДК 82:801.6


## ОБРАЗ ГАЯЗА ИСХАКИ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ


***Н.М. Юсупова, А.Ф. Юсупов***

*Казанский федеральный университет (Казань)*



В данной статье образ Г. Исхаки рассматривается как национальный идеал, выявляются основные философско-эстетические предпосылки формирования концепции идеала в татарской поэзии и роли в этом процессе культурно-общественных воззрений. В татарской литературе начала XX века произошли качественные изменения, результатом которых стало возникновение новой концепции идеала, появляется образ «национального хадима».

В истории каждого народа есть личности, жизнь и деятельность которых, несмотря на социально-политические катаклизмы в обществе, сохраняют в памяти и сознании поколений образ национального героя, ибо наследием и жизнедеятельностью таких личностей оценивается вклад каждого народа в мировую культуру. В этом смысле они являются не только талантливыми сыновьями своего народа, но и представителями конкретной национальной культуры, национальным идеалом и образцом совершенства, чистоты и гуманизма, из которой и формируется мировая цивилизация. В силу своей культурной значимости в творчестве Г. Тукая Г. Исхаки интерпретируется как национальный хадим.



**Ключевые слова:** идеал, национальный хадим, Г. Тукай, Г. Исхаки.



In this article, the image of G. Iskhaki is considered as a national ideal, the main philosophical and aesthetic prerequisites for the formation of the concept of the ideal in Tatar poetry and the role of cultural and social views in this process are revealed. In the Tatar literature of the early twentieth century, qualitative changes took place, the result of which was the emergence of a new concept of the ideal, the image of the «national khadim» appears.

In the history of each nation there are individuals whose life and activities, despite the socio-political cataclysms in society, preserve the image of a national hero in the memory and consciousness of generations, because the heritage and vital activity of such individuals assesses the contribution of each nation to world culture. In this sense, they are not only talented sons of their people, but also representatives of a specific national culture, a national ideal and a model of perfection, purity and humanism, from which the world civilization is formed. Due to its cultural significance in the works of G. Tukai, G. Iskhaki is interpreted as a national khadim.



**Key words:** ideal, national khadim, Tukai, Iskhaki.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ОБРАЗЫ

***Н.М. Юсупова, А.Ф. Юсупов***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый шәхесләре XX йөз башы татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере үсешендә гаять зур урын тота. Аларның иҗаты әдәбият мәйданында үзенчәлекле үрнәк-өлге, әдәби бизмән булып күтәрелеп кенә калмый, шәхесләре татар милләте өчен идеалга, әйдаманга әверелә.

Билгеле булганча, XX йөз башында – татарларның милләт буларак оешкан чорында – халыкны туплап, җыйнап торырлык хадимгә, әйдаманга ихтыяҗ барлыкка килә. Г. Исхакый бу күренешне болай аңлата: «Элгәреге заманда бабайларыбызның үзләренең милләтләрен саклар өчен тоткан юллары бер генә булган... Читләрдән килә торган һәртөрле мәдәни, гыйльми, дини, гадәти хәрәкәтләрнең һәммәсен дингә каршы дип сеңдергәннәр. Шуның аркасында безне – Русиянең эчендә калган бер уч Идел буе татарларын руслашудан саклап алып кала алганнар. Бабайларыбызның бу хәрәкәте ул вакытта иң табигый бер хәрәкәт булган» [7: 175–176]. Ләкин XX йөз башында бу юл белән генә үсеп, алгарышка юл алып булмаячагы ачыклана. Агымдагы чорда шушы ихтыяҗны канәгатьләндерү юлында халыкка игелек күрсәтүче, аңа риясыз хезмәт итүче, тормыш ләззәтен татарга хезмәттә күргән, милләт үсеше, «халык бәхете, хаклык өчен көрәшүче, кешенең фикри-рухи азатлыгын таләп итүче» [10: 12] шәхес кирәклеге ачыклана, аның «...халык мәнфәгатьләре өчен иҗтимагый әһәмияте булган эшчәнлеге» [9: 88], бөтен катлаулар бәхетен яклап көрәшүче гуманист булуы әһәмиятле санала. Мондый шәхесне «милләт хадиме», ягъни милләткә хезмәт итүче буларак күтәреп чыгалар.

Аның нигезен И. Гаспралы тәкъдим итә, соңрак бу фикерләр Г. Баруди тарафыннан үстерелә. Аның фикеренчә, «шәхес өчен иң зур бәхет иленә хезмәт итү булса, «милләт хадиме» өчен ул – милләт бәхете өчен көрәшү» [15: 36]. 1907 нче елда Галимҗан Барудиның эшчәнлегенә 25 ел тулуга багышлап язылган «Дамелла Галимҗан әл-Баруди» хезмәтендә Йосыф Акчура бу фикерләрне үстереп алып китә. Иҗтимагый фикер иясе «милләт хадиме»нең төп бурычын «милләтнең диндар, мөтәфәннин, күркәм холыклы, һөнәрле, куәтле булуыннан, вә һичбер җәһәт илә башка милләтләргә әһәмиятсез калмау»да [1: 11] күрә. Аның фикеренчә, «милләт хадиме – милләт сулышы белән яшәүче рухи юлбашчы, бөтендөнья фикер үсешендәге яңалыкларны үз милләте файдасына хезмәт иттерүче» [1: 11]. Милли идеал мәсьәләсе Габдулла Тукайны да битараф калдырмый, шушы мәсьәләне күз уңында тотып, ул «Хиссияте миллия» мәкаләсендә: «...Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ», – дип язып чыга [12: 155].

Алга таба әлеге фикерләр Н. Хәлфин, Җ. Вәлиди, Г. Зәбирев хезмәтләрендә тагын да камилләшә, үз иҗтимагый, иҗади эшчәнлеге белән милләт бәхете өчен көрәшүче патриотик рухлы гуманист шәхес милләт хадиме, идеал, әйдаман буларак тәкъдим ителә. Г. Зәбирев Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романына язган рецензиясендә мондый идеалның татар әдәбиятындагы гына түгел, милләт үсешендәге әһәмиятен күрсәтеп: «Милли идеалы булмаган, бу идеал өчен тырышмаган милләтләр үләргә мәхкүмдер. Һәр яшь татарның зиһенендә милли идеал урнашмалы. Бар хәрәкәтендә милли йолдызны алдында тотып, ул йолдызның күрсәткән юлларындан гына йөрмәле» [5: 313], – дип язып чыга. Күренгәнчә, автор идеалны билгеләүдә милли хисне беренче шарт итеп куя һәм үрнәк шәхес – идеалны татар халкын үстерүдәге, туплаудагы бер үзәк дип саный. Шул рәвешле, татар иҗтимагый-фәлсәфи, әдәби-эстетик фикерендә халыкка игелеклелек, милләткә хезмәт итү, милләт бәхетен югары кую кебек сыйфатлар калкытып куела һәм идеалны билгеләүдә төп бизмән ролен үти. Әдипләр «яхшылык һәм матурлыкны, эстетика һәм әхлакны берләштергән» [8: 5] идеал эзли. Халыкка мәхәббәтләре, явызлык, хаксызлыкка каршы нәфрәт белән тулы эшчәнлекләре, гуманистик сыйфатлары аларны шул чор тудырган идеал итеп күтәрүдә нигез

итеп алына. Шушы критерийлар яссылыгында XX йөз башы татар шигъриятендә Ш. Мәрҗани, Х. Ямашев, Г. Тукай, Г. Исхакый образлары идеал итеп күтәрелә.

Х. Ямашевның үлеме уңае белән язылган, күтәренке романтик пафос белән сугарылган «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре Габдулла Тукай иҗатында бу юнәлештәге шигырьләрнең беренчесе булып тора. Шагыйрь халкы һәм туган Ватанына тугрылыклы хезмәт итеп, шул юлда җанын фида кылган якты шәхес образын тудыра:

Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,
Үткен акълы шул көрәшкә пакъ көмештән юл булып.
Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәләнд:
Карны-бозны ул ничек эртә көлеп һәм нур коеп [13: 154].

Тукай үз идеалына халыкка хезмәт итү, үзара дуслык-туганлык, ягъни гуманистик позициядән якын килеп, әхлакый сыйфатларын югары күтәрә, «заман тудырган халык героеннан» [10: 142] бигрәк, үз аңында формалашкан милли җанлы, күңеле саф, үз идеяләренә тугрылыклы идеалны сурәтли. «Мин Хөсәен мәрхүмне тәкъдир вә ихтирам итәм һәм аны бик сагынам, – дип искә ала Тукай үзе дә Петербургта сәяхәте вакытында. – Мин үзем социалист түгелмен, шуның өчен дә ул мәсләктәге кешеләр хакында артык сүз сөйли алмыйм. Фәкать һәркем үз мәсләгеп гүзәл аңлап, чыннан халкына, ватанга хезмәт итсен иде» [2: 168]. Моннан тыш, әсәрдә матди байлык, шәхси милекне кире кагып, рухи камиллекне алга куйган толстойчылык мотивлары да үзен сиздерә. Шагыйрь халыкның бәхет-сәгадәт, якты киләчәккә инкыйлабый юл белән түгел, эволюцион, рухи үсеш ярдәмендә барырга тиешлеген билгели һәм идеалны шушы юлда маяк итеп күтәрә, шундый шәхес буларак тәкъдим ителгән Хөсәен Ямашев җирдәге яшәешне үзгәртергә сәләтле әйдаман булып гәүдәләнә [4: 31]. Шагыйрь үз халкына бирелеп хезмәт иткән Х. Ямашевны әүлияга тиңли.

Соңрак Габдулла Тукай Гаяз Исхакыйны милләт хадиме итеп күтәрә. Г. Тукай, гомумән, гомере буена Г. Исхакый шәхесенә һәм иҗатына сокланып яши, алар һәрдаим бер-берсенә рухи терәк булып торалар. Күрешеп-сөйләшеп, очрашып яшәмәсәләр дә, алар арасында рухи дуслык хөкем сөрә. Тукай вафатыннан соң Исхакый аңа багышлап «Тукай мәхәббәте» (1914), «Милли фаҗига» (1914), «Тукай мәрхүм» (1915), «Мәрхүм Тукай» (1916) кебек мәкаләләр яза. «Тукай – безнең киләчәктә татар әдәбиятына салына торган таза бер нигеземез. Мәрхүм Тукайның милли кыйммәте аның шагыйрь – милли шагыйрь булуындадыр», – дип бәяли ул аны [6: 83]. Миллилекне ул «матбугатның куәтен, көчен, ирлеген, балалыгын, пакълеген, пычраклыгын күрсәтә торган үлчәү» дип карый [6: 83]. Һәм әдәби мәйданга шул чорда килеп кергән Г. Тукайны Г. Исхакый халыкны «чит милләтләрнең көчләре тарафыннан йотылмаслык дәрәҗәдә, милли авызларына сыймаслык дәрәҗәдә зур» [7: 178] итәргә омтылган идеал, әйдаман буларак күтәреп чыга.

Г. Тукай да үз иҗат дәверендә Г. Исхакыйга берничә шигырен багышлый. «Кем ул?», «Даһигә» шигырьләрендә дә ул Исхакыйның эшчәнлегенә югары бәя бирә. «Даһигә» шигырендә шагыйрь «кара төнгә әверелгән татар дөньясын идеал уты белән яктыртырга теләгән» [3: 25] әдипне даһи итеп күтәрә. Г. Исхакыйга багышлап язган «Мөхәрриргә» шигыре шушы юнәлештә барган эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә, биредә шагыйрьнең рухи хадим, идеал хакындагы үзенчәлекле, төпле фәлсәфи уй-фикерләре тупланып бирелә. Тукай шигырендә Исхакый «пакь вә чын» сүз иясе, сурәт ясаучы, олы дан иясе, милләтпәрвәр шәхес буларак ачыла. Шигырьдә чагылган борчу хисенә «яшь көтү кебек аерылып, карт бүре күк, аерым-аерым оя корган» халыкның «чупансыз», көтүчесез, ягъни җитәкчесез калуы сәбәп булып килә. Тукай Исхакыйны 1905-1907 нче еллардагы инкыйлаб чорында демократик идеаллар белән рухланып йөреп тә, соңыннан шул юлдан читләшеп, үзара ызгышып яшәүгә күчкән «зыялылар» белән каршылыкта сурәтли һәм үз идеяләренә тугрылыклы калган, «бер карашы иң шома ялганчыны сүздән тыйган» әдипне татар халкының рухи юлбашчысы, милли идеалы итеп күтәрә:

«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар», дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя... [14: 174]

Әнә шулай Тукай татар халкының язмышын рухи идеаллар белән бәйли, татар халкының бәхетен бердәмлектә күрә, бәхеткә ирешү өчен бердәм яшәргә тиешлеген ассызыклый, моның өчен халыкны җыеп, туплап торучы, киләчәген билгеләүче идеалы, рухи җитәкчесе булырга тиешлеген ассызыклый. Мондый шәхес итеп ул Г. Исхакыйны күтәрә. Шагыйрь әдипне Мөхәммәд Пәйгамбәрнең варисы Гомәргә тиңли. Гомәр Мөхәммәд Пәйгамбәр вафатыннан соң Гарәп хәлифәтенең чикләрен киңәйтү, халыкны туплау өчен күп хезмәт куйган шәхес буларак билгеле. Шагыйрь Г. Исхакый шәхесендә менә шушы сыйфатларны күрә, милли рухлы иҗаты, әдәби сүз шуңа ирешүдә төп корал итеп күзаллана [11: 215].

Шул рәвешле, татар әдәбияты тамырдан үзгәргән: Шәрыктан Гаребкә, динимәгърифәтчел рухтан – җәдитчелеккә, традицион халык мәдәниятеннән югары мәдәнияткә борылган вакытта әдәбиятта яңа идеал – әдип, замандаш милләт хадиме образы пәйда була. Габдулла Тукай иҗатында да бу мәсьәләнең күтәрелүе үзенчәлекле күренеш итеп бәяләнергә хаклы. Гаяз Исхакый образын изге китаплардагы пәйгамбәрләр баскычына кую аша ул әдәбиятның иҗтимагый дәрәҗәсен күтәрә, Исхакый шәхесен татар халкы өчен маяк, идеал, әйдаман буларак билгели.

ӘДӘБИЯТ


1. Акчура Й. Дамелла Галимҗан әл-Баруди. – Казан: «Иман», 1997. – 76 б.
2. Әхмәтҗанов Ш. Искә төшерү // Тукай турында хатирәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 164–170.
3. Ганиева Р.К. Исхакый иҗаты // Мирас. – 1998. – № 5. – Б. 63–78.
4. Гафиятуллина Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә Тукай. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – 152 б.
5. Зәбирев Г. «Яшь йөрәкләр» китабы мөнәсәбәте илә // Шура. – 1913. – №10. – Б. 312–313.
6. Исхакый Г. Тукай мәхәббәте // Мирас. – 1992. – №4. – Б. 82–84.
7. Исхакый Г. Яшь көчләрнең бурычы // Мәйдан. – 2001. – № 8. – Б. 173–180.
8. Кадыров О. Л.Н. Толстой сквозь призму татарской мысли. – Наб. Челны, 1995. – 110 с.
9. Камал Т. Идеал һәм инкыйлаб. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 96 б.
10. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3: XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 599 б.
11. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 4: XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 533 б.
12. Тукай Г. Хиссияте миллия // Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 154–158.
13. Тукай Г. Хөрмәтле Хөсәен ядкяре // Тукай Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – Б. 154.
14. Тукай Г. Мөхәрриргә // Тукай Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – Б. 174.
15. Хабутдинов А. Татарское общественно-политическое движение в досоветский период: 1900–1918 гг. Ч. 1. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1997. – 62 с.



УДК 821.512.145


## ХУДОЖЕСТВЕННЫЙ ПАРАЛЛЕЛИЗМ У Г. ИСХАКИ И А. ЯСАВИ: НА ПРИМЕРЕ ОБРАЗА СУННАТЧИ


***Ф.З. Яхин***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



В повести «Суннатчи бабай» Г. Исхаки главный герой в деревенском кладбище сам копает себе могилу. Данная деталь, хотя произведение любимо читателями и изучается в школах, оставалась без объяснения и текстологического комментирования.

В статье раскрывается история и причина появления данного обычая у татар и первая фиксация его в художественной литературе. До средневекового тюрко-мусульманского святого А. Ясави такого обычая не было. По этому поводу им были созданы ряд стихотворных произведений, которые анализируются в данной публикации в рамках выявления художественного параллелизма в идейно-смысловом содержании с повестью Г. Исхаки.



**Ключевые слова:** Старик суннист, хикмет, Ясави, ашириды, суннизм, обычаи, образ святого.



In the story «The Old Sunni» by G. Ishaki, the main character in the village cemetery digs his own grave. This detail, although the works are loved by readers and studied in schools, remained without explanation and textual commentary. The article reveals the history and

reason for the appearance of this custom among the Tatars and the first fixation of it in fiction. There was no such custom before the medieval Turkic-Muslim Saint A. Yasavi. On this occasion, he created a number of poetic works, which are analyzed in this publication in the framework of identifying artistic parallelism in the ideological and semantic content with the story of G. Iskhaki.
**Key words:** The old man is a Sunni, Hikmet, Yasawi, Ashirids, Sunnism, customs, the image of a saint.

## Г. ИСХАКЫЙ ҺӘМ Ә. ЯСӘВИДӘ ӘДӘБИ ТӘҢГӘЛЛЕК: СӨННӘТЧЕ БАБАЙ ОБРАЗЫ МИСАЛЫНДА

***Ф.З. Яхин***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» (1911) реалистик хикәясендә хәзрәттән төп каһарманы Сөннәтче бабай үзеңә үзең кабер казырга ярый-ярамау хакында белешә. Хәзрәт аңа бер әүлияның шулай эшләве хакында әйтә. Бу гамәлне башкарырга мөмкин икәнлегенә хуплаулы фәтва алына. Әсәрдә бу хакта болай сөйләнә: «Бик ихлас берлән кырыгынчы, йөзенче мәртәбә үлем хәлләреннән, Мөнкир-Нәкир килүләреннән, кабер газабыннан, оҗмах нигъмәтләреннән сорашты. Ахырдан гына, куркып кына: «Хәзрәт, терек кешегә кабер казырга ярыймы? – дип, хәзрәттән фәтва сорады. Хәзрәт әллә нинди бер әүлияның үз каберене үзе казуыны сөйләгәч, бик зур бер мәсьәлә хәл кылган кеби, шатланып кайтып китте» [1: 183].

Вакыйгада телгә адынган ул «әллә нинди бер әүлия» – чынлыкта урта гасырларның данлыклы төрки шәхесе Әхмәт Ясәви (1092–1166). Аңардан гайре алдан үзенә кабер казып, ләхетенә тере хәлендә кереп яткан, тарихлардан билгеле. Башка һичбер әүлия дә юк [3: 48]. Аның болай эшләвенең сәбәбе шунда: Мөхәммәд пәйгамбәр 63 яшендә вафат була, Ә. Ясәви дә, шәригатьне төгәл үтәүче мөселман сыйфатында, нәкъ пәйгамбәрчә, сөннәтенә туры китерәм дип, 63 яшендә үзенә кабер казый һәм ләхеткә кереп ята [2: 48].

Бу хакта ачык белдереп, ул үзенең «Диваны-хикмәт»» («Хикмәтләр тупланмасы») китабынының «Алтынчы хикмәт»ендә болай дип яза:

Собхе-садикъ дүшәмбе көн йиргә кердем,
Мостафага матәм тотып кердем мына;
«Алтмыш өчтә сөннәт!» – диде, ишетеп белдем,
Мостафага матәм тотып керлем мына [2: 35].

Мөхәммәд пәйгамбәрчә гамәлләр кылган мөселманны гына Ә. Ясәви өммәт санавын «Егерме дүртенче хикмәт»ендә атап белдерә һәм бу хакта болай дип яза:

Һәркем: «Өммәтмен!» – дисә,
Рәсүл эшен куймаса,
Шәфәгать көне булса,
Мәхрүм куймас Мөхәммәд [2: 76].

Монда белдерелгәннән аңлашылганча, шушындый кешеләрне генә Кыямәт көнендә Мөхәммәд пәйгамбәр үз яклавыннан мәхрүм калдырмаячак икән. Әгәр дә аның өйрәткәннәрен-нәсыйхәтләрен бозып, үзеңә кирәкчә үтәдең икән, андыйларны өммәтеннән санамас, шулай аларның кемлеге-ниндилеге рисвай булыр, ди [2: 76].

Димәк, Ә. Ясәви болар белән үзенең сөннәт иясе, ягъни сөнни сәләфиядән булуын да төгәл һәм ачык белдерә. Алтмыш өч яшендә гүргә кереп ятуын ул хикмәтләре тупланмасының «Икенче хикмәт»ендә үк тасвир кылып яза. Анда Ә. Ясәви үзен чын мәгънәдә мистик шагыйрь буларак та күрсәтә. Вакыйгаларны бәянен дусларына мөрәҗәгать итеп башлап китә:

Ай-йа дустлар, колак салың әйттегыма,
Ни сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә,
Мигъраҗ үзрә хак Мостафа рухым күрде,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Хак Мостафа Җәбраилдин кылды сөаль:
«Ничек бу рух тәнгә кермәй тапты кәмал?
Күзе – яшьлигъ, хилка башлигъ, кадде һилал?»
Ул сәбәпдин алмыш өчтә кердем йиргә [2: 21].

«Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә» җөмләсеннән гыйбарәт шигъри юл риторик төзек нәзем тудырып, кяфия буларак, һәр куплетның ахырында кабатланып килә. Бу стилистик күренеш, беренчедән, суфи ритуалы өчен уңай, ракс-сәмаг кору өчен җайлы, икенчедән, шигъри фикергә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен бирә, өченчедән, гамәлнең дөреслеген раслау мотивын тудыра, ягъни, башкача булырга мөмкин түгел икәнлекне төшендерә. Ә. Ясәви, әүлия һәм шагыйрь, шул ук вакытта акыл иясе дә. Менә шушы акыл иясе булуы аңа һәр сүзен дәлилле ясауны таләп итә. Дәлилле сүз икән, ул фикер белдерү генә түгел, бәлки хакыйкатьне ачу юнәлешен һәм эчтәлеген дә ала.

Хикмәтен ул ни сәбәпле алтмыш өч яшендә гүргә кергәнлеген белдерәчәген әйтеп башлап китә, алга таба мистик фикерләү алымнарына бара, рухын-җанын Мигъраҗы вакытында Мөхәммәд пәйгамбәрнең күрүен, Җәбраил фәрештәдән кызыксынып соравын сөйләүгә күчә. Мигъраҗ – суфиларның гыйбадәттә ирешергә омтылу халәте ул. Мөхәммәт пәйгамбәргә насыйп ителгән, аны күкләргә буракка атланган хәлдә ашуы, җәннәтләрне, тәмугларны күрүе, Аллаһы Тәгаләнең хөрмәтенә лаек булуы белән озатылган [4: 126–178].

Ә. Ясәви асыл картиналар тудыра белеп яза, бу осталыгы үз рухының нинди булуын сурәтләвендә бигрәк тә ачык күренә: күзләре – яшьле, башы өстендә түгәрәге булган, ягъни илаһи нурлы-раунаклы, яңа туган ай сыйфатлы күркәм икән ул. Боларны белдерү өчен шагыйрьгә чыннан да аларга ия икәнлеген әйтүе генә аз, башкаларның да аның ул сыйфатларга ия икәнлеген тануы таләп ителгән, билгеле. Шагыйрь моны яхшы аңлап яза. Алай булмаса, сүзләрен ялганга чыгарырлар иде. Башкаларны дөрес, хакыйкать юлына әйдәүчегә, хаталану бер дә файда бирмәсен Ә. Ясәви аңламаганмы? Димәк, аның тормышта да нәкъ шундый затлы рухка ия икәнендә һичбер шик була алмаган. Чөнки:

Җибрил әйтте: «Өммәт эше сезгә бәрхак,
Күккә чыкып, мәләикдин алыр сабак,
Налишедин налә кылыр һәфтүм табак».
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 21].

Шунда Мөхәммәд пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә: «Өммәт гамәлләре сезгә дөрес», – ди, ягъни, сезнеке, сезнеңчә булыр, дигәне бу аның, әмма Ә. Ясәвине ул, күкләргә күтәрелеп, фәрештәләрдән сабак алучы итеп атап белдерә, ә күзе яшьләрен күреп, хәтта җиденче кат Күкләр дә елый икән. Бу шигъри юлларда суфиларның чын рухи халәткә ирешүләре әдәби алымнар эчендә тасвир ителә. Ә. Ясәвинең максаты, аңлашылганча, хикмәтләре белән башкаларны шәригать һәм тарикать серләренә өйрәтүдән дә гыйбарәт. Бу аның хикмәтләренең ике яки берничә эчтәлеккә ия икәнлеге хакында да сөйли. Шигъри әсәр берничә төрле эчтәлеккә ия булганда, аның эчтәлеге һәм мәгънәләре дә катлаулана, тирәнәя. Хакыйкать серләрен башкача ачу мөмкин түгел, билгеле.

«Фәрзәндем!» – дип, хак Мостафа кылды кәлам,
Андин соңра барча әрвах кылды сәлам;
«Рәхмәт дәрья, тулып таш!» – дип йитте пәям,
Ул сәбәптин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 21].

Автор монда үзен Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән буларак белдерә. Алга таба бирелгән тасвир аның рухының иңдерелүе хакында бара. Ана күмәнендә чагында ук зикр әйтүен, бәдәннәренең калтырануын, чыннан да үзенең Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән икәнен кабат раслап уза. Шуңа да ул алтмыш өч яшендә гүргә керергә карар кылган икән.

Шагыйрь үзенең туу вакыйгасын «дүрт йөз елдин ки, ин чыкып, өммәт булгай» [2; 22] дигән сүзләр белән белдерә. Әгәр монда хаталанмаган, дисәк, Мөхәммәд пәйгамбәр вафатыннан соң 400 ел узгач ул дөньяга килгән икән. Әгәр дә моны хакыйкатькә

санасак, аның дөнья йөзендә 125 ел яшәгән булуы хакындагы риваятьне чынга алырга кала. Һәрхәлдә Ә. Ясәви бу фактны юкка гына искә алмаган. Шулай да аның 125 яшькә җитүе хакындагы хәбәренә бүтән мәгънәләр салынган булуы да бик мөмкин. Моны төшенер өчен әүвәлдә бу хикмәтне тулысынча, өзми өйрәнеп чыгарга кирәк.

Хуҗа Әхмәт Ясәвинең тормышын тикшерү, вакыйгаларны тәртипкә салып барлау һәм бәяләү эше фәндә бервакытта та туктап торганы булмады. Совет чорында гына бераз сүлпәнләнеп алды. Шулай да аның дөньякүләм бөек шәхес икәнен һич кенә дә инкарь итү мөмкин түгел иде. Төрки халыкларның рухын ныгытуда аның шигъриятенең әһәмияте югары бәяләнү тапканын бүгенге Төркестан каласында исемен йөрткән Гыйльми үзәкнең, университетның булуы да бу хакта ачык сөйли.

Ә. Ясәви – мистик шагыйрь, аның һәр белдергән төшенчәсе берничә мәгънәгә ия булырга мөмкин. 125 яшь яшәве хакында искәртүе исә метафора да була ала. Әлегә аның мәгънәсе безнең өчен ачык кала.

Шушы ук хикмәтендә алга таба шагыйрь үзенең туу вакыйгасын болай сурәтли:

Тукыз ай да тукыз көндә йиргә төштем,
Тукыз сәгать торалмадым, күккә очтым,
Гарше Көрси паясыны барып кочтым,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Гарш-өстедә намаз укып, яшем түктем,
Разым әйтеп, Хакка бакып, яшем түктем,
Ялган гашыйк, ялган суфи күрдем, сүктем,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Җандин кичмәй «һу-һу!» дигән бары ялган,
Бу халыктан сорама сөаль – юлда калган,
Хакны тапкай үзе пәнһан, сүзе пәнһан,
Ул сәбәпдир алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 22]

Димәк, Аллаһы Тәгаләне тапкан кеше үзе сер һәм аның сүзләре дә сердән гыйбарәт икән. Боларны ул каян белде дә, бишек яшендәге, хәтта көмәндәге хәлләрне хәтерендә саклый алды соң дигән сораулар укучы күңелендә тумый калмый. Бары тик суфичылыкның мистик системасыннан һәм гакыйдә гыйлеме өйрәтмәләреннән хәбәрдар, ягъни үз телләре белән әйтсәк, «мәгърифәт» баскычын узганнар гына аларның мәгънәләрен аңлый ала. Бу куплетларда сүзләр адәм баласы җанының җирдә бәдән эчендә булырга теләмәве, кабат Күкләр катындагы җәннәтенә кайтырга ашкынуы хакында бара. Мондый мәгънәләр кеше тормышын ул заманнарда бермә-бер җиңеләйткәннәр булса кирәк? Югыйсә бөтен ислам дөньясын суфилар, христиан илләрен заһит-диндарлар тутырмас иде. Халык үз тормышын җайларга яраклы һәм уңай идеяләрне, шулар белән бергә идеалларны гына күңеленә якын ала. Идеяләрне югары идарәчел катламнар үз итә, гади халык идеаллар белән яши. Ул иҗтимагый тормыштан түбәннәргә генә идеяләр дә, идеаллар да кирәкми.

Ә. Ясәви катлаулы булып тоелырга мөмкин идеяләрне гадиләштерелгән әдәбиметафорик тәртиптә тәкъдим итә. Алары аның әдәби яктан да отышлы килеп чыкканар. Авторның «Гарше Көрси паясы» дигәне Аллаһы Тәгаләнең күкләр катындагы тәхете буларак күзаллана. Ә. Ясәви шул Көрсинең аягын барып кочуы хакында сүз алып бара. Ул шушы гамәлен белдергәнендә, тумышыннан иманлы икәненә дәлил буларак, сабый чагында ук сөннәткә утыртылуын да искәртә. Аның туганчы намаз укуын искә алуы да, елавын язуы да мәгънәләрнең дөрес ачылуына дәлил, ярдәм-күрсәткеч булып тора. Ялган суфи, ялган гашыйкларны ачулануы да шушы ук серләрне төшендерә. Мәгънәләрне суфичылыкка бәйләве аларның эчтәлегенә серлелек өсти, гади сыман күзалланырга мөмкин гадәтләр яңача аңлашыла башлый. Шушы рәвешле ул мәдәни төшенчәләр тудыра, хикмәттә әдәби мәдәни мәгънәләр катламы барлыкка китерелә һәм алар үз эчтәлекләрендә үзгәреш кичерәләр, югары идеяләр белән йөкләнәләр. Аларның беренчел эчтәлеге сергә әвереләдерелә, шул беренчел төшенчәләрен аңлый башлау укучыны мәгърифәтле итә һәм бу хәл кешелекнең мәдәни дәвере буена иҗтимагый аң дәрәҗәсендә эшли, фикерләвебездә һәм гамәлләребездә яшәвеннән туктамый. Г. Исхакыйның нәкъ «Сөннәтче бабай» әсәрендәге кебек. Мистик мәгънәләр әдәбиятта

да, тормыштагы кебек, шулай тудырыла һәм яши. Төшләр символикасы да, эзотерик күзаллаулар да шушы төшенчәләр белән яшиләр һәм ныгытылалар.

«Һу-һу!»ның мәгънәсе «Лә иләһә илләләһү!» шәһадәтеннән гыйбарәт кәлимәи таибәт санала. Аллаһыга ирешкән суфи ул сүзләрне «һу-һу!» буларак әйтүгә күчә. Бу – суфичылык ритуалына да карый торган гыйбарәләрдән. Шуңа да Ә. Ясәви җаннан кичү хакында сүз алып бара. Аның аңлатуларында һәм сурәтләүләрендә тәннән җан аерылу – чын үлем дигән сүз түгел, бәлки алар белән монда рух сафлыгы хакында мәгънәләр бирелә.

Алга таба шагыйрь бер яшеннән җиде яшенәчә булган тормышын бу рәвешле бәян итә:

Бер яшемдә әрвах килеп сәлам бирде,
Ике яшьтә пәйгамбәрләр килеп күрде,
Өч яшемдә Чилтән килеп хәлем сорды,
Шул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 22].

Монда «Чилтән» сүзе, дини-суфичылык төшенчәләреннән берсе буларак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең рухын атый [2: 22]. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгада лирик геройга өч яшендәге вакытында Мөхәммәд пәйгамбәрнең рухы килеп хәлен соравы хакында мәгънәләр бирә. Бу аның өч яшендә иман китерүен белдерүеннән гыйбарәт төшенчәләрне башкаларга җиткерүе дә әле.

Түрт яшемдә хак Мостафа бирде хөрмә,
Юл күрсәттем, юлга керде ничә гөмраһ,
Кайда барсам, Хызыр бабам миңа һәмраһ,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Биш яшемдә билем баглап, тагать кылдым,
Тәтәввогы руза тотып, гадәт кылдым,
Кичә-көндез зикрен әйтеп рәхәт кылдым,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Алты яшьтә тормай качтым халаикъдин,
Күккә чыкып, дәрс үргәндем мәләикдин,
Даман кисеп һәммә әһле галәикъдин,
Ул сәбәпле алтмыш өчтә кердем йиргә.

Йите яшьтә Арслан бабам эзләп тапты,
Һәр сер күреп, пәрдә берлә бөркәп япты:
«Бихәмдулләһ, күрдем!» – диде, эзем үпте,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем гүргә [2: 23].

Бу куплетларда Ә. Ясәви мәгънәләрне суфичыл төшенчәләрдә тасвирлавын дәвам итә. Ул дүрт яшендә Коръән өйрәнә башлаган. Моны «түрт яшемдә хак Мостафа бирде хөрмә» дигән шигъри юллары раслый. Кайда йөрсә дә Хозер пәйгамбәргә юлдашлыгы хакындагы белдерүен ничек аңларга? Ул хәтта аны бабасы буларак та атый. Хозер пәйгамбәрнең золмәт иленнән, ягъни төньяк җирләреннән Ильяс пәйгамбәргә килеп йөрүе кыйссаларда сөйләнелә. Шушы хәбәр нигезендә төрки дөнья Хозер пәйгамбәрне үзләренең борынгы бабасы итеп беләләр дип фараз кылырга була. Әмма Хозер гомумән дә барча төр суфилар тарафыннан юлдашлары саналганын аларның әдәби әсәрләреннән дә укый алабыз. Димәк, Хозер хакында белдереп, аңа юлдашлыгы турында язуы Ә. Ясәвинең үз дәрвишлеген искәртүе ул.

Алты яшендә күккә чыгуы хакында белдерүе суфичылыкка керүен, мөритләр рәтенә басуы, хәтта дини белем серләренә төшенә башлавын да аңлата. Бу, әлбәттә, мөмкин хәл. Аның әтисе – Ибраһим Яссы, танылган суфилардан булган. Мондый кешеләр үз балаларын кечкенәдән барча гадәтләренә өйрәтүчән булалар.

Ә. Ясәви халыктан «итәк кисүен» яза, ягъни халыктан аерылуын ачык белдерә. Фәрештәләрдән дәрес өйрәнүен юелдерүе зиһене яхшы булганлыгы хакында искәртүе аның.

Җиде яшендә үз шәһәрләрендә Арслан бабадан дәрес укый башлый һәм аның горурлыгына әверелә. Димәк, яхшы зиһен иясе булуы белән ул соклангыч укучыларның берсенә әверелә.

Шулай итеп, бу хикмәтеннән без Ә. Ясәвинең бала вакытындагы холкын да ачык белә алабыз. Ул белемгә омтылучан, яхшы зиһен, саф аң иясе булган. Диндарлыгын да укучыдан яшерми. Халыктан итәк кисүен язганыннан чыгып аның икътикады юнәлешен дә билгели алабыз. Гашыйрилардан икәнлеге бәхәс тудырмаска тиеш, чөнки тәкъдир фәлсәфәсендә ул Аллаһыга буйсынуны алга куя һәм иманнан китү, иман югалту хакында да мөгътәзәлиләр юлында түгел. Бохарада чәчәк аткан матрудиядән, аларның ихтыяр фәлсәфәсеннән дә ул читтә. Әмма барча гамәлләрне кылганда да сөннәт юлын тотуы белән ихтыярны да алга чыгара түгелме? Юк, дибез. Чөнки аның ихтыяры – сөннилек, шулай дигәндә дә, моны ихтыяр буларак түгел, язмыш итеп кабул итүе икәнен танырга тиешбез. Ә. Ясәвинең гакыйдә фәлсәфәсен бәяләгәндә, аның гашириядә катгый торуы, икеләнмәве, башка юнәлешләре алмавы сөендерә. Шуның өчен дә гасырдан-гасырга ул башлаган тарикать, ягъни диндарлык-суфичылык таркалмый һәм сүтелми яшәгән. Җаһриянең нәкышбәндия белән ныгытылуы да шушыңа бәйле. Күбрия дә яссәвийә йогынтысында калган, аның «исмеәгъзам» догалары да бакырганийә юлында бер өстәмә иярчен фәлсәфи гамәлия иде, дия алабыз. Һәм менә шул үк карашлар системасы вәкиле булуы җәдит дәвере әдибе Г. Исхакыйның әсәрендәге Сөннәтче бабайның һичбер шикләнүсез һәм икеләнүсез үлемгә әзерләнүенә юл ача, ул хәтта каберенә кадәр үзе казып куя. Болар аның Ә. Ясәви үрнәген алуыннан, димәк.

Кабиз, килеп, Арслан бабам җанын алды,
Хурлар, килеп, хәрир тундин кәфен кыллы,
Йитмеш меңе фәрештәләр йигълап килде,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 23].

Монда, «кабиз» дигәндә, «кабизел-әрвах», ягъни «җаннарны алучы», әҗәл хакында сүз бара. «Хәрир тун» дигәнендә, фәрештәләрнең «ефәктән кәфен» ясаулары әйтелә, шуның белән Арслан бабаның рухы җәннәтле ителү дә белдерелә, чөнки җәннәттә рухлар ефәк киемнән икәннәр.

Җеназасын укып бийирдин күтәрделәр,
Бер форсатта оҗмах эчрә йиткерделәр,
Рухын алып, гыйльлиюнә кергезделәр,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [б. 24].

«Бийирдин» гыйбарәсе «бу җирдән» дигәнне шигъри калыпка салып, көйле аһәңдә әйтергә уңай булуны күздә тотып үзгәртү сәбәпле ясалган. Арслан бабаның рухын фәрештәләр ефәккә төреп алалар һәм күкләрнең югары катына, автордагы дини термин белән әйтсәк, «гыйльлиюнә» («галийүнгә») алып китәләр.

«Аллаһ!» – диеп, йыр астында ватан кылды,
Мөнкир-Нәкир: «Мән Раббик?» – дип соруг сорды,
Арслан бабам: «Ислами!» – дип бәян кылды,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 24].

Ә. Ясәви тәннең җирдә калдырылуына, аңардан кабердә сорау алучы фәрештәләргә ислам дине вәкиле буларак мөслими икәнлеген белдереп җавап тотуын да ачык яза. Бусы да аның игътикады гаширийәләр юлында икәнлеген раслаучы фактлардан берсе буларак искә алынырга тиеш.

Алга таба шагыйрь үгет-нәсыйхәт биреп ала. Ул үзе бер куплетка сузыла һәм әле генә сурәт ителгәннәргә мәгънәви йомгак ролен дә үти. Акыллы кешенең «ирләргә» хезмәт итүе искәртелә. Аның күзаллавында «ирләр» алар – чын диндар суфилар, ягъни «ислам рыцарьлары» – шәһитләр. Шәригатьне аңлап-белеп тотучыларны, яман эшләрдән тыелучыларны хөрмәт итәргә куша шагыйрь. Шушы үгет-нәсихәт куплетын «ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә» кяфиясе белән тәмамлавы үзенең боларны үтәп яшәвен белдерүе буларак та кабул ителә.

Сигез яшендә аңа «сигез яндин юл ачыла», ягъни ул тәмам ирекле булып кала һәм аның бу ирегә икеләтә мөмкинлекләр бирелүдән гыйбарәт икән. Бу исә тулысынча үз ихтыярында калуы хакында белдерүе дә. Һәм автор хикмәт әйтә башлавын, моның өчен «пире Муган мәй эчерүен», шунда «башларымнан нур сачылуын» [2: 24] сөйли

дә, алга таба куплетны «пире Муган – хак Мостафа, бишәк белең» [2: 24] дип башлап китә, кайда барсаң да Мөхәммәд пәйгамбәрнең сыйфатларын искә алып, аны мактап, шулай «Мостафага өммәт булың» [2: 24], ди. Димәк, өммәт булуны Мөхәммәд пәйгамбәрне тормышта үрнәк итеп яшәүдә күрә.

Әмма тугыз яшендә ул мактауларга куанмыйча «качтым чүлгә» [2: 25], ди. Суфилар телендә «чүл» – «адашып йөрү», «хаталану» инде ул, асылда «бакча»га каршы куела, дип беләбез.

Ун яшеңдә угълан булдың, Кол Хуҗахмәт,
Хуҗалыкка бина куеп кылмай тагать,
«Хуҗа мән!» – дип, юлда калсаң, вай, нә хәсрәт,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә [2: 25].

Бу хикмәт шушылай тәмамлана. «Угълан» сүзенең «көрәшче», «шәһитлек юлына баскан яшь кеше» мәгънәләрендә кулланылган булуы бу урында бер дә шик тудырмый. Шагыйрь боларны үзе хакында сөйли. Аның ул үзенчәлекләре Сөннәтче бабайның образын тулы күзаллар өчен дә ярдәм итә. Алдан үзенә кабер казып куюы шуңа да укучыда һичбер аптырау, чиркану тойгысын тудырмый. Безгә ул бу гамәле сәбәпле саф, тугыры, дөрес кеше булып тойдырыла. Әсәрдә Г. Исхакый моның өчен аның ничек казуы, эш процессы вакыйгаларын сурәтләп уза.

Ә. Ясәви хикмәтләрен татар халкы укымый тормаган, шуңа да Казанда аның китаплары еш басылып таратылган. Сөннәтче бабайның яссәвия юлында булып, Ә. Ясәви хикмәтләрендә бирелгән лирик герой белән әдәби-мәгънәви тәңгәллеге сурәтләнелгән вакыйгалар һәм алардагы тасвири детальләр белән тулысынча раслана, дия алабыз. Теманы дәвам итеп, башка детальләренә дә тукталып үтәргә мөмкин. Алар барысы бергә Сөннәтче бабайны Ә. Ясәви кебек әүлиялардан итеп күз алдында формалаштыра.

## ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. II / Тектологы Л.Р. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 464 б.

2. Яхин Ф.З. Әхмәт Ясәви. – Казан: Татарстан республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2003.– 383 б.

3. Яхин Ф.З. Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: Раннур, 2003. – 416 б.

4. Яхин Ф.З. Пәйгамбәребез Мөхәммәд: тарихи роман-трилогия. – Казан: Раннур, 1999. – 575 б.

# ЛИЧНОСТЬ И ТВОРЧЕСТВО ГАЯЗА ИСХАКИ В ИСТОРИИ ТАТАР И НАЦИОНАЛЬНОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ ЖИЗНИ / ТАТАР ТАРИХЫНДА ҺӘМ МИЛЛИ ИҖТИМАГЫЙ ХӘЯТЫНДА ГАЯЗ ИХАКЫЙ ШӘХЕСЕ ҺӘМ ИҖАТЫ / THE PERSONALITY AND CREATIVE OUTPUT OF GAYAZ ISKHAKIE IN THE HISTORY OF THE TATARS AND NATIONAL PUBLIC THOUGHT

УДК 82.091

## ДОЧЬ ГАЯЗА ИСХАКИ – САГАДАТ

***Л.Р. Гайнанова***
*(Казань)*

В статье представлены обширные сведения о жизни Сагадат Чагатай – дочери Гаяза Исхаки. Раскрываются отдельные детали ее биографии, подробно и последовательно исследуется ее деятельность в эмиграции.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхакый, Сагадат Чагатай, наследие, эмиграция.

The article presents extensive information about the life of Sagadat Chagatai, the daughter of Gayaz Iskhaki. Individual details of her biography are revealed, her activities in emigration are investigated in detail and consistently.
**Key words:** Gayaz Iskhaky, Sagadat Chagatai, heritage, emigration.

## ИСХАКЫЙ КЫЗЫ СӘГАДӘТ

***Л.Р. Гайнанова***
*(Казан)*

Г. Исхакыйның кызы Сәгадәтнең туган елы мәсьәләсе баштарак бераз бәхәслерәк булды. Төрле елларда язылган анкеталарда ул үзенең туган елын 1907 ел дип күрсәтә. 1989 елда әнисе Мәрьям Шәрипованың икенче ире Ибраһимнан туган сеңлесе Суфияга җибәргән хатында да «мин 1907 елда туганмын», дип язган иде. Г. Исхакыйның мин төзегән «Зиндан» җыентыгында (1991) шул ук исемдә автобиографик повесть та бар. Анда автор, беренче мәртәбә тотылып, Казан төрмәсендә 2 тәүлек утырганнан соң, административ рәвештә туган авылы Яушырмәгә сөрелүе турында яза. 1906 елның 5 нче ноябрендә ул авылына кайтып җитә. «Менә миңа үземнең кызымны алып чыктылар... Кызымны күрмәгәнемә өч-дүрт ай үтсә дә, ул миннән бер дә ятсынмаенча килде», – ди Г. Исхакый. Димәк, бала 1907 елдан алдарак дөньяга килгән булып чыга. Сәгадәтнең туу датасын ачыклар өчен Татарстан милли архивындагы муллалар тутырып барган метрикә дәфтәрләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк булды. Баксаң, Сәгадәт Исхакый 1905 елның 15 июлендә (яңа стильдә 28) туган икән. Әтисе Казан төрмәсеннән котылып авылга кайтканда балага 1 яшь тә 3 ай ярым була. Бу хәлләргә Ибраһим Нуруллин да игътибар иткән, ул да, метрикә дәфтәреннән карап, Сәгадәтнең туган елын ачыклаган икән. Ә менә метрикәдә Г. Исхакыйның беренче баласы – Сәгадәткә кадәр туган бер улы да булуын И. Нуруллин күрмәгән.

Татар энциклопедиясендә Сәгадәтнең туган елы ике урында ике төрле: 1905 дип тә, 1907 дип тә язылган. Шулай ук Г. Исхакыйның да туган көне 22 февраль дип ялгыш күрсәтелгән. Әдип үзенең «Тәрҗемәи хәлем»ендә: «Мин иске стильдә 10 февральдә (яңа стильдә 23 февральдә) кояш чыкканда туранмын», ди. «Кояш чыкканда»

дип әйтүне дә кирәк тапкан. Энциклопедиягә бу бөек затлар турында текстлар язарга алынган кеше даталарны архивтагы метрикә дәфтәрләре буенча тикшерергә тиеш иде. Укучы бит иң дөрес мәгълүматны белер өчен җитди басмага – энциклопедиягә мөрәҗәгать итә. Хаталар энциклопедиядән тизрәк тарала.

Гаяз Исхакыйга мулла таныклыгы 1903 елның 17 апрелендә (яңа стильдә 27 апрельдә) бирелә. Ә шул ук елның 3 ноябрендә (яңа стильдә 16) Гаяз Исхакый белән Мәрьям Фәтхетдин кызы Шәрипова никахланалар. 1904 елның 3 августында (яңа стильдә 16) аларның Мәэмүн исемле уллары дөньяга килә. Ләкин бала 9 атналык булгач, үлеп китә. «Әтисенә бик тә охшаган иде», дип әйтә торган булган әнисе Мәрьям. Тагын бер елдан ул кызлары Сәгадәтне таба. Ләкин, агалары сәбәпче булып (аларга «йорттотмас» кияүләре ошамый), Г. Исхакый белән Мәрьям 1906 елның 26 июлендә аерылышалар. Шул ук елның 28 ноябрендә алар никахларын яңартып тагын кушылалар. Әмма 1908 елның 21 июнендә Г. Исхакый, Мәрьямнең үтенече буенча, Архангель губернасыннан «...үземнең никахымдагы хатыным Мәрьям Фәтхетдин кызыны үзенең мәһаре бәрабәренә, габде нәфкасы (тияр мал) бәрабәренә хәлгы кылдым (аерылырга рөхсәт бирдем)» дигән документ җибәрә.

Сәгадәт, нигездә, әбисе Камәрия янында тәрбияләнә. Истәлекләрендә Сәгадәт «мин әтием белән 1913 елда гына таныштым», – ди. Г. Исхакый төрмәгә эләккәндә бик нәни калып, әтисе 1913 елда сөргеннән кайтканда инде балага 8 яшь була. Аннан соң да әле Казанда яшәргә рөхсәт ителмәгәнгә күрә, Петербургта, Мәскәүдә яшәргә мәҗбүр булган әтисе белән кызына сирәк кенә очрашырга туры килә. Яшь кыз турында «Петербургка китеп, кызлар гимназиясендә укыган, илдә һаман болганышлар дәвам иткәнгә, Петербургтан әбисе янына Яуширмәгә кайткан» дигән имеш-мимеш хәбәрләрне Сәгадәт апаның туганнарыннан еш ишетергә туры килә иде. Мәрьямнең оныгы (Сәгадәт апаның әнисе ягыннан бертуган сеңлесе Суфия кызы) Рәисә ханым әле дә: «Юк, Сәгадәт апа Смольныйда укыган, дәү әни шулай дия иде», – ди. Татар энциклопедиясендә дә шул ук версия бирелгән. Баксаң, Сәгадәт апа үзе язганча, әтисе аны 1917 елда Казанда «Мариинская гимназия»гә укырга биргән икән. Бу I разрядлы кызлар гимназиясе Казан шәһәре уртасында, мәһабәт йортта (хәзерге Рәхмәтуллин урамы, 2 нче йорт) урнашкан булган. Профессор Катанов, Терегулов, Апанаев кызлары да шунда белем ала, берара М.И. Ульянова да шунда укый. Аларны Вакытлы хөкүмәт башлыгы Керенскийның әтисе укыта. Кызганыч, Татарстан Милли архивында бу гимназиягә кагылышлы документлар өлешчә генә сакланган. Сәгадәт укыган елларга караган кәгазьләрне күрә алмадык. Ә Сәгадәтнең «Петербург гимназиясендә уку»ына килгәндә исә, бу аның ул шәһәргә чит илгә чыгып китәр өчен баруын яшерер өчен, саклык өчен махсус таратылган булса кирәк.

1917 елның мартында Казандагы «Сәйяр» труппасы куйган «Зөләйха» спектаклен Сәгадәт Мәскәүдән кайткан әтисе белән бер ложада утырып карый. Ә инде 1917 елның августында Г. Исхакый, туган йортында туганнарын соңгы тапкыр күреп, тагын китеп бара. Шул китүдән кайтмый.

Сәгадәт укыган гимназия, Совет власте урнашкач, мәктәп итеп үзгәртелә. 1921 елда ягарга утын булмыйча, балаларны өйләренә тараталар. Шул ачлыкта Сәгадәт, әбисе һәм әтисенең энесе Әхмәтхәсән белән бергә Ташкентка китеп, анда торып кайта.

Үзенең автобиографиясендә язганча, Сәгадәт 1922 елда 9 сыйныфлы совет мәктәбен тәмамлавы турында таныклык ала.

Ә өйдә Гаязны югалталар. «Үлгән икән», «төрмәдә икән», «чит илгә китеп котылган» кебек имеш-мимешләр гаиләне бер утка, бер суга сала. 1919 елның җәендә 80 яшенә җиткән Гыйләҗетдин хәзрәт «Мөхәммәтгаяз угылым, Мөхәммәтгаяз угылым» дип, соңгы сулышын ала.

Тагын ни хәбәр ишетербез дип, ут йотып яшәгән туганнары 1921 елның язында гына Гаязның Париждан язган хатын ала. «Әбием елый башлады. Әти хатларны еш язып торуын әйткән, ләкин без аларны ала алмадык. Почталар эшләми иде. Бу хат нинди могҗиза белән безгә килеп җиткәндер. Әбием хатны миннән кат-кат укыта, кәгазь белән битен сөртеп, бертуктаусыз елый иде. Хат алыша башлагач, әти мине үз янына чакырды», – дип яза Сәгадәт.

Сәгадәт абыйсы Әхмәтхәсән һәм җиңгәсе Нурия белән бергә Казанда паспорт алу артыннан йөри. Сәгадәтнең кем кызы икәнен аңласалар да, паспортны бирәләр, ләкин: «Безгә мөрәҗәгать итүегезне беркемгә дә әйтмәгез», – дип кисәтәләр. Һәм ничек итеп Мәскәүдә илдән чыгарга рөхсәт алу юлларын өйрәтәләр. Сәгадәт үзе язганча, Мәскәүдә дә кем кызы белән эш итүләрен аңлаучылар була һәм аңа рәсми юл белән йөрмәскә, ә Петербургка барып, качакчылар белән Финляндиягә чыгарга киңәш бирәләр.

Туганнары белән бергә Петербургка килеп, Сәгадәт биредә кырык көн уздыра. Килгәндә бу кадәр вакытка исәп тотмаганлыктан, акчалары бетә. Ачыгалар. Кичләрен генә йөреп, көндезләрен йоклап үткәрәләр. Шунысы бар, ачлык йокы бирми. Торган йортлары астында гына кафе-бар була. «Шуннан чыккан тәмле исләр белән туена идем», – ди Сәгадәт.

Бу урында Исхакыйның 1922 елның 16 октябрендә Финляндиянең Хелсенфорс шәһәреннән Садри Максудига язган хатына игътибар итик: «...Петроградка кызым килеп җитте. Ул вакытта Выборгта бик уңайсыз вакыйга булып үткән иде. Ул да Инҗалның энесе Хәсәннең 10 көн мәхбүс (тоткын) булып торуы. Шуның өчен аның тирәсендә йөри торган кешеләр куркып-посып калганга, кызымны чыгарту эше чуалып тора. Бу бик начар тәэсир итә. Тау кадәр вәгъдәләр ясаган Габдерахман аркылыны-буйга алып салмаган икән... Кызым хакында ачыграк мәгълүмат алу өмете берлә бүген Выборгка барам». Бу юллардан Сәгадәтнең ни өчен Петербургта озакка калуы аңлашылса кирәк. Тотылу куркынычы зур булганга, качарга җайлы вакыт һәм озатасы качакчыларның үзен алырга килүләрен көтеп тоткарланган икән ул.

Ленинградта Бакый Урманченың мәдрәсә шәриге, тарихи открыткалар коллекционеры Әхәт Усманов дигән олы галим яши иде. 1986 елда ул өендә миңа Г. Исхакыйның берничә китабын һәм фотоларын күрсәтте. Шунда: «Мин аның үзен дә күргәнем булды, кызын да Финляндиягә озатыштым, – дип куйды. – Чибәрлеге һушың китәрлек иде. Без, яшьләр, аның әтисе янына качар өчен килгәнлеген каяндыр белеп алдык. Көн саен чиратлашып шул тәвәккәл кыз торган йортка барабыз. Хәвеф-хәтәрдән саклыйсыбыз килә. Менә, көне җитте, диделәр. Без, караңгы төшкәч, аны каядыр озата бардык. Кемдер безне туктатты. Үзен генә алып киттеләр. Соңыннан әтисе белән кавышканын ишетеп сөендек».

Сәгадәт үзе илдән качуны болай тасвирлый: «Качакчылар кичке алтыда мине алачаклар иде, янибызда китергән юрганнарга сарылып яттык. Соңгы көн булганы өчен минем юрганымның кирәге калмады. Тиз генә барып юрганны сатып, ул көнне тамагыбызны туйдырдык. Соңыннан качакчылар килде, мине алганнан соң һич туктамыйча иртәнге алтыга кадәр бардык. Һава яктырганда чик сызыгына килеп җиттек. Бердән, тирә-ягымда халык төркемен күрдем. Еракта әтиемнең тавышы ишетелде: «Курыкма, кызым, куркыныч артта калды. Хәрбиләргә бирел, алар – Финляндия гаскәрләре». Финляндия хәрбиләренә тапшырылганнан соң, алар мине полициягә китерде.

Бу 1922 елның 10 ноябре иде. Андагы карантин бер айга сузылды. Соңыннан әтиемә тапшырдылар. Гаяз Исхакый бик шатланды».

Әтисе кызын үз янына бик вакытлы алдыра. Күп газаплар кичеп, тырышыптырмашып әтисе янына барып сыеныргa омтылган 17 яшьлек бу батыр йөрәкле кыз үлемнән качуын ул чагында башына да китермәгәндер. Бөтен нәселен җәзага тартканда, Гаяз Исхакыйның үз баласын, әлбәттә, шундук юк иткән булырлар иде.

Ә Яуширмәдә, Сәгадәтнең әтисе янына исән-сау барып җитүен ишетеп, хәзер инде улының да ялгыз түгеллегенә, оныгының да таянычы барлыгына куанып, Камәрия остазбикә тынычланып кала. Ул 1923 елның 17 мартында тифтән вафат була.

Г. Исхакый кызын, Берлинга алып китеп, гимназиягә урнаштыра. Сәгадәт пансионатта яши. Бер ел чамасы әтисе дә Берлинда була. Ашау такы-токы. Әтисенең дә хәле әйбәт түгел. Исхакый Төркиягә киткәч, Сәгадәт ачлыктан зарланып хат яза: «Әтием мине бик “тынычландырып” җавап бирде: “Очсыз булганга, мин бер карт ат ите пешерә торган ашханәгә йөрим. Ә Фуат Туктар торган өе янында йомырка сатучының

ватылган йомыркаларын ашап көн күрә... Әлбәттә, әгәр үзебезнең илебез ачык булса, синең өчен чит мәмләкәтләргә сыенып, мәктәптә уку зарурияте булмас иде. Тагын бераз сабыр ит, син минем күгәрченем"». Исхакыйларга иң зур ярдәмне Финляндиядә яшәүче милләттәш эшкуарлар күрсәтә. Алардан посылкалар килеп тора.

1927 елда Сәгадәт Берлин университетына укырга керә. Шул елларда немец телендә язылган автобиографиясендә Сәгадәт: «Әтием кулындагы документларга караганда, мин 1907 елда туганмын», ди. Бу сүзләр Сәгадәтнең туган елы мәсьәләсендәге «төрлелек»не аңларга ярдәм итсә кирәк. Әтисенә, бәлки, кызын Казан гимназиясенә урнаштыру өчен аның яшен киметеп күрсәтә торган документ кирәк булгандыр. Ул документ 17 яшькә җиткән кызын Берлин гимназиясенә урнаштырганда да ярдәм иткән булырга мөмкин.

Сәгадәт университетны тәмамлап, аспирантурада укый. 1932 елда үзбәк егете Таһир Чагатайга кияүгә чыга. Икесе дә 1939 елның сентябренә кадәр Берлинда Г. Исхакый оештырган «Милли юл» журналын чыгаруда булыша. 1939 елның сентябрендә Гитлер Германиясе Польшага сугыш ачкач, Г. Исхакый Варшавадан Төркиягә китә. Ә Чагатайлар Берлиннан Төркиягә 1940 елда күченә.

Сәгадәт Чагатай Әнкара университетында төрек телен укыта, аның ире профессор Таһир Чагатай (1902–1984) шул ук университетта студентларга социология буенча белем бирә.

Сәгадәт баштарак, хәтта университетта эшләгән елларында да, «Исхакый кызы» гына булып йөри. Югары дәрәҗәләр аңа җиңел генә бирелми. Көндәшләре аның турында: «Ул урысча укыган, төрек телен Әхмәтҗан кадәр генә белә», – дип, еш кына аяк чалалар. Г. Исхакыйның Истанбулдан Әнкарага язган хатларында әтисенең кызы өчен бик борчылуы, кызына ярдәм итәргә тырышуы күренә. Сәгадәт үзенең белеме, тырышлыгы белән югары дәрәҗәләргә ирешә. «Исхакый кызы» гына булудан чыгып, профессор-тюрколог исемен үзе яулап ала.

Сәгадәт апа белән мин 1989 елның башында хат аша таныштым. 90 нчы еллар ахырына таба үзгәртеп кору җилләре татарларга да килеп җитте һәм язучылар, галимнәр исемнәре бездән ераклаштырылган күренекле кешеләребезне барларга кереште.1987 елда Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мирфатыйх абый Зәкиев карары белән Мирас комиссиясе төзелде. Шул чагында Гаяз Исхакыйның үзем күп еллар буе эшләп, туплап куйган 4 томлык әсәрләр җыелмасын – әдипнең үз ватанында басылган барлык әсәрләрен өстәлгә куйдым. Боларның кайчаннан бирле һәм ничек эшләнүе – бусы озын һәм гыйбрәтле бер тарих. Анысына кереп тормыйм. Мәскәүдә тыелган фондлар ачылып, аннан Исхакыйның чит илдә басылган әсәрләреннән беренчесен – «Жан Баевич» пьесасын алып кайттым.

Шуннан соң гына мин Әнкарага Сәгадәт апага хат язарга батырчылык иттем. Үзем эшли торган институтның грифлы кәгазьләренең берсенә: «Миндә барлар» дип куеп, машинкада басылган бит саннарын да күрсәтеп, тупланган, безнең язуга күчерелгән әсәрләрнең исемлеген, икенче кәгазьгә «Миндә юклар» дип язып, Төркиядә Г. Исхакыйның 100 еллыгына чыгарылган китаптагы исемлектән алып, чит илдә басылган, әмма кулымда булмаган әсәрләрне теркәдем. Сәгадәт апа миңа ышаныр микән, дип борчылдым. Ә Сәгадәт апа миңа ышанган һәм сөенеч тулы хаты белән бергә берничә китап та җибәргән. Ул бандероль умырып ертылган, соңыннан бик тупас итеп скотч белән ябыштырылган иде. Ул чорда бездә читтән килгән һәр пакетны тикшерәләр иде әле. Сәгадәт апаның хаты Г. Исхакыйның чит илдә язылган әсәрләре хакында без белмәгән, ишетмәгән беренче яңалыкларны алып килгән иде.

Соңыннан сөйләүләренә караганда, Сәгадәт апа миннән алган хатны үбеп-үбеп, битенә сөртеп елаган, әле бер, әле икенче танышын өенә чакырып, хатны кат-кат укыткан. Истанбулга танышларына шылтыратып та хәбәр иткән. «Әтиемнең бөтен китаплары табылган, шул мәхшәрле елларда Советлар Берлегендә аларны укыганнар икән, бер ханым аларны җыеп алып, эшкәртеп өлгергән, бастырабыз, дип яза», – дип кабатлый икән.

Кызганычка, бу вакытта инде Сәгадәт апа бик каты авыру, хәлсез булган. Шулай да, «мин үзем салам» дип, почтага барып, миңа дигән хатны да, бандерольне дә үзе

җибәргән. Чыннан да, почтада төрелгән бандероль тышлыгында Сәгадәт апаның кул язуы тора.

Сәгадәт апа күндергән адрес буенча Мәхмүт Таһирга хат яздым. Ул үзенең беренче хатларында ук: «Сәгадәт апа, нәрсә булдыра аласың, шулай ярдәм ит Лена ханымга, диде. Аның высыятен үтәргә тырышырмын», – дип язды. Г. Исхакыйның чит илдә язылган китапларының байтагын, күп кенә фотоматериалларны Төркиядән мин Мәхмүт Таһир аша алдым. Бик күп сорауларыма җаваплар да яза иде. Мин үзем дә ул сораган һәр китапны яки күчермәләрен аңа җибәрә тордым.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк: Мәрьям белән кызы Сәгадәтнең мөнәсәбәтләре турында төрле сүзләр йөргән. Әмма Сәгадәт бик яшьли әтисе янына чит илгә чыгып китсә дә, Чистайда, соңыннан Казанда яши торган әнисе белән араларын өзмәгән. Алар хатлар алышканнар. Моны исбатлый торган фактлар бар. Мәсәлән, Сәгадәт Чагатайның фоторәсемнәр альбомында Мәрьям белән кызы Суфия төшкән рәсем артына «21 август 28 ел. Сәгадәт апага истәлек. Суфия. Чистай» дип язылган. 1928 елда төшкән рәсем: «Сөекле балам! Илһамия белән төшкән рәсememне җибәрәм. Сагынганда карарсың. Әнием». Альбомда Суфиянең 1933 елда үзе генә төшкән рәсеме дә бар.

Илләр арасында чикләр ябылгач, Мәрьям белән Сәгадәтнең дә бәйләнешләре өзелә.

1989 елда Сәгадәт апа әнисе ягыннан бертуган сеңлесе Суфия белән яңадан хат алыша башлый. Казанга Әнкарадан бүләкләр дә килә. Ләкин бу аралашу бик кыска гомерле була. Сәгадәт Чагатай-Исхакый 1989 елның 24 июнендә 84 яшендә Әнкарада дөнья куя. Шул шәһәрдә җирләнә. Сәгадәт ападан варислар калмый.

Мәхмүт Таһир миңа: «Сәгадәт апа тагын бер генә ел яшәсә дә, Г. Исхакый буенча никадәр эш башкарып кала идек!» – дип үкенеп язды. 1991 елның декабрендә Мәхмүт Таһир үзе дә вафат булгач: «Мәхмүт әфәнде, ичмасам, бер генә ел яшәсә дә, күпме мәгълүмат, материал кайткан булыр иде Казанга», – дип мин үрсәләндем....

Г. Исхакыйның Сәгадәт апа хатында телгә алынган китаплары әдипнең 15 томлык әсәрләр тупламасының 5 нче томында басылып чыкты инде. Хатта «Локман хәким» – урысча тәрҗемәсе бар, татарчасы юк», дип язылган. Бу әсәрнең татарчасы Әнкарада галим Рәшит Рәхмәти Арат архивыннан табылды. М. Худяковның Г. Исхакый төрекчәгә тәрҗемә иткән «Казан тарихы очеркы» турында Сәгадәт апа: «Әнкарада Тарих корымында саклана», – дип язды. Тарих җәмгыяте бу китапны Әнкарада 2010 елда бастырып чыгарды.

Күңелдә әрнеп торган үкенеч калды. Без Сәгадәт апа белән очрашырга өлгермәдек. Мин Г. Исхакый әсәрләреннән алты китап әзерләп чыгардым. Әдипнең сөекле кызы, өзелеп көтсә дә, аларның берсен дә күрә алмады. Соң, бик соң тотындык без Исхакыйларны кайтарырга... Күңелемне бары бер нәрсә юата: Сәгадәт апа әтисенең барлык китапларының да исән икәнлеген, аларның басарга әзерләнгәнен белеп китте.

Профессор-тюрколог Сәгадәт Чагатай русча, алманча, инглизчә, французча, төрекчә, латинча, гарәпчә, фарсыча яхшы укыган һәм сөйләшкән. Ул дөньяның төрле илләрендә фәнни конференцияләрдә катнашкан, күп илләрдәге тюркология җәмгыятьләренә әгъза итеп сайланган. Аурупа һәм Азия илләрендә аны яхшы беләләр, китапларын да өйрәнәләр. Шуңа күрә, чит илләрдә хатлар аша Г. Исхакый турында эзләнүләремдә профессор Сәгадәт Чагатай-Исхакый исемен атау үзенә күрә бер ышаныч визиткасы булып тора, дияр идем. Беренче хатта ук башланган теләктәшлек һаман дәвам итә, Г. Исхакый буенча башкарган эшләремдә Сәгадәт апа һаман да юлымны яктыртып тора сыман...

Исән булса, Сәгадәт апага быел 28 июльдә 113 яшь тулган булыр иде.

2007 елның октябрь аенда Әнкара университетының Сәгадәт Чагатай эшләп киткән төрек теле, әдәбияты һәм география бүлеге Сәгадәт Чагатайга һәм аның остазы Вилли Ванг-Каупка багышланган конференция үткәрде. Анда «Профессор др. Сәгадәт Чагатайның тәрҗемәи хәле» исемле югары зәвык белән эшләнгән, Истанбулда нәшер ителгән китап та тәкъдим ителде. Китапның авторы Һади Шенол бездән соратып алган фоторәсемнәр дә биредә урын алган иде.

Конференциядә чыгыш ясаучылар якташыбызның фәнни эшчәнлеген бик югары бәяләде. Шәкертләре – хәзер үзләре дә профессорлар – Сәгадәт апаның югары әхлаклы, әни кебек йомшак күңелле, хәлгә керә белә торган, мәрхәмәтле, акыллы киңәшче булуын искә төшерде. Күңелне каршылыклы, үкенечле хисләр биләде. Затлы нәселдән булган Сәгадәт, Туган илен бер күрергә тилмереп яшәсә дә, бик күп газаплы киртәләрне үтеп, барыбер үзенең чын асылын саклап кала алган һәм үзенә лаеклы биеклеккә ирешкән. Әтисе кебек үк көчле рухлы бу татар кызын Төркия үстергән. Милләтебезнең чит илләргә хезмәт итәргә мәҗбүр булган талантлы кызларын, улларын без әле бик аз беләбез.

2008 елда Истанбулда «Профессор др. Сәгадәт Чагатайның басылып чыккан барлык мәкаләләре» исемле ике томлык мәҗмуга дөнья күрде. Аның төзүчесе профессор Айсу Ата. Сәгадәт Чагатай турындагы китап та, мәкаләләре урын алган томнары да 1988 елда Сәгадәт апа үзе төзеп калдырган Айаз-Таһир (Төркестан-Идел-Урал) вакыфы тарафыннан нәшер ителгән.

Сәгадәт Чагатайның үзе исән чакта басылган «Чура батыр» (1935), «Алтын яруктан ике парча» (1945), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (I т., 1963), «Казакъча мәтеннәр» (1961), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (II т, 1972) һәм башка хезмәтләре бар. Кайберләре Яуширмәдәге Гаяз Исхакый музеена да куелды. Әтисенә җан җылысы, яшәргә көч биреп торган, аның өчен Ватанының бер сөекле кисәкчеге, сагынмалыгы булган Сәгадәтнең, күренекле профессор-тюрколог Сәгадәт Чагатай-Исхакыйның хезмәтләрен тәрҗемә итә башларга иде. Тарихи сәбәпләр аркасында бөтен дөньяга сибелгән талантларыбызны барлау, аларны Туган илләрендә танытырга ярдәм итү ватандашларыбызның бурычы дип саныйм.

Биредә укучыларга тәкъдим ителә торган хатларның икенчесе Сәгадәт апаның соңгы көннәрен тасвирлый. Сәйдә ханым Арсланбәк болар турында әлеге конференциядә сөйләгән иде. Сәйдә Арсланбәк Әнкарада Төрек мәдәниятен өйрәнү институтында профессор Әхмәт Тимер белән бергә эшләгән. Аның әтисе Мансур Арсланбәк Ерак Шәрекътә, Мукденда Г. Исхакый нигезләгән «Милли байрак» гәзитендә хезмәт иткән. Гәзиттә аның мәкаләләре, шигырьләре дә басыла. Сәйдә ханым Г. Исхакый архивының Мәхмүт Таһирда сакланган өлешен тәртипкә сала, тасвирлама төзи, башка материаллар белән бергә Казанга кайтарырга әзерли. 1997 елда Сафия Имре-Мәңгәр ул архивны Казанга алып килеп, Президент Минтимер Шәймиев кулына тапшыра. Хәзер ул материаллар Татарстан Милли архивында саклана.

Сәйдә ханым 1970–1980 елларда Әнкарада татар телендә «Казан» журналын чыгаруда катнаша. Татар милләтенә күрсәткән хезмәтләре өчен Сәйдә ханым Арсланбәк «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

*Сөекле Лена ханым!*

*Хатыгызга күп рәхмәтләр, 27.3 тә язылган, 12.4 тарихында килде. Әтинең мирасы илә мәшгуль булуыгыз мине бик сөендерде. Моның өчен никадәр рәхмәт әйтсәм дә, аз калыр... Табигый, бу эш халкыбызның ярарына булыр. Сез сораган китапларның бер кыйсьме бар, боларны азлап-азлап фотокопияләрен чыгарып юлларбыз, хәзер болар кулымда юк, мин бик картаеп киткәнгә, берсенә сакларга биргән идем, ул Истанбулда. Иншалла, китаплар вә башка әврак (кәгазьләр) саглам торадыр... Алар белән Мәхмүд бәй мәшгуль булачак булды. Бер кыйсьме – Mecid бәйгә дә сөйләдем – «юк»лар арасындагылар Варшавада банк кассасында калгандыр, бу арада без дә, әлбәттә, сугышның зарарларын күрдек. Ул Варшавадан качып чыкты, без дә Берлинда бик күп китап вә әврак калдырып китмәк мәҗбүриятендә калдык, алар бомбалар астында калып янды...*

*2 нөсхә «Идел-Урал»ның французчасын, «Көз» (копиясе) вә 1 нөсхә «Казан» мәҗмугасын бу хат белән сезгә күндерәм. «Тәүбәкәр кадин», урысчасы «Society fon central Asian Studies», № 14. Лондон, 1988 дә басылды, татарчасы юк, язылмады. «Юлсызлар» әсәрен 1918–1919 да Сибириядә «соң язган китабым» дип артист Абдулла Карыйга тәслим итеп китүен сөйләр иде, А. Карыйның вә йә Татар театрының көтепханәсе вә йә архивы бар исә, бәлки, табылыр... «Казан тарихы» Худяковтан*

*тәрҗемә, аның әсәре түгел, сезнең өчен бер кыйммәте юк дип беләм, Төркия төрекчәсендә, Тарих корымында, Анкара.*

*Хат белән күп нәрсә сөйләнә алмый. Бу эш бу! Зур көннәр эчендә бу кадәрене саклый белү дә бер казаныштыр. Ни коткарылса, ул коткарылыр, бик зур заман кичте. Сез эшегезгә дәвам итегез, бастырма эшене башлагыз. Сез Мәхмүд бәйгә мөрәҗәгать итегез. Адрес: Mahtud Tahir, Ankara, Balgat 10. Sokak, 10/9. Китапларны алуыгыз хакында хәбәр алмыйча, башкаларын күндерә алмам, хәбәр бирүегезне үтенәм.*

*«Олуг Мөхәммәд» – кульъязма;*

*«Локман Хәким»нең урысча тәрҗемәсе бар, татарчасы юк;*

*Төрекчә «Өйгә таба».*

*Күп сәлам вә хөрмәтләр белән Сәгадәт Чагатай-Исхакый.*

*Мине сораганнарга да күп сәламнәр.*

*Анкара, 17.04, 1989.*

* * *

*Бөегебез Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт апа турында байтак хатирәләребез бар. Төрек культурасын өйрәнү институтында эшләгәндә Сәгадәт апа, профессор Әхмәт Тимер бәй, Абдулкадыйр Инан, Хәмит Зөбәер Кошай, Наилә Бинарклар белән бергәләп, чәй янында, мәмләкәт мәсьәләләрен сөйләшеп, хәсрәтләрен бүлешәләр иде.*

*1987 елның 24–26 апрель көннәрендә «Дөньяда төрекләр» дигән симпозиумга өстәмә буларак, безгә Татарстан мәдәниятенә кагылышлы, аны танытачак күргәзмә әзерләвебезне үтенделәр. Милләттәшләребез кулындагы әйберләрдән матур бер почмак әзерләдек. Беренче көнне Сәгадәт апа килде. Күргәзмәне күргәч, шатланып: «Ватанымны күргән кебек булдым», – диде. Бер сәгать узгач, кулында бер пакет белән тагын килде. Татар милли киемен китерде. «Моны әтием алган иде, аны да күргәзмәгә куегыз», – диде. Җефәк кием, төймәләре көмеш ялтыравыклы иде. Күргәзмә бетемендә күлмәкне һәм шул күлмәкне киеп әтисе белән бергә төшкән фотоны да миңа бирде. «Башка күргәзмәләрдә дә кулланырсыз», – диде. Соңыннан мин ул күлмәкне Казанга музейга җибәрдем. Мәрхүмә үзе бара алмады, ләкин киемнәре китте. (Хәзер ул күлмәк Казан милли-мәдәни үзәге музеенда саклана. – Л.Г.)*

*Сәгадәт апа мәмләкәтнең ризыкларын яратыр һәм аларны үзе дә бик әйбәт пешерер иде. «Казан» культура һәм ярдәмләшү җәмгыяте җыелышларына килер һәм һәрвакыт матди ярдәм калдырыр иде. Шундый җыелышларның берсендә аның авыру кыяфәтен күреп: «Авырыйсызмы әллә, төсегез яхшы түгел?» – дип сорадым. «Хәлем юк, врачка алып бардылар, суык кына тигән, диделәр, витамин бирделәр», – диде Сәгадәт апа. Ә кичен, хәзер мәрхүм инде, Нәҗип Хабләмит углына шылтыраттым. «Синең таныш доктор Нәҗәти бәйнең профессор Сәгадәт апаны кабул итүен оештыра алмассың микән? Үзен бик әйбәт күрмәдем», – дидем. Доктор бәй дә шунда ук: «Мөгаллимәгезне иртәгә иртәнге якта китерегез», – дигән. Телефоннан Сәгадәт апага: «Иртәнге сәгать 8 дә врачка алып барырбыз», – дидем. Сөенде. Иртәнге 8 дә киенгән, сумкасы кулында килеш безгә ишек ачты.*

*Шулай итеп, авыруны тикшерүләр башланды. Доктор безгә начар хәбәр әйтте: «Бавыр рагы. Кызганыч, соңгы стадия. Нигә соңга калдыгыз?» – диде. Үзенә бернәрсә әйтмәдек. Анализлардан соң өенә бик арыган хәлдә кайтты. Мин үзем аны кәнәфигә яткырдым, ризыгын хәзерләдем. Бер көнне башын кочагыма алып, ризыгын ашаттым. Сөйләшкәндә: «Балалар, сезгә бик мәшәкатьләр ясыйм», – диде. Мин дә: «Нишләп мәшәкать булсын, без дә сезнең балаларыгыз саналабыз», – дидем. Аның зәңгәр күзләре яшь белән тулды. «Сезнең кебек балаларым булса иде», – дип елады.*

*Профессор Исмәгыйл Каябалы бәй Сәгадәт апаны медицина факультетының реанимация бүлегенә салды. Үзен ташланган кебек хис итмәсен өчен, көненә өч тапкыр аның янына бара идем. Әмма хәле көннән-көн начарая барды. Бер көнне янында озакка калдым. Аерылганда учыма алкаларын һәм беләзеген куйды. Мин бик борчылдым. Ул үлгәннән соң әманәтләрне Казанга кыз кардәшенә җибәрдем.*

Сәйдә Арсланбәк.

УДК 821.512.145

# ГАЯЗ ИСХАКИ НА СТРАНИЦАХ НЕКОТОРЫХ ИЗДАНИЙ ЗАРУБЕЖЬЯ

*Л.Ш. Галиева*
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье освещаются некоторые зарубежные издания («Rocznik tatarski» («Татарский ежегодник»), «Życie tatarskie» («Татарская жизнь»), «Wschod» («Wschod-Orient», «Восток»), «Горцы Кавказа» («Северный Кавказ»), «Daleki wschod» («Дальний Восток»), «Przeglad tatarski» («Татарский обзор»), «Вольное казачество», «Promethee» («Прометей»), на страницах которых были опубликованы статьи известного татарского писателя и общественного деятеля Гаяза Исхаки, публикации о нем, а также сопутствующая информация из хроник и другие материалы.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Идель-Урал, Дальний Восток, эмигрантская пресса, издания польских татар.

The article highlights some foreign publications («Rocznik tatarski», «Życie tatarskie», «Wschod» («Wschod-Orient», («Northern Caucasus»), «Daleki wschod», «Przeglad tatarski», «Free Cossacks», «Promethee», on the pages of which articles of the famous Tatar writer and public figure Gayaz Iskhaki, publications about him, as well as related information from the chronicles and other materials were published.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, Idel-Ural, Far East, emigrant press, publications of Polish Tatars.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КАЙБЕР ЧИТ ИЛ БАСМАЛАРЫНДА

*Л.Ш. Галиева*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

«Матур әдәбиятның проза, драмтургия өлкәләрендә, шулай ук публицистика һәм әдәби тәнкыйтьтә киң танылып, ул үз вакытында замандашлары Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Й. Акчура, Г. Кәрам һ.б. тарафыннан бик югары бәяләнгән» [3: 59] күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты хакында күп кенә хезмәтләр дөнья күрсә дә, аңа кагылышлы яңадан-яңа фактлар табыла тора. Хәзерге вакытта аларның күбесе әдипнең мөһаҗирлек чорына бәйле. Әлбәттә, бу юнәлештәге эшне язучының чит илләрдә яшәгән дәверен яктырткан галимнәребез И. Нуруллин, М. Хәсәнов, Ә. Кәримуллин, Ф. Мусин, Х. Миңнегулов, Л. Гайнанова, Ә. Сәхапов, Р. Гайнетдинов, Б. Гали, С. Исхаков, З. Мөхәммәтшин, А. Заһидуллин, И. Мансуров, Г. Галәветдинов һ.б. хезмәтләренә таянып кына алып барырга мөмкин. Әлеге мәкалә кысаларында Г. Исхакыйның кайбер чит ил басмаларында дөнья күргән мәкаләләре, аның турында басылып чыккан язмалар һәм төрле мәгълүматлар карала. Аларның төп өлешен Россия эмигрантларының матбугаты тәшкил итә. Шулай ук биредә Польша татарларының басмаларына мөрәҗәгать ителде.

Билгеле булганча, 1994 елда күренекле галим Ә. Кәримуллин татар җәмәгатьчелеген Г. Исхакыйның 1932 елда Вильно (хәзерге Вильнюс) шәһәрендә, «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы») басмасында поляк телендә дөнья күргән «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсе белән таныштыра [6]. Мәкаләне рус теленә галим Рифкать Йосыпов тәрҗемә итә. Соңрак ул аны «Польские страницы жизни Гаяза Исхаки» дип исемләнгән мәкаләсендә дә бастырып чыгара [7]. Язмадан аңлашылганча, Г. Исхакый Польшада яшәүче татарларның тарихы, мәдәнияте белән кызыксынган, аны аларның язмышы борчыган. Галимә Л. Гайнанова 1999 елда басылып чыккан Г. Исхакый әсәрләренең икенче томында телгә алынган «Rocznik tatarski» журналы хакында өстәмәләр кертә: «Бөек Ватан сугышына кадәр Польшада поляк телендә поляк-литва татарларының тарихы, тормышы, мәдәнияте турында «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы») дигән исемдә өч җыентык чыгып өлгерә (1932 елда – Вильнода, 1935 елда – Замощчта, 1938 елда – Варшавада) [5: 458]. Ә. Кәримуллинда әлеге басманың соңрак нәшер ителгән саннарын да эзләп карый, әмма Казан, Мәскәү һәм Санкт-Петербург китапханәләрендә китапчы галим кулында булган мәҗмуга да

табылмый. Хәзерге вакытта «Татар елъязмасы»ның әлеге һәм башка саннары белән Польшаның электрон китапханәләре аша танышырга мөмкин.

Чыннан да, «Татар елъязмасы»ның өч саны өч шәһәрдә дөнья күрә, дүртенчесе 1939 елда башланган сугыш аркасында басылмый кала.

1932 елда нәшер ителгән җыентыкта Г. Исхакыйның «Польша татарларының милли бурычлары» дип исемләнгән мәкаләсе урнаштырылган. Моннан тыш әдипнең эшчәнлеге хакында башка мәгълүматлар да бар: Арслан Бәй тарафыннан язылган «Генерал Мацей Сулькевич» язмасында Г. Исхакыйның «Wschod» журналында дөнья күргән «Сугыш вакытында татар хәрби оешмалары» мәкаләсенә сылтама бирелә (бу мәкаләнең эчтәлеге белән үз хезмәтендә галим Б. Гали таныштыра [2: 58–59]); «Яңа милли юл»да поляк татар гаскәриләре рәсемнәре урнаштырылуы; мөхәррире Г. Исхакый булган «Яңа милли юл» журналының чыгып килүе һ.б. турында хәбәр ителә. Елъязманың редакторы – Леон Найман Мирза Кричинский (1887–1939) – Вильнода Татар халык музее һәм Татар халык архивын оештырган зат.

«Татар елъязмасы»ның икенче томында да Г. Исхакый, аның эшчәнлегенә кагылышлы фактлар теркәлгән. Мәсәлән, мәҗмугада ислам журналлары мөхәррирләре төшкән фотосурәт бар, биредә Барасби Байтуган («Төньяк Кавказ»), Вассан Гәрәй Җабагый («Ислам күзәтүе»), Л.Н.М. Кричинский («Татар елъязмасы»), Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә («Истикъляль»), Г. Исхакый («Яңа милли юл») бергә утырганнар. Әлеге фотосурәт шулай ук Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә энциклопедиясендә дә урнаштырылган. Сүз уңаеннан, энциклопедиядә Г. Исхакыйның «Прометей» хәрәкәте лидерлары белән төшкән фотосурәте дә бар. «Татар елъязмасы»ның өченче томы исә Литва татарлары тарихына багышланган.

«Rocznik tatarski»дан тыш поляк җирендә Польша татарлары һәм шулай ук Казан татарлары тормышына күзәтү ясап башка басмалар да чыгып килә. Шулар арасында иң билгеле булганы – «Życie tatarskie» («Татар тормышы»). Журнал 1934–1939 елларда нәшер ителә, редакторы – Стефан Туган-Барановский. Әлеге басманың барлык саннары белән дә әлегә танышу мөмкин булмады. Шулай да 1937 елгы 5 нче санның беренче битләрендә урнаштырылган Али Мурза-Мурзич мәкаләсе игътибарга лаек, чөнки биредә Г. Исхакыйны 40 еллык әдәби эшчәнлеге белән котлау сүзләре урнаштырылган [12]. Мәкаләдә әдипнең биографиясе китерелә, иҗатына күзәтү ясала. Моннан тыш, журналның күзәтү, хроника өлешләрендә Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге хакында да мәгълүматлар туплап була. Журналның 1938 һәм 1939 елгы 8 нче саннарында Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» («Sunetczy-Babaj») әсәре басылып чыккан дигән мәгълүмат бар [13: 287]. Кызганычка каршы, журналның әлеге саннары безнең кулда юк. Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәре исә тагын бер кат 1994 елда Адам Мурман тәрҗемәсендә һәм кереш сүзе белән «Rocznik Tatarow Polskich» журналында поляк телендә дөнья күрә [11]. Әсәрнең сканер вариантын безгә поляк галиме Г. Червинский тапшырды.

Билгеле булганча, Г. Исхакый Варшаваның Көнчыгыш институты белән дә хезмәттәшлек итә. Институтның Көнчыгышны өйрәнүче яшьләр түгәрәге исеменнән Көнчыгыш мәсьәләләренә кагылышлы өч айга бер «Wschod» (соңрак «Wschod-Orient») дип исемләнгән журнал нәшер ителә. 1930–1939 еллар аралыгында аның барлыгы 31 саны дөнья күрә.

Журналда Г. Исхакыйның өч мәкаләсе басыла: «Идел-Урал», «Сугыш вакытында татар хәрби оешмалары», «1931 елгы мөселман конгрессы». Алар поляк һәм инглиз телләрендә язылган. Г. Исхакыйның иҗади эшчәнлегенә 40 ел тулу уңаеннан «Wschod» журналында поляк телендә Мәхмәд Вәисинең мәкаләсе басылган. Шунысын билгеләп үтәргә мөмкин: Мәхмәд Вәиси исеме белән бастырган авторны, галимә Д.М. Госманованың хезмәтләренә таянып, 1920 елларда Вильнога килеп урнашкан Мөхәммәдгаян Вәисев, тарихка кереп калган Вәисиләр хәрәкәте нәселенең бер вәкиле дип танырга кирәк [8: 257].

Харбин шәһәрендә поляк телендә «Daleki Wschod» («Ерак Шәрык») дип исемләнгән журнал да чыгып килгән. Аның азагында гарәп шрифтында «Безнең барыш» – «Ошбу исемдә Харбинда әледән-әле чыгып торачак татар тормышына багышланган

сәхифәләр» урын алган. Биредә сәхифәләрнең идарәсе тарафыннан Тукай тантанасы яктыртыла. Кушымтаның икенче мәкаләсе булып Г. Исхакыйның «Ерак Шәрык» язмасы урнаштырылган. Бу сәхифәләрнең тарихы әлегә журналның шушы саны белән чикләнә.

Г. Исхакыйга бәйле кызыклы фактларны Россия эмигрантларының тарихын тикшергән галимнәрнең хезмәтләреннән дә туплап була. Мисал өчен, Төньяк Кавказ мөһаҗирләренең басмаларын өйрәнгән галимә А.Н. Рубанова үзенең «Горцы Кавказа» и «Северный Кавказ» как источник по истории горской эмиграции мәкаләсендә шундый сүзләр китерә: «В журнале печатали свои статьи и очерки представители северокавказских эмигрантских общин Варшавы, Лиона, Лозанны, Нью-Йорка, Парижа, Праги – Арслан, Аптек, Таулу, Кази-хан, Хаджи-Билал, Азамат, Аяс-Исхаки, Адиль-Бек Кулатти, Догуж, Темир Базырыкхо, Кундух, Дауд, Адыге, Хурш, Андемыркан, Джанхот и другие» [9]. «Северный Кавказ» – Кавказда яшәүче тау Халыклары партиясенең басма органы. Ул 1929 елдан алып 1934 елның апреленә кадәр Парижда «Горцы Кавказа», 1934 елның май аеннан 1939 елга кадәр «Северный Кавказ» исеме белән чыгып килә.

1933 елда «Төньяк Кавказ» журналында рус телендә Г. Исхакыйның «Дальний Восток» дип исемләнгән мәкаләсе басыла. 1930 елгы 12 санында исә әдипнең редакциягә язган хаты урнаштырылган. Әлеге хатта Г. Исхакый «Дни» журналы редакторына мөрәҗәгать итә һәм әлеге басмада «Төркиягә хезмәттә» дип мәкалә белән чыгыш ясаган господин Хондкарьян язганнарына каршы чыга. Бәхәс Г. Исхакыйның 1925 елда «Төрек йорты» журналында төрек телендә басылып чыккан «Бөтен төрекләр өчен уртак төрек теленең барлыкка килүе мөмкинме?» мәкаләсенә бәйле. Эчтәлектән аңлашылганча, Г. Исхакыйны Хондкарьянның дүрт ел элек дөнья күргән язмасына мөрәҗәгать итүе гаҗәпләндерә. Аны инде ул «сәяси актуальлеген югалткан», дип саный.

«Төньяк Кавказ» журналының барлык саннары да безнең кулда булмау сәбәпле, Г. Исхакый имзасы белән басылган язмалар биредә башка табылмады. Шулай да басманың 1938 елгы 47–48 саннарында язучының чыгышы урнаштырылган. Аны Г. Исхакый «Прометей» клубында В. Бончковский ясаган докладтан соң башланып киткән бәхәс дәвамында яңгырата. Мәкаләгә кереш сүздә әдип Идел-Урал милли хәрәкәтенең лидеры буларак тәкъдим ителә.

Г. Исхакыйның әдәби һәм публицистик эшчәнлегенә кырык ел тулу уңаеннан «Северный Кавказ» журналының 1937 елгы 7 санында аңа багышланган ике мәкалә бастырылган. Җәгъфәр Сәедәхмәднең «Казан әдәбияты һәм Гаяз Исхакый» дигәне татар укучысына әдипнең унбиш томлыгы аша таныш. Ул төрек телендә язылган. Мөхәммәт Вәйсинең «Аяз Исхаки» язмасы исә рус телендә басылган. Биредә мәкалә авторы юбилярның тормыш һәм иҗат юлына кыскача күзәтү ясый.

«Горцы Кавказа» журналының 1931 елгы 26 санында О. Идилли имзасы белән «Об Идль-Урале» мәкаләсе урын ала. Текст эчтәлегеннән чыгып әлеге язманы да Г. Исхакый язган дигән фикер туа. Биредә автор М. Худяков хезмәтләренә мөрәҗәгать итә, «Кызыл Татарстан» газетасыннан өземтәләр китерә. Моннан тыш, журналның хроника өлешендә Г. Исхакыйның Ерак Шәрыктагы сәяхәтенә бәйле күп кенә фактлар теркәлгән. Мәсәлән, саннарның берсендә язучыга һөҗүм ителү турында хәбәр ителә. Әлеге хәл Япония мөселманнарының ачуын чыгара. Журналның тагын бер саны күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесенә багышланган кичә турында яза. Биредә Г. Исхакыйның «Жан Баевич» комедиясе беренче тапкыр сәхнәдә куела. Язучы җирле халык алдында Европада яшәүче татарлар турында чыгышлар ясый. Шулай ук журналда Идел-Урал Бәйсезлек комитетының барлык мөселманнарга мөрәҗәгате дә бастырылган.

Билгеле булганча, Г. Исхакый кайбер мәкаләләрен төрле тәхәллүсләр белән bvpfksq. Галимә Л. Гайнанова аның берсе хакында шундый мәгълүмат җиткерә: «Гаяз Исхакый 11 ел буена Берлинда үзе чыгарган «Милли юл», соңыннан «Яңа милли юл» журналында байтак мәкаләләрен «Чура батыр» псевдонимы белән язган» [3: 384]. Сүзләрен дәлилләү өчен ул Г. Исхакыйның тәрҗемәи хәленә игътибарны юнәлтә: «Г. Исхакый үзенең төрек телендә гарәп хәрефләре белән язган, берничә вариантта каралама килеш калган “Тәрҗемәи хәлем” кулъязмасында: “Әниемнең этиләре, әниләре дүрт буынга кадәр голяма (укымышлылар) зөмрәсеннән, Казанның хәле авыр вакытта Кырымнан Кырым шаһзадәләре идарәсеннән Казанга ярдәм итәргә килгән,

“Чура батыр” хикәясенә тема биргән кешеләр токымыннан”, – ди» [3: 384]. Л. Гайнанова бу тәхәллүс турында кабат быел «Мәдәни җомга» битләрендә язып чыга [1]. «Горцы Кавказа» журналының 1930 елгы 12 санында Чура Батыр исеме белән «Развал татарской коммунистической партии в Казани» мәкаләсе бастырылган. Аны да, ихтимал, Г. Исхакый язган дияргә мөмкин.

Эмигрантларның тагын бер басмасында – «Вольное казачество» журналында шулай ук Г. Исхакый язмаларына тап булабыз. Журнал 1927 елдан алып 1934 елга кадәр Прагада, 1934 елдан 1939 елга кадәр Париж шәһәрендә дөнья күрә. 1932 елда басылган 25 санда «Вольное казачество» журналының бишьелkык юбилее уңаеннан «Милли юл» журналының мөхәррире Г. Исхакый чыгышы бастырылган. Чыгышның ахырында ул, «Прометей»ның Варшава клубы вәкиле буларак, әлеге оешманың сәламләү хатын җиткерә. Соңрак, 1933 елның май санында, журналда рус телендә Г. Исхакыйның «Идель-Урал» язмасы да чыга.

Тарихчы С.М. Исхаков мәкаләсеннән күренгәнчә, «Prométhée» («Прометей») журналында Г. Исхакыйның «Кызыл хаҗилар яки большевикларның икейөзлелеге» (1931, №52), соңрак «La Revue de Prométhée»да француз телендә «Loukman le Saga» («Локман Хәким») әсәре дөнья күрә (1938, №2). Соңгысы язучының «Шәхесләребез» сериясендә басылып чыккан тарихи-документаль җыентыкта китерелгән библиографик исемлектә дә теркәлгән. «Прометей» журналында Г. Исхакый имзасы (Ishaki) куелган тагын бер мәкалә бар. Ул 1933 елгы 77 санда басылып чыккан, «Идел-Урал татарларының бәйсезлек өчен көрәшенә күзәтү» дип атала. Авторы билгесез бер язмада Г. Исхакыйның Европага әйләнеп кайтуы хәбәр ителә. Мостафа Чокайның «Милли юл» хакындагы күләмле мәкаләсе 1929 елгы санда урын алган.

«Прометей» журналының 137 саны дөнья күргән. Шулардан кырыгының эчтәлеге, кызганыч, әлегә безгә таныш түгел.

Эзләнү барышында Г. Исхакыйга бәйле тагын бер фотография табылды. Аны 2014 елда «Przeglad tatarski» («Татар күзәтүе») журналында поляк татары Селим Хасбиевич урнаштырган [10: 25]. С. Хасбиевич фотосурәтне редакциянең архивыннан алуы турында хәбәр итте. Г. Исхакый узган гасырның утызынчы елларында редакциягә килеп йөргән дигән мәгълүмат бар. Әмма әлеге фотография бәхәс уята.

Гомеренең яртысын диярлек чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган Г. Исхакыйның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү дәвам итә. Күрәбез, ачыклыйсы фактлар да, каткат тикшерүне сорый торган мәсьәләләр дә күп. Киләчәктәге эзләнүләр дә табышлы булсын.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гайнанова Л. Исхакыйның яңа тәхәллүсләре // Мәдәни җомга. – 2023. – 22 февраль.

2. Гали Б.Т. Щедрый талант. Общественно-политическая деятельность и исторические взгляды Гаяза Исхаки. – Казань: «Унипресс». – 2002. – 96 с.

3. Закирҗанов Ә.М. Гаяз Исхакый һәм XX йөз башы татар драматургиясе // Фәнни Татарстан. – 2018. – № 2. – Б. 59–66.

4. Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 398 б.

5. Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Б. 419–462.

6. Кәримуллин Ә., Нигъмәтҗанова А. Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары // Мирас. – 1994. – № 5–6. – Б. 196–199.

7. Юсупов Р.Р. Польские страницы жизни Гаяза Исхаки // Вестник Челябинской государственной академии культуры и искусств. – 2012. – № 1 (29). – С. 144–146.

8. Усманова Д.М. Ваисовцы в Литве // Orientas Lietuvos Didžiosios Kunigaikštijos visuomenės tradicijoje: totoriai ir karaimai. Vilnius: VU leidykla, 2008. – P. 253–262, summary 360 p.

9. Рубанова А.Н. Журналы «Горцы Кавказа» и «Северный Кавказ» как источник по истории горской эмиграции // Вестник Адыгейского государственного университета. Серия 1: Регионоведение: философия, история, социология, юриспруденция, политология, культурология. 2013. №1 (113). URL: https://cyberleninka.ru/article/n/zhurnaly-gortsy-kavkaza-i-severnyy-kavkaz-kak-istochnik-po-istorii-gorskoy-emigratsii (дата обращения: 20.10.2019).

10. Chazbijewicz S. Tatarstan. Pomiedzy autonomia a tesknota do suwerennosci // Przeglad tatrski. – 2014. – № 2. – S. 23–27.

11. Ishaki Ayaz. Sunetczy-Babaj // Rocznik Tatarow Polskich. – 1994. [t.] 2 s. – S. 172–192.

12. Murza-Murzicz A. Akademja ku czci Ayasa Ishaki Bey’a // Życie Tatarskie. – 1937. – № 5. – S. 1–3.

13. Wroblewska U. Czasopisma tatarskie jako źródło do analizy oświaty Tatarów w latach 1918–1939 Addenda do dziejów oświaty. Z badań nad prasą Drugiej Rzeczypospolitej. – Łódź, 2013. – S. 281–295.

УДК 82.091

# О ЛИЧНОМ АРХИВЕ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Л.Ш. Гарипова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В 1990–1991 гг. в ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ на основе материалов, собранных во время археографических экспедиций, и благодаря непосредственной помощи и содействию отдельных лиц, формируется фонд, посвященный жизнедеятельности известного татарского общественного деятеля, публициста, писателя Г. Исхаки (1878–1954). В 2008, 2018 годах при поддержке руководителя фонда «Аяз-Тахир (Туркестан – Идел-Урал)» Тулей Дуран на родину писателя возвращаются более трехсот материалов из его личного архива (оригиналы и электронные копии документов, личные дневники, письма, фотографии и т.д.). Статья посвящена вводному аналитическому обзору фонда деятеля, сформированного на основе вышеуказанных источников, его историографии и предпосылках создания. В качестве дополнительного материала ознокомительного характера представлены отдельные отрывки из воспоминаний о годах, прожитых в эмиграции, записи о произведениях, где прослеживается творческий путь писателя.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, фонд, эмиграция, дневники, наследие.

In 1990–1991 In Iali them. G. Ibragimova Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan based on materials collected during archaeographic expeditions, and thanks to the direct help and assistance of individuals, a fund is formed dedicated to the life of the famous Tatar public figure, publicist, writer G. Iskhaki (1878–1954). In 2008, 2018, with the support of the head of the Ayaz-Takhir (Turkestan–Idel-Ural) Foundation, Tula Duran, more than three hundred materials from the writer's personal archive (originals and electronic copies of documents, personal diaries, letters, photographs, etc. are returned to the writer's homeland. d.). Thus, the fund is supplemented by the new richest heritage of the classic, which is value both for historians, literary critics, political scientists, and for a wide range of readers. The article is dedicated to the introductory analytical review of the Foundation of a figure formed on the basis of the above sources, his historiography and the prerequisites for the creation. As an additional material of an overgrown nature, separate excerpts are presented from the memories of the years lived in exile, entries about the works where the writer's creative path is traced.
**Key words:** G. Iskhaki, foundation, emigration, diaries, legacy.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ШӘХСИ АРХИВЫ ХАКЫНДА

***Л.Ш. Гарипова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар әдәбияты классигы, танылган җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый – XX гасыр төрки-татар милли-сәяси тормышында тирән эз калдырган, аның рухи-мәдәни үсешенә көчле йогынты ясаган күренекле шәхес. XX йөз башы татар әдәби хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе булган, аның яңарышына гаять зур өлеш керткән әдип большевиклар властен кабул итми, 1919 елда чит илгә китә. Г. Исхакый совет власте дошманы дип игълан ителә, исеме, хезмәтләре әдәбият-мәдәният тарихыннан алып ташлана.

1990 елларда Россиядә сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләр башлангач, мөһаҗирлектә гомер кичерергә мәҗбүр булган татар әдәбияты классигы, танылган җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның язма мирасын барлау һәм халыкка кайтару эше башланып китә. 1993 елда Татарстан Республикасының Чистай районы Яуширмә авылында Гаяз Исхакыйның мемориаль музее ачыла, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге Әдәби премиясе булдырыла.

Әдипнең тормыш юлы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, әдәби мирасы, фәнни яктан шактый җитди өйрәнелеп, аерым хезмәтләрдә чагылыш таба. Шуның белән берлектә ТР Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә, шулай ук аерым кешеләрнең ярдәме белән дә язучы мирасы туплана башлый. Алар нигезендә 1990 елда язучының шәхси фондын оештыру да мөмкин була, аның беренче тасвирламасы да

төзелә (135 нче фонд). Соңрак, Г. Исхакый иҗаты туган илендә өйрәнелә башлап, мирасы акрынлап халкына кайтарыла, тормышын, иҗатын яктырткан материаллар күпләп басыла, аларның күчермәләре үзәккә туплана бара. Галимнең кызы Сәгадәт Чагатай нигезләгән «Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал Вакыфы» фонды җитәкчелеге әлеге бәһасез эштә һәрдаим ярдәм итеп килә. Шунысы мөһим: 1993 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре язучы әсәрләрен 15 том итеп бастырып чыгару эшен башлап җибәрәләр. Шушы җәһәттән Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге чорын яктырту өчен әлеге Вакыф белән тыгыз элемтәдә торып эш итәләр. 2008 елда, язучының юбилее уңаеннан, Төркиянең «Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакый мирасының бер өлешен ватанына кайтаруда зур ярдәм итә: олуг ватандашыбызның сирәк документлары, язмалары, кайбер мәкаләләренең, хатларының электрон күчермәләре институт Мирасханәсенә тапшырыла. 2018 елда исә язучы архивындагы документларның оригиналлары да институтка тапшырыла: 7 сентябрь көнне Фәннәр академиясендә фондны тапшыру тантанасы уза.

Гаяз Исхакый архивы язучының әдиплек, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә, шәхси тормышына мөнәсәбәтле документлардан гыйбарәт. Алар арасында язучы әсәрләренең кульязмалары, аның 1919 елдан алып вафатына кадәр алып барган хатирә дәфтәрләре, эш кәгазьләре, төрле оешмаларга юлланган мөрәҗәгать-хатлары, фотосурәтләре, үзе исән вакытта нәшер ителгән басмалары бар. Шулай ук биредә Сәгадәт Чагатай тарафыннан язылган көндәлек дәфтәрләре дә (барлыгы 36 дәфтәр: ЯМҮ, 135 ф., 5 тасв., 1–36 сакл. бер.) кыйммәтле мирас булып тора. Алар аша шул чор вазгыяте, Г. Исхакыйның даирәсе, халәте һәм язучының соңгы көннәре хакында да мәгълүмат ала алабыз. Фонд тасвирланган, ул 366 саклану берәмлегеннән гыйбарәт һәм алар 2022 елда тулысынча цифрлы форматка күчерелде.

Язучының фондында, аерым алганда, аның мөһаҗирлек дәверен яктырткан материаллар арасында көндәлек дәфтәрләре аеруча зур әһәмияткә ия. Көндәлекләр 1919 елның апрель аеннан башланып, 1953 елның 10 нчы ноябренә кадәрге вакыйгаларны, ягъни Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге хәятен үз эченә ала [1: 103]. Алар гарәп язуында гади укучы дәфтәренә язылганнар, күләмнәре ягыннан төрлечә. 1919 елдан 1921 елга кадәр алып барылган көндәлекләр үзләре 20 дәфтәрдән гыйбарәт булып, һәр көн булып үткән вакыйгаларга җентекле анализ ясалып барыла. Ләкин шуннан соң көндәлек алып бару эше тукталып кала һәм 1928–1932 еллардагы хатирәләр 2 дәфтәргә тупланган. Аннан тагын, ягъни 1932 елдан 1942 елга кадәр вакыт аралыгында тынлык, өзеклек. Яңадан көндәлек алып бару соңрак, бары 1943 елда Төркиядә яңартыла. «Истанбулдагы хатирә дәфтәрләрем» дип аталган әлеге истәлекләр үзләре 19 дәфтәрдән гыйбарәт, бу – 1943 елның 13 августыннан 1953 елның ноябренә кадәр вакыт арасы.

Көндәлекләр язучының Версаль тынычлык конференциясенә баргандагы авыр, михнәтле һәм дә җаваплы юлның төрле яктан тасвирлануы белән башланып, әдипнең мөһаҗирлектәге – Европа һәм Азиянең төрле мәмләкәтләрендә яшәгән тормышын, эшчәнлеген тулы күзалларга ярдәм итә: «Русиядән чыккандан башлап, көндәлек дәфтәр язу гадәтем иде. Ләкин бу өч сәнәдән артык дәвам итә алмады. Германиягә күчеп килгәч, хәятем бик гади юлга керде. Немесләрнең тормышында төрле үзгәрү булса да, никтер аңарга сәерче (*читтән карап торучы*) булып калдым. Зур әһәмият бирмәдем. Төркиягә килдем. Анда бик зур өмид берлә, бик күп ихласлар берлә килгән идем. Төркия, хакыйкатән, безнең кебекләрнең хезмәтләренә мохтаҗ иде. Һәм дә безнең буш вакытымыз күп иде. Төркия үзенең тормышында бик күп өстендәге үзгәрүләргә мәгъруз (*күз алдына куелган)* кала иде, язарга бик күп нәрсә бар иде. Ләкин Төркиядә аз гына да хөррият булмаганга, хатирә дәфтәрем язмадым», – дип аңлата ул. Гомер буе «шәхси тартыш, милли тартыш, сәяси тартыш» белән яшәгән әдип көндәлекләренең ахыргы битләрендә аның авыру тарихы языла. Хастаханәдә ятканда да ул көндәлек дәфтәрен ташламаган, кыска гына булса да, нидер теркәп барырга тырышкан. Үзен караган табиблар, дәвалану барышы, нәтиҗәләре турында күп мәгълүмат бирелә аларда: «Бик күпләр килде-китде, мине ялгыз, үзбашым калдырмадылар. Халыкның җылы дустлыгы, безнең кебек халык юлында хаста булганларга, мәгънән, шифалы дару кебек буладыр. 15 октябрь, 1953».

Гомеренең күп өлешен чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган язучының тормыш-көнкүрешен ачыграк күзаллар өчен аның дус-ишләренә, фикердәшләренә язган хатлары әһәмиятле [6, 7]. Мәсәлән, Г. Исхакый Финляндиядәге милләттәшләребезне туплауда зур эш башкара. Бередә Зиннәт Вафиннар гаиләсе белән тыгыз бәйләнештә тора, соңыннан аларның кызлары Халидә Вафина белән еш хат алыша (135 ф., 3 тасв., 28 сакл. бер.). Архивта Идел-Урал милли мәркәзенең Америкадагы даими вәкиле Хәмид Рәшидкә (1912–1964), 135 ф., 3 тасв., 26 сакл. бер.), Америка илчелегенә, Квантун армиясе майоры Ямаокага (135 ф., 3 тасв., 13 сакл. бер.), һ.б. язган хатлар белән танышырга мөмкин. Варшавада яшәгәндә ул шунда килеп төпләнгән татар мөһаҗирләре белән ныклы элемтәдә була. Мәсәлән, Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдгәрәй әфәнделәр белән язышкан хатлары фондта саклана, алар белән очрашулары хакында көндәлекләрендә дә телгә алына. 1946 елда язучы «Хәят юлында» исемле драма әсәре яза. Ул шул елны «Яңа чаг» («Яңа заман») басмасында нәшер ителә. Г. Исхакый әлеге әсәрен сәхнәдә дә күрергә тели, шушы максат белән аның «Измир бәләдиясе язу эшләре мөдирлегенә» язган хаты белән дә танышырга мөмкин:

«Газеталарда тәэлиф пьесалары хакында игъланыгыз күрәрәк арсенал әсәрем улан «Хәят юлында» намлы пьесамы тәдкыйкыңызә *(игътибарыгызга)* тәкъдим идейүрем. Бу әсәр 1946 сәнә шөбат *(февраль)* аеннан май 1есенең 18 нә кадәр 16 тәфәррекый сурәтдә *(өлешләп)* «Яңа чаг» мәҗмугасында нәшер иделмешде, бу пьесам бу вакытә кадәр һичбер йирдә сәхнәйә куелмасдыр. Әсәреме [...] сәхнәбезә мөнасиб булырсаңыз, мәктүблә шәраятеңезе белдермәңези рижа идәрем *(үтенәмен)*.

Бән – Шимале төрек мөхәррирләреннән. Мәмләкәтем Идел-Уралда 1905 сәнәсеннән башлап, милли театрымызның большевикларның тәхәккеменә *(хөкем сөрүенә)* кадәр (1920) унбишдән фазлә (*артык*) пьесам Казан, Уфа, Әстерхан, Оренбург шәһәренең сәхнәсендә бөек мәүкыйг *(вакыйга)* тотмышлардыр. 19 гыйнвар, 1951 ел». (135 ф, 3 тасв., 22 сакл. бер.)». Ләкин пьеса сәхнәдә куелганмы, юкмы, әлегә бу хакта мәгълүмат юк. Әсәр Исхакыйның 15 томлык «Әсәрләр»е тупланмасына кергән, аны том өчен төрек теленнән галим Рәшит Кадыйров тәрҗемә итә, һәм ул әлеге академик басманың 5 нче томында урын ала (2009).

Фондта Г. Исхакыйның 30 га якын хаты саклана. Аларда әдипнең эзләнүләре, теләк-омтылышлары, канәгатьсезлекләре дә чагылыш тапкан. Хатлары аша горур, үткен сүзле, кырыс һәм таләпчән язучыны күрәбез, милләттәшләренең тормышларын мәгънәлерәк, җиңелрәк итү өчен бөтен көчен куйган, үз-үзен аямаган шәхес белән очрашабыз.

Гаяз Исхакыйның эшчәнлеген тулырак күзалларга мөмкинлек биргән язмалары, аның төрки-татар дөньясы көнүзәк мәсьәләләренә багышланган публицистик мәкаләләре, чыгышлары аерым әһәмияткә ия. Кайберләре төрек, инглиз, алман телләренә тәрҗемәдә бирелгәннәр. Мәсәлән, «Төрек учагының тәэсисе хакында», «Төрк галәме гаять бөек мәгънәви инкыйлаб кичерде...», «Мәгариф нәзарәтләре», «Милләтемә», «Әлифба мәсьәләсенә» кебек мәкаләләренең караламалары, шулай ук К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Г.Идриси хакындагы язмалары белән танышырга мөмкин. Мәсәлән, «Милләтемә» исемле күләмле мәкаләдә авторның «Ерак Көнчыгыштагы төрк-татар мөһиҗирләрен Идел-Урал оешмасына берләштерү»не максат итеп Японияга юл алуы, андагы очрашулары хакында бәян ителә: «1928 елдан башлап, Харбин, Мукден, Токио кебек мәркәзрәк йирләрдәге мәгълүм затларга мәктүбләр төрле юллардан төрлечә язылса да, көтелгән нәтиҗәне бирмәде вә без милләттәшләремез берлә якыная алмадык. «Милли юл» журналы көннән-көн Ерак Шәрыктә күпләп укылса да, таралса да, аның идарәсе дә Японияңең һәрбер шәһәрендә үзенең учагыны кора алмады. Шуңарга күрә безнең алдымызда мөмкин кадәр тиз Ерак Шәрыкга вәкил күндерүнең лөзүме *(кирәклеге)* торды. Вә бу эшкә без билфигыль (*чынлыкта*) 1930 нчы елдан башладык, 1931 дә төрле юллар да булдырырга тырыштык. Ләкин, бер тарафтан, Яурупадагы мөһаҗәрәтебез арасындагы эшнең күплеге, икенче тарафтан матди көчемезнең азлыгы шуңарга киртә булып килде». Алга таба аркадашлары әдип-публицистның «бу зур эшкә аның баруын кирәк табалар» – Япониягә ул үзе чыгып китә: милләттәшләре аны югары дәрәҗәдә, бик җылы каршы алалар. Монда Исхакый

30 нчы елларда төрек-татар мәдәни тормышында актив катнашкан профессор, тюрколог Окубо сан (Окубо Кочи) белән дә очраша (очрашу мизгелләре сурәтләнгән фото шулай ук архивында урын алган). Гомумән, язучының сәяси темага кагылган һәр язмасында шул елларның сәясәт галәмендәге кискен вакыйгалар тасвир ителә, һәрберсенә мөнәсәбәте белдерелә бара, милли бердәмлекнең булмавына да кат-кат басым ясый, кыю публицист буларак чыгыш ясый. Фондта язучының Берлинда басылып чыккан, мөһаҗирәтенең башлангыч чорында иҗат ителгән китаплары хакында аерым әйтергә кирәк. Мәсәлән, «Өйгә таба», «Көз» повестьләре, «Җан Баевич» драмасы шундыйлардан. Билгеле булганча, шуннан соң күп еллар ул әдәби әсәрләр язмый.

Г. Исхакый фондындагы иң кыйммәтле өлешләрнең берсе – фотографияләр. Монда аның 1908 елда сөргендә вакытта алынган фоторәсеменнән алып, язучы үзе имзалаганча, «Сибириядә Пинега шәһәрендә»ге рәсеме, 1913 елда Архангелдәге сөрген елларында алдырылган фото, 1919 елда Токиода, 1920 елда С. Максуди һәм Ф. Туктар белән төшкән рәсеме, 1925 елда Әнкарада, 1928 елда Варшавада, 1934 елда Япониянең Кобе шәһәрендә, 1935 елда Мукденда Беренче корылтай ачу тантанасын актырткан рәсем, язучының соңгы туган көнен билгеләп үтү уңаеннан алдырылган һ.б. күп төрле кызыклы, эчтәлекле рәсемнәр саклана. Мәсәлән, 1928 ел – язучының юбилей елы: «Мин 1878 нче елда 23 нче февральдә туганмын. Шуның өчен бу ел илле яшем тулды. Шуны бераз бәйрәм ясарга уйланган идем, ләкин, ярдәмче булмаганга, эшли алмадым. Ләкин шул көн бөтенләй буш үтмәсен дип, мондагы дус-иптәшне чакырдым. Сәгадәт татарча пылау пешерде, татарча тавык тутырды. Кунакларым күбесе минем иттифакый дустларым иде. Үземнең [...] милли [...] бергә булган кеше берәү дә юк иде. Татар хәрәкәтендә [...] бергә булышкан Гомәр генә бар иде. Татар исемендән икенчесе мондагы акыллырак бер агай-эне Мөхәммәдҗан Ибраһим. Башкалар кавказлы Әхмәд Салихан. Вассан Гәрәй Ябагый *(Җабагый, «Ислам күзәтүе» журналы мөхәррире).* Аннан соң дүрт поляк. Мәҗлес үзенә күрә матур үтде. Озын иттереп утырдык. Сәгать җидедән башланган мәҗлес бердә генә бетте. Нотыклар, теләкләр сөйләделәр. Эз калдырырлык бер нәрсә булмаса да, үзенә күрә ярыйсы үтде. Үзең милли [...] беренче буыны, үзең мөселман, үзең өзек, үзең мөһаҗир, үзең шул пычрак берлә томаланган дөньяда пакь булып яшәргә теләгән ахмак язучыга бары инде шуннан артык тагы ни кирәк?!» дип искә ала ул көндәлегендә. Милләте өчен үзен аямыйча көрәшкән фидаинең җан авазында күпме әрнү, ачыну, сыкрау... Шушы көннең матур бер истәлеге – фоторәсем язучы фондында саклана. Ул аны кызы Сәгадәткә бүләк иткән. Фото артында язучының кульязмасы: «Илле яшь тулган көннең хатирәсе. Сөекле кызым Сәгадәткә сагынмалык» дип тә язылган. 1935 елда Мукденда Ерак көнчыгыш Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының корылтае булып уза. Язучы бирелә чыгыш ясый, гомумән, Ерак Көнчыгыш татарлары тормышында Г. Исхакыйның роле искиткеч зур, аның тырышлыгы белән «Милли байрак», «Яңа япон мөхбире» исемендә газета-журналлар да чыга башлый. Корылтайда Исхакыйның чыгыш ясаган вакыттагы фотосы да сакланып калган (4 тасв., сакл. бер. 19). Фондта җәмәгать эшлеклесе, әдип, журналист һәм мәгърифәтче әдип, нашир Фатыйх Кәриминең бертуган энесе дә булган Мөхәммәдгариф Гыйльман улы Кәримовның (1892–1934) каберен зиярәт итү белән бәйле 5 фото саклана. «Варшаваның шәһәре генә түгел, Варшаваның мөселман зияраты да безнең милли хәрәкәтебезнең эчендә йир тотты вә аның шул моңлы зияраты безнең милли тарихыбызга кайтышты. Гариф Кәрими бәкнең вафаты, аның җеназасы, аның күмелүе, аның милли эшебездәге роле хакында милли матбугатта бик күп нәрсә язылган, вә шул көтмәгән фаҗиганең никадәр авыр булуы төрле төстә сөйләнгән, вә мөһаҗәрәтебезнең һәрбер почмагында мәрхүмнең рухы өчен догалар кылынган иде,» дип яза Г. Исхакый «Гариф Кәрими бәкнең мәзары башында» дигән мәкаләсендә [5: 198]. 1936 елда Варшавада Тел конгрессы үткәрелә. Анда катнашкан вәкилләр мөһаҗирлектәге милли бәйсезлек хәрәкәтендә аерым бер урын тоткан Гариф Кәриминең каберенә дә баралар. Шул вакыйга белән төшерелгән фотоларга Г. Исхакыйның шәрехе дә язылган. Гомумән, фондтагы һәр фото кыйммәтле тарихи чыганак булып тора.

Шунысы да мөһим, Гаяз Исхакый мирасын туплау һәм өйрәнү юлындагы фәнни эзләнүләрнең дәвамы буларак, аның фондындагы материалларга нигезләнеп, «Рухи

мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең бишенче чыгарылышы дөнья күрде [4]. Биредә әдипнең тормышын, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, иҗатын яктырткан язмалар, бүгенге укучыга таныш булмаган архив материаллары укучылар игътибарына тәкъдим ителде. Шулай ук «Г. Исхакый фотографияләрдә» [3] дигән басма да нәшер ителде. Бүген дә бу эш дәвам итә: язучының хатирә дәфтәрләре гамәлдәге язуга күчерелеп, басмага әзерләнә.

«Хаклык югалмаган кеби, хаклык корбаны да онытылмыйдыр», – дип яза Г. Исхакый Фуад Туктаров турындагы мәкаләсендә. Бу сүзләрне без аның үзенә карата да әйтә алабыз. Татар милли азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы булган, бу юлда үзен аямыйча көрәшкән олуг язучыбызның мирасын халкы өйрәнергә, сакларга-якларга бурычлы.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гарипова Л.Ш., Ханнанова Г.М. Гаяз Исхакый Япония турында (1919 елгы көндәлек хатирәләре буенча) // Гасырлар авазы. – 2018. – № 3. – Б. 102–112.
2. Гаяз Исхакый фонды. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 135 ф.
3. Гаяз Исхаки в фотографиях / А.М. Ахунов. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 60 с.
4. Духовное наследие: поиски и открытия: Вып. 5 / под ред. И.Г. Гумерова; сост.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Н.Ш. Насибуллина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 280 с.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. – Казан: Татар. Кит. нәшр., 1998. – 11 т.: публицистика / томны төз., текст., иск. һәм аңлат. әзерл., кереш мәкалә авт. З. Мөхәммәтшин. – 2011. – 399 б.
6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар / томны төз., текст. һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина. – 2013. – 479 б.
7. Фәйзулина Ф.Г. Гаяз Исхакый хатларында яктыртылган кайбер әдәби проблемалар // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – С. 377–380.


УДК 297.17

# ЭВОЛЮЦИЯ ТАТАРСКОГО СЕКУЛЯРИЗМА – КЕЙС ГАЯЗА ИСХАКИ

***Д.Р. Гильмутдинов***
*Центр исламоведческих исследований АН РТ (Казань)*

В данной статье анализируются взгляды известного татарского общественного деятеля и писателя Г. Исхаки с точки зрения его отношения к исламу. Используя методологию Н. Ардича демонстрируется рост секулярного, технического отношения к феномену религии, который заключается в том, что, когда религия становится делом публичным, она связана с отходом от личного, искреннего отношения.
**Ключевые слова:** татарский ислам, Исхаки, исламская секуляризация, модернизм, модернизация.

In this paper we are analizing the worldview of famous Tatar social thinker and writer G. Ishaki with the main focus on his religious outlook. Using methodology of N. Ardiç it is demonstrated the growing of secular, technical attitude towards the religious *phenomena*, which tells that in the case of turning the religion from personal to public sphere, it starts to move far from its main feature of personal and sincere relation with God.
**Key words:** Tatar Islam, Ishaki, Islamic secularity, modernism, secularization.

Совсем недавно было издано 15 томов наследия великого татарского писателя и политика Гаяза Исхаки (1878–1954). Он учился в чистопольском и казанском «кадимистском» медресе (Касимовском, Апанаевском). Здесь уже начал выпускать нелегальную газету шакирдов. На него сильно повлияли турецкие романы и исторические произведения. Его становление как прагматичной личности, сформированного татарского политика произошло в татарской учительской школе (КТУШ).

Начнём анализ его взглядов по публицистическим материалам, опубликованным в многотомном собрании сочинений. Они начинают публиковаться с 6 тома. Он пишет: «Сохранять религию в целом говорится для обмана. Религию никто не трогает,

даже не хочет трогать. Если начнут трогать, то, не веря толстопузым муллам, надо будет себя сохранять» [5: 33]. Также он пишет через запятую «черносотенный, динче (“воцерквленный”)» [5: 37]. «Из-за того, что рабочие и крестьяне, а также образованные переходят на нашу сторону вы, боясь опустошения живота, поёте песню тех, кто кричит о написанном нами: «Противоречит религии! Противоречит религии!» [5: 53].

Сегодня народ уже не ведётся на лозунги о «спасении религии». Они были в охоте на западню ишанов, которые подпирали собой горы мира и ахирата [5: 213].

В 1915–1916 гг., во время войны тон смягчается. Он пишет: «Если “Джамгия хайрия” проведёт маулид, то это усилит религиозные чувства» (7 т., Публицистика [6: 13].

Он задумывается о том, чтобы на фронте для мусульман было достаточно мулл, и чтобы их хоронили отдельно [6: 15], о том, что дети мусульман всё время проводят на улице вместе с русскими детьми, не получая достойного воспитания (дин, диният, әдәп вә инсаф) [6: 22].

В это время он радикализируется. Не видя надежду среди центристов (кадетов и «иттифаковцев»), он пытается сблизиться с «кадимистами», пытается обелить их. Он пишет: «Наш народ это принял как «новый метод», что и стало дорогой нашей национальной школы. Чтобы многому научиться за короткое время, при преподавании для того чтобы самое важное поставить прежде менее, прежние слепые суфии, старые муэдзины и слабые солдаты, вернувшиеся с фронта, уже были не нужны» [6: 57]. Далее ещё более чётко: «Для того чтобы создать новые начинания надо сломать старые крепкие основы, холодными, уничтожающими бюрократию руками, если принять во внимание непрерывную работу вместе с кадимистским духовенством, будет известно какая нескончаемая сила спрятана во внутреннем мире серьёзного, немногословного и послушного татарского народа» [6: 57]. Политическую середину, полость, пустое место между левыми протестными массами и консерваторами заняли «иттифаковцы» [6: 90]. Однако сила (войско) стремится к центру, что является проблемой. Из-за этого кочевники-консерваторы на ишаках в поисках прокорма, будут дрейфовать по направлению к центру [6: 91]. У них общее образование – поэтому граница между ними стёрта. Но эта общность интересов – это “наркотик”, от которого они не могут отказаться. Это союз фанатичного муллы и ресторатора, который развивает бизнес среди русских, продавая опьяняющие напитки и свинину» [6: 91]. Он пишет: «российский ислам – мумия» [6: 63]. Он рад что татары не поддались иранским стихам, арабской религиозной литературе и славянской культуре [6: 57]. Мистицизм (суфизм) – это гриб, который вырос на утонувшей в мистицизме персидской культуре» [6: 69].

С 1917 г. он начинает критиковать союз ислама и власти в царскую эпоху. Главные его враги – чиновники, «русификаторы», мурзы и улемы [7: 38]. Он против того, что самыми политически активными остались имамы. Народ должен показать свою численную мощь. Имамы, как и попы [7: 63], с черным сердцем [7: 67]. Для них не интересны вопросы земли-воды, женщин и образования [7: 64].

После большевистского переворота Исхаки делает выводы. Марксизм зародился в татарской среде в Казани и здесь же стал «банкротом». Муллы (Ахметджан мулла) стали понимать, что «Джами ар-румуз» и «Капитал» отличаются по содержанию [8: 99].

Исхаки видит разницу между официальными духовными структурами в Волго-Уралье и других регионах. Глубоко не вдаваясь, он говорит, что у них «недозрелый» ислам, когда религия и нация не объединились и не приняло фанатичную форму, как у казанцев из-за трехсотлетнего противостояния русификации [8: 141].

В 20-е гг. Исхаки становится защитником ислама. Он пишет: «Там религией торговать, использовать Коран в корыстных личных целях, предавать миллет (нацию), прикрываясь Кораном запрещено [9: 101]. Также он хвалит журнал «Ислам», который издается официальными религиозными структурами [9: 181]. Рашида Ибрагимова критикует, а Ризу-казыя хвалит. В это время его лексика очень сильно исламизируется (более подробно [4]). Однако не может примириться с Абдулбари Батталом, Г. Идриси, А.-З. Валиди, Г.-Р. Ибрагимовым.

Наша статья опирается на книгу Нуруллы Ардича «Ислам и политика секуляризма: Халифат и ближневосточная модернизация в начале XX века» (Nurullah Ardiç,

Islam and the Politics of Secularism: The Caliphate and Middle Eastern Modernization in the Early 20th Century [1]). Здесь рассматривается использование исламской лексики, терминологии, сюжетов, выдержек из священных текстов в борьбе за конкретную, реальную политику. Данное использование исламских текстов для доказательства своей политической позиции характерно для всех акторов политической жизни Османской империи, даже крайних секуляристов, подобно Мустафы Кемалю Ататюрку. В центре османских проблем стоит вопрос халифата. Сам вопрос достаточно спорный, доводов из священных книг очень мало. Все хадисы, которые используются (причём одни и те же хадисы используются для доказательства противоположных утверждений) в большинстве своём слабые.

Гаяз Исхаки, как мы видим, тоже использует исламский лексикон, особенно в период эмиграции. Там язык ислама превращается для него в метод донесения сведений до мусульманского населения. Население уже секуляризовалось, а он апеллировал до сих пор к дореволюционному сознанию, пытаясь воссоздать некое подобие идеального прошлого. Однако, по-видимому, это только отдаляло общественного деятеля от его целевой аудитории.

У Исхаки главными оппонентами были «панисламисты», олицетворением которых для него был Абдурашид Ибрагимов. В газете «Ульфат», издаваемой Ибрагимовым вышла заметка о том, что выпускники КТУШ (главными из которых были Садри Максуди и Гаяз Исхаки (другие все были из лагеря социалистов) не понимают ислам [см. 3]. Ислам, действительно, для Г. Исхаки был методом донесения своих идей до читателя. Его привлекала новая интерпретация, использованная в политической борьбе с оппонентами. Он был за упрощение языка (против Р. Фахретдина), выступал за территориальную автономию вместе с остальными крымскими и казанскими татарами (против Гаспринского). Его раздражало всё, связанное с государством, когда люди начинают терять свою личную свободу.

Он не был «панисламизмом», но он не понял, почему в огромной мечети в Египте не было сказано славословий в адрес праведных халифов. Не написал ни одного религиозного трактата, но его миропонимание было очень религиозным. Он рассчитывал на человеческую веру и понимал, что мало что в этом мире зависит от действий человека.

Вопрос о форме политической власти не стоял для российских мусульман остро. Это особенно сильно ощутил Исхаки в эмиграции. Вновь возвратилась актуальность средневековых признаков общины – религии, традиций, языка. Как и у турков, важное место занимала территориальная автономия.

По нашему мнению, Г. Исхаки был одним из трёх лидеров татар, представляющих публичную сферу, то есть артикулированно сформулировавших свои требования по улучшению, изменению социального положения татар. Он был за равенство против угнетения. Это был единственный «светский» представитель. Однако, для публичной сферы мусульманского общества, необходимо так или иначе продемонстрировать свою аффиляцию с исламом [2].

Можно ли было совместить возобладавший национализм с религиозной риторикой? На наш взгляд они очень хорошо ложились друг на друга. Если в Стамбуле эта была отсылка к текстам, то в случае с Г. Исхаки, это была лишь мнимая, фиктивная отсылка к исламу, опора на его авторитет. Речь не шла даже об уровне статуса священного текста. Просто через религиозную риторику, привычную слуху татар, доказывалось их право на суверенитет.

Таким образом, исламская (даже исламистская) риторика была признаком любого татаро-башкирского общественного деятеля в Российской империи – от панисламистской до социалистической направленности. Формы использования религиозной лексики отличались. Если в России это были общие термины веры и исламской практики, то в исламских центрах это были ключевые вопросы исламской истории (отношение к праведным халифам или халифату в целом). Этими терминами особенно любили пользоваться апеллирующие к чувствам писатели и поэты.

Если человек сегодня использует исламскую лексику (иншалла, субханалла и т. д.), то это говорит о том, что это человек верующий. Однако в то время, время

«народной религиозности», «фитры» использование подобной лексики отражало противоположный тренд, когда человек пытался куда-либо направить религиозного читателя (или избирателя). Эта тенденция до сих пор сохраняется у некоторых представителей интеллектуальной и политической элиты, которые таким образом передают своим соратникам и поклонникам некие «послания». Например, использование слова «джадидизм» или «евроислам».

ЛИТЕРАТУРА


1. Nurullah Ardiç, Islam and the Politics of Secularism: The Caliphate and Middle Eastern Modernization in the Early 20th Century (New York: Routledge, 2012)

2. Salvatore A. The Public Sphere Liberal Modernity, Catholicism, Islam by Armando Salvatore (New York: Palgrave Macmillan, 2007. 293 p.

3. Гильмутдинов Д.Р. «Дух ислама»,«Исламскость» как ultima ratio конфессионального публичного пространства татар на рубеже XIX–XX веков // Исламоведение. – 2017. – № 4. – С. 43–52.

4. Гильмутдинов Д.Р. Исламизация политического дискурса досоветской татароязычной Казанской прессы как форма секуляризации [электрон. журн.] // Современный мусульманский мир. – 2017. – № 1.

5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 447 б.

6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 7 т.: Публицистика (1915–1916). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 365 б.

7. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 9 т.: Публицистика (1917–1926). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 414 б.

8. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 10 т.: Публицистика (1928–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 527 б.

9. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 11 т.: Публицистика (1934–1936). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 398 б.


УДК 82.091

# КОНСТРУИРОВАНИЕ НАЦИОНАЛЬНОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ ТАТАР ПОСРЕДСТВОМ ЛИТЕРАТУРЫ: ГАЯЗ ИСХАКИ

***Д.Ф. Загидуллина***
*Академия наук Республики Татарстан (Казань)*

В статье рассматривается художественное и публицистическое творчество Гаяза Исхаки с точки зрения направленности на формирование национальной идентичности татар. Исхаки во главу угла в нациестроительстве ставил художественную литературу. Однако с этой точки зрения его позиция переживала определенную трансформацию. Если в начальный период творчества писатель уделял особое внимание общественно-просветительской функции литературы, то на рубеже 1908–1910-х годов для него приобретает значимость этнокультурная составляющая. На материале анализа произведений Г. Исхаки определяются точки трансформации в его творчестве, произведения, которые стали знаковыми на эволюционном пути его художественных поисков.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, национальная идентичность, татарская литература, этнокультурность, просветительство, публицистика.

The article examines the artistic and journalistic creativity of Gayaz Iskhaki from the point of view of orientation to the formation of the national identity of the Tatars. Iskhaki put fiction at the forefront of nation-building. However, from this point of view, his position was undergoing a certain transformation. If in the initial period of creativity the writer paid special attention to the social and educational function of literature, then at the turn of the 1908–1910-ies the ethnocultural component becomes important. Based on the analysis of G. Iskhaki's works, the points of transformation in his work are determined, works that have become iconic in the evolutionary path of artistic search.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, national identity, Tatar literature, ethnoculturalism, enlightenment, journalism.

Формирование нации как социокультурной общности у каждого народа связано с глубокими изменениями в сознании его представителей. Прежде всего – речь идет об «осознании индивидом своей принадлежности к этой общности и осознание общ-

ностью своей специфики и самобытности» [9: 7]. Среди факторов, способствовавших таким переменам, особая роль принадлежит художественной литературе [8; и др.].

В последнее время эта научная проблема стала активно обсуждаться и разрабатываться [7; 12; и др.]. Многие исследователи считают конец XIX – начало XX в. периодом, существенно повлиявшим на формирование национальной идентичности народов и, в конечном счете, облика современного мира [10: 63].

ләренә күчереп бастырып чыгарды һәм киң катлам укучыга файдалану мөмкинлеге тудырды [13]. Журналда татар мөһаҗирләренең дә актив катнашуын, Идел-Урал буе белән бәйләнешле язмаларның шактый күп булуын редакция әһелләре дә таныган. Әйтик, Мәхмәд Әмин Рәсүлзадә 1924 елның 6 мартында Җәйхун Хаҗибәйлегә (1891–1962) язган бер хатында Аурупадагы һәм Истанбулдагы кайбер мөһаҗир азәрбайҗан зыялыларының, милли мәсьәләләрдә битараф калып, тавышсыз-тынсыз калуларыннан зарланганнан соң, сүзен «Йәни Кафкасйа» журналына китерә һәм «Без чыгара торган мәҗмуга илә азәриләрдән зыядә шималь төрекләре кызыксындылар, – дип, татарларның журналга күрсәткән игътибарын ачыклый. Кырым татарлары елга бер-ике язма язсалар, Идел-Уралдан килгән зыялылар: Зәки Вәлиди (Тоган), Садри Максуди (Арсал), Абдуллах Баттал (Таймас), Гаяз Исхакый (Иделле) журналның беренче елында милли көрәшкә үз язмалары белән мөһим өлеш керттеләр, ди [13; с. XXXI].

«Йәни Кафкасйа»ның беренче елында Гаяз Исхакыйның Берлиннан язган ике зур мәкаләсе 7 һәм 20 нче саннарында басылып чыга. Беренче мәкалә «Хариҗтәке төрекләрнең диләги» ([Төркиядән]читтәге төркиләрнең теләге) дип атала [2]. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң иске Госманлы империясендә ике мөһим тәшкилат мәйданга килде, ди Исхакый, боларның берсе ислам хәлифәлеге (хилафәт-и исламия), икенчесе Төркия халык җөмһүрияте, беренчесе ислам диненә, дини хиссияткә нигезләнсә, икенчесе төрек милләтенең икътисади мәнфәгатьләренә, хәрби горурлыгына, сәяси киләчәгенә таяна, ди. Бу ике тәшкилат читтәге, бигрәк тә Русиядә яшәгән төрки халыклар өчен нинди әһәмияткә ия, шул турыда фикер йөртә автор. 30 миллион мөселман халкы булган Русиядә элекке чорларда, вәгазьләрдә генә булса да, ислам хәлифәсенең исемен телгә алып, аның өчен дога кылу мөмкин түгел иде, чөнки бөтен дөнья мөселманнарының хәлифәсе булган кеше шул ук вакытта Госманлы Төркиясенең солтаны да булып тора, ә Төркия Русиянең иң якын күршесе һәм тарихы буенча дошманы булганга, догаларда хәлифә исемен телгә алу кискен тыелган иде, ди. Инде хәзер Төркиядә хилафәт дәүләттән аерылгач, дөнья мөселманнарының проблемалары кайда һәм кем тарафыннан чишеләчәк? дигән сорау куя, хәзер мәдрәсәләр ябылып, дин галимнәре Себергә сөрген ителгән вакытта Русия мөселманнары үз хакларын яклар өчен беркая да мөрәҗәгать итә алмыйлар, дип борчыла. Төзеләчәк яңа оешма һәм сайланып куелачак хәлифә-и мөслимин хәзрәтләре, бер Төркия мөселманнарының гына түгел, бар җиһандагы ислам әһелләренең хокукларын якларлык, Г. Исхакый сүзләре белән әйткәндә, «кылыч илә киселмәс, туп илә кырылмас, дини бөек бер мәгънәви куәт» булып мәйданга чыгарга тиеш, ди. Автор фикеренчә, төрек милли-азатлык хәрәкәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән Төркия халык җөмһүрияте, милли күзлектән караганда, зур мөмкинлекләр вәгъдә итә. Гарәп, грек, әрмән ватандашлар белән катнашмаган чиста төрек милләте үз сәясәтендә тулысынча хөр булачак һәм төреклек идеологиясен бары тик Анатолиядә генә түгел, читтә яшәгән 40–45 миллионлык төрки халыкларга якынлаштырачак һәм монда аңа комачаулар булмас, ди. Бу мәкаләсендә Г. Исхакый яңа гына төзелә башлаган Төркия җөмһүриятенең милли һәм дини сәясәтендә Төркиядән читтә яшәүче башка төрки милләтләргә нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеге турында уйлана, сораулар бирә, теләкләр белдерә. Нәкъ бер гасыр элек язылган әлеге язмада әйтелгән теләкләрнең хәзерге Төркия шартларында никадәр кабул ителүен дә инде күрергә була. Максатка ирешү өчен өч өлкәдә җитди эшчәнлек таләп ителүен әйтә автор: 1) милли тел, 2) милли тарих һәм әдәбият, 3) милли тәрбия. Әлеге эшчәнлекне җитди рәвештә оештырыр өчен Аурупа өлкәләреннән, алман, итальян, поляк халыкларының бердәмлек үрнәкләреннән файдаланырга кирәклеген искәртә. Госманлы телен/лисанын җитди рәвештә «төрекләштерү», гадиләштерү, халыкның күпчелеге җайлы аңлый алырлык хәлгә китерү; төрек әдәбиятын һәм тарихын башка төрки халыкларга кардәшчә якынлашу максатында яңадан карап чыгарга, дошманнар тарафыннан төркиләрне бер-берләреннән ераклаштыру өчен язылган тезисларны инде кабул итмәскә, аларга каршы көрәшергә. Өченче өлкәдә исә милли тәрбияне Көнбатышка иярү/тәкълид юнәлешендә түгел, үз милли өлгебезгә, төреклеккә нигезләп оештырырга кирәклеген әйтә. Яңа Төркия җөмһүриятенең мәктәбе, яңа төреклек тәрбиясе нигезендә Төркестан, Азәрбайҗан, Кавказ, Идел буе һәм Себердә яшәгән халыкларны

колачлап, бөтен төрки галәмгә юлбашчы булсын, дип тели. Без, Төркиядән читтә калган төркиләр, яңа җөмһүрияттән әлеге асыл мәсьәләнең күз уңында тотылуын телибез, бу теләгебезнең кабул булуын бөек бер иман белән, кардәшчә бер дога белән көтәбез, ди.

Исхакыйның «Яңа Кафкасйа»дагы икенче мәкаләсе «Идел-Урал илләре» дип атала [3]. Яшәгән тарихи-географик шартлар нәтиҗәсендә Идел-Урал буенда урнашкан төрки халыклар, Анадолу, Төркестан, Азәрбайҗаннан ерак калганга, рус золымына каршы берүзләре көрәшергә мәҗбүр булдылар, ди автор. Бу өч йөз илле ел буе барган авыр көрәштә бик күп корбан биргән, мадди-мәгънәви югалтуларга дучар калган Идел буе төркиләре ярым авыру/хаста хәлендә яшәделәр, үз милли хосусиятен югалтмас өчен, динен милли байрак итеп күтәрергә мәҗбүр булды. Бары тик XIX гасырның икенче яртысыннан гына Идел буе төркиләре арасында интибах/уяну дәвере башланып, гареб мәдәниятенә таба зур гына адымнар ясалды: мәктәп-мәдрәсләрдә ислах, милли әдәбият, милли театр, милли музыка барлыкка килде. 1917 ел Русия ихтиляле башланган чорда Идел буенда башлангыч мәктәбе булмаган бер генә мәхәллә дә калмаган иде. Кече яшьтәге балаларның мәктәптә укуын дәвам итә алмаучылары юк дәрәҗәсенә төшкән иде, ди. Шәһәрләрдә ислах ителгән мәдрәсәләр янында дарелмөгаллимат, шәхси милли гимназияләр ачылган, һәр зур шәһәрнең үз милли матбугаты булдырылган, китап нәшрияты эше алга киткән иде, ди. Мәсәлән, 1915 ел матбугат күргәзмәсендә Идел буенда басылып чыккан китапларның саны бер ел эчендә генә меңгә якын дип күрсәтелгән иде. Сәүдә эше җанланып китеп, 1915–1916 елларында Идел һәм Урал буе, Себер татарлары арасында миллионерларның саны ике йөздән артык, капиталы миллионнан азрак булган байларның саны исә меңнәрчә иде, ди. Большевик сәясәте башлангач, милли идарәләр, милли хәзинә бетерелде, милли гаскәр, милли матбугаттан берни калмады, хәтта «милли» исеме йөрткән һәрнәрсә харам яки гөнаһ дип игълан ителде, ди. Узган алты ел эчендә милләт күпме генә кулына корал алып, үз мәнфәгатен якларга тырышса да, җиңелеп, большевизм идарәсенең аяк астында калды, ди. 1921 елгы ачлык темасына кагылып, Г. Исхакый бу афәтнең төп гаеплесе итеп большевизмның Идел буе халыкларын үз сәясәтенә буйсындыру юлында кулланган радикаль ысулларын, шуның бер мисалы итеп, халык өстенә 300–350 % арттырып налог салуын күрсәтә.

«Йәни Кафкасйа» журналының икенче елгы саннарында исә төрле уңайдан татар исемнәре тагын да күбрәк очрый: Сәлах Атнагулов, Фуат Туктаров, Җамал Вәлиди, Фатих Әмирхан һ.б.лар. Редакциягә килгән хәбәрләр арасында да Гаяз Исхакый исемен еш күрергә була. Әйтик, эмигрантлар арасында 1924 елның 27 апрель көнен Азәрбайҗанның большевиклар тарафыннан алынуын матәм көне итеп билгеләп үтәләр. Бу уңайдан төрле илләрдә яшәгән мөһаҗирләр вакытлы матбугатта язмалар урнаштырып, төрле чыгышлар ясап, искә алалар. Берлинда уздырылган чараларда Г. Исхакыйның да нотык сөйләве хәбәр ителә [13, 2.yıl: 250]. «Берлинда «Туран» академисе җәмгыятендә» исемле язмада Г. Исхакыйның азәрбайҗан зыялылары белән берлектә Азәрбайҗан бәйсезлек көнен котлау чараларында катнашу хәбәрен укыйбыз [13, 2.yıl: 288] һ.б.лар

Моннан тыш, журналның беренче ел саннарында Гаяз Исхакый белән бәйле төрле язмаларны очратырга мөмкин. Мәсәлән, «Казанлы» псевдонимы белән язган Абдуллах Баттал ««Шималь төрекләре» түгел, «Казан төрекләре»»» исемле бәхәсле чыгышында Казан татарлары өчен кулланылган этноним яки төрле гыйбарәләр турында сүз кузгата. «Йәни Кафкасйа» редакциясе бу язмага үз фикерен белдереп, мөһаҗәрәттә яшәгән кайбер күренекле татарларның, шул исәптән, Йосыф Акчура, Закир Кадыйри, Гаяз Исхакыйларның үзләрен ничек дип атауларына мисаллар китерә [13, 1.yıl: 539].

Галимнәрнең дикъкатеннән читтә калган тагын бер язмасына юлыктык Г. Исхакыйның, ул 1947 елда төрек-ислам энциклопедиясе өчен язылган [1], соңрак башка исем белән 1990 елда төрек матбугатында яңадан дөнья күргән мәкалә [5]. Фәнни тел һәм стиль белән язылган бу энциклопедия маддәсендә ул Русиядә яшәгән төрки һәм башка рус булмаган халыкларның әлифбасын кирилл алфавитына күчерү һәм руслаштыру процессының үзенчәлекләрен, максатын, тарихи этапларын санап күрсәтә.

Төркиядә соңгы елларда Гаяз Исхакый белән бәйле фәнни-эзләнүләр турында сүз кузгатканда, иң беренче буларак, Истанбулдагы «Өтүкән» нәшриятының «Төркестан айдынланмасы китаплыгы» сериясендә чыккан ике китапка махсус тукталырга кирәк: «Социализмнан төркичелеккә Гаяз Исхакый (1878–1954)» [10] һәм «Идел-Урал һәм Төркестанда фикер хәрәкәтләре: дини ислахчылык һәм җәдитчелек» [11] исемле бу хезмәтләрнең икесенең дә авторы Мәрмәрә университеты профессоры Әхмәт Канлыдәрә. Беренче китап өч бүлектән гыйбарәт булып, безнең карашка, аеруча икенче бүлеге кызыклы, чөнки анда Исхакыйның госманлы-төрек фикер хәятенә ясаган йогынтысы һәм төркичелек идеологиясен аңлаешы турында сүз бара: барлык төрки халыкларның берләшүе мөмкинме, уртак төрки тел нинди булырга тиеш, Төркия төрки дөньяга лидер була алырмы, латин әлифбасына күчү эшендәге сораулар һ.б. темалар тикшерелә. Өченче бүлектә исә Исхакыйның Аурупа мөһаҗәрәте чорында язган язмалары, бигрәк тә 1928–1939 елларда «Милли юл» журналында чыккан мәкаләләре анализлана. Кушымта өлешендә Г. Исхакыйның 1920 елларда төрек матбугатында, аеруча «Төрек йорды», Җөмһурият», «Вакит» кебек органнарда басылган ике дистә мәкаләсенең тексты бирелү дә, татар галимнәре өчен зур табыш саналачак.

Әхмәт Канлыдәрәнең икенче китабында «Госманлы һәм Русия төркиләре арасындагы бәйләнешләр» бүлегендә Гаяз Исхакыйга аерым бер параграф аерылган. Анда әдипнең 1909 елда Истанбулга килеп, дүрт ай яшәгәннән соң туган яңа фикер һәм бәяләмәләре, төрекләрнең татарлар хакында гаять аз белүләре, мәдәни яктан татарлар өстен булганга, төрекләргә «татар моделен» үрнәк алырга кирәклеге фикерен алга сөрүе, гомумән алганда, бу чорда аның карашларының нигезендә «татарчылык» (татаризм) идеясе ятуы ассызыклана. Соңгырак бүлекләрдә татар зыялыларының, шул исәптән, Г. Исхакыйның да фикер эволюциясе тарихи шартлар белән бәйләнешле рәвештә анализалана.

Гаяз Исхакый белән бәйле сожгы елларда яңа табылган истәлекләргә кыскача тукталыйк. Әдипнең ингуш эмигрантлардан Вассан-Гирәй Җабагиев (1882–1961) белән берлектә Петербургта, Варшавада, Истанбулда еш кына очрашып көрешүе турында кайбер чыганакларда телгә алынса да, аларның дуслыгы-хезмәттәшлеге әлегә кадәр ныклап өйрәнелмәгән. Югыйсә, Вассан-Гирәй Г. Исхакыйның вафаты уңаеннан мәкалә язып, азмы-күпме истәлекләре белән бүлешкән, югалту хисләрен белдергән иде [14]. Менә күптән түгел генә ингуш халкының каһарманы саналучы Вассан-Гирәйнең кече кызы Тамара Җабаги-Җанкатның истәлекләр китабы [9] басылып чыкты, анда Гаяз Исхакый һәм кызы Сәгадәт Чагатай (1907–1989) җылы хисләр белән телгә алына һәм ике гаилә арасындагы дуслыкның детальләре китерелә.

Монда китерелгән чыганаклар галимнәребезнең игътибарын җәлеп итәр һәм Г. Исхакый мирасын барлау һәм бәяләү эшенә, аз да булса, өлеш кертер дигән өметтә калабыз. Барыбызга да яңа табышлар юлдаш булсын.

## ӘДӘБИЯТ


1. İshaki, Ayaz. Büyük Suikastlar // İslâm-Türk Ansiklopedisi Muhitülmaarif Mecmuası. – 1947. – № 2, cilt 71. – S. 14.

2. İshaki, Ayaz. Hariçteki Türklerin Dileği // Yeni Kafkasya. – I № 8. – 1923. – S. 6–9.

3. İshaki, Ayaz. İdil Ural İlleri // Yeni Kafkasya. – I № 20. – 1924. – S. 10–13.

4. İshaki, Ayaz. Fetvaya Dair // Liva el-İslam. – 1922. – № 2, cilt 11–12. – S. 46–49.

5. İshaki, Ayaz. Komünistler Türk Elifbasını Nasıl Ruslaştırdılar? // Dergi: Bisav Bülten. – 1990. – № 3. – S. 27.

6. Kazanlı Ayaz. Lisan Meselesi: Tasvir-i Efkar muharrilerinden Süleyman Nazif Bey'e // Sırat-ı Müstakim. – II № 46. – 1909. – S. 316–317.

7. Kazanlı Ayaz. Lisan Meselesine dair // Sırat-ı Müstakim. – II № 50. 1909. – S. 380 –381.

8. Kazanlı Ayaz. Rusya Müslümanları // Sırat-i Müstakim. – II № 51. – 1909. – S. 398 –399; III № 53. – S. 14–16; III № 55. – S. 47–48; III № 56. – S. 60–62.

9. Kamacıoğlu, Birsen Cankat. Tamara. Annemin Bana Anlattıkları. Hayatı, Yaşadıkları ve Yeni Nesillere Söylemek Istedikleri. 2022. İtunes Store. Дата публикации: 21.09.2022. – 137 с.

10. Kanlıdere, Ahmet. Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki (1878–1954). – İstanbul: Ötüken, 2019. – 318 s.

11. Kanlıdere, Ahmet. İdil-Ural ve Türkistan'da Fikir Hareketleri. Dini İslahçılık ve Ceditçilik. – İstanbul: Ötüken, 2021. – 480 s.

12. Meşrutiyet'ten Cumhuriyet'e Yakın Tarihimizin Belgeseli 1908–1925. Sıratımüstakım Mecmuası. – İstanbul: Bağcılar, 2012. – 1–2 ciltler.
13. Yeni Kafkasya. 1. yıl 1923–1924. Sayı 1–24; 2. yıl 1924–1925. Sayı 1–24; 3. yıl 1925–1926. Sayı 1–21; 1926–1927. Yıl:4 Sayı 1–24. Yıl: 5 Sayı 1–2. Neşre hazırlayanlar. Yavuz Akpınar, Selçuk Türkyılmaz, Yılmaz Özkaya. İstanbul, 2018.
14. Vassan Girey Cabagi. Hatırlıyorum // Milli Mücahit ve Milli Edip Ayaz İshaki. İdil Ural Mecmuasının 1. Sayı İlavesidir. – İstabul, 1955. – S. 39–41.

УДК 070

## «ИСТОРИЧЕСКАЯ ЦЕННОСТЬ МОИХ ТЕТРАДЕЙ – БЕССПОРНА» (дневники Гаяза Исхаки)

***Ф.Г. Файзуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена тетрадям татарского писателя и общественного деятеля Гаяза Исхаки, написанным с 26 апреля 1919 по 10 марта 1920 года. Эти тетради – и путевые заметки, и дневники автора, где он описывает события по дороге в Париж. Всего 16 тетрадей.
Дневники Гаяза Исхаки вместе с другими документами из личного архива писателя были переданы в Центр письменного наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ в 2018 году председателем фонда «Аяз – Тахир Туркестан Идель-Урал» Тюляй Дуран. Фонд был организован дочерью писателя Сагадат Чагатай в Анкаре в 1988 году и внес значительный вклад в сохранение творческого наследия Гаяза Исхаки в эмиграции.
Надеемся, что публикация этих дневников прольет свет на некоторые страницы жизни и деятельности Гаяза Исхаки.
**Ключевые слова:** Татарская литература, Гаяз Исхаки, дневники Г. Исхаки, текстология татарской литературы.

The article is devoted to the notebooks of the Tatar writer and public figure Gayaz Iskhaki, written from April 26, 1919 to March 10, 1920. These notebooks are both travel notes and the author's diaries, where he describes the events on the way to Paris. There are 16 notebooks in total.
The notebooks of Gayaz Iskhaki, along with other documents from the personal archive of the writer, were transferred to the Center for Written Heritage of the IYALI named after. G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2018 as the chairman of the Ayaz-Takhir Turkestan Idel-Ural Foundation Tulyai Duran. The foundation was organized by the daughter of the writer Sagadat Chagatai in Ankara in 1988 and made a significant contribution to the preservation of the creative heritage of Gayaz Iskhaki in exile.
We hope that the publication of these diaries will shed light on some pages of the life and work of Gayaz Iskhaki.
**Key words:** Tatar literature, Gayaz Iskhaki, diaries of G. Iskhaki, textual criticism of Tatar literature.

## «ДӘФТӘРЛӘРЕМНЕҢ КЫЙММӘТЕ – ТАРИХИ ҺӘМ МӘГЪНӘВИ ЯГЫНДА» (Г. Исхакыйның көндәлек дәфтәрләре)

***Ф.Г. Фәйзуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйның (1878–1954) мирасы озак еллар халыктан читләштерелде. Шулай да татар халкы үз язучысының әсәрләрен төрле юллар белән саклап кала алды, читтә калган мирасын туган иленә кайтару юлында зур көч куйды. Әдипнең иҗат җимешләрен туплаган унбиштомлык «Әсәрләр»е басылып чыгу моның ачык дәлиле булып тора.

Г. Исхакыйның архивын саклап калуда Төркиядәге аерым оешмаларның галим-голәмалары аеруча зур эшчәнлек күрсәтәләр. Г. Исхакыйның кызы профессор Сәгадәт Чагатай 12 ел тырышлык куйганнан соң, 1988 елның 13 октябрендә Әнкара шәһәрендә «Аяз – Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фондын төзүгә ирешә. Фондны этисе Гаяз (Исхакый) һәм ире профессор доктор Таһир (Чагатай) исеме белән атый. Сәгадәт

Чагатайның үлеменнән соң, 1989 елның 24 нче июленнән, фондның җитәкчесе итеп Түләй Дуран билгеләнә. Әлеге фонд инде күп еллар Төркестан – Идел-Уралда яшәгән төрки халыкларның тарихын, мәдәниятен, иҗтимагый тормышын фәнни яктан өйрәнү юнәлешендә күпкырлы эш алып бара. Ул аерым шәхесләр, фондлар, фән үзәкләре, уку йортлары, архивлар һәм китапханәләр кебек дәүләт оешмалары белән берлектә уртак проектлар булдырып, аларны тормышка ашыру белән шөгыльләнә. Фәнни хезмәткәрләр-галимнәр, китапханәчеләр, архив хезмәткәрләре әзерләү белән шөгыльләнүче оешмаларга булышу да фондның максатларыннан берсе булып тора. Аларга ярдәм итү һәм бу эшләрендә дәртләндерү йөзеннән, фонд иганәләр ясый, стипендияләр бүлеп бирә. Фондның үзенең китапханәсе бар. Әлеге китапханәдә Сәгадәт һәм Таһир Чагатайларның шәхси архивлары да саклана. Анда төрле фәнни чаралар, очрашулар оештырыла, төрле искә алу кичәләре үткәрелә [4].

Узган гасырның 90 нчы елларында Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә дә Г. Исхакыйның шәхси фонды оеша башлый. 2008 елда, язучының юбилее уңаеннан, Төркиядәге «Аяз – Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакый мирасының бер өлешен – документлар, хатлар, көндәлекләренең электрон күчермәләрен, ә 2018 елда төп нөсхәләрен институт мирасханәсенә тапшыра. Әлеге документлар арасында иң кыйммәтлеләре – Г. Исхакыйның үз кулы белән язып барган көндәлек дәфтәрләре. Бу көндәлекләрдә әдипнең 1919 елның 26 нчы апреленнән 1953 елның 10 нчы ноябренә кадәрге тормышы яктыртыла [1].

Бүгенге көнгә әлеге көндәлекләренең 2–17 нче (барлыгы 16) дәфтәрләре өйрәнелде. Аларда 1919 елның 26 апреленнан, ягъни Г. Исхакыйның Япония башкаласы Токио белән бәйле истәлекләреннән башлап, 1920 елның 10 мартында Франциянең Париж шәһәренә килеп җитүенә кадәр булган вакыйгалар урын алган. Кызганычка, 1 нче дәфтәр сакланмаган.

Көндәлекләрендәге: «Бүген 24 нче гыйнвар. Мин үткән елны шул көнне солых сәфәренә чыгып киткән идем. Инде ел тулды...» [3: 16 нчы дәфтәр] дигән 1920 елның 24 нче гыйнвар язмасына караганда, Г. Исхакый 1919 елның 24 гыйнварында солых сәфәренә кузгалган. 1920 елның 16 нчы гыйнварында Садри Максудига язган хатында да ул үзенең 24 нче гыйнварда Кызылъярдан (Петропавловскидан) чыгып китүе турында яза [2: 28].

Хатларыннан, көндәлек язмаларыннан күренгәнчә, Г. Исхакый Мәскәүдән 1918 елның 9 нчы августында качып чыгып китә. Бу турыда ул соңрак: «Мөселман комиссариатының доносы берлән, унынчы августта Мәскәүдә миңа революционный трибуналда хөкем булачак иде. Минем контр-революционлыгымның дәрәҗәсенә карап, миңа җәза бирәчәк иде. Ләкин төрмәләр бик тулы булганга, ашау-эчү төрмәдә тәмаман юк дәрәҗәдә булганга һәм дә төрмәгә алып барганда красный армеецларның үтерүләре гадәт булганга, мин качып киттем» – дип искә ала [3: 6 нчы дәфтәр]. Шуннан «атлы-җәяүле» [2: 29], Идел буйлап көймәдә кайтып, 18 нче августа Казанга килеп керә. Ләкин анда дусларыннан беркемне дә тапмагач, авылына да кайтып тормыйча, бер атнадан, Киңәш Мәҗлесенә дип, Самарага китә. Кеше җыелып бетмәгәнгә, Киңәш Мәҗлесе дә Самарада булмаганга, берәр атнадан Уфага килә. Уфада, Миллимәдәни мохтарият тарафдарлары берләшеп, 21 сентябрьдә үзенең мәҗлесен ачып җибәрә. Монда торуы да куркыныч була башлагач, Мәҗлес Себергә күченергә мәҗбүр була һәм 12 нче октябрь көнне, алар, «телячий вагоннар»га [2: 29; 3: 6 нчы дәфтәр] төялеп, Кызылъяр шәһәренә чыгып китәләр. Себердә милли хәрәкәтне ныгыту, берәр зур газета чыгаруны үзләренең төп максатлары итеп куялар. Ләкин биредә милли хезмәт моңарчы да бик өстән генә булганлыктан, Г. Исхакый зур эшләр эшли алмый. Шулай да мәкаләләре, лекцияләре белән Кызылъярны «шактый кайната» [3: 6 нчы дәфтәр]. Кызылъярда Учредительное Собрание әгъзалары – Г. Исхакый, Гомәр Терегулов, Фуад Туктаров, Габделбари Баттал – газета чыгаруга ирешәләр. 1918 елның 7 декабрендә «Маяк» газетасының беренче саны дөнья күрә. Шул араларда Солых һәйәте оештыру мәсьәләсе килеп туа. Кызылъярда чыккан каршы хәрәкәтләр белән ике ай көрәшеп, вакыт әрәм иткәннән соң, Г. Исхакый Ф. Туктаров һәм Г. Терегулов

белән солых сәфәренә китәргә тиеш дигән карарга киленә. Г. Исхакый 1919 елның 24 нче гыйнварында акча җыярга чыгып китә. Ул «шәһәрдән шәһәргә кереп, халыкны җыеп, лекция укып, моназарә кылышып *(бәхәсләшеп)*, кычкырышып-бакырышып, ай ярым юлда калып, ике йөз мең сум акча җыйнап» [3: 6 нчы дәфтәр], 10 нчы апрельдә Россия чиген үтеп, Харбинга барып җитә. Алдан сүз куешканча, ул Г. Терегулов белән Иркутскида очраша, соңрак килергә тиеш булган Ф. Туктаров әле Харбинда да булмый. Г. Исхакый белән Г. Терегулов, Ф. Туктаровны көтеп бераз калганнан соң, виза ала торырга дип, Японияга чыгып китәләр. Анда 3 айлап торып та рөхсәт ала алмагач, яңадан Харбинга кайтырга мәҗбүр булалар. 4 ай элек килергә тиеш булган Ф. Туктаров шулвакыт кына килеп чыга. Юлдашының Солых сәфәрен җимерүчеләрнең берсе булуында шикләнгән Г. Исхакый Ф. Туктаровны кабул да итми, аның белән арасын өзүне дә кирәк тапмый.

Г. Исхакый чыгып китеп, 6 ай үткәч кенә Милли Идарәдән беренче мәртәбә хат ала һәм шунда гына үзен борчыган кайбер сорауларга җавап таба. Солых сәфәренә чыгып китүенә ярты ел булды дигәндә, Г. Исхакый 23 июльдә яңадан Харбинга әйләнеп кайта. Һәм Парижга китүнең башка юлларын тапмаганлыктан, Владивостокка кайтып, аннан чех солдаты сыйфатында, чех кешесе исемендә, сәфәрен яңадан башлау нияте белән, 3 нче октябрьдә алар пароходка утыралар. Кытай, Корея, Сингапур, Цейлон утраулары, Көньяк-көнчыгыш Африка, Согуд Гарәбстаны, Италия, Чехия, Австрияләр аша, бик күп авырлыклар кичеп, 10 нчы мартта үзләренең максатлары булган Париж шәһәренә килеп җитәләр. Башыннан үткән мәшәкатьләрне «оҗмахка керү берлән бер дәрәҗәдәге авырлыкларга» тиңләп, Г. Исхакый Париж урамнарыннан нииндидер гайре табигыйлек өмет итә. Ләкин үзе булган шәһәрләр белән чагыштырып караганнан соң, күзгә ташланырлык аерымлыклар күрмәгәч, «Париж беренче көнне бик сөеп каршы алмады» [3: 17 нче дәфтәр] дип язып куя.

Г. Исхакыйга бик күп авырлыклар кичерергә туры килсә дә, ул үз алдына куйган максатыннан кире кайтуны уйламый. «Шул манигъларга *(каршылыкларга)* карап, кире китү тагы милләтнең шәэненә муафыйк түгел *(дәрәҗәсенә туры килмәгән)* хәрәкәт кебек» [3: 5 нче дәфтәр] тоела аңа. Ләкин Г. Исхакый бу китүеннән кабат туган иленә әйләнеп кайтмаячагын уена да кертми. Ул, барлык эшләрне дә җайга салып, үз максатына ирешкәннән соң, «җәй көне кайтып китәргә дә мөмкин булыр» [3: 15 нче дәфтәр] дигән планнар белән яши.

Көндәлекләрдән Гаяз Исхакый шәхесе төрле яклап ачыла. Укый башлау белән, аларның авторы язучы, әдип булуы күзгә ташлана. Ул гади генә табигать күренешләрен дә әдәби әсәр язгандагы кебек образлы итеп тасвирлый: «Дулаган диңгез өстендә биеп йөри торган дулкыннары берлән бу көн бик матур. Аның йотарга киләм дип килә торган тау кадәр дулкыннары егетчә җитез. Аның (дулкынның) өсте кигән ап-ак челтәр киеме, җефәк челтәр кебек нәфис, Себер кары кебек ак башы күккә күтәрелгәндә, аның ачылып китә торган зөмреддән *(зөбәрҗәттән)* яшел муен, Зөһрә йолдыз нурыннан да саф, бөтен диңгез ап-ак челтәргә киенгән» [3: 12 нче дәфтәр]. Г. Исхакый монда әдип кенә түгел, матурлыкны күрә белүче оста рәссам булып та күз алдына килеп баса.

Җәмәгать эшлеклесе, милләт язмышын кайгыртучы буларак, Г. Исхакый, кая гына барса да, андагы тормышны татар дөньясы белән чагыштыра. Сәнгать сөючән кешене чит ил мәдәнияте үзенә җәлеп итә. Матди авырлыкларга карамастан, Г. Исхакый һәр тукталган җирендә музейларга, уку йортларына, китапханәләргә бару җаен эзли. Ул бигрәк тә театрларга йөрергә ярата. Театрларның биналарыннан башлап, артистларның сөйләменә кадәр, аны һәр нәрсә кызыксындыра. Прагадагы Немец театрыннан кайткач ул: «Телен аңламасам да, музыкасы һәм дә нәфасәте *(гүзәллеге)* берлән бик зур күңел азыгы бирде. Күптән мондый уен, мондый оста театр күрмәгән идем» [3: 17 нче дәфтәр], – дип, тәэсирләнеп яза.

Сәфарәттән сәфарәткә йөреп, Г. Исхакый кемнәр белә генә очрашмый, кемнәр белән генә сөйләшми. Ләкин аралашкан кешеләренең кем булуына да карамастан, ул үз сүзенә ышанган кеше булганга, уйлаганын әйтергә курыкмый. Дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, дипломат, икътисадчы, Япониянең элеккеге премьер-министры

Окума Сигэнобу белән очрашу вакытында да аның ярдәм итә алмаячагын белгәч: «Рәхмәт, ләкин бездә сезгә, японнарга, зур ышаныч бар иде. Монда кечкенә хезмәтләрне генә түгел, зурларны да итәчәк, дип уйлыйлар иде. Сезнең хакта шундый хата фикердә булуымыз өчен гафуыңызны үтенәмез» [3: 4 нче дәфтәр], – дип, горур гына чыгып китә.

Г. Исхакый бик аралашучан, кызыксынучан кеше була. Юлда барганда да вакытын бушка уздырмас өчен, төрле кешеләр белән таныша, үзен кызыксындырган сорауларына җаваплар эзли, мәгълүмат туплый. Һәр минутын файдалы итеп үткәрергә тырышып, хәтта инглиз теле белгечләреннән дәресләр алуга да омтылыш ясый.

Көндәлекләр укучыны тулысы белән Г. Исхакый дөньясына алып кереп китәләр. Аларны укыганда, әдип артыннан ияреп, илдән илгә, шәһәрдән шәһәргә йөрисең, ул кайнаган вакыйгалар эчендә кайныйсың кебек хис ителә.

Әлеге көндәлекләрнең кыйммәте әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Гаяз Исхакый шәхесен төрле яклап тулы итеп ачуда гына түгел, ә Г. Исхакый үзе үк васыятьнамәсендә язып калдырганча: «…Дәфтәрләремнең кыйммәте – тарихи һәм мәгънәви ягында. Һәм бу дәфтәрләрнең эчтәлеге киләчәктә Идел-Урал төрки-татар мөселманнарының милли хәрәкәтләренең зур әһәмиятен яктыртачак...» [2: 410].

Әлеге көндәлекләрнең дөньяга чыгуы, Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлек чорындагы тормышы һәм эшчәнлегенең томанлы сәхифәләрен киңрәк ачып, киләчәктә көрәшче-әдип белән бәйле төрле вакыйга һәм фактларны ачыграк яктыртырга, иҗатын һәм эшчәнлеген дөрес бәяләргә ярдәм итәр дигән өметтә калабыз.


ӘДӘБИЯТ

1. Гарипова Л.Ш., Ханнанова Г.М. Гаяз Исхакый Япония турында (1919 елгы көндәлек хатирәләре буенча) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2018. – № 3. – С. 102–112.

2. Исхаков М.Г. Әсәрләр. 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар / [томны төз., текст һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. – 2013. – 479 б.

3. Исхакый Г. Көндәлек дәфтәрләре // ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 135 нче фонд.

4. Kurban Roza. Doğumunun 115.Yılında Türkolog, Dilbilimci Prof. Dr. Saadet Çağatay (1907–1989) // Türk Dünyası Tarih Kültür Dergisi. – Ankara. – 2022. – № 427. – S. 12–17.


УДК 070

## ОБЩЕСТВЕННАЯ ЖИЗНЬ, КУЛЬТУРА И ПЕРИОДИЧЕСКАЯ ПЕЧАТЬ ЗАРУБЕЖНЫХ СТРАН В ДНЕВНИКАХ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Г.М. Ханнанова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье освещаются события, общественная и культурная жизнь стран, по которым пролегал маршрут поездки татарского литератора и общественного деятеля Гаяза Исхаки из Японии в Европу в 1919–1920 гг. Г. Исхаки, будучи профессиональным издателем и журналистом, особое внимание уделял органам печати и журналистам, с которыми знакомился в ходе своей поездки. В своих дневниках он оставил многочисленные наблюдения о нравах и менталитете разных народов, что является важным источником о мировосприятии как самого Г. Исхаки, так и татарской интеллигенции первой четверти XX в. в целом.
**Ключевые слова:** татарская литература, Гаяз Исхаки, тюрко-татарская эмиграция, журналистика, дневники.

The article highlights the events, social and cultural life of the countries along which the route of the trip of the Tatar writer and public figure Gayaz Ishaki from Japan to Europe in 1919–1920 ran. G. Ishaki, being a professional publisher and journalist, paid special attention to the press and journalists whom he met during his trip. In his diaries, he left numerous observations about the customs and mentality of different peoples, which is an important source about the worldview of both G. Iskhaki himself and the Tatar intellectuals of the first quarter of the twentieth century as a whole.
**Key words:** Tatar literature, Gayaz Iskhaki, Turkic-Tatar emigration, journalism, diaries.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ЧИТ ИЛ ИҖТИМАГЫЙ-МӘДӘНИ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫ

***Г.М. Ханнанова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX йөз башы Россия халыклары өчен хәлиткеч дәверләрнең берсе. 1917 елгы революция һәм гражданнар сугышы бередә яшәгән халыкларның, шул исәптән татарлар тормышына кискен үзгәрешләр кертә, аның киләчәгенә йогынты ясый. 1917 елгы инкыйлаб вакыйгалары үзәгендә төрки-татар милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең берсе, әдип Гаяз Исхакый (1878–1954) да кайный. 1918 елны большевиклар алып килгән милли оешмаларны бетерү, матбугатларны ябу сәясәте башлангач, бу вакытта Мәскәүдә булган Г. Исхакый аннан китәргә мәҗбүр була. Күпмедер вакыт Казан, Уфа шәһәрләрендә булганнан соң, 1918 елның көзендә әдип Себер якларына юл тота. Кызылъяр шәһәрендә берара яшәп, фикердәшләре белән «Маяк» исемле газета чыгарырга керешә, әмма бу газетаның да барлыгы 30 саны гына дөнья күрергә өлгерә [7: 359].

1918 елның 11 ноябрендә Беренче бөтендөнья сугышы (1914–1918) тәмамланып, вакытлы килешү игълан ителгәннән соң, 1919 елның 28 июнендә Франциянең Версаль шәһәрендә солых килешүе кабул ителү көтелә. Бу вакыйгалардан читтә калмас өчен, Г. Исхакый, үзенең фикердәшләре белән, төрки-татарларның милли-мәдәни автономиясе башкаручы органы булган Милли Идарәдән вәкил буларак, солых мәҗлесендә катнашуны максат итеп куя һәм Омск, Томск, Иркутск шәһәрләре аркылы, юлда бераз акча юнәтеп, Харбинга юл тота. Монда да озак тормыйча, Гомәр Терегулов (1883–1938) һәм Нияз Максудилар белән Япониягә юнәлә. Максатлары – японнардан Европага чыгар өчен ярдәм сорау [2: 236].

Россиядән чыгып киткән көннән башлап Г. Исхакый юлда күргән-кичергәннәрен көн саен диярлек дәфтәргә көндәлек рәвешендә теркәп бара. Кызганычка каршы, әлеге көндәлекләрнең беренче дәфтәре югалган һәм кайдалыгы безгә мәгълүм түгел, язмалар икенче дәфтәр белән башланып китә. Көндәлекләр Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге хәятының 1919 елның апрель аеннан башланып, 1953 елның 10 нчы ноябренә кадәрге вакыйгаларын үз эченә ала. Бу көндәлекләр хәзер Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә, Г. Исхакый фондында (135 нче фонд) саклана.

Бүгенге көндә Институтның текстология бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әлеге көндәлекләрне басмага әзерләү эше алып барыла һәм аларның беренче китабы Г. Исхакыйның тууына 145 ел тулу уңае белән дөнья күрәчәк. Китап әдипнең Япония башкаласы Токиодагы истәлекләреннән башланып, Франциянең Париж шәһәренә килеп җитүенә кадәр (1919 елның 26 нчы апреленнән 1920 елның 10 мартына) булган вакыйгаларны үз эченә ала.

Япониядә Г. Исхакый 1919 елның апрель ае ахырларыннан алып, июнь ахырына хәтле була. Торулары башта Япониянең башкаласы Токиода булса, соңрак Йокоһама шәһәренә күчәләр. Г. Исхакыйның Япониягә килүенең төп максаты япон цивилизациясе белән танышу булмаса да, ул япон мәдәнияте һәм сәнгатенә, японнарның гореф-гадәтләренә, уку-укыту системасына игътибар итми калмый һәм үз күзәтүләрен һәм тәэсирләрен көндәлегенә теркәп бара. Әлбәттә, һәр шәхси документ кебек үк, Исхакый көндәлекләре дә субъектив чыганак. Шулай да традицион мөселман тәрбиясе алган, милли азатлык юлбашчыларының берсе булган, киң карашлы татар зыялысының күзәтүләре шактый кызыклы. Бередә әдип бик күп аралаша: дәүләт эшлеклелере белән күрешә, алар белән фикер алыша, мәсәлән, Япониянең элекке премьер-министры маркиз Окума Сигэнобу (1838–1922) белән аларның бик җылы очрашулары була. Төрле сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр белән очрашып фикер алыша. Төрек телен өйрәнүче тел галиме Кооджи (ул аны Кочи дип яза) Окубо белән таныша һәм бик күп аралаша. Японнарның музыка мәктәбе, башлангыч, урта, югары белем бирү мәктәбләрендә була, берничә музей һәм сәнгать әсәрләре күргәзмәсе белән таныша. Исхакый кайда гына булмасын, нәрсә генә күрмәсен, һәрнәрсәне төрки тарих, туган ватан һәм

аның милли гадәтләре белән чагыштырып бара. Шулай ук япон матбугаты вәкилләре, мөхәррирләре белән очраша, берничә япон газетасына интервью бирә, алар турында мәкалә япон матбугатында басылып та чыга. Мәсәлән, бу турыда ул: «Иң әүвәл, иртә торуга безгә япон газетасы кертәләр. Бу газетада безнең үземезнең дә рәсемнәремезне төшергән дә, тәрҗемәи хәлемезне язган. Япончадан тәрҗемә иттереп карыймыз. Гади газета мөхбирләре ялганлаган кадәр генә ялганлаган. Биргән мәгълүматы милли ноктаи назардан (*күзлектән*) караганда файдалы», – дип яза (*1919 ел, 29 апрель*) [4: 2 нче дәфтәр].

Шул ук көнне Г. Исхакыйларны Токиодагы «Хочи Шимбун» (Hochi Shimbun) газетасы идарәсенә кунакка чакыралар. Исхакый үзенең көндәлекләрендә әлеге газетаның язылышын төрле җирдә төрлечә бирә: «Һоши Шимбун» (هوشی شیمبون), «Һоҗи Шимбун» ( هوجی شیمبون) һәм «Хоҗи Шимбун» (حوجی شیمبون). Уйлавымызча, Г. Исхакый, тел белмәү сәбәпле, япон сүзләрен һәм атамаларны ничек ишетсә, шулай язган. Бу газета исеменең язылышында булган төрлелекне дә шул сәбәп белән аңлатырга мөмкиндер, мөгаен. Кызганычка каршы, бу газета турында мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Безгә бу «Хочи Шимбун» газетасының хуҗасы Окума Сигэнобу икәнен генә ачыкларга мөмкин булды [8] һәм бу мәгълүмат Исхакый көндәлекләрендәге язмаларда да чагыла. Әлеге очрашуда газета журналистлары килгән кунаклардан үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап ала, Исхакый Россия сәяси әхвәлен бераз яктыртып, Европага нинди максат белән юнәлүләрен аңлатып үтә һәм: «Сез безгә, иншалла, кардәшлек ярдәме итәрсез. Мин үзем әһле каләм *(каләм иясе. – Г.Х.)* булганга, сезгә, каләм иптәшләрем, безгә илтифатыңыз *(игътибарыгыз. – Г.Х.)* өчен, безнең эшемезгә ярдәмгә кул сузуыңыз өчен татар-төрек матбугаты исеменнән рәхмәт укыйм» дип ихтирамын белдерә (*1919 ел, 29 апрель*) [4: 2 нче дәфтәр]. Әңгәмә өлеше тәмам булганнан соң, газетаның матбагасын карарга юнәләләр. Газета конторасы, телеграфханәсе, хезмәтчеләренең эш шартлары белән танышалар, хәреф җыю һәм типографик басма җайланмалары карап үтәләр. Исхакый биредә сигез йөзләп кеше хезмәт итүен һәм: «Бу газета Токионың оста бер газеталарыннан саналса да, өч йөз мең нөсхә басыла, үзе, иртәнле-кичле булып, ике мең нәшер ителә икән» дип билгеләп үтә *(1919 ел, 29 апрель)* [4: 2 нче дәфтәр].

Исхакыйга 22 май көнне (1919 ел) «Хочи Шимбун» идарәсенә тагы бер кат барырга туры килә. Биредә ул газетаның «Хатын-кыз дөньясы» рубрикасын алып баручы корреспондентына татар хатын-кызлары хакында интервью бирә. Әдип татар хатын-кызларын хөр фикерле, эшчән, укымышлы, шул ук вакытта гаилә җанлы, балаларына яхшы әни, иренә ышанычлы хатын, гомумән, гаилә сакчысы, милләт сакчысы буларак тасвирлый. Соңгы вакытларда, укымышлы, үз хокукларын һәм мөмкинлекләрен яхшы белгән, тормышта үз урынын табып, үз хәятен тәэмин итә торган ханымнар хакында: «Хатыннарның иң зур эше хәзердә мөгаллимәлек. Аннан соң бик күп хатыннар читек-кәвеш каеп, калфак, кәләпүш эшләп, хәятларын тәэмин итәләр. Соңгы елда хатыннарымыздан докторлар, адвокатлар да бар, зур мәктәпләрдә мөгаллимәләр бик күбәйде, елдан ел күбәя бара» дип хәбәр итә (*1919 ел, 22 май*) [4: 4 нче дәфтәр].

Г. Исхакыйның матбагачалык, наширлык хезмәте белән бу рәвешле җентекле кызыксынуы очраклы түгел. Әдип үзе дә танылган нашир, журналист, мөхәррир. Гаяз Исхакыйның XX йөз башы татар вакытлы матбугаты барлыкка килү, аякка басу һәм аның үсешенә зур өлеш керткән, хезмәт күрсәткән милләт хадимнәре арасында лаеклы урыны бар.

Г. Исхакый 1904–1905 елларда ук Казанның алдынгы татар яшьләре «Хөррият» (элеккеге исеме «Шәкертлек) сәяси оешмасы эшчәнлегендә һәм «Хөррият» кульязма газетасын бастыруда актив катнаша. 1905 елның ахырында, фикердәшләре белән берлектә проектларын төзеп, «Таң» һәм «Хөррият» исемле басма газеталар булдырырга талпынып карый. 1906–1907 елларда татар эсерлары төркеменең матбугат органнары булган «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», «Тавыш» исемле газеталар нәшер итүгә ирешә. Г. Исхакый тырышлыгы белән 1913–1918 еллар аралыгында Петербург, соңрак Мәскәү шәһәрләрендә бер-бер артлы «Ил», «Сүз», «Безнең ил» нәшер ителә [1: 119]. Бу чорда әдипнең публицистик мәкаләләре, әдәби әсәрләре Казан, Оренбург,

Уральск һ.б. шәһәрләрдә урнашкан вакытлы матбугат басмаларында нәшер ителеп килә. Исхакый дөньяга чыгарга әзерләнгән, әле оешып кына килә торган басмаларга да (мәсәлән, «Әлгасрелҗәдит» журналына) теләктәшлек белдерә, киңәшләрен бирә [6: 395–397]. Әдип үзенең матбагачалык эшчәнлеген «Гәзитәчелек эшендә егерме биш ел» (1931) исемле мәкаләсендә шактый киң яктырта [2: 216–238].

Г. Исхакыйны аеруча Азия халыклары, төркиләр, мөселманнарга караган басмалар кызыксындыра. Һәм бер көндәлегендә ул: «Бүген бер журнал китереп бирделәр, исеме “Мәшрикы әгъзам” *(“Бөек Көнчыгыш”. – Г.Х.*), Асия милләтләрен берләштерер өчен тәэсис ителгән (*төзелгән. – Г.Х.*) икән. Нашире “Асия кай” җәмгыяте. Бу җәмгыятьтә японнар, чиннәр (*кытайлылар. – Г.Х.*), кореялеләр мәшгульләр. Төрекләр, татарлар иштирак итә (*катнаша. – Г.Х.*) икән, ләкин соңгы вакытта җәмгыять һичбер төрле җанлылык галәмәте күрсәтмәгән. Шул җәмгыятькә визит берлән барырга торамыз. Рәшид казый заманасында башланган эш булырга кирәк» дип яза (*1919 ел, 20 май*) [4: 4 нче дәфтәр].

Көндәлектә Исхакый җәмгыять исемен үз ишетүе буенча «Асия кай» («اسيا قاى») дип бирә. Чыннан да, 1909 елның 7 июнендә, Габдерәшит Ибраһимов (1857–1944) Япониядә вакытта «Азия Гикай» («Азиянең уяну җәмгыяте») дип аталган Азия халыклары союзы оеша [5: 180]. Шул ук елны Г. Ибраһимов Токиода мәчет салырга рөхсәт ала.

Кызганычка каршы, Г. Исхакый искә алган «Мәшрикы әгъзам» журналы хакында мәгълүмат әлегә табылмады. Бу мәсьәлә алга таба, аерым эзләнүләр таләп итә.

Г. Исхакый, Г. Терегулов Япониядә берничә ай торып та, Европага чыгар өчен виза юнәтә алмагач, Әмрулла Аги һәм Нияз Максудиларның чакыруы белән Харбинга юл алалар. Анда барып җиткәч, Г. Исхакый белән Г. Терегуловның юллары аерыла. Алдагы юлын Исхакый Фуад Туктаров (1880–1938) белән дәвам итә. Алар 1919 елның 3 нче октябрендә Владивостоктан «Karachi maru» исемле пароходка утырып, ялган документлар юнәтеп, чех солдатлары булып (Исхакый Һайнек Схазел исемле чех кешесе булып) Европага кузгалалар. Юллары Кытай, Корея, Сингапур, Цейлон утраулары, Африка, Гарәбстан ярлары, Кызыл диңгез аша Триест портына кадәр дәвам итә.

Сәфәр вакытында пароход бер генә тәүлеккә яки берничә сәгатькә кенә туктап торган урыннарда да, Исхакый гыйлемле, аралашучан һәм тынгысыз кеше буларак, китап кибетләре, китапханәләр, мәдрәсәләр, мәчетләр, газета-журнал идарәләре эзли, җирле халык белән аралашып калырга ашыга, Мөмкин булганда, җирле газеталар сатып алып, юл буе аларны укып, хәбәрләр белән танышып бара.

Юлчылар Триест шәһәрендә поездга утырып Чехославакиянең Прага шәһәренә юл алалар. Прагада Россиядән килгән бик күп сәяси эшлеклеләр булуы ачыклана. Комучның рәис ярдәмчесе И.М. Брушвит (1879–1946), Комуч хөкүмәтендә эчке эшләр министры П.Д. Климушкин (1886–1969), мәгариф министры Е.Е. Лазарев (1855–1937) һ.б. барысы да монда икән (*1919 ел, 5 декабрь).*

Исхакый Прагада да төрле кичәләргә, театрларга, музейларга йөри, бик күп яңа кешеләр белән таныша. Прагада нәшер ителгән газета-журналлар белән кызыксына. Биредә дагыстанлылар грузиннар белән берләшеп «Шәркый Европа» исемле журнал, руслар «Русское дело»[1] дигән газета чыгаралар икән (*1919 ел, 6, 8 декабрь*) [4: 14 нче дәфтәр].

Исхакый җирле чех матбугаты белән дә танышып барырга тырыша. Аның күзәтүләренә караганда, «Право лиду»[2] («Pravo lidu») исемле чех социал-демократлар газетасы инглизләрнең «Дейли кроникл»[3] гәзитәләреннән Һарольд Вильямсның[4]

---

[1] «Русское дело» – 1919–1920 елларда Прагада атнасына 3 тапкыр, рус телендә нәшер ителгән газета.

[2] «Право лиду» – 1893–1948 елларда нәшер ителгән чех социал-демократик газетасы.

[3] «Дейли кроникл» – 1872–1930 елларда нәшер ителгән британ газетасы.

[4] Биредә сүз Британия лингвисты, журналист, разведка хезмәткәре, танылган полиглот (58 телдә сөйләшкән) Гарольд Вильямс (1876-1928) турында бара. Вильямс Россиядә «The Times», «Manchester Guardian», «The Morning Post», «Daily Chronicle», «New York Times» газеталары корреспонденты булып эшли. Россиядә 14 ел яшәү дәверендә Вильямс бик күп сәяхәт кыла һәм фин, эстон, латыш, грузин һәм татар телләрен өйрәнә. 1914 елда Вильямс «Russia of the Russians» дигән китап нәшер итә.

мәкаләсен алып нәшер итә. Мәкалә Идел буе татарлары хакында. Вильямс татарларның славян милләте белән ислам галәмен берләштерә торган җеп ролен уйнаячагын билгеләп үтә һәм дә большевиклар татарларга таянып Төркестан, Иран аша Һиндстанга бәйсезлек кертмәкчеләр һәм уңышка ирешү ихтималлары да бар дигән фикердә тора. Мәкалә авторы: «Татарлар – төрек кавеменең иң алдагы кабиләсе, аларның зыялылары күп, аларда миллият фикере нык урынлашкан. Большевик аларның бөтен теләкләрен булдырырга вәгъдә биреп, үзләрен куллана» ди һәм инглиз җәмәгатьчелеген Һиндстан һәм гомумән Шәрык мәсьәләләре хакында сак булырга чакыра. Исхакый фикеренчә, бу мәкаләнең төп уе тугры, әмма: «Монда бик күп сүзләр әйтеп бетерелмәгән. Безнең большевикка каршы булган хәрәкәтемез бөтенләй томанда калдырылган» (*1919 ел, 23 декабрь*) [4: 15 нче дәфтәр]. Шуның өчен әлеге мәсьәләләргә ачыклык кертү максаты белән мәкалә язарга ниятли.

Исхакый җирле матбугат белән үзе генә танышып калмыйча, мөмкинлек туганда Харбиндагы милләттәшләренә мондагы газета-журналларны җибәрергә тырыша: «Русиягә китүче бер чех артыннан мин Харбин Гыйнаять муллага озын бер мәктүб язам... Аларга бер айлык «Голос России»[1] дигән газетаны җибәрәмез, мондагы әхваль берлән бераз танышсыннар», – дип яза 31 нче гыйнвар (1920 ел) көндәлегендә [4: 16 нчы дәфтәр].

Шулай итеп, Г. Исхакый Европага юл ялган авыр сәяхәте барышында да табигый күзәтүчәнлеген җуймый, чит ил халыкларының тормыш көнкүрешен игътибар белән күзәтә, татар яшәү рәвешенә, менталитетына туры килер-туры килмәс җәһәтләрен билгеләп бара, аларны журналистик осталык белән тасвирлый. Аның чит ил газеталарында татар халкына бәйле мәкаләләр турында мәгълүмат китерүе аеруча әһәмияткә ия. Шул җәһәттән әдипнең көндәлекләре мөһим һәм өйрәнүгә лаеклы чыганак булып торалар.

## ӘДӘБИЯТ

1. Галимҗанова Э.М. Гаяз Исхакыйның 1917 елгы иҗтимагый-сәяси эчәнлеге һәм «Ил» газетасы // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф.Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 118–121.

2. Исхаков М.Г. Әсәрләр. Унбиш томда. 10 т.: публицистика / [томны төз. һәм текст. әзерл. Г. Хөснетдинова; аңлат. һәм иск. әзерл. З. Рәмиев һ.б.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 527 б.

3. Исхаков М.Г. Әсәрләр. Унбиш томда. 10 т.: публицистика / [томны төз. һәм текст. әзерл. Г. Хөснетдинова; аңлат. һәм иск. әзерл. З. Рәмиев һ.б.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 527 б.

4. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 135 нче фонд.

5. Усманова Л. «Он выступал как просветитель, преследующий цели пробуждения мусульман Азии» (Р. Ибрагимов в Японии) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2010. – № 1. – С. 177–189.

6. Ханнанова Г.М. Камил Мотыйгый белән Гаяз Исхакыйның «Әлгасрелҗәдит» журналы хакында язышкан хатлары // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф.Ганиева. Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – Б. 395–397.

7. Хөснетдинова Г.А. Большевиклар хакимияте килгәч // Исхаков М.Г. Әсәрләр. Унбиш томда. 9 т.: публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 358–360.

8. https://www.encyclopedia.com/people/history/japanese-history-biographies/okuma-shigenobu (дата обращения – 19.03.2023)

[1] «Голос России» – 1919–1922 елларда Берлинда чыккан рус эмигрант газетасы.

# ЛИНГВИСТИЧЕСКИЕ АСПЕКТЫ ИЗУЧЕНИЯ ТВОРЧЕСТВА ГАЯЗА ИСХАКИ / ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ ЛИНГВИСТИК АСПЕКТЛАРЫ / LINGUISTIC ASPECTS OF STUDYING GAYAZ ISKHAKIE'S WORKS

УДК 811.512.145

## СРАВНЕНИЕ КАК СРЕДСТВО ХУДОЖЕСТВЕННОЙ ВЫРАЗИТЕЛЬНОСТИ
### (на основе письменных памятников XVII–XVIII веков и произведений Гаяза Исхаки)

***М.З. Валиева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена анализу сравнительных конструкций в произведениях Муслими «Таварихе Булгария», неизвестного автора «Дафтаре Чингизнаме» и Г. Исхаки «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Ике йөз елдан соң инкыйраз». Были рассмотрены наиболее частотные послелоги, участвующие в образовании сравнительных конструкций, а также их семантические группы и выявлена их роль в достижении художественной выразительности.
**Ключевые слова:** татарский язык, письменный источник, произведения Г. Исхаки, сравнения, художественная выразительность.

The article is devoted to the analysis of comparative constructions in the works of Muslimi «Tavarikhe Bulgaria», an unknown author «Daftare Chingizname» and G.Iskhaki «Ochrashu yaki Gölgyizar», «Ike yöz eldan son inkyyraz». The most frequent postpositions involved in the formation of comparative constructions, as well as their semantic groups, were considered, and their role in achieving artistic expressiveness was revealed.
**Key words:** Tatar language, written source, G. Iskhaki's works, comparisons, artistic expressiveness.

## ЧАГЫШТЫРУЛАРНЫҢ СТИЛИСТИК ЧАРА БУЛАРАК МАТУР ӘДӘБИЯТТА КУЛЛАНЫЛУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
### (XVII–XVIII гасыр язма истәлекләре һәм Г. Исхакый әсәрләре мисалында)

***М.З. Вәлиева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Сурәтләү чарасының бер төре буларак кулланыла торган чагыштырулар һәрбер чорда, һәрбер әдәбип яисә шагыйрьнең иҗатында иң төп поэтик бизәкләрнең берсе буларак урын ала. Әсәр героеның эчке һәм тышкы сыйфатларын ачамы, вакыйгаларны сурәтлиме яисә табигать күренешләрен тасвирлыймы һ.б. – һәр очракта да авторлар чагыштыруларга мөрәҗәгать итә. Татар телендә чагыштыруларның кулланылу үзенчәлекләре шактый кызыклы. Алар арасында аерым чорда гына актив булганнары да, гасырдан-гасырга күчеп килә торганнары да, шул исәптән теге яки бу язучы иҗатына гына хас булганнары да бар. Бу чагыштыруларга гына түгел, ә чагыштыру чараларына да хас. Чагыштыручы һәм чагыштырылучы предметларны бәйләүче чараларның байтагы гасырлар дәвамында әсәрдән әсәргә күчеп, кулланылышын дәвам итә. Бу берничә гасыр әсәрләренә күзәтү ясаганда аеруча ачык күренә. Шуларны күздә тотып, әлеге мәкаләдә XVII–XVIII гасыр язма истәлекләре һәм XX гасыр башында иҗат иткән

Г. Исхакый әсәрләрендә урын алган чагыштыруларны барлауны һәм аларга мөмкин булган кадәр анализ ясауны максат итәбез. Г. Исхакый чагыштыруларны яратып, киң кулланган, аның катлаулы төрләренә мөрәҗәгать иткән язучылардан санала. Шушы ике чор әдипләренең иҗатларында урын алган чагыштыруларны барлау барышында әлеге стиль чарасының ничек үсеш-үзгәреш кичерүе, кайсының активлашуы, кайсыдыр төрләренең кулланылыштан төшеп калуын күрергә мөмкин. Мисаллар туплаганда XVII–XVIII гасыр язма истәлекләреннән Мөслиминең «Тәварихе Болгария», билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә» һәм Г. Исхакыйның «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләренә мөрәҗәгать иттек.

Мәгълүм булганча, чагыштыру берничә кисәктән – чагыштыручы һәм чагыштырылучы предметлардан, шуларны бәйләүче чаралардан тора. Гадәттә, әлеге бәйләүче чаралар чагыштыручы предметлар белән янәшә киләләр. Чагыштыру өчен ниндидер сыйфаты, билгесе белән бер-берсенә охшаш предметлар алына. Сөйләм һәм стиль таләпләреннән чыгып, аларның арасы якынайтыла [4: 37]. Чагыштыру чаралары арасында бәйлекләр, кушымчалар һәм теркәгечләрләрнең киң кулланылуын искәртергә кирәк. Без тупланган фактик материалдан чыгып, бәйлекләр ярдәмендә ясалган чагыштыруларга тукталдык. Чагыштырулар ясауда катнаша торган бәйлекләр арасыннан XVII – XVIII гасыр язма истәлекләрендә һәм Г. Исхакый әсәрләрендә *кеби / кебек* бәйлекләре ярдәмендә ясалганнарының аеруча киң кулланылуы күренә. Алардан тыш, Г. Исхакый үзенең иҗатында *төсле* бәйлеге ярдәмендә ясалган чагыштыруларга да еш мөрәҗәгать итә. Тулаем алганда, фактик материалдан чыгып, чагыштыруларны түбәндәге төрләргә бүлеп бирергә мөмкин:

1. Җанлы предметларның, затларның үзара чагыштырылуы. Мөслиминең «Тәварихе Болгария», билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрләрендә үзенең башкалар шикелле үк гади, кол, яисә ятим булуын күрсәтергә теләгән геройларны сурәтләгәндә, җиһаннын иң күркәм затларның чагылдырырга теләгәндә авторлар әсәр тукымасына чагыштыруларны кертеп җибәрә:

*Мән <u>сәнең кеби кол</u> мән, илля Мәләкел-мәүт див бәне әйтерләр, ягъни барча мәхлукатлар җаныны вә һәм атаң-анаң җаныны бән алдым, див әйтде* [3: 16].

*Үзенә <u>үзе кебек үксезләрне</u> ийәләндерде һәм йәтимләрне ийәләндерде* [1: 82].

*Бу ике <u>кемсәнә кеби</u> җиһанда күркәм кемсәнәләрне күргәнем юк ирде, диде* [3: 40].

Г. Исхакый үзенең герое Гөлгыйзарны бала белән чагыштырып, аның матурлыгына гына түгел, ә сабый бала сыман самими булуына да басым ясый:

*Шул «әйем!» дигән сүзне әйткәндә, Гөлгыйзар үзе дә мәгъсум бер бала төсле булып китә, миңа тагы матур, тагы сөемле күренә иде* [2: 87].

2. Җансыз күренеш-предметларның үзара чагыштырылуы. XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә, нигездә, табигать күренешләре, кошлар, хайваннар чагыштырыла:

*Вә сачлары ат <u>койрыгы кебидер</u>* [3: 22].

*Өстендә төкләре вардыр, ак <u>мамык кеби</u>* [3: 23].

Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә Сөембикәнең гүзәллеген сурәтләгәндә шулай ук чагыштыруга мөрәҗәгать итә. Биредә, бер яктан, авторның соклануы, мәхәббәте чагылыш тапса, икенчедән, югалту-сагыш хисләре бирелә:

*Юкны сөйләмә, бетәме соң бу кара күзләр, бу <u>урак төсле</u> кашлар бетәме соң?* [2: 225]

Шулай ук тирән мәгънә салынмыйча, бары тик тышкы сыйфат-үзенчәлекләрен янәшә кую нигезендә барлыкка килгән чагыштырулар да урын ала:

*Минем иптәшләрем шарык-шарык көлә-көлә әллә кайдан урман арасыннан төн караңгысында күрмәенчә чәчәк дип кайсысы кычыткан, кайсысы әрем кеби үләннәр җыеп килделәр* [2: 91].

3. Җанлы һәм җансыз күренеш-предметларның үзара чагыштырылуы. Бу төр чагыштырулардан XVII – XVIII гасыр язма истәлекләрендә күбрәк хайваннар, кош-кортлар белән чагыштырып ясалган сурәтләү чаралары кулланылышта йөри:

*Бу диңгездә <u>таг кеби</u> аҗдаһалар вардыр* [3: 23].

Тоемлауны: *Акыртын гына торып утырды, бөтен тәненнән бик кызулап үтеп бара торган **карлыгач очуы кебек тәнен чемердәтеп бер суыклык**, бер чиркану узды, юрганын ябына төшеп, янындагы шырпысын кабызып идәнгә басты* («Ул икеләнә иде»). Биредә үз организмыңның билгеле бер халәтен сиземләү, физик тоемлау күздә тотыла.

Хәрәкәт үзенчәлекләрен: *Кайвакытларны чәчәктән чәчәккә очып йөри торган умарта кортының бызылдавы, ерактагы чикерткә туеның йырлавы әле югары менеп, әле түбән төшеп **лезгинга бии торган чиркес кызы кебек әйләнә-бәйләнә торган карлыгачның көйләве**, иксез-чиксез тургайларның моңнары, дәртләнүе астында изелеп киттек* («Көз»). Гаяз Исхакыйга хас тагын бер үзенчәлекле чагыштыру. Биредә кешенең хәрәкәт үзенчәлеге кошларныкы белән түгел, киресенчә, карлыгач очышы кешеләр ясаган хәрәкәт, ягъни, лезгинка биюе белән тәңгәлләштерелә.

Г. Исхакый фразеологизмнарга да еш мөрәҗәгать итә. Аның кошларга мөнәсәбәтле фразеологик әйтелмәләр кергән сурәтләүләре шактый уңышлы. Мисал өчен, чиксез шатлануны белдерергә теләгәндә, халкыбыз *кош тоткан кебек* дисә, Гаяз Исхакыйда: *Аның күзендә нур уйный, йөзе көлә, теле дөньядагы әйтмәгән матур сүзне калдырмый... Әйтерсең лә **бәхет кошы тоткан*** («Ул икеләнә иде»). «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә күрсәтелгәнчә, ***бәхет кошы*** «бәхет символы; бәхет китерүче» дигән мәгънәне белдерә [9: 471]. Бәхет китерүче кошны тоткан кешенең шатлыгын, сөенечен күз алдына китерү авыр түгел.

*Атлар, **кошлар кеби очып**, вокзалга барып иштеләр* («Ул икеләнә иде»). *Мин эчемнән: «Таба алырмын микән? Урынны онытмадым микән? Ил үлмәде микән?» – фикерләре белән мәшгуль булсам да, **канатлы кош кеби очам** гына* («Тормышмы бу?»).

Беренче фразеологизм «бик тиз хәрәкәтләнү»не белдерсә, икенче җөмләдә *тиз бару, йөгереп бару* мәгънәләренә «бик шатланып, үзен бәхетле сизеп» дигәннәре дә өстәлә. «Җаваплылыктан качу, катнашмыйча, качып калу» мәгънәсендәге ***башны комга яшерү, башны комга тыгу*** фразеологизмы Г. Исхакыйда нинди кош кебек икәнен дә тәгаенләп, ***тәвә кошы кебек башын комга тыгу*** дип тулысынча бирелә («Өйгә таба»). «Бик ерак» дигән мәгънәне белдерү өчен *кош очып җитмәс, кош очып җитмәслек* фразеологизмнары ярдәмгә килә: *Ирем, хәләл ирем, әллә кайларда...* ***кош очып җитмәс җирләрдә*** *богаулы аягы белән чалдыр-чолдыр таш кисә торгандыр* («Зөләйха»).

Үз иҗатында мәкаль-әйтемнәрне яратып файдаланган авторда кошларга кагылышлылары да очрап куя. Мисал өчен: ***Карга карганың күзен чукымый****, бар да бер кара йөрәк инде. Бар да бер дошман инде, Алла гына ярдәмчебез булсын!* («Зөләйха) һ.б.

Кош атамаларын Г. Исхакый хәл-вакыйгаларны, кешеләрне сурәтләү, тасвирлау өчен генә түгел, ә антропоним буларак та кулланган: *Камәр берлә дустлыклары бар һәм Камәр берлә «Сандугач» исеме берлә эндәшергә сүз куешканнар иде. < > Шуның өчен Сандугачына бераз үгет сөйләсә дә, Камәр үгет тыңлар дәрәҗәсеннән үткәнгә, һич файдасы булмаган иде. < > Бу хатын Камәрнең үги сеңелесе, Сандугачы Васфибану иде* («Кәләпүшче кыз»).

Яратып эндәшү, иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе буларак, автор ***канатым*** сүзен файдалана: *Авыл хатыннарына: «****Канатым****, абыстаем!» дип сүзләргә башлаган кебек, кош-кортларга, мал-туарга да сөюле атлар кушты* («Остазбикә»). Хәтта йорт кошларына да матур итеп, яратып эндәшә: *Тавыкларга* ***«тавыккаем»*** *дип, чебешләргә* ***«чебешкәем»*** *дип дәшүгә башка, өстләрен мамыклы җон гөнаһсыз иттереп каплаган чебешләрне кулына алып, авызына китереп сөя торган булды* («Остазбикә»).

Орнитонимнар Г. Исхакыйның һәр әсәрендә диярлек очрый. Төрле сүзләр, эпитетлар кулланып, язучы кошлар дөньясының нинди булуын күрсәтә. Мәсәлән:

кошларның күплеген (*йөз төрле кошлар, көтү-көтү тавыклар, мең төрле кошлар, иксез-чиксез тургайлар* һ.б.);

кошларның матурлыгын (*гаҗәп-гаҗәп кошлар, матур кошлар, күз явын алырлык кошлар* һ.б.).

Кошларны автор төрле фигыльләр ярдәмендә җанландыра. Г. Исхакыйның кошлары: *сайрый, кырлый, җырлый, көйли* (*карлыгачның көйләве, иксез-чиксез тургайларның моңнары* һ.б.). Күңел халәте ягыннан караганда, кошлар *шатлана, сөенә, куана, моңлана, кайгыра (кошлар шатлана-шатлана сайраганда; куана-куана җырлый*).

Кайбер кошларга аерым бер югары мәгънә бирү, аларны илаһилаштыру, изгеләштерү, хәбәр җиткерүче, киләчәкне әйтә алучы итеп күрү бөтендөнья әдәбиятына хас. Исхакыйда болар түбәндәге юлларда чагыла: *Агачларның яфраклары коелып, үләннәрнең чәчәкләре саргаеп, җәй фасылының бетүенә хәсрәтләр чигүдә, кошларның тавышлары үзгәреп, урыннарының бетүенә, гомерләренең тәмам булуына хәсрәтләнеп* ***«әлвидаг әлвидаг» дия сайрамакта*** («Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер»). Әлвидаг – аерылышу, саубуллашу җыры, биредә кошларның хушлашу сүзе, моңы.

Башка авторлардан аермалы буларак, Г. Исхакыйның кошлар чыгарган тавышларга зур игътибар бирүе күренә: *Минем шул шатлыклы көнемдә галәме әрзәк халкы музыкачылары музыкалар уйнарлар,* ***сандугачның, садасыннан: «Мәктәп юлы – җәннәт юлы», карлугачның тавышыннан: «Вар мәктәбә, ал мәртәбә», кенарикның тәрмененнән: «Ит тәгаллем, күр тәкәрем»,*** *– дигән сүзләр берлә минем шул мәктәпкә китүемне тәбрик итәрләр* («Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер»); *Аккош баласы төсле* ***«тый сөнтә, тый сөнтә»*** *дип сайрап торучы балалар булмаса, мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә ни ямь булыр?* («Ике йөз елдан соң инкыйраз»).

Г. Исхакый авыл кешеләренең күтәренке рухын, шатлыгын, хезмәт яратуын, кыр эшләрен куана-куана башкаруын якты, матур төсләр белән һәм оста итеп тасвирлый. Иң мөһиме, әлеге матурлык һәрвакыт кошларны сурәтләү белән үрелеп бара. Авторның кошлар дөньясының кеше өчен ни дәрәҗәдә мөһим, әһәмиятле булуын аңлатырга омтылуын күрсәтү максатыннан, әлеге юлларны кыскартмыйча, мөмкин кадәр тулы

итеп китерәбез: *Һәр кешенең кулында чаж-чож итә торган ураклар да үзләренең елтыраулары берлә бу тәңкәләрнең рәхмәтләренә, тәбрикләренә катнашалар иде.* ***Кыр тургайлары, кырдагы әллә ничә йөз төрле кошлар****, кортлар, күбәләкләр дә кешеләрнең фикерләрене бүлешәләр, анлар да шул игенне уңдырган кояшка* ***үзләренең шатлыкларын, сөенүләрен мең төрле авызларыннан мең төрле аваз чыгарып сайрыйлар****, шул кояшның олуглык җырын җырлыйлар иде. Бөтен кыр эшли иде. Бөтен кыр шул эшнең барлыгына шатлана, шул эшнең бәйрәмене итә иде. Кай тарафына карасаң да, шул сачтакмалар, ураклар ялтыравы берлә* ***кошлар сайравы*** *күрелә, кай тарафына баксаң да, бөтен кешеләрнең эшкә чумганлыклары, шул эшнең күплегеннән шатлана-шатлана эшләүләре, шул эшнең бәйрәменә тагы эш берлә бәйрәм итешкәннәре хис ителә иде* («Тормышмы бу?»); --- *урамнарда* ***көтү-көтү тавыкларның әтәч әфәнденең командасы астында сузып-сузып кырлаулары; әтәчнең авылның башка урамындагы әтәчләр берлә кычкырышып сөйләшүләре*** *– бу манзарәне тагы матурлата, аңар тагы күбрәк мәгънә бирә иде* («Тормышмы бу?»).

Мисаллардан күренгәнчә, күп очракларда кошлар сайравы күтәренке рухта сурәтләнә. Г. Исхакый өчен «кошлар сайравы – шатлык». Моңа күңелсез мизгелләрне тасвирлаган җөмләләрне укыганда тагын да ныграк инанабыз. Чөнки, табигатьнең, кешеләрнең күңелсез, борчулы, кайгылы чагында Исхакый әсәрләрендә хәтта кошлар да сайрамый: *Менә кап-караңгы... Гөлгыйзар да юк, бакча да, рәхәт тә юк,* ***сандугачлар*** *да сайрамый, бакалар да кычкырмый* («Очрашу яки Гөлгыйзар»). Сайраган очракта да, аларның кәефе, халәте кешеләрнеке белән аваздаш: *Матур* ***кошларның*** *сайрауларыннан моңлы, кайгылы тавышлар ишетелүдә иде* («Бай углы»).

Гаяз Исхакый әсәрләре буенча фикер йөрткәндә, татар халкы тормышында кошларның зур роль уйнавы, беренче чиратта, һәр кешенең хуҗалыгында йорт кошларының мөһим урын тотуына бәйле. Авыл кешесенең тормышын, яшәешен кошлардан башка күз алдына да китереп булмый. Игътибар итсәк, Исхакый әсәрләрендә сүз һәрвакыт кошлар тирәсендә бара. Шуның иң ачык мисалы булган юллар: *Мәдрәсәдәге кеби, милләт кайгысы урынына мужиклар үзләренең сары алашаларының корчаңгы булуыны, чуар сыерның бозаулавыны, караколак сарыкның йоны кыркылуыны,* ***каз бәпкәсенең югалуыны, үрдәкнең икенче мәртәбә сала башлавыны, тавыкларның йомырка салудан туктауларыны*** *сөйлиләр* («Тормышмы бу?»).

Нинди дә булса хәл, вакыйга турында сөйләгәндә, кайсы вакыт булуын төгәлрәк аңлату, ел фасылларын, айларны билгеләү өчен, Г. Исхакый кошлар дөньясына мөрәҗәгать итә: *Киленнәр, эшләр беткәч,* ***тавыклар йомырка салудан туктагач****, бәрәңгеләр алынып беткәч,* ***казлар, үрдәкләр су буеннан җыелып алынгач,*** *--- ире берлә әниләренә кунакка барырга, анда өч-дүрт көн кунак булып һәр иртәне мунча кереп, карендәш-кабилә, дуст-ишкә ашка барып йөрүне уйлыйлар иде* («Тормышмы бу?»); --- *Сәгыйдә, кышкы озын төннәрдә ялгыз – кияү хәзрәтсез булуы уеннан коты очканга, бөтен юллар белән китәргә тырышты һәм дә* ***көзге казлар суюдан элек*** *килен булып төште дә* («Остазбикә»); *Иртәнге* ***сандугачның сайравы бетмәенчә*** *тау башыннан иңмәделәр. < >* ***Кыр чыпчыгының беренче сайрауларыны ишетеп, тургайның иртәнге азанын тыңлап бетереп*** *кенә ятакларына киттеләр* («Ул әле өйләнмәгән иде»).

Исхакый үз әсәрләрендә кошларның кеше тормышындагы ролен, әһәмиятен тулысынча яктырта алган. Биредә кошларның сайраулары белән сөендерүләренә, хәбәр китерүләренә, матурлыклары белән сокландыруларына, кешеләрнең һәрдаим күңелләрен күтәрүләренә генә түгел, ә алар өчен гаять мөһим, туклыклы, файдалы ризык булуларына да зур урын бирелә: *Ит аз калып китсә, хатыннар мәҗлесенә бирәр* ***тутырган тавык*** *та бирермез* («Кияү»); *– Бу ни? Әсма ханым: – Бу –* ***тавык тулмасы****, безнең илдә аны* ***«тавык тутырмасы»*** *яки* ***«тутырган тавык»*** *диләр* («Татар кызы»); *Килен иртәдән бирле чәй эчмәсә дә, ул бик тиз мичне җыеп, берсе дөгедән, берсе* ***тавыктан****, берсе кич өчен ике-өч бәлеш ясап тыкты* («Кияү»); *Ул Мансур тугач ук угылыма бик матур кыз алып бирермез, кодалый килеп алырлар, ак оннан, эченә алма кагы кыстырып, зур сумсалар ясармын, шурпалы катлама пешерермен,* ***пар каз*** *куярмын, дошманнарның эчен яндырып, кыңгыраулы тройка атта «кодагый» булып*

*китәрмен, дип уйлый иде* («Мансур»); *Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, аның артыннан* ***тавык бәлеше****, аның артыннан дөге бәлеше, аның артыннан тутырма белән ит, аннан соң чия суы* («Кияү»); ***Менә тутырган тавык****: ул, туп эченә тутырып, дошман гаскәренә атып, аның крепостене ватарга ясаган кеби катырылган; киселгәч, йомыркалар беләү кеби ялтырап торалар; тозлылыгыннан авызга кабарлык түгел* («Сөннәтче бабай») һ.б.

Мәҗлесләрдә пешерелгән ризыкларны (*тутырган тавык, тавык бәлеше, пар каз һ. б.*), өйләнгән яки кияүгә чыккан балаларының үз хуҗалыклары өчен *каз, үрдәк, тавык* бирүләрне (*Тагы,* ***казы-үрдәге*** *хатын-кыз эше булганга, Мәрфуга абыстай, ирләргә киңәш итеп тормаенча,* ***икешәр оя каз, үрдәк, унбер-унике баш тавык*** *бирергә дип, суйдырмый калдырды*; «Кияү») сурәтләүләр татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, милли ризыклары турында бай мәгълүмат чыганагы ролен үти.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Гаяз Исхакый вакыйгаларны эпитетлар, чагыштырулар аша, буяуларны мулдан, ачык, җете итеп кулланып сурәтли. Кешеләрнең үз-үзен тотышын, холык-фигыльләрен ачып бирү өчен кошларга хас үзенчәлекләргә игътибар юнәлтеп, җиткерергә теләгән фикерне кошларга кагылышлы фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр аша көчәйтеп, ассызыклап бирү һ.б. авторның орнитонимнарны яратып һәм оста файдалануы турында сөйли, Г. Исхакыйның гаять дәрәҗәдә күзәтүчәнлеге, юморга осталыгы, тормыш-көнкүрешне бик нечкәләп белүен күрсәтә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Губайдуллина Г.Ф. Языковые и стилистические особенности ранней художественной прозы Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2008. – 26 с.

2. Исмагилова Г.К. Лексика романов Гаяза Исхаки «Нищенка», «Мулла бабай»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2001. – 23 с.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 399 б.

4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 464 б.

5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 448 б.

6. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авторлары: И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 671 б.

7. Сафина Э.И. Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 184 б.

8. Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. – Казань, 2006. – 157 с.

9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге I том: А–В / Р.Р. Абдуллина, А.М. Сәгыйтова, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, О.Н. Галимова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Ф. Фәтхетдинова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.М. Газизова. – Казань, ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

УДК 81'366.58

# ОСОБЕННОСТИ ФУНКЦИОНИРОВАНИЯ РЕДУПЛИКАТИВНЫХ И ПАРНЫХ ГЛАГОЛОВ В ПРОИЗВЕДЕНИИ Г. ИСХАКИ «КӨЗ»

***Р.Р. Салахова***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

В данной статье рассматривается проблема редупликации и ее использование для передачи различных оттенков характера совершения действия в современном татарском языке. Редупликация глагольных форм необходимо отличать от парных глаголов. Новизна работы заключается в том, что впервые на материале повести Г. Исхаки производится разграничение редупликационных глагольных форм от составных глагольных лексем. В результате выделены и охарактеризованы стуктурно-семантические особенности представленных глаголов и определены критерии их разграничения.
**Ключевые слова**: татарский язык, редупликация, глагольная форма, парные глаголы.

This article discusses the problem of reduplication and its use to convey various shades of the nature of the action in the modern Tatar language. Reduplication of verb forms must be distinguished from paired verbs. The novelty of the work lies in the fact that for the first time on

the material of G. Iskhaki's story, reduplication verbal forms are distinguished from compound verbal lexemes. As a result, the structural and semantic features of the presented verbs are identified and characterized, and the criteria for their differentiation are determined.
**Key words:** Tatar language, reduplication, verb form, compound verbs.

## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «КӨЗ» ӘСӘРЕНДӘ КАБАТЛАУЛЫ ҺӘМ ПАРЛЫ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Р.Р. Сәлахова***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Кайсы гына телне алсак та, анда хәрәкәтне, эш-хәлне, процессны белдерә торган сүзләр аерым һәм зур урынны алып торалар. Дөрестән дә, фигыль сүз төркеме үзенең кулланылыш ешлыгы белән дә, грамматик категорияләргә бай булуы белән дә аерылып тора. Тел белемендә, шул исәптән татар телендә дә, фигыльне, аның грамматик һәм лексик үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләр шактый күп, шуңа да карамастан, әлеге хезмәтләрдә төрле карашлар күзәтелә, аналитик формаларның үзенчәлекләре дә төрлечә билгеләнә. Бу күренеш, аңлашылганча, фигыль сүз төркеменә караган сүзләрнең семантик һәм грамматик спектры киң булуы белән аңлатыла. Биредә әлеге мәгънәләрне барлыкка китерә торган чараларның функциональ мөмкинлекләрен ачыклау мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Телебез полифункциональ чараларга бай, шуларның берсе – сүзләр кабатланышы. Тел белемендә әлеге чара редупликация термины белән билгеләнә. Редупликация (лат. reduplicatio 'повторение, удвоение') – тамырның өлешчә яки тулаем кабатланып килү юлы белән башкарыла торган сүз ясагыч яки грамматик чара [3: 231].

Соңгы елларда редупликация проблемасына кызыксыну арта бара, моңа дәлил итеп Н.С. Сарьянова (2017), М.Г. Сәфәрова (2018), О.В. Козаченко, О.В. Ковальчук (2020) хезмәтләрен китерергә мөмкин. Әлеге теманы чагыштырма аспектта өйрәнгән Е.Ф. Арсентьева, Р.Б. Вәлиуллина (2013), О.В. Столбова (2018), А.М. Зарипова (2019) кебек галимнәрнең тикшеренүләре дә зур игътибарга лаек.

Татар телендә редупликация мәсьәләсе стилистик чара буларак В. Хаков, Х. Курбатов, Г. Нуриев, Ф. Галләмов хезмәтләрендә яктыртылган, әмма бүгенге көндә редупликация проблемасы грамматик аспектта өйрәнүне таләп итә, чөнки редупликация, грамматик (аналитик) форма буларак, фигыльләрдә дәрәҗә мәгънәсен белдерсә, сүз ясагыч чара буларак, парлы сүзләр ясауда катнаша. Телебездә әлеге проблемага үз вакытында Ф.А. Ганиев игътибар итә, галим аналитик фигыльләрнең татар морфологиясе һәм сүзьясалышында мөһим һәм актуаль мәсьәләләрдән булуын, аны фәнни нигездә өйрәнү зарурлыгын ассызыклый [1: 178]. Әмма бу проблема бүгенгәчә хәл ителмәгән. Биредә аналитик фигыльләр мәсьәләсе генә түгел, гомумән, татар грамматикасында саллы вазифа башкара торган редупликация, редупликат һәм редупликантлар проблемасы калкып чыга. Бу күренеш, үз чиратында, телдә грамматик һәм ясагыч чараларны аера белмәү, шуңа бәйле рәвештә, аналитик формаларны, безнең очракта аналитик формалы фигыльләрне, кушма(парлы) фигыльләр белән бутауга китерә. Теманың актуальлеген искә алып, Гаяз Исхакыйның «Көз» повесте җирлегендә редупликация юлы белән белдерелгән фигыль дәрәҗәләре һәм аналитик (парлы) фигыльләрне тикшерергә алындык.

Гаяз Исхакый барлык төрки дөньяда дан алган татар әдибе. Ул сәнгатьле проза әсәрләре белән бергә, озак еллар буена күпсанлы драма әсәрләре дә иҗат итә. Гаяз Исхакыйның иҗаты әдәби яктан өйрәнелсә дә, тел сөйләме ягыннан җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелгән дип әйтә алмыйбыз. Аның әсәрләрендә аналитик сүзләрнең (аеруча парлы сүзләр) мул кулланылышы һәм фигыльләрнең, дәрәҗә-ысул мәгънәләренең күп очракта редупликация ярдәмендә тасвирлануы күзгә ташлана.

Гаяз Исхакыйның «Көз» әсәрендә генә дә фигыльләр редупликациясенә 36 мисал табылды, алар нигездә түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр:

1. *-а/-ә, -ый/-и* формасындагы хәл фигыль кабатланышы ярдәмендә процессның дәвамлылыгы белдерелә [2: 216]. Мәсәлән, *Ике хатын да кәрзиннәреннән ашамлыклар*

*чыгарып, берсен-берсе* ***сыйлаша-сыйлаша, сөйләшә-сөйләшә*** *чәй эчәргә тотындылар* [4: 245]; *Кучер минем капризларымн* ***тыңлый-тыңлый*** *йөдәп беткәнгә, мыгырдарга тотынды* [4: 259].

2. *-ып/-еп, -п* формасындагы хәл фигыль кабатланышы дәвамлылык мәгънәсе белән процессның кабатланып үтәлеше мәгънәсе үзара тыгыз бәйләнгән. *Әти котырган бүре кебек әллә ниләр сөйләп, кычкырып, бакырып, идән буе* ***йөреп-йөреп*** *шелтәләргә, тиргәргә тотынды* [4: 257]. *Бакчаның теге почмагынды чырлый торган теге марҗа* ***кычкырып-кычкырып*** *әллә нинди әмерләр бирә иде* [4: 280]; *Картлар эчештергәләделәр, минем күршем дә мине* ***сыйлап-сыйлап*** *җибәргәләде* [4: 280].

3. *раслау һәм инкяр* формасындагы сыйфат фигыльләр кабатланышы (асиндентик кабатлану) ярдәмендә процессның, тулысынча түгел, өлешчә үтәлүе белдерелә: *Кереп* ***утырыр-утырмас****, күзем берлә таныш егетне эзләргә тотындым* [4: 251]; *Күрешеп* ***бетерер-бетермәс*** *уен башланды* [4: 257]; *Мин өн белән төн арасында* ***саташыр-саташмас*** *бикләнеп калдым* [4: 291]; *Аның күзләренә яшь тыгылды, ул* ***тавышланыр-тавышланмас*** *елый башлады* [4: 293].

4. затланышлы фигыльләр кабатланышы дәвамлы яки тәкрарлы эш-хәрәкәтне белдерә:

а) *-ган\-гән, -кан/кән* билгесез үткән заман формасы: *Әни юри, миңа күп сөйләргә ирек бирмәс өчен кебек, сөйли, сөаль артыннан сөаль бирә бара, егетем дә җавапларны* ***агызганнан-агыза*** *бара иде* [4: 254]; *Гөлсем бер яктан кичә Нәфисәгә ул кадәр ачылуыннан үкенеп, икенчедән, көтелмәгәндә килеп чыккан очрашудан аптырап калып, язмышның шул авыр йөге астында башын* ***игәннән-игән*** *иде* [4: 301]; *Гөлсем, әллә нидән качкан кебек, аның кочагына* ***кергәннән-керде*** [4: 305].

ә) *-ды/-де, -ты/-те* билгеле үткән заман формасы: *Әни башын саллый-саллый(?)* ***тыңлады-тыңлады*** *да: «Менә әтиең шуннан куркып театрга йөрүне яратмый, кем очраса шуның берлә буй кызга танышып йөрергә ярыймыни?» – диде* [4: 252]; *Яттым,* ***егъладым-егъладым*** *да яттым* [4: 290].

Югарыда китерелгән мисаллардагы фигыль компонентлар үзара тезүле бәйләнешкә корылган, әмма аларны шушы ук бәйләнеш нигезендә ясалган парлы фигыльләрдән аера белү мөһим.

Мәсәлән, «Көз» әсәрендә компонентлары тезүле бәйләнештә булган 52 фигыльнең 37 се кабатлау юлы белән дәрәҗә мәгънәсен белдерсә (*саташыр-саташмас, егълап-егълап, агызганнан-агыза, кычкырып-кычкырып), җырлап-көйләп, тирләп-пешеп* кебек парлы фигыльләргә 15 мисал гына табылды. Төзелеш-бәйләнеш үзенчәлекләре белән бер-берсенә охшаш булсалар да, мисаллардан күренгәнчә, соңгыларында фигыльләр кабатланышы күзәтелми, мондый төр фигыльләрнең компонентлары үзара кушылып, гомумиләштерү мәгънәсенә ия һәм алар парлы (куш) сүз буларак каралалар [6: 361].

Шулай итеп, компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә ясалган парлы фигыльләрдә, аналитик дәрәҗә формаларынннан аермалы буларак, компонентлар кабатланышы (редупликация) сүзьясагыч вазифасын үтәми. Әмма бу фигыльләргә генә кагыла, телебездә редупликация юлы белән ясалган башка сүз төркемнәре барлыгын да онытмаска кирәк, мәсәлән, парлы рәвешләр (*көчкә-көчкә, бергә-бергә, бәйнә-бәйнә*), парлы сыйфатлар (*уем-уем, дулкын-дулкын, кат-кат*), парлы ияртемнәр (*гөр-гөр, тук-тук, келт-келт*), парлы ымлыклар (*дөгә-дөгә, уф-уф, көш-көш*) һ.б. бар.

Димәк, парлы фигыльләр редупликация нәтиҗәсендә ясалмый, әлеге факт фигыльләр кабатланышы аналитик(куш) фигыльләрне дәрәҗә категориясенең аналитик формация юлы белән ясалган формаларыннан аеру өчен төп күрсәткеч булып тора.

Редупликация күренешенә бәйле бәхәсле мәсьәләләр укыту өлкәсендә дә авырлыклар тудыра. Алар нигездә фигыльләргә морфемик яки морфологик анализ ясаганда килеп чыга. Биредә укучыларга сүзләр кабатланышының грамматик һәм сүз ясагыч чара буларак, һәр ике очрактагы аермалы якларын күрсәтү мөһим. Телдәге әлеге күренешләрне дөрес аңлау өчен, укучылар беренчедән, дәрәҗәнең аналитик формаларын үзләштерергә, икенчедән, парлы фигыльләрнең ясалыш типлары һәм модельләрен билгели белергә, семантик - төзелеш үзенчәлекләренә игътибар итәргә тиеш.

Хәзерге татар әдәби телендә парлы (куш) фигыльләр ясалышының бер генә тибы бар: фигыль + фигыль[5: 361]. Семантикасы ягыннан алар ясауда катнаша торган компонентларның конкрет мәгънәсенә туры килеп бетми, гадәттә гомумиләштерү килеп чыга, хәтта кайчак абстракция барлыкка килә. Мәсәлән, *кагу-сугу, киенү-ясану, яну-көю, әйләнү-тулгану, бөгелү-сыгылу, елау-сыктау, ару-талу, ялыну-ялвару* һ.б.ш.

Гаяз Исхакыйның «Көз» әсәрендә югарыда күрсәтелгән типның берничә моделе күзәтелде:

1. *-а/-ә, -ый/-и* формасындагы фигыль нигезләренең кушылуы:

*Әти инде **акырына-бакырына** башлады* [4: 257]. *Кайвакытларны чәчәктән чәчәккә очып йөри торган умарта кортының бызылдавы, ерактагы чикерткә туеның җырлавы әле югары менеп, әле түбән төшеп лезгингә бии торган чиркәс кызы кебек **әйләнә-бәйләнә** торган карлыгачларның моңнары, дәртләнүе астында изелеп киттек* [4: 278].

2. *-ды/-де, -ты/-те* формасындагы фигыль нигезләренең кушылуы. Мәсәлән: *Шуннан: «Мин чыгып керим әле алай булса, мин әле яңа гына вокзалдан килгәндә театрның игъланнарын күрдем дә, **ашамадым-эчмәдем**, юындым да килдем», – диде дә чыгып* китте [4: 249].

3. *-ып/-еп, -п* формасындагы хәл фигыльле нигезләр кушылуы: *Шул урыс малаена аяк арасында чуалып йөрүе өчен шулкадәр ачуым килде, шуны төшеп, **бәреп-сугып** егасым килде* [4: 259]. *Күңелле төшләр күреп уяндым, **җырлап-көйләп** бүлмәдән бүлмәгә йөри башладым* [4: 265]. *Анда тутакай, селкенә торган урындыкка утырган да, **тибрәнеп-салланып**, әллә ни сөйли иде* [4: 289].

Югарыда күренгәнчә, башка сүз төркемнәренә кергән, беренче компонентлары кушымча алмый торган куш сүзләрдән аермалы буларак, парлы фигыльләрнең ике компоненты да грамматик формантлар алырга мөмкин.

Әсәрдә парлы сүзләр бихисап, алар арасында ике нигезен дә фигыль тәшкил иткән фигыль+фигыль тибы белән ясалган парлы исемнәр дә күзәтелде, мәсәлән: *Иртә тору белән без **ашамак-эчмәкләр** төяп, дүрт-биш атка төялеп, су буена хозурга киттек* [4: 281]. Шулай ук раслау һәм инкяр формасындагы фигыль нигезләренә *-чан/-чән* ясагыч кушымчасы ялганып ясалган парлы сыйфатларның ды төзелеше бик үзенчәлекле: *Төрле җирләрдә хезмәт итә торган Кавказ әфисәрләре, төрекмән егетләре бар да безгә **килүчән-китүчән** иде* [4: 274].

Шулай итеп, Г. Исхакыйның әлеге әсәрендә барлыгы 127 парлы сүз билгеләнде, аларның бер өлешен компонентлар кабатланышы ярдәмендә ясалганнары (42 куш сүз) тәшкил итә, араларында авторның үз редупликативлары да очрый, бу ономатопларда аеруча чагылыш тапкан: *поштыр-поштыр* (тәгәрмәч тавышы), *меңер-меңер, мер-мер* (елау тавышы), *чыр - чыр* (сөйләшү тавышы), *шыр-шыр* (су тавышы), *йолт-йолт* (хәрәкәт (сикерү) тавышы), *шак-шак* (тешләр тавышы) һ.б.

Тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Г. Исхакый үзенең «Көз» әсәрендә редупликация чарасы аша фигыльләрне өстәмә мәгънә төсмерләре белән баетып, вакыйгалар сөрешен җанландырып сурәтләүгә ирешкән. Әдип кабатлау чарасын хәрәкәт, сөйләм эшчәнлеген һәм физиологик халәтне белдергән фигыльләрдә аеруча яратып кулланган. Язучының бай иҗаты җирлегендә аналитик фигыльләргә нисбәтле ачыкланмаган мәсьәләләрне фәнни нигездә тикшерү телебезнең грамматикасындагы бәхәсле мәсьәләләргә ачыклык кертү белән бергә, мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакый әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләү мөмкинлеге дә бирер, дип ышанып калабыз.

## ӘДӘБИЯТ

1. Ганиев Ф.А. Функциональная грамматика татарского языка. – Казань, 2015 – 272.
2. Исхакый Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002.
3. Лингвистический энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1990. – 685 с.
4. Татар грамматикасы. – Т. II. – М.: ИНСАН, Казан: ФИКЕР, 2002. – 448 б.
5. Татар грамматикасы. – Т. III. – М.: ИНСАН, Казан: ФИКЕР, 2002. – 512 б.

УДК 811.512.145’367

# ВЫРАЖЕНИЕ УСТУПИТЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Л.Г. Хабибуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена исследованию глубинных сложных семантических структур – логических отношений уступки в языке произведений классика татарской литературы Гаяза Исхаки. В современной лингвистической науке основным принципом познания системно-структурного и функционально-семантического исследования языка является соотношение языка и мысли, на первое место выдвигаются вопросы функционирования языковой структуры и ее внутренней организации. Актуальность выбранной темы объясняется особым интересом современного языкознания к семантическому исследованию языковых категорий, потребностью изучения семантико-синтаксических отношений.
**Ключевые слова:** уступительность, обратная обусловленность, татарский язык, язык произведений Гаяза Исхаки.

The article is devoted to the study of deep complex semantic structures – logical relations of assignment in the language of the literary works of the classic of Tatar literature Gayaz Iskhaki. In modern linguistic science, the main principle of cognition of the system-structural and functional-semantic study of language is the relationship between language and thought, the issues of the functioning of the language structure and its internal organization are put forward in the first place. The relevance of the chosen topic is explained by the special interest of modern linguistics in the semantic study of language categories, the need to study semantic-syntactic relations.
**Key words:** compliance, reverse conditionality, Tatar language, the language of Gayaz Iskhaki’s literary works.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНДӘ КИРЕ ШАРТ МӨНӘСӘБӘТЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

***Л.Г. Хәбибуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Синтаксисның хәзерге үсеш этабында тел категорияләрен структур-семантик анализлауга багышланган тикшеренүләр аеруча актуаль. Кире шарт мөнәсәбәте хәл мөнәсәбәтләре системасында аерым урынны алып тора, катлаулы һәм семантик күптармаклы санала.

Кире шарт мәгънәсе ике компоненттан формалаша: бер эш-хәлнең тормышка ашуына комачаулый торган гамәл һәм булган каршылыкка карамастан тормышка ашырылган гамәл. Мондый мәгънәви конструкция компонентлары арасында капма-каршылык урнаша: иярчен өлештә бирелгән вакыйга төп өлештә әйтелгән ситуацияне гамәлдән чыгару өчен нигез булып тормый.

Кайбер галимнәр (М.В. Ляпон, Е.В. Падучева, Е.В. Урысон) кире шарт мөнәсәбәтен сәбәп-нәтиҗәнең капма-каршысы итеп карый; башка тикшеренүчеләр хезмәтләрендә кире шарт мәгънәсе шарт белән якынайтыла (В.С. Храковский) яки алар капма-каршы куела (А.Г. Азизова).

М.В. Ляпон кире шартны тормышка ашырылмаган шарт итеп карый: «бер өлештә хәбәр ителгән мәгълүмат потенциаль сәбәп, кире кагылган нигез (уңайсыз, каршы килүче шарт һ.б.), ягъни теге яки бу рәвештә башка өлештә хәбәр ителгән ситуацияне гамәлдән чыгару өчен җитәрлек булмаган нигез буларак карала» [2: 137].

А.А. Озонова, алтай телендә шартлы теләк наклонениесен өйрәнеп, әлеге наклонениенең шарт конструкцияләрендә дә, шарт-кире шарт конструкцияләрендә дә кулланылуын билгеләгән [4: 78].

Әлеге мәкаләнең максаты Гаяз Исхакый әсәрләре телендә кире шарт мөнәсәбәтенең семантик һәм структур үзенчәлекләрен ачыклаудан гыйбарәт.

Кире шарт конструкцияләренең үзенчәлеге – аларның мәгънәсендә модальлек, сөйләүче позициясе булу. Кире шарт семантикасы ярдәмендә ике конкрет фактның капма-каршылыгы түгел, ә сөйләүченең әлеге фактлар турындагы типик күзаллавы теркәлә.

Тел материалын анализлаудан күренгәнчә, кире шарт конструкцияләренең семантик структурасында белдерелмәгән компонент – фараз ителгән нәтиҗә бар. Мәгънәви эчтәлеге буенча кире шарт өч өлештән тора, нигез-нәтиҗә һәм капма-каршы кую мөнәсәбәтләрен берләштерә. Шул ук вакытта шарт (сәбәп) белән нәтиҗә түгел, ә бер үк шартлардан килеп чыккан көтелгән һәм көтелмәгән нәтиҗә үзара каршылыкка керә. Шулай итеп, кире шарт конструкцияләрендә имплицит нәтиҗә дә була, үтәлүенә кирәкле шартларның булып та, көтелгән нәтиҗәнең булмавы белдерелә.

Тел структурасында кире шарт категориясе кире шарт ситуациясе ярдәмендә күрсәтелә. Кире шарт конструкциясе катлаулы семантик төзелешкә ия, аңа эчтәлек һәм форма планнарының тәңгәл килмәве хас: структурасы буенча ике компонентлы конструкция семантик яктан өч компонентлы була.

Кире шарт конструкцияләрендә бәйләүче чара буларак *-са да* формасы иң еш кулланыла. Бу очракта, кагыйдә буларак, реаль кире шарт мәгънәсе белдерелә. Мәсәлән: *Кызымны күргәнемә өч-дүрт ай вакыт үт**сә дә**, ул миннән бер дә ятсынмаенча килде* (Г. Исхакый. Зиндан); *Кырга уракчылар килеп беткәнгә, юл буп-буш бул**са да**, бөтен җир тулы халык иде* (Г. Исхакый. Тормышмы бу?); *Шәмсинең өе якын бул**са да**, миңа керик диярга база алмады* (Г. Исхакый. Ул әле өйләнмәгән иде).

Кире шарт мөнәсәбәтләре *карамастан, карамый* бәйлекләре белән дә күрсәтелә. Мондый төр конструкцияләрдә вакыйгалар арасында катгый туры килмәү белдерелә. Мәсәлән: *Төрмә ашлары бик тә рәтсез булуга **карамастан**, ашказаныбызга җылы берәр нәрсә ашарга мәҗбүр идек* (Г. Исхакый. Зиндан); *Хатынының сүзенә **карамаенча**, ул, димләп-нитеп, мәхдүмне Хәдичә тора торган апаларына кунакка җибәрде* (Г. Исхакый. Татар гакылы).

*Бернигә дә карамастан, бернигә карамый* тезмәсе, комачаулаучы шартларга карамастан, эш-хәлнең үтәлүенә сөйләүченең катгый ышанычын белдерә. Мәсәлән: *...Күңелемнән: «Сезнең берлән танышасы иде», – дидем һәм таныштым; менә хәзер **бернигә карамый** сөйләшеп барам* (Г. Исхакый).

Кире шарт мөнәсәбәтен боеру наклонениесе формасы белән белдергәндә, җөмлә өлешләре мәгънәләре капма-каршы куела, ихтималлык төсмере була. Каршылык тудыручы нигез фараз ителүче факт сыйфатында була, шуңа күрә мондый мисалларны фараз ителүче кире шарт семантикасын белдерә дип карарга мөмкин. Мәсәлән: *Бу мәсьәлә, инде күптән хәл ителергә вә, нинди юл берлә генә булма**сын**, гыйлем алуның нә милләткә, нә дингә, вә нә дә ватанга һичбер вакытта зарар итмәгәнен вә итмәячәген күптән аңларга тиеш иде* (Г. Исхакый).

Кайбер җөмләләрдә процесс эш-хәлнең дәвамлылыгына, кабатлануына карамастан үтәлү турында хәбәр ителә. Мондый мисалларда, кагыйдә буларак, вакыйганы тормышка ашыру омтылышының уңышсызлыгы хәбәрлек билгесе белдерелүенең күләме һәм чамасы белән бәйләнә, микъдар-кире шарт семантикасы белдерелә. Мәсәлән: *Галим абзый **никадәр** гакыл ягыннан мин сөйләгән кешеләрдән ким булма**са да**, уңганлык ягыннан сез белгән кызыл авызлардан артык та бул**са да**, баласыны тәрбиясе бөтенләй башкача* (Г. Исхакый. Татар гакылы); *...**Никадәр** бай бул**са да**, үзе үлгәч кызына **никадәр** дәүләт каласыны бел**сә дә**, кызының шул дәүләтне үзе алып барып үстерүене ул уйламый да, күңеленә дә китерми* (Г. Исхакый. Татар гакылы); ***Никадәр** йокысы кил**сә дә**, **никадәр** арыган бул**са да**, абыстай хәзрәт чишенеп ятмаенча урынга якын килми* (Г. Исхакый. Остазбикә).

*Ничек кенә булмасын* тезмәсе башка фактка каршы куелучы фактның дөреслеге сөйләүче тарафыннан инкарь ителмәгәндә, ул икенче фактка каршы башка фикерләрнең дә булу ихтималын аңлаганда кулланыла. Мондый очракларда нәтиҗәгә каршы факторларның йогынты көче гомумиләштерү белән бәйле булырга мөмкин. Шулай да каршы хәлләр нәтиҗәнең гамәлгә ашуы өчен киртә була алмый. Мондый мисалларны көчәйтү-кире шарт семантикасын белдерүче дип классификацияләргә була, аларда шулай ук бернинди дә авырлыкларга карамастан, алдан уйлаган эшне тормышка ашыру нияте мәгънәсе дә була. Мәсәлән: *Штат даирәсе **ничек кенә булмасын,** гайре мөселман милләтләр монда азчылык тәшкил итәчәкләр* (Г. Исхакый).

Кире шарт конструкциясендә *барыбер* сүзе кулланылганда, я теге яки бу вакыйгаларның, процессларның, һичшиксез, тормышка ашуы мәгънәсе ассызыклана, я бер ситуациянең булу ихтималлыгы күрсәтелә. Мәсәлән: *Бездән качырып йөретмә, **барыбер** булдыра алмассың* (Г. Исхакый).

Кире шарт семантикасы *да/дә* кисәкчәсе белән кулланылган яки үзе генә килгән *-п* формалы хәл фигыль белән дә белдерелә ала. Мәсәлән: *Болай егла**п та,** бер дә файда юк, ничек булса да үзеңне үзең җуатып торырга кирәк* (Г. Исхакый).

Г.А. Мусатова билгеләгәнчә, кире шарт кыры семантик структурасында үзәк урынны реаль кире шарт мәгънәсе микрокыры алып тора. «Үзәккә якынрак – фараз ителгән кире шарт мәгънәсе микрокыры, периферийдә көчәйтү-кире шарт мәгънәсе микрокыры урнаша» [3: 12].

Кире шарт конструкцияләре составында көтелгән һәм булган нәтиҗәнең туры килмәве мәгънәсен көчәйтә торган теркәгечләр дә булырга мөмкин. Теркәгеч һәм кире шарт формасының бергә кулланылуы күренешләрнең катгый капма-каршылыгын белдерә. Гаяз Исхакый әсәрләрендә мондый мисаллар шактый еш очрый. Мәсәлән: *Яңы эш юк иде, **гәрчә** Казанда матбагалар булып, һәр лисанда китап бастырырга, әдәбият нәшер итәргә рөхсәт бул**са да**, дин китапларына башка «Сәйфелмөлек», «Йосыф китабы», вә башка нә кешегә, нә дөньясына, нә ахирәтенә файда бирми торган китаплар басыл**са да**, кирәкле фән китаплары, әдәби хикәяләр, милли театр уенналары һич күзгә-башка күренми иде* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз); ***Гәрчә** тәгълим-тәгаллемдә тәртип кабул ителде диер дәрәҗәдә булма**са да**, шәкертләр өчен урыннар иркенәйтелә башланды* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз); ***Ләкин** мин үтер**сәләр дә**, бу приходта калырга разый түгел, шуны бел!* (Г. Исхакый); ***Ләкин** шул Беренче, Икенче Дума яшә**сә дә**, «Мөселман иттифакы»ның сәяси партия уларак яши алмавына җитәрлек дәлилләр тормышымызда юкмы?* (Г. Исхакый).

Шул ук вакытта мондый җөмләләрдә теркәгечләр кулланылуның факультативлыгын ассызыкларга кирәк, чөнки аларны төшереп калдыру конструкцияләрнең мәгънәви эчтәлегенә зыян китерми, алар җөмләнең структур яктан мәҗбүри элементлары составына керми.

Кире шарт мөнәсәбәтләре каршы кую мөнәсәбәтләреннән шуның белән аерыла: кире шарт булганда, каршы куелучы фактлар логик яктан үзара бәйләнгән була, ә каршы кую мәгънәсе булганда, фактларны капма-каршы кую ирекле характерда була.

Кагыйдә буларак, кире шарт конструкцияләрендә бер үк вакытта булган һәм бербер артлы булган хронологик мөнәсәбәтләр белдерелә. Шул ук вакытта эзлеклелек мөнәсәбәте формаль рәвештә еш кына бер вакыт планы белән бирелә. Кире шарт конструкцияләрендә булган нәтиҗәне логик кире кага алган, әмма гамәлдән чыгармаган өстәмә сәбәп мәгънәсе була. Шулай итеп, нәтиҗә көтелгәннең тулысынча капмакаршысы булып чыга.

Үткәрелгән тикшеренү күрсәткәнчә, кире шарт семантикасы капма-каршы куюга нигезләнә, каузаль, кондициональ, каршы кую мәгънәләре нигезендә формалаша. Көтелгән һәм фактик нәтиҗә арасындагы семантик бәйләнеш кире шартны барлыкка китерә. Кире шарт семантикасын белдергәндә, башлангыч һәм нәтиҗәледән аермалы буларак, имплицит белдерелгән арадаш звено да була.

## ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Гаяз. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 671 б.

2. Ляпон М.В. Смысловая структура сложного предложения и текст: к типологии внутритекстовых отношений. – М.: Наука, 1986. – 447 с.

3. Мусатова Г.А. Семантика уступки: автореф. дис. …канд. филол. наук. – М., 2008. – 21 с.

4. Озонова А.А. Сослагательное наклонение в алтайском языке // Языки и фольклор коренных народов Сибири. – 2019. – № 1. Выпуск 37. – С. 74–83.

5. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – Т. III. – 536 б.

6. Типология уступительных конструкций / ред. В. С. Храковский. – Санкт-Петербург: Наука, 2004. – 625 с.

7. Урысон Е.В. Союз *хотя* и обманутое ожидание // Известия Российской академии наук. Серия литературы и языка. – 2012. – Т. 71. – № 1. – С. 44–51.

8. Храковский В. С. Универсальные уступительные конструкции // Вопросы языкознания. – 1999. – № 1. – С. 103–122.

# ПРОБЛЕМЫ ИЗУЧЕНИЯ ТВОРЧЕСТВА Г. ИСХАКИ В ШКОЛЕ / Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ / PROBLEMS OF STUDYING G. ISKHAKIE'S WRITINGS AT SCHOOL

УДК 37.02+821.512.145

## ИЗУЧЕНИЕ В ШКОЛЕ ПОВЕСТИ Г. ИСХАКИ «СУННАТЧИ БАБАЙ»

***Д.М. Абдуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются особенности изучения повести Г. Исхаки «Суннатчи бабай». В этом произведении нашли отражение материальные и духовные богатства, традиции, быт, особенности национального характера татарского народа. Поэтому оно является незаменимым источником национального воспитания молодого поколения, приобщая к образцовым качествам народа.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, повесть «Суннатчи бабай», родная (татарская) литература, национальный характер.

The article discusses some features of the study of the work of the writer G. Iskhaki according to modern school curricula of native (Tatar) literature, namely, the story «Sunnatche Babai». This story reflects the material and spiritual riches, traditions, way of life, peculiarities of the national character of our people. That is why it is an indispensable source of national education of the younger generation, introducing it to the exemplary qualities of our people.
**Key words:** G. Iskhaki, the story «Sunnatchi babai», native (Tatar) literature, national character.

## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» ПОВЕСТЕН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ

***Д.М. Абдуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Яшь буынга милли тәрбия бирү, аны халкыбызның рухи байлыгы, милләтебезгә хас булган холык-табигате белән якынайтуда төп таяныч булып мәктәпләрдәге туган тел һәм туган телдәге әдәбият дәресләре тора. Дәреслекләргә кертелгән әдәби әсәрләр халкыбыз тормышын һәрьяклап дөрес, төгәл һәм тасвирлы итеп ачып бирә, шул хәл, вакыйгалар эчендә герой күңелендәге кичерешләрне, аның рухи халәтен бөтен тулылыгы белән укучыга җиткерә. Әдәбиятны фән буларак өйрәнүгә нигезләнгән уку предметына караганда, туган телдәге әдәбият предметы бу мөмкинлекләрне тагын да киңәйтә. Әсәрләрне өйрәнгәндә милли-мәдәни мохиткә тагын да тирәнрәк үтеп керүне, аны тәфсилле күзәтүне һәм укучыны бу байлык белән таныштыруны максат итеп куя ала.

Г. Исхакый әсәрләре бу уңайдан зур милли-мәдәни байлыкның чыганагы булып тора. Мәктәп дәреслекләрендә әлегә кадәр Г. Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде», «Көз», «Сөннәтче бабай», «Кәҗүл читек», «Җан Баевич», «Остазбикә» һәм башка әсәрләре өйрәнелеп килендe. Яңа программаларда да бу әсәрләрнең күбесе сакланып калынды. Бу язучының әсәрләрендә халкыбызның матур сыйфатлары, тормышы җентекләп тасвирлануы һәм шуның белән зур тәрбияви әһәмияткә ия булуы белән дә аңлатыла.

«Сөннәтче бабай» повестенда автор озак еллар бергә матур гомер иткән Корбанколый бабай һәм Гөлйөзем әби гаиләсен сурәтләү аша татар халкының милли холкына

хас булган гаилә тормышы калыбын тасвирлый. Аларның һәр җирендә тәртип булган көнитеше, бернинди каршылыкларсыз, табигый рәвештә килеп туган хезмәт бүленеше, үзара һәм авылдашлары белән булган мөнәсәбәтләрен җентекләп сурәтләп, халкыбызга хас булган тормыш алып баруның үрнәген тәкъдим итә.

Язучы иң элек, авыл халкының әлеге гаиләгә тирән ихтирамын ачып бирә. Ә алга таба, берәм-берәм, бу ихтирамны яулауның сәбәпләрен ачыклап китә. Башта гаиләдә ике кешенең бер җан булып, бер-берсен тирәнтен аңлап, бер-берсен тулыландырып яшәүләре турында сөйли: «Бунларның төсләрендә, йөзләрендә, кылынышларында, табигатьләрендә дә һичбер аерма юк иде... Буйларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде. Мәсәлән, Сөннәтче бабай: «Карчык, түтәлләргә сибәргә вакыт түгелме?» – дияргә өлгерә алмый иде. Гөлйөзем әби чиләкне күтәреп чыга башлый иде. Көз йитеп, «сөннәт туйлары» итә башларга вакыт йитеп, Гөлйөзем әби: «Карт, «сөннәтләр» йитә», – дияргә өлгерми, Сөннәтче бабай, тәһарәт төзеп, чалгы пәкесене кайрарга тотына иде» [2: 203].

Алга таба автор бу гаиләдәге хезмәткә булган мөнәсәбәтне дә бик тәфсилләп сурәтли. Йорт эчендә хатын-кыз һәм ир-ат вазифасының бүленеше, бу хезмәтне һәркемнең зур җаваплылык белән һәм яратып башкаруы да укучыга аңлашылып тора. «Ул гына да түгел, бунлар арасында эштә дә аерма бар иде: кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самавыр кую Гөлйөзем әбинең эше булган кеби, миләшкә су сибү, йортны себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Онытканмын икән әле, өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. Ул һәркөнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атнакич ком берлән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларыны ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур берлән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде. Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт-карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде» [2: 203],– дип сөйләнелә повестьта. Биредә йорт-җирдәге тәртипнең эзлекле хезмәт нәтиҗәсе булуы да, татар халкына хас чисталык һәм пөхтәлек үрнәге булуы да ачык аңлашылла.

Хезмәтнең нәтиҗәсен күрсәтүгә дә тиешле урын бирелгән. Бөтен гомере буена йорттагы һәр хезмәткә кулы ятып торган, һәр нәрсәне тәртип белән вакытында эшләгән һәм шул ук вакытта бу хезмәттән бер вакытта да зарланмаган, аны күңел җылылыгы биреп үтәгән Корбанколый бабайның хуҗалыгын язучы укучыга үрнәк итеп тәкъдим итә: «Җәйнең һәр вакытында аның шул бакчасы ямь-яшел тора, илдәге корылык аның арышыны саргайтмый, җәйге эсселек аның карабодаены көйдерми иде. Һәр елны кояшка карап тора торган каш йирендә аның бодае уңа, уйсу йиргә чәчкән аның солысы кара туткыллы булып гөрләп үсә, карабогдае, миләш кеби, сабаклары берлән тулы була; арышы, сары ука кеби, башыны күтәрә алмаенча сузылып ята иде. Аның кыяры, шалканы, кишере хакында сөйләмә дә инде – анлар бөтен авылның авызыннан суыны агыза, бөтен авылны кызыктыра иде» [2: 202].

Шулай ук повестьта гаиләдә борынгыдан килгән тәртипләргә, мираска, дингә булган олы ихтирамын күрсәтә. Сөннәтче бабайның шәҗәрәсенә булган ихтирамы, буыннан-буынга тапшырылган сөннәтчелек һөнәренә җаваплылык һәм ихтирам белән каравы, боларның һәммәсенең гаиләдә хөрмәт ителүен язучы кат-кат искәртә. Бу һөнәр аның кулына керү тарихын сөйләгәндә, аның җиңел генә бирелмәгәнлеген дә аңлатып сөйли. Моның белән кешегә һөнәр иясенә әверелү юлының катлаулы булуын, зур тырышлык таләп итәкәнлеген раслый.

Сөннәт пәкесе әсәрдә символик мәгънә ала. Ул буыннан-буынга тапшырыла торган мирас. Берьяктан, халкыбызның пакьлеген сакларга ярдәм иткән гореф-гадәтләрне, икенче яктан, тормыш тәҗрибәсе, һөнәри осталыкны үзеңнән соң килгән яңа буынга тапшырып китүне чагылдыра. Әсәр ахырында сөннәт пәкесенең мәхдүмгә тапшырылуы да алда әйткән фикерләрне дәлилләп тора.

Әсәр дәвамында Сөннәтче бабайның сөннәт пәкесенә булган мөнәсәбәтен язучы бик тирән психологик кичерешләр аша гәүдәләндерә. Карчыгы үлгәннән соң, Сөннәтче бабай кабат өйләнә. Әсәр сюжетына кертелгән мондый борылыш белән автор хатын-кызның гаиләдәге урыны бик зур икәнлеген дәлилли. Карчыгы үлү белән,

Сөннәтче бабайның бөтен гомере буена көйләнгән тормышы үз җаен югалта. Йортка килгән яңа карчыгына ул зур өметләр багласа да, бу акланмый. Үзенең шапшаклыгы, аш-су рәтен белмәве белән аерылып торган карчык, әдәпсез һәм мәгънәсез дә булып чыга. Өйдәге элеккеге тәртипләр югала, тормышның көе китә. Сөннәтче бабайның үзенә хөрмәте белән карамаган карчык аның һөнәренә дә ихтирам күрсәтми. Ул аның сөннәт пәкесе белән бәрәңге әрчергә утыра. Шул күренешкә тап булган Сөннәтче бабай тормыштагы соңгы өметен югалта: «Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Ул калтырана башлады. Ап-ак булып авызыннан күбеге агып, һушсыз булып егылды. Хәзрәт килеп Коръән укыганнан соң, аның һушы килсә дә, теле ачылмады. Пәкене никадәр алырга теләсәләр дә, кулыннан ычкындырмады...» [2: 228].

Сөннәтче бабай үзенең сөннәт пәкесен мирас итеп хәзрәтнең улына тапшырганнан соң гына, тынычланып бу якты дөнья белән бәхилләшә.

Әсәрне уку һәм анализлау барышында повестьның сюжетына нигезләнеп, милләтебезгә хас булган күп кенә матур сыйфатларны, халкыбызның тормыш алып бару үзенчәлеген, гаиләдәге тәртипләр, ир һәм хатын-кызның гаиләдәге урыны, милли аш-су, кунак каршы алу, кунак итү, хезмәт ярату, аннан тәм таба белү, гаилә традицияләренә хөрмәт саклау кебек күркәм гадәтләрне үрнәк итеп тәкъдим итәргә, укучыларда шул күнекмәләрнең булдыруның нигезен салырга була.

ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллина Д.М., Мухарлямова Г.Н. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родная (татарская) литература» для 5–9 классов основного общего образования. – Казань, 2022. – 65 с. URL: https://fgosreestr.ru/oop/primernaia-rabochaia-programma-uchebnogo-predmeta-rodnaia-tatarskaia-literatura-dlia-5-9-klassov-osnovnogo-obshchego-obrazovaniia

2. Исхакый Г. Сөннәтче бабай // Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 671 б.


УДК 371.3

## ИЗУЧЕНИЕ ТВОРЧЕСТВА ГАЯЗА ИСХАКИ В ШКОЛЕ


***Р.Б. Камаева***

*Елабужский институт КФУ (Елабуга)*



В рамках данной статьи рассматриваются вопросы изучения творчества Гаяза Исхаки в школе. Анализируются методы и приемы работы с текстами, включенными в школьную программу, «Кәҗүл читек», «Ул әле өйләнмәгән иде» («Он был еще не женат»). Особое внимание уделяется активным методам анализа художественного произведения.



**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, художественное произведение, татарская литература, урок.



Within the framework of this article, the issues of studying the work of Gayaz Iskhaki at school are considered. The methods and techniques of working with texts included in the school curriculum, «Kaҗul chitek», «Ul alle oylanmegan ide» («He was not married yet») are analyzed. Special attention is paid to the active methods of analyzing the artwork.



**Key words:** Gayaz Iskhaki, artwork, Tatar literature, lesson.


## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ


***Р.Б. Камаева***

*Казан федераль университетының Алабуга институты (Алабуга)*


Гаяз Исхакый – татар әдәбиятында тоткан урыны, иҗатының киңлеге, актуальлеге белән кабатланмас, үзенчәлекле шәхес. «Ул татар милли азатлык хәрәкәтенең башында торып, алдан күрүче зирәк акылы белән татарларны милләт буларак юкка чыгу куркынычыннан, инкыйраздан йолып алу идеясен тудырган һәм халкының киләчәк язмышы өчен борчылып, җан атып яшәгән милләтпәрвәр. Аның үлемсез әсәрләрендә, үткен публицистикасында, ялкынлы чыгышларында чагылыш тапкан милли программасы: төрки татарларның чын мәгънәсендә федераль дәүләтчелеген булдыру, телләрен, диннәрен, үз йөзләрен саклап калу, милли культураларын үстерү турындагы

идея-карашлары бүген дә үз көчендә кала һәм милләтебезне яклап Гаяз Исхакый кебек фидакарь һәм кыю көрәшергә чакыра» [1: 65].

Бу мәкалә кысаларында без язучының иҗатын мәктәптә өйрәнү мәсьәләләренә тукталырбыз. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар» (Казан, 2011) нигезендә мәктәптә Гаяз Исхакый иҗатыннан «Кәҗүл читек», «Ул әле өйләнмәгән» әсәрләрен өйрәнү каралган.

Гаяз Исхакыйның «Кәҗүл читек» хикәясе 6 сыйныфта өйрәнелә. Әсәрне өйрәнү өчен 2 сәгать вакыт бирелгән. Дәресләрдә үткәрелергә тиешле булган кайбер эш төрләренә тукталып үтәрбез.

Язучының биографиясен өйрәнү. Беренче дәрестә укучылар язучының биографиясе белән танышалар. Бу эшне төрлечә оештырырга мөмкин. Биография өйрәнүгә, гадәттә, бик аз вакыт бирелә. Шуңа күрә игътибар үзәгенә әдип тормышында әһәмиятле роль уйнаган вакыйга-хәл, кеше һәм язучы буларак характерын ачыклау алынса яхшы. Язучы биографиясе белән танышканда, шәхси көндәлекләре, хатлары, истәлекләре, алар турындагы язмалар файдаланыла ала. Әдипнең тормыш юлын өйрәнү әңгәмә, мәгълүмат бирү, лекция-әңгәмә, портрет белән эшләү һ.б. шундый алымнар ярдәмендә башкарылырга мөмкин. Дәреснең актив формаларына мөрәҗәгать итү уңай нәтиҗәләр бирә (дәрес-экскурсия, дәрес-сәяхәт, дәрес-викторина, дәрес-кичә, дәрес-эшлекле уен һ. б.). Дәреслек белән эшләү дә мөһим роль уйный. Дәреслектәге Гаяз Исхакыйның биографиясе турындагы язмадан да файдалану уңышлы булыр (Ф.Ф. Хәсәнова «Татар әдәбияты», Казан, 2017, 33-34 битләр). Укытучы алдагы дәрестә укучыларга өй эшенә авторның биографиясе белән танышып, хронологик таблица төзеп килергә кушып җибәрергә мөмкин. Бу очракта дәрестә таблицаны экранга чыгарып, язучының биографиясе буенча фотосурәтләрдән файдаланып, тарихи даталарга игътибар итеп, авторның биографиясен өйрәнү эше оештырыла. Бу дәрестә язучының әсәрләреннән күргәзмә оештыру, төрле әсәрләрнең эчтәлеге буенча ясалган фотосурәтләрне, автор турында замандашлары әйткән фикерләрне файдалану, истәлекләр уку максатка ярашлы булыр.

Портрет белән эш. Иң башта язучының портреты буенча әңгәмә үткәрергә мөмкин, ә аннан соң истәлекләрне уку эше оештырыла. Укучылар биргән характеристика белән замандашларының фикерләре тәңгәл килүен чагыштырып карарга мөмкин.

Текст өстендә эш. «Кәҗүл читек» хикәясен уку дәрестә оештырыла (әсәрне уку өй эше итеп тә бирелгән булырга мөмкин). Текстны укуның төрле формасы файдаланыла: сәнгатьле уку, аңлатмалы уку, үзлектән уку, рольләргә бүлеп уку. Текстны укып чыкканнан соң, түбәндәге эшләр башкарылырга мөмкин: сүзлек өстендә эш, вакыйгаларга бәйле рәвештә әсәрне өлешләргә бүлү, өлешләргә исем кушу, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү, өлешчә эчтәлекне сөйләү, аерым эпизодларны сәнгатьле уку, төп геройның (Әхмәдулланың) тышкы кыяфәтен сурәтләү (рәсемен ясарга яки аерым әзер элементлардан төзү эшен оештырырга мөмкин), вакыйгаларны уку барышында Әхмәдуллага хас сыйфатларны табу (уңай, тискәре сыйфатлар), Әхмәдулла образын башка геройлар белән мөнәсәбәттә карау, Әхмәдулланың кичерешләрен сөйләү, авторның әйтергә теләгән фикерен ачыклау, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын анализлау.

Икенче дәрес тулысынча әсәрне анализлауга багышлана. Әңгәмә өчен якынча сораулар: Әсәр нинди жанрда язылган? Ни өчен? Төп герой кем? Ул нинди малай? Әхмәдулланың читекне көткәндә нинди хисләр кичерә? Әхмәдулла читекне киеп кая барачак? Бәйрәм көнне малай ни өчен кыен хәлдә калган? Хәзерге вакытта читек киләрме? Гает бәйрәме нинди бәйрәм? Тагын нинди дини бәйрәмнәрне беләсез? Әсәрдә күтәрелгән проблема бүген дә актуальме? һ.б. шундый сораулар бирелә. Образ-символларга да аерым игътибар ителә. Әхмәдулланың кигән киемнәренә аерым игътибар юнәлтелә. (Бу киемнәрнең нинди кием булуы, нәрсә өчен хезмәт итүе ачыклана. Чапан нинди? Нинди материалдан тегелгән? Ни өчен яшел төстә? Ни өчен Әхмәдулланың чалмасы чуар?) Бу дәрестә укучыларга кейс-биремнәр дә тәкъдим итәргә мөмкин. Аерым эпизодларны сәхнәләштереп күрсәтү дә максатка ярашлы булыр.

Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» хикәясе 10 сыйныфта өйрәнелә. Язучының иҗатын өйрәнү өчен программа буенча 3 сәгать вакыт бирелгән. Беренче дәресне тулысы белән язучының иҗаты һәм тормыш юлына багышларга мөмкин. Дәрес-семинар, дәрес-конференция формасында үткәрергә була. Бу вакытта язучының программага кертелмәгән әсәрләре буенча фикер алышу мөмкинлеге дә булачак.

«Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрен өйрәнүгә 2 сәгать вакытны багышларга мөмкин. Повестьны укучылар өйдә укып килгәннән соң, дәресне дәрес-әңгәмә формасында үткәрергә мөмкин. Әсәрне бүлекләп өйрәнү уңышлырак булыр, һәр вакыйганы анализлап, төп геройларга характерлы сыйфатларны аларның портретлары, эш-гамәлләре аша анализлап нәтиҗә ясау максатка ярашлы. Анализ өчен һәр бүлек саен бирелгән сораулар һәм биремнәрдән дә файдаланырга мөмкин (Ф.Ф. Хәсәнова авторлыгындагы 10 сыйныф өчен татар әдәбияты дәреслеге, Казан, 2017, 234–237 битләр). Төркемнәрдә эш оештырып, укучыларга мөстәкыйль фикер йөртү, геройларга карата үз фикерләрен белдерү мөмкинлеген бирергә кирәк. Дәрес нинди формада үткәрелсә дә, укучыларга үз фикерләрен текстка таянып, дәлилләп сөйләргә мөмкинлек бирү отышлы булыр.

Әсәрне анализлау өчен кайбер сораулар һәм биремнәр:

Шәмси нинди тәрбия алган? Аның әти-әнисе кем?

Шәмсигә гаиләле булырга нәрсә комачаулый?

Шәмси образына мөнәсәбәтегез нинди?

Анна Ислам динен кабул итә алыр идеме?

Шәмсидәге эчке һәм тышкы каршылыкларны ачыклагыз.

Бу каршылыклар Аннада да бармы?

Ничек уйлыйсыз, Шәмсинең «мөселманча тәрбия иттерермен» дигән теләге тормышка ашармы? Җавапларны әсәргә нигезләнеп дәлилләгез.

Гомумән алганда, шуны әйтергә кирәк: Гаяз Исхакый үзенең әсәрләрендә татар халкының үткәндәге яшәү рәвешенә күзәтү ясый, киләчәге турында уйланып, аның аерым милләт сыйфатында сакланып калу чараларын эзли. Әдипнең әсәрләре укучыларны уйланырга, тормыш коруга җитди карарга, үз телебезне хөрмәт итәргә, гореф-гадәтләребезне сакларга чакыра.

ӘДӘБИЯТ


1. Бакиров М. Гаяз Исхакый иҗаты нәрсәгә өнди, яки Милли яңарыш һәм милләтне саклап калу идеясе // Мирас. – 2001. – № 10. – Б. 65–70.

2. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1–11 сыйныфлар / (басма өчен Ч.М. Харисова, К.С. Фәтхуллова, З.Н. Хәбибуллина җаваплы). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 239 б.

3. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 сыйныф / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ф. Җамалиева. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2011. – 431 б.



УДК 801


## НЕКОТОРЫЕ ОСОБЕННОСТИ ИЗУЧЕНИЯ ТВОРЧЕСТВА Г. ИСХАКИ В СТАРШИХ КЛАССАХ


***Г.Ф. Каюмова***

*Казанский федеральный университет (Казань)*



В статье раскрываются некоторые особенности изучения творчества Г. Исхаки в старших классах. Повесть выдающегося татарского писателя Г. Исхаки «Он не был женат» раскрывает проблему смешанных браков. Начало XX века – переломный момент в истории и культуре татарского народа, это эпоха, когда произошел всплекс национального самосознания. Данная повесть интересна тем, что Г. Исхаки вдумчиво и даже спокойно рассматривает все нюансы проблемы, не оставляя без внимания противоречащий душе интеллигентного Шамси уклад жизни в татарских селах, душевные терзания, которые герой то старается утопить в вине, то в иллюзорных мечтах. Авторы учебника Ф.Ф. Хасанова предлагают учащимся также детально и вдумчиво охарактризовать героя, его возлюблен-

ную и на основе вышесказанного составить собственную оценку ситуации. Мы предлагаем дополнить изучение повести дополнительным чтением произведения «Осень», где на примере судеб героинь раскрывается значимость воспитания уважения к собственной национальной культуре.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, повесть «Он не был женат», повесть «Осень», смешанный брак, урок литературы.

The article reveals some features of the study of G. Iskhaki's creativity in high school. The story of the outstanding Tatar writer «He was not married» reveals the problem of mixed marriages. The beginning of the twentieth century is a turning point in the history and culture of the Tatar people, an era when there was a surge of national consciousness. This story is interesting because G. Iskhaki thoughtfully and even calmly examines all the nuances of the problem, without ignoring the way of life in Tatar villages that contradicts the soul of the intelligent Shamsi, the spiritual torments that the hero tries to drown in wine, then in illusory dreams. The authors of the textbook by F.F. Khasanov also offer students a detailed and thoughtful characterization of the hero, his beloved. and based on the above, make your own assessment of the situation.We propose to supplement the study of the story with an additional reading of the work «Autumn», where the importance of fostering respect for one's own national culture is revealed by the example of the destinies of the heroines.
**Key words:** G. Iskhaki, the story «He was not married», the story «Autumn», mixed marriage, literature lesson.

## ЮГАРЫ СЫЙНЫФЛАРДА ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Г.Ф. Каюмова***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Әдәбият укыту методикасында аерым шәхесләр иҗатын өйрәнү үзенчәлекләрен махсус тикшеренүләрне таләп итә. Бу күренеш күптөрле факторларга бәйле була ала: язучы тормышы гыйбрәтле булу, иҗади тематикасы, иҗат лабораториясе үзенчәлекләре, иҗатында яңачалыкның үзенчәлекле яңгырашы һ.б. Г. Исхакыйның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты да әдәбиятыбызда феноменаль күренеш хасил итәләр. Әлеге мәкалә кысаларында без 10 нчы сыйныфта «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрен өйрәнү үзенчәлекләрен тикшерергә тәкъдим итәбез. Ф.Ф. Хәсәнова һ.б. авторлыгындагы дәреслек 10 нчы сыйныф укучыларына Г. Исхакый иҗаты белән танышуны түбәндәге тәртиптә алып барырга тәкъдим итә:

– Г. Исхакыйның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә күзәтү. Рус мәктәпләрендә татар төркемнәрендә укучылар өчен бу күзәтү шактый күләмле, тәфсилле һәм әдип тормышы һәм эшчәнлеге, иҗатының төрле якларын шактый төпле итеп җиткерү максатына ирешә. Аерым алганда, дәреслектә традицион шәкелдә язучының туу, укыган урыннары турында мәгълүмат бирелә, инкыйлаби дулкыннар тәэсиренә бирелүе, актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә жандармерия күзәтәүе астында яшәве, журналистика өлкәсендәге беренче адымнары атала. Г. Исхакыйның сәясәт һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге турында сөйләгәндә, «Идел-Урал» штаты һәм аның идеяләре турында мәгълүмат бирелә; язучының мөһаҗирлек чорына кыскача тукталына;

– Г. Исхакый турында күренекле шәхесләрнең сүзләре теркәлә (Г. Тукай, Җ. Вәлиди);

– Р. Рәкыйповның «Гаяз Исхакыйга багышлама» шигыре бирелә;

– «Ул әле өйләнмәгән иде» повестена идея-проблематик яктан күзәтү ясала;

– «Ул әле өйләнмәгән иде» повесте кыскарытылып бирелә.

XIX гасыр ахыры-XX йөз башында гаилә кору проблемасын иң элек мәгърифәтчелек позициясеннән торып хәл итеlә һәм төп идея хатын-кыз ирегә яссылыгында хәл ителә. Бу яктан М.Акъегетнең «Хисаметдин мулла» әсәре башлап эз салучы буларак санала ала. Традицион гадәтләрнең тискәре яклары Г. Исхакый тарафыннан да ассызыклана. Аерым алганда, «Өч хатын берлә тормыш» пьесасында ул кыз ирегә, кыз теләгеннән башка никах уку, кызларның үз хокукларын белмәүләре, күпхатынлылык

кебек проблемаларны күтәрә. «Кияү» хикәясендә тормыш иптәшләрен сайлаганда мораль якка түгел, ә матди байлыкка яки кияү / кәләшнең ата-аналары торган социаль баскычка гына игътибар итүнең фаҗигале яклары тасвирлана. Унсигез яшьлек кызлары Сәҗидәне мулла улына кияүгә бирүләренә шул кадәр шатланып, һәр адымны «мулалаларча» ясап, аена егерме көнне кияү мулланы сыйлап яши башлагач, гаилә эченнән таркала башлый: уллары гауга белән йорттан аерылып китә, гаилә башлыгының сәламәтлеге начарая, ә инде кияү теләгәнчә акча килми башлагач, ул хатынын бик тиз аерып, кире өенә кайтарып җибәрә.

Икенче – «Башкорт бәхете» хикәясендә дә ата-ана сайлаган кызга өйләнергә егетнең тормышы кире якка тәгәри башлый. Мишәр кызын яратмыйча, башкорт кызын сайлаган ата-ана яшь гаиләнең киләчәге, җәмгыять ячейкасы буларак, нәселне дәвам итүче буларак яшәешкә сәләтле була алу яки алмавы хакында уйламый. Туйдан соң гына хатынын күрә алган егет гаҗәпкә кала: «Аның ун-унөч яшендә генәлекене белгән булсам да, мин аны һәрвакыт зур, йитеп беткән кыз дип уйларга өйрәнгән идем. Аның йөзе генә түгел, бөтен әгъзаларыннан да балалыктан башка нәрсә тапмадым. Күкрәк дигән нәрсә үсә дә башламаган иде; кул-аяк тулырга да тотынмаган иде» [2: 460]. Шушы үсмерлеккә әле керә генә башлаган кызны инде солдаттан кайткан егеткә кияү итеп бирүләре нәтиҗәсендә өлгергән гаилә – җәмгыять ячейкасы формалаша алмый, әлбәттә. Егет өчен бу табигый теләкләрен тормышка ашыра алмауда чагылыш тапса, физиологик һәм психологик яктан хатынлыкка әзер булмаган кыз туйдан соң берничә ел үтүгә, табигатенә ярашлы рәвештә матураеп, пешеп җитешми, ә картайган бала сурәтенә керә.

Катнаш никахлар проблемасы XX гасыр башы әдәбиятында төрле әдипләр иҗатында очрый. Шундыйлардан мәктәп программасы нигезендә Ф. Әмирханның «Хәят», Г. Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрләре өйрәнелә. «Милләтебезнең ассимиляциясен тизләтүче катнаш никахлар мәсьәләсе – җәмәгатьчелекне нык борчыган җитди мәсьәләләрнең берсе. Татар милләтен һәлакәткә китерүче бу хәлгә әдипләребез битараф кала алмыйлар, җәмгыятебезнең милли-рухи ярасына әверелгән әлеге проблеманы әсәрләрендә кыю күтәреп чыгалар һәм катнаш никахның милли рухка гаять зур зыян китерүен ачыктан-ачык язалар», – дип искәртә Г.И. Каюмова [3: 60]. Г. Исхакый әсәре шул яктан кызыклы: ул проблеманы, дәреслек авторлары ассызыклап киткәнчә, «хискә бирелмичә, аек акыл белән һәм мөмкин кадәр объектив булырга тырышып яктырта» [7: 233]. Әсәрнең үзенчәлеге генә түгел, көче дә нәкъ шунда.

Мәктәп укучыларына татар әдәбияты дәресләрендә мондый проблематикага кагылышлы әсәрләр тәкъдим ителүнең иҗтимагый-социаль сәбәпләренә дә тукталыйк. Заманыбыз катнаш никахлар саны арту тенденциясе белән характерлана, тенденциянең озак еллар дәвамында үсүе, хәзергәчә дәвам итүе, җәмгыятьтә моңа карата нигездә уңай караш хакимлек итүе саф татар гаиләләренең кимүенә йогынты ясый. Соңгы берничә елгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, Татарстанда һәр бишенче гаилә – катнаш никах кору нәтиҗәсе. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, күпчелек респондентлар мондый никахларда милләт, этнос өчен куркыныч янавын күрмиләр һәм бик аз сандагылар гына бу проблема өчен борчыла. Галим-социологлар язганча, «Күрәсең, халык, милләтнең юкка чыгуыннан курыккан аз санлы респондентлар мондый гаиләләдә милли рух, милли үзенчәлекләрнең югалуыннан куркадыр. Әмма бу проблема күпкә күпертелгән, чөнки милли мәдәният генетик дәрәҗәдә түгел, аң дәрәҗәсендә саклана» [5: 228]. Икенче галимә – Г.Р. Столярова да проблеманың күпертелгән булуы ассызыклый, мондый гаиләләрдә үскән балаларның да милли, этник үзаңнарының тотрыклы булмаулары турындагы фикерләр дә нык арттырылган, дигән фикерне җиткерә. Икенче бер проблема – төрле милләт кешеләренең күзаллаулары, дөнья картиналары төрле булу сәбәпле, катнаш гаиләнең тизрәк таркалуын да миф булуын расларга тырышып, болай яза: «Республика материалларында этникара гаиләләрнең бермилләтле гаиләләр белән чагыштырганда тотрыксызрак яисә тотрыклырак булуы дәлил тапмый. Гаилә өчен таркалу куркынычы күбрәк социаль һәм демографик детерминантлар белән бәйле (гаилә әгъзаларының социаль һәм белем статусы арасындагы аермалар зур бул-

ган гаиләләрдә аерылышу очраклары ешрак теркәлә, бик яшьли яисә киресенчә соң рәсмиләштерелгән, икенче, өченче, дүртенче мәртәбә корылган гаиләләргә аерылышу куркынычы яный» [6: 27]. Бу галимнәрнең фикере белән өлешчә генә килешеп була шикелле. Иҗтимагый-социаль яктан имин булган очракта да, гаиләләрдәге балалар ике милләт, ә еш кына ике дин арасындагы аермалыкларның тискәре йогынтысын тоячаклар, әлбәттә. Кире күренеш тә очрый: гаилә әгъзалары, балалар милләтләр арасындагы аермаларга нигезләнгән тискәре йогынты тоймый, чөнки гаилә бер генә милләт кануннары буенча яши. Кызганычка каршы, мондый очраклар сирәк түгел, һәм алар татар милләте файдасына карамый. Г. Исхакый иҗатында һәр очракка да мисал табарга, күрергә була. «Ул әле өйләнмәгән иде» һәм «Көз» повестьлары мисалында әдипнең фикерен төгәлләштерергә тырышырбыз.

Шәмсетдиннең Анна белән танышуы Петербург – Россиянең затлы, мәдәни яктан югары үсеш алган Борынгы шәһәрендә була. Ул аның исеме Анна Васильевна булуын, «үзенең ике ел элек ире үлгәч, ире урынына сатучы булып кереп, үзәзер киемнәр кибетендә приказчик икәнен, эче пошканнан театрларга йөрергә, вечерларга барырга ярата торган күңелле хатын» булуына ышана [7: 235]. Аралар якыная баргач, язучы Аннаның һәртөрле уңай сыйфатларына игътибар итә: ул – уңган хуҗабикә, Шәмсетдин өчен кызыклы әңгәмәдәш, әхлакый яктан да бөтен шикелле, һәрхәлдә, Шәмсетдин авыргач, аны тәрбияләве, кайгыртуы шул хакта сөйли. XX гасыр башы – катнаш никахлар җәмгыять тарафыннан хупланмый торган чор. Шәмсетдин дә Анна белән араларны өзү, Аннадагы сыйфатларга ия булган татар кызына өйләнү турында хыяллана. Ни кадәр эзләмәсен, ул мондый кыз таба алмый. Ә вакыйгалар исә яңа юнәлештә үсә башлый: Анна балага уза. Элек татар гореф-гадәтләре буенча яшәргә, татар кызына өйләнергә теләген күңелендә йөрткән Шәмси боларга чик куелуын аңлый. Элекке күңелле, шаян чагына ул бары эчерткеч эчемлек кулланганда гына кайта. Шуңа да мәҗлесләрдә ул күбрәк, ешрак эчәргә тырыша башлый. Күңел бушлыгын, милли йолалардан аерылуын, бигрәк тә баласының саф татар милләте вәкиле булмавы нәтиҗәсендә туган кара бушлыкны шулай тутырырга тырыша. Икенче кызлары да тугач, аны бер юаныч яшәтә – бала үсә төшкәч, Истанбулга алып китеп, мөселманча тәрбия итү һәм татар мөгаллимәсе итеп күрү. Мәгърифәтчелек позициясеннән караганда да бу бик гүзәл хыяллар була. Әмма көннәрнең берендә Шәмси аларның тормышка ашмаячагына төгәл үк ышана: Анна кызларының икесен дә чукындыра, Шәмсидән качырып, чиркәүләргә йөртә. Шушы көннәрдә ул Аннадан китеп, мулла кызына өйләнеп яшәргә карар бирә. Укучылар биредә шуны күрәләр: бер яктан, авылдагы татар тормышы шәһәр, бигрәк тә Петербург кебек югары мәдәниятле шәһәр тормышыннан, әлбәттә, аерыла. Шәмсигә җиңгиләренең балаларына мөнәсәбәтләре дә дорфа, ризыклар да тәмсез исле кебек тоела. Аннаның исә, киресенчә, гаҗәеп оста психолог булуын күрәбез. Башкага өйләнергә киткән Шәмсигә ялынмый, еламый. Аның каравы кызларының матур фотосурәтләрен җибәрә, аларның әтиләрен сагынуын, елауларын, авырып китеп, бары әти кайткач кына терелергә теләүләрен итагатьле генә хәбәр итә. Мондый зирәклек-хәйләкәрлек мең кат шелтәдән дә тәэсирлерәк булып чыга. Шәмси, сөйләшенгән булса да, ул мулла өенә кермичә, Петербургка китә. Хәзер инде ул өченчегә узган Аннаның малай табып, монысын төгәл Истанбулда укытырга, мөселман итәргә хыялланып яшәргә, үз-үзен шулай юатырга тырыша.

Дәреслек авторлары, Анна, Шәмсинең гамәлләренә бәя биреп баруны күздә тоткан сораулар һәм биремнәрне әсәр белән танышу дәвамында биреп баралар. Повесть идеясен, проблемага автор мөнәсәбәтен, укучыларның мөнәсәбәтен ачыклау өчен дә сораулар тәкъдим ителә. Шуларның кайберләрен генә теркәп китик:

– Автор үз геройлары язмышы аркылы нәрсә аңлатырга тели дип уйлыйсыз?

– Татар кызларына Аннада булган нинди сыйфталар җитми, дип уйлыйсыз?

– Катнаш гаиләләргә сезнең мөнәсәбәтегез ничек? Бу гаиләләрдә гореф-гадәтләр, традицияләр сакланамы? [7: 257]

Безнең фикеребезчә, әлеге әсәрдә күтәрелгән проблемаларны тулырак аңлау өчен өстәмә уку өчен «Көз» повестен тәкъдим итеп, алдагы дәрестә шул әсәр буенча да фикер алышу үзен аклый. Бу әсәрдә ике хатын-кызның язмышы тасвирлана. Нәфисә

язмышы – беренче сюжет сызыгын, Гөлсем язмышы икенче сюжет сызыгын тәшкил итеп, алар өченче сюжет сызыгында – пристаньда Хәлил белән очрашуга бәйләнгән сюжетта кисешәләр. Нәфисә – сәүдәгәр кызы, саф татар гаиләсендә тәрбия ала, театр-мәҗлесләрне калдырмый, авыр чакта Коръән укый, хисләрен әнисе белән уртаклаша. Гөлсем – рус мохитенә тартылган этисе һәм тутакаенда, кыска вакытта мөселман әбисендә тәрбияләнгән, рус һәм татар мохите арасында тарткалаша торгач, үз ихтыярын югалткан, әбисенә ярар өчен, ураза тоткан, тутакаена ярар өчен, уразаны бүлеп чәй эчкән йомшак кыз булып җитешә. Аларны мөһим үзәк берләштерә – гомерләренең язында алар Хәлилгә гашыйк булалар. Гөлсемнең тутакае, үз файдасы өчен, кызны таныш офицерга өйләндерергә, шуның өчен, күп акча алырга тели. Дөреслекне белгәч тә, Гөлсем бәхете өчен көрәшми диярлек, корбан булырга тавышсыз ризалаша. Ә бит Хәлил (аны ул вакытта Паша кушаматы белән атап йөртәләр) аңа ярдәм кулын сузарга тели: «Сез, туташ, сазлыкта үскән бер гөл. Тирә-юнеңез баткаклык, эчкән суыңыз сазлык суы, сулаган һаваңыз черегән сазлык һавасы, монда гөлгә үсәргә, гөл булып яшәргә имкян юк. Бу тирә-юньдә сез бетәчәксез, сез дә башкалар кебек сазлыкка батачаксыз. Сезне бу сазлыктан алсаң гына, сез мәңгегә гөл булып кала беләчәксез... Чыгыгыз моннан... Чыгыйк моннан, сарылыңыз минем кулыма, туташ», – ди [1: 126]. Әмма ихтыярсыз Гөлсем көрәш юлына басудан курка. Нәтиҗәдә гомеренең көзендә ул – эчкече ирнең хатыны, җыерчыклы, картаеп баручы ханым, балалары нерв авырулы (төнлә куркып уяналар). «Мирза кызы үз катлавының милләт алдындагы вазифасын үтәмәгәне өчен җәзалана кебек»,– дип яза Ф. Мусин [4: 158].

Нәфисәнең тормышы бәхетле. Ул ирен чиксез ярата, ире дә аны сөя, балалары да акыллы, тәртипле булып үсеп киләләр. Ләкин бу бәхет өчен Нәфисәгә көрәшергә туры килә: ул этисе белән конфликтка керүдән курыкмый, Хәлилне табу өчен, бөтен шәһәр буйлап йөри, гайбәт сүзләргә игътибар итмичә, Хәлилне озатырга чәкчәкләр пешертеп килә, үзе беренче булып егеткә истәлеккә балдагын бүләк итә, Хәлилнең икенче кайтуында, этисенең бай егеткә кияүгә бирергә теләвенә карамастан, хәзрәтнең Хәлил белән үзенә никах укуына ирешә.

Милли мохиттән, татар җирлегеннән, халкыннан аерылу Гөлсемне драматик финалга китерә. Үз балалары Гөлсем язмышын кичермәсеннәр өчен, татар мохитендә үссеннәр өчен, Нәфисә белән Хәлил тырышалар. Торган урыннары Мәскәү булса да, «балаларга үз халкымыз арасында торырга уңай булсын дип, бер зур мөселман авылы янында кечкенә генә йирле, сулы» утар сатып алалар [1: 114].

Шул рәвешле, укучылар үз асылыңнан, милләтеңнән аерылуның тирән проблема булуын шушы ике әсәр мисалында аңлый алалар. Катнаш никах проблемасы бүген дә актуаль яңгырый. Социолог-галимнәр мондый күренешнең, Россия Федерациясе кебек күпмилләтле дәүләт шартларында табигый дип таныйлар. Татарстан – Россия Федерациясе субъекты булып тора. Россия исә үз эчендә 160 ка якын милләтне берләштергән эре полиэтник дәүләт буларак билгеле. Татарстан территориясендә татар, рус, мари, мордва, чуаш, башкорт кебек милләтләренең вәкилләре көн күрә. Шулай да күпчелекне татарлар һәм руслар тәшкил итә. Катнаш гаиләләр арасында да ир – рус, хатын – татар яисә киресенчә ир – татар, хатын – рус булганнары күпчелекне тәшкил итә. Г. Исхакый кебек җәмәгать эшлеклеләре, язучылар социология кысаларыннан чыгып, тирәнрәк уйларга чакырылар: катнаш никах милли йөзеңне югалтуга юл ачмасмы? Балаларың, нәселеңә моның йогынтысы нинди булачак? Милләтебезнең асыл ирләре, кызлары чит милләт вәкилләреннән җаннарына якын нинди сыйфатлар эзлиләр? Югары сыйныф укучылары, Г. Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» повестен анализлап, әнә шулар хакында уйланырга тиешләр.

Сүзебезне йомгаклап, шуны әйтер идек: әдәбият – предмет белемнәр белән коралландыру гына түгел, шәхес формалаштыру ягыннан да зур куәткә ия. Югары сыйныфта дәреслек авторлары катлаулы, иҗтимагый-әхлаклылык ягыннан әһәмияткә ия, шул ук вакытта каршылыклы проблемалар турында уйланырга этәрәләр. Бүген, гаилә институты җимерелү ягында торганда, никах, гаилә кору мәсьәләсенә җитди якын килергә өйрәтүнең әһәмиятен төшендерә һәм әдәбият дәресләре мөмкинлекләр бирә икән, укытучы-галимнәр моннан файдаланырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. V том: хикәяләр, повестьлар, пьесалар (1920–1947). – Казан: Идел-Пресс, 2009. – 559 б.

2. Исхакый Г. Остазбикә: повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 495 с.

3. Каюмова Г.И. «Битлекләр» уенында – милләт фаҗигасе... // Фәнни Татарстан. – 2019. – № 1. – Б. 60–67.

4. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.

5. Нагматуллина Л.К., Максимова О.А. Межэтнические браки в оценках молодежи Татарстана: тренды и региональная специфика // Вестник экономики, права и социологии. – 2020. – № 4. – С. 227–230.

6. Столярова Г.Р. Феномен межэтнического взаимодействия: опыт постсоветского Татарстана: автореф. дис. …д-ра ист. наук. – Чебоксары, 2004. – 40 с.

7. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Әхмәтҗанова Г.М., Җамалиева Л.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 10 сыйныф. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2017. – 431 б.

УДК 371.3

# ТВОРЧЕСТВО ГАЯЗА ИСХАКИ В НОВЫХ ПРОГРАММАХ И УЧЕБНИКАХ

***Г.Н. Мухарлямова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются вопросы включения произведений Гаяза Исхаки в новые программы по родной (татарской) литературе. Изучение творчества писателя подразумевается в 8–10 классах основного и среднего общего образования. В программе собраны самые лучшие образцы творчества Гаяза Исхаки, доступные для понимания обучающимися с позиции идеи произведения, его тематики и проблематики.
**Ключевые слова**: творчество Гаяза Исхаки, произведение, Примерная рабочая программа, Федеральная рабочая программа, учебник.

The article discusses the inclusion of Gayaz Iskhaki's works in new programs on native (Tatar) literature. The study of the writer's work is meant in grades 8–10 of basic and secondary general education. The program includes the best examples of the work of Gayaz Iskhaki, accessible to understanding from the perspective of the idea of the work, its themes and issues.
**Key words**: creativity of Gayaz Iskhaki, work, Approximate work program, Federal work program, textbook.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНЫҢ ЯҢА ПРОГРАММА-ДӘРЕСЛЕКЛӘРДӘ БИРЕЛЕШЕ

***Г.Н. Мөхәрләмова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX йөз татар әдәбиятында аерым урынны алдынгы фикер иясе, зур дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, күренекле язучыларның берсе, драматург, нәшир, публицист Гаяз Исхакый алып тора. Аның әдәби мирасы бай һәм күпкырлы. Ул күп кенә хикәя-повестьларында, романнарында, драма әсәрләрендә татар милләте, иҗтимагый яшәеш, гаилә, әхлак проблемаларын күтәрелеп чыккан. Әдип әсәрләренең мәктәп программаларында шактый еллар күренекле урын алып торуы шуның белән аңлатыла да.

Бүген «Туган телдәге (татар телендәге) әдәбият» уку предметыннан яңа буын үрнәк программалар дөнья күрде. Үрнәк белем бирү программасында, Үрнәк эш программасында, Федераль эш программасында [2; 3] Гаяз Исхакый иҗатын өйрәнүгә аерым сәгатьләр каралган. Биредә язучының иң матур, укучыларга төшенү өчен идея-проблематикасы аңлаешлы, тәрбияви әһәмияте зур булган әсәрләр сайланды. Аерым алганда, әдәби алымнарны өйрәнүгә багышланган 8 сыйныф материалы үз эченә Гаяз Исхакыйның «Көз» повестен кертеп карый. Биредә әсәр әдәби урын һәм вакытны тәшкил иткән хронотоп төшенчәсен өйрәнү белән бәйле үзләштерелә. Повестны урын-вакыт аспектында өйрәнү предметны өйрәнүгә сәгатьләр саны кыскару сәбәпле әсәргә

тулы анализ ясау мөмкинлеге кими барганда, шуңа бәйле материалның шактый өлешен бик кыска вакыт эчендә өйрәнү кирәк булганда отышлы санала.

Бу тема кысаларында укучылар әдәби урын һәм вакыт турында төшенчә белән танышалар, төрле хронотопик образларны билгеләргә өйрәнәләр, аларны әсәрдә танып, күреп, алар белән эш итү күнекмәсен алалар.

Гаяз Исхакыйның «Көз» повестен бу яктан өйрәнүне максат итеп кую күп кенә мәсьәләләрне чишүдә ярдәм итәчәк. Әсәрнең идеясен аңлау укучыларда шәхескә бәйле нәтиҗәләргә ирешүгә, ягъни тормышта үз юлын, урынын дөрес таба алу әһәмиятен аңлауга җиткерәчәк. Дәрестәге эшчәнлек укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрү, тамга-символик гамәлләр формалашу, хезмәттәшлек итү, фикерләрен дәлилле җиткерә, эшне планлаштыра алу, уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя кебек метапредмет нәтиҗәләргә ия булуына китерәчәк. Предмет нәтиҗә булып бу очракта Гаяз Исхакыйның «Көз» повестен урын-вакыт аспектында өйрәнү аша әсәрнең идеясенә төшенү санала. Дәрестә үзләштерелергә тиешле төшенчәләрдән хронотоп, урын һәм вакыт, пространство, тупса хронотобы, хронотопик образлар дигәннәрен күрсәтә алабыз. Гаяз Исхакыйның «Көз» повестен әдәби урын-вакыт аспектында өйрәнү табигать күренешләре, пейзаж, портрет, диалог, монологлар кебек төрле әдәби чаралар белән беррәттән укучыга геройларның уйкичерешләрен, төрле халәтләрнең, үз бәхетләре өчен көрәшү-көрәшмәвен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә.

9 сыйныф программасы әдәбият тарихын өйрәнү барышында XX йөз башы әдәбияты темасы кысаларында Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясен тәкъдим итә.

Билгеле булганча, мәктәпнең урта звеносында язучы иҗатын монографик планда өйрәнү аның әсәрләре белән бәйләп, аларны анализлау аша алып барыла. Бу рәвешле эшләү әдип иҗатын тикшерү, бәяләү һәм, гомумән, әдәбият тарихындагы урынын билгеләүне дә күздә тота. Бу вакытта укучы язучының биографиясен, аның әсәрләрен чор белән бәйләп өйрәнергә тиеш була. Язучы иҗатына хас төп сыйфатлар, нинди темаларга язарга ярата, нинди жанрларга өстенлек бирә – барысы да мөһим булып санала.

Биредә хикәяне өйрәнүгә керешкәнче Гаяз Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү ясау сорала. Дәреслектә язучының биографиясен чагыштырмача тулы рәвештә өйрәнү каралган. Монда Гаяз Исхакыйның патша хөкүмәтенә каршы көрәше, бу көрәштә төп омтылышлары, эшче-крестьян мәнфәгатьләрен кайгырту, аларны иҗтимагый изелүдән коткару максаты белән януы турында сөйләү, әдипнең милләт язмышы өчен борчылуы дә керә. Дәрестә Гаяз Исхакыйның тормыш юлы белән бергә көрәш юлы, төрмәләрдә утыруы, сөргендә булуы, чит илгә эмиграциягә китүе белән таныштыру, бай әдәби мирасын барлау да күздә тотыла.

Программада халыкның милли яшәешенә, күркәм гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, нәселенә, борынгы тамырларына юнәлткән әсәргә – «Сөннәтче бабай» повестена якынрак тукталу каралган. Программа әсәрне татар халкының әхлакый сыйфатларын барлау яссылыгында өйрәнүне күздә тота. Шуңа күрә, иң элек, аның халыкчан җирлеге ачыклана. Төп герой – Сөннәтче картның рухи дөньясы, рухи кичерешләренең нечкә борылышлары, гадәт-йолаларга тугрылыкның чагылышы, әхлакый пакьлекнең әһәмияте ачыклана. Укучылар шуларның кеше рухын матурлавы, кешене кеше итеп яшәтүе һәм шәхес буларак күтәрүен аңларга тиеш булалар. Шулай ук алар, традицияләрнең дәвамчанлыгын, татар халкы үзендә җыеп барган һәм буыннанбуынга күчереп барган тарихи тәҗрибәсен күзәтә алачаклар.

10–11 сыйныфлар өчен төзелгән үрнәк эш программасы татар әдәбиятын проблемалы-тематик блокларга («Кеше – иң зур кыйммәт», «Кеше һәм гаилә», «Кеше һәм милли характер» һ.б.) аерып өйрәнү белән үзенчәлекле. Аерым алганда, «Кеше һәм гаилә» темасы кысаларында Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» әсәрен өйрәнү каралган. Гаилә, никах, мәхәббәт проблемаларын Гаяз Исхакый татар хатын-кызы бәхете мәсьәләсен үзәккә куеп яктырта. Язучы героинясы Сәгыйдәнең фикер-кичерешләрен шул вакыттагы татар авылы тормышы шартларында сурәтли. Биредә Гаяз Исхакый

«муллалар тормышын иҗтимагый-милли мәсьәләләр яссылыгында сурәтләүдән баш тартып, аны мәңгелек, гомумкешелек проблемаларын калкытып куюга буйсындыра: аерым кеше, гаилә бәхете, яшәү мәгънәсе, фани дөньяга яратылу максаты һ.б.» [8: 158]. Мәктәптә дә нәкъ менә шул якларга игътибарны юнәлтеп өйрәнергә тиеш булабыз. Сәгыйдә образына характеристика биреп укучылар аның тыныч, сабыр, акыллы, зирәк һ.б. булуын билгеләүгә чыгалар. Татар хатын-кызына хас булган сыйфатларның Сәгыйдә образында тупланып чагылыш табуы милләтебезнең асылын, аның гүзәл затларыбызга йөкләтелгән миссиясен билгеләргә ярдәм итә.

Укучы тормышның мәгънәсе, гаилә бәхете мәсьәләләре турында уйлана. Мәхәббәт көче һәм тугрылыкның әһәмиятен күрү гаилә кануннарының асылын аңлауга, алга таба тормыш корып гаилә булып яшәүдә туарга мөмкин аңлашылмаучанлыкларны, киртәләрне җиңел үтү мөмкинлеген бирәчәк, төзелгән гаиләнең ныклыгын тәэмин итәчәк. Шулай ук бүгенге яшьләргә җиткерелергә тиешле – хатын-кыз бәхете ана булуда дигән мөһим фикерне шушы әсәр мисалында аңлату отышлы.

Әлеге әсәрне өйрәнү барышында теоретик төшенчә буларак психологизм үзенчәлекләрен үзләштерү дә тәкъдим ителә. Бу очракта ул Сәгыйдәнең эчке конфликтына нигезләнеп аңлату рәвешен ала. Эчке драматизмы һәм тирән психологизмы белән көчле булган бу әсәр героиняның рухи фаҗигасын үзенчәлекле рәвештә ача.

10 сыйныфта үзләштерүгә Гаяз Исхакыйның тагын бер әсәре – «Җан Баевич» комедиясе тәкъдим ителә. Ул «Кеше һәм милли характер» проблемалы-тематик блок эченә кертелеп өйрәнелә. «Җан Баевич» комедиясе – Гаяз Исхакыйның татар тормышында очрый торган наданлыктан, маңкортлыктан көлеп, аны тәнкыйтьли торган күренекле әсәрләрнең берсе. Ул милли асылыңны югалту проблемасы яктылыгында өйрәнүне күздә тота.

Укучылар әсәр герое Җан Баевичны характерлап, аның мин-минлекле, үз тиңнәреннән үзен өстен куючы, тәкәббер, шапырына торган кеше булуын ачыклыйлар. Нәтиҗәдә аның бөлүе, үз милләтенә, аның тарихына, гореф-гадәтләренә кимсетеп каравы өчен җәза алуын дөрес дип билгелиләр. Бу очракта индивидуаль характерлар тудыруда авторның осталыгына игътибар иттерергә кирәк.

Әсәрне өйрәнү барышында манкорт (үз милләтеңнең рухи кыйммәтләренә кимсетеп карауче, үз милләтеннән ваз кичкән кеше), мөртәт (үз диненә хыянәт иткән, башка дингә күчкән кеше), милли нигилист (туган телгә, халкына, аның гореф-гадәтләренә, милли традицияләренә тискәре мөнәсәбәттәге кеше), тәрәккыйпәрвәр (иҗтимагый тормышта алга китүне, үсүне, прогрессны яклаучы, яңалыкны яратучы кеше) төшенчәләренә аңлатма биреп, шуларны төп образны характерлаганда кулланырга тәкъдим итеп була.

Әсәрнең проблематикасын ачыклау, ярдәмче һәм төп конфликтларны билгеләү укучыларга әсәрнең идеясен билгеләүдә ярдәм итә, ягъни алар үз милләтеңнән ваз кичеп мөртәт татар буларак тарихта яман эз калдырмаска, үз ишләреңнән өстен булырга омытылып шапырынмаска кирәк дигән фикергә киләләр.

Программа бу әсәрне өйрәнү барышында теоретик материал буларак фарс төшенчәсенә билгеләмә бирүне күздә тота. Укучылар фарсның үзенчәлекле юморга ия булуын, персонажларның һәрвакыт карикатура хәлендә, аларның җитешсезлекләре соңгы чиккә җиткерелеп, күпертеп сурәтләнүен аңларга тиеш булалар.

Шул рәвешле, Гаяз Исхакый әсәрләре, яңа программаларда лаеклы урынын алып, мәктәп укучысының үз халкына, аның тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, туган телгә хөрмәт белән караучы милли җанлы шәхес булып формалашуына ярдәм итә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. Әдәбият дәресләрендә шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру: методик ярдәмлек. – Казан: ТӘһСИ нәшр., 2018. – 46 б.

2. Абдуллина Д.М., Мухарлямова Г.Н. Примерная образовательная программа учебного предмета «Родная литература (татарская)» для 5–9 классов основного общего образования с обучением на родном (татарском) языке. – Казань, 2021. – 85 с. https://fgosreestr.ru/oop/primernaia-obrazovatelnaia-programma-uchebnogo-predmeta-rodnaia-literatura-tatarskaia-dlia-5-9-klassov-osnovnogo-obshchego-obrazovaniia-s-obucheniem-na-rodnom-tatarskom-iazyke

3. Абдуллина Д.М., Мухарлямова Г.Н. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родная (татарская) литература» для 5–9 классов основного общего образования с обучением на родном (татарском) языке. – Казань, 2022. – 79 с. https://fgosreestr.ru/oop/primernaia-rabochaia-programma-uchebnogo-predmeta-rodnaia-tatarskaia-literatura-dlia-5-9-klassov-osnovnogo-obshchego-obrazovaniia-dlia-obrazovatelnykh-organizatsii-s-obucheniem-na-rodnom-tatarskom-iazyke

4. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Второе издание, переработанное и дополненное. – Казан: «Мәгариф», 2004. – 367 б.

5. Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. Әдәбият дәресләрендә хронотопны өйрәнү үзенчәлекләре // Фәнни Татарстан. – 2018. – № 4. – Б. 111–117.

6. Мухарлямова Г.Н., Абдуллина Д.М. Изучение литературных произведений в аспекте художественного времени и пространства (на примере уроков родной литературы) // Вестник Майкопского государственного технологического университета. Вып. 3/42. – Майкоп: Издательство ФГБОУ ВО «МГТУ», 2019. – 200 с.

7. Мухарлямова Г.Н., Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М., Абдуллина Д.М. Создание современных УМК по родному (татарскому) языку и литературе: проблемы, подходы, решения // Преподавание родных языков в современных условиях: эффективные методики и технологии: материалы всероссийской научно-практической конференции с международным участием (Улан-Удэ, 17–18 декабря 2020 г.) / науч. ред. Л.В. Аюшеева, отв. ред. Б.Д. Цырендоржиева. – Улан-Удэ: Издательство Бурятского госуниверситета, 2021. – С. 70–76.

8. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казань: «Мәгариф», 2006. – 319 б.

УДК 371.214.41=512.145

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ТАТАРСКИХ МЕТОДИСТОВ В СФЕРЕ ПРЕПОДАВАНИЯ РОДНОГО ЯЗЫКА

***М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Хронологически разработка научных основ методики преподавания татарского языка как неродного относится ко второй половине XIX и первой половине XX веков (В.В. Радлов, В.А. Богородицкий, К. Насыри, Г. Тукай, Г. Исхаки, М.Х. Курбангалиев, Р.С. Газизов и др.). В этот период основное внимание сосредоточено на изучении языка, на целях и задачах, методах и формах обучения татарскому языку. Исходной вехой лингвистической, а впоследствии и методической науки, без всякого сомнения, следует считать деятельность Каюма Насыри. Его идеи оказали решающее влияние на формирование лингвометодической науки.
**Ключевые слова**: лингвометодическая наука, методика преподавания татарского языка, русско-татарский словарь, педагогика, грамматика.

Chronologically, the development of the scientific foundations of the methodology for teaching the Tatar language as a non-native language refers to the second half of the 19th and the first half of the 20th centuries (V.V. Radlov, V.A. Bogoroditsky, K. Nasyri, G. Tukay, G. Iskhaki, M.Kh. Kurbangaliev , R.S. Gazizov and others). During this period, the main attention is focused on the study of the language, on the goals and objectives, methods and forms of teaching the Tatar language. The initial milestone of linguistic, and later methodological science, without any doubt, should be considered the activity of Kayum Nasyri. His ideas had a decisive influence on the formation of linguo-methodological science.
**Key words**: linguo-methodological science, methods of teaching the Tatar language, Russian-Tatar dictionary, education, grammar.

# ТАТАР МЕТОДИСТЛАРЫНЫҢ ТУГАН ТЕЛНЕ УКЫТУ ЮНӘЛЕШЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XIX–XX гасырлар чиге – мәктәпләр өчен дәреслекләр, үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр язу, сүзлекләр төзү һәм тәҗрибә туплау чоры буларак тарихта билгеле. Нигездә бу чор рус телендә сөйләшүчеләр өчен сөйләүлекләр, үзөйрәткечләр, грамматика китапларының күпләп чыгуы белән аерылып тора (А.Троянский, М. Казимбәк, С. Кукляшев, М. Иванов, М. Бекчурин, Г. Ваһапов, Н. Ильминский, И. Кондратов, А. Мәх-

мүдов, Г. Фәисханов, К. Насыйри һ.б.). Әлеге чорда татар теле Тобольск, Томск, Оренбург, Саратов, Астрахань, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә укытыла. Яңа белем бирү системасы бер-берсе белән нык бәйләнгән дүрт баскычтан тора: югары – университет (һәр округта), урта – гимназия (һәр губернада), урталыкта – өязләрдәге училищелар (һәр өяздә берәр), түбән – мәхәллә (шәһәрләрдә һәм авылларда). Университет училищелар, гимназияләр, мәктәпләр ачуга, программалар, дәреслекләр эшләүгә, укытучылар әзерләүгә дә зур көч куя. 1804 елда Устав («Устав учебных заведений, подведомых университетам») басылып чыкканнан соң яңа типтагы гимназияләр дә ачыла.

XIX гасырның 60 елларында бер төркем рус педагоглары (П.Г. Редкин, К.Д. Ушинский, А.С. Воронов, Д.Д. Семенов, В.Я. Стоюнин һ.б.) С.-Петербургта Педагогик җәмгыять төзиләр: искечә укыту алымнарын, тәрбия чараларын, дәреслекләрне тәнкыйтьлиләр, Россиядә грамоталылык дәрәҗәсе түбән булуны ассызыклыйлар, бигрәк тә авыл җирләре өчен белемле укытучылар әзерләү, алар өчен китапханәләр ачу турында фикерләшәләр. «Педагогик елъязмалар» дигән журнал да чыгаралар [1: 7]. Кызганычка каршы, 1879 елда патша хөкүмәте бу Педагогик җәмгыятьне яба.

1905 елда булган инкыйлаб җилләре нәтиҗәсендә Россия империясенең төрле төбәкләрендә (Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург һ.б.) татар телендә газета-журналлар чыга башлый («Тәрбияи әтфаль» («Балалар тәрбиясе». Мәскәү), «Тәрбия» (Казан), «Мәктәп» (Казан), «Мөгаллим» (Оренбург) журналлары һ.б.). 1913–14 елларда чыккан «Мәктәп» журналы түбәндәге мәсьәләләрне яктырта: уку-укыту һәм тәрбиягә караган хәбәрләр; мәктәп фәннәре һәм аларның программалары; хатын-кыз мәгарифе; чил илләрдә мәгариф; әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре, тел белеме; фәнни, тарихи һәм икътисади мәкаләләр; мәктәп-мәдрәсә тарихлары һ.б. (XX йөз 1997: 5). Татар зыялыларыннан Г. Баттал, Һ. Атласи, Һ. Максуди, Г. Алпаров, Г. Ибраһимов, Н. Думавый, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һ.б. мәгариф мәсьәләләренә караган мәкаләләрен атап үтәсе килә. Бу елларда шәкертләр уку-укыту программасына, надан хәлфә һәм ишаннарга ризасызлык белдерәләр, мәдрәсәләрне ташлап китәләр, фәннәрне киңрәк өйрәнүне таләп итәләр.

Татар укытучылар мәктәбендә белем алган Гаяз Исхакый үзенең хезмәтләрендә мәхәббәт, хатан-кыз бәхете, гаилә һәм бурыч, гаиләдә балаларны тәрбияләү, аң-белем тарату, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту мәсьәләләренә дә кагыла («Кәҗүл читек», «Остазбикә», «Сөннәтче бабай», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Ул әле өйләнмәгән иде», «Көз», «Татарның кызы» һ.б.).

Г. Тукай кадими укыту системасын тәнкыйтьли, бердәм, мәгърифәтле булырга чакыра («Туган тел», «Дустларга бер сүз», «Шәкерт, яки бер очрашу», «И каләм», «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару», «Әлифба» һ.б.). Шагыйрь «Исемдә калганнар» (1909) дигән автобиографик әсәрендә Кырлай авылында башта бер ел кызлар белән бергә абыстайга дини китаплардан «Иман шарты»н өйрәнергә йөрүе, аннары икенче елны мәдрәсәгә баруы турында болай дип яза: «Мин мәдрәсәдә, «Һәфтияк» иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар». Г. Тукай үзенең «Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910) дигән хезмәтләрендә укыту-тәрбия өлкәсендәге методик фикерләре белән дә уртаклаша.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров беренчеләрдән булып К.Д. Ушинскийның педагогика һәм уку-укыту методикасына караган фикерләрен дәвам иттерүче, татар телен фән буларак мәктәпләрдә өйрәнү кирәклеген пропагандалаучы була [4: 17]. Ул 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы гаиләдә туган. Ул тәрҗемәче; тарихчы; эпиграфист; тел галиме; лексикограф, педагог. Каюм Насыйриның гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарыннан башлана, төрле уку китаплары һәм дәреслекләр яза башлый: «Нәхү (Рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип атала): Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды (1860). Мәгърифәтче-укытучы буларак, татар һәм рус телләренең грамматикасын

яхшы белә, чагыштырма методка нигезләп аңлата: *«...Ләкин гайре телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйдатен белмәк зарурдыр»* («Фәвакиһел җөләса»). Әлеге дөньякүләм танылган хезмәт бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Ул XIX гасырның икенче яртысында татар лингвистикасының үсешенә үзеннән зур өлеш керткән галим. Профессор Л.З. Шакирова XX гасыр башларында татарларга рус телен өйрәтү барышында файдаланылган табигый, тәрҗемәи (чагыштырма), катнаш һ.б. методларга тирән анализ ясады, үзенең тасвирый бәяләмәсен бирде. Ул тәрҗемәи (чагыштырма) методның нәкъ менә Каюм Насыйрилар заманында ук кулланылышка керүен, алар тарафыннан тәкъдим ителүен ассызыклады [2: 5–6].

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында бөек педагогның да роле бик зур. Бу чорда Каюм Насыйриның татар һәм рус телләрен укытуга керткән өлешен дә ассызыклап үтәргә кирәк [6: 56]. «Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы» дигән хезмәтендә 1871 елда педагог Каюм Насыйриның күргән кыенлыклары, яшәү шартлары, ачлы-туклы яшәүгә дә карамастан, укучыларны берәмләп эзләп табып, ихлас татар телен өйрәтүе, татар һәм рус мәдрәсәләрендә телгә өйрәтү вакыты, баланы русчага укытуда министрлык, инспектор хәзрәтләре, әти-әниләрнең фикерләре зур ихтирамга лаек: *«Бөтен кыш буенча утыз биш малайдан ким булмады, һәм укырга-язарга вә һәм гыйльме хисапка яхшы төшенүчеләр булды»* («Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы»). Духовная семинариядә татар телен укыту белән берлектә рус телен дә яхшылап өйрәнә, соңыннан булачак галим Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1889 елда татарларны русча укырга-язарга өйрәтү өчен, Каюм Насыйри «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән. Телгә өйрәтүдә татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләре дә (1878,1892) мөһим роль уйный: *«Сүзләрне берәм-берәм ятлап, һәрбер ишеткән сүзне исеңдә тотып, берәм-берәм зиһен тубалына тутырырга кирәк. Моның мисалы менә шундый: берәү, бер чиләк алып, урманга җиләк җыярга бара. Иң элек, урман авызына кергәч, чиләгенә бер җиләк өзеп сала. Шулай кичкә чаклы йөреп, чиләген тутыра»* («Русча-татарча лөгать»тән) [2: 36].

Каюм Насыйри әхлак, тәрбия, уку-укыту мәсьәләләрен бергә үреп бирә: «Гыйлемлек вә наданлык», «Ата-ана хакы», «Хәйләкәрлек», «Әдәп» һ.б. Педагог баланы яшьтән үк акны карадан, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтсәк, үсеп җиткәч аңа күпкә җиңел булачагын, тормышта ориентлашып, үз урынын, үз юлын дөрес табачагын ассызыклый, *«... балалар яшь агач кебектер, яшь агач һәрникадәр кәкре булса да, төзәтмәк асандыр»* («Әхлак рисаләсе» (1890)) [2: 38].

1892 елда аның «Кавагыйде китабәт» (Язу кагыйдәләре) дигән кулланмасы басылып чыга. Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» дигән хезмәтен (1895) шул чорның беренче гыйльми тулы грамматикасы дип атыйлар [6: 57]: *«Утыз-утыз биш елдан бирле ике тел фәннәреннән, ягъни үз телебездән вә дәхи рус теленнән балаларга сабак укытканда, хосусан рус телен укытканда үз телебезнең кагыйдәсен бәян кылгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем»*. Шул уңайдан татар телен гыйльми өйрәнүгә, татар телен укыту методикасын үстерүгә зур өлеш керткән Казан тюркология мәктәбенең роле дә, һичшиксез, зур (В. Радлов, Н. Катанов, И.А. Бодуэн де Куртене, В.А. Богородицкий һ.б.).

Россиядә XIX ның ахырына кадәр уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләре буенча күпме проектлар эшләнсә дә, 1917 елга кадәр аларны тормышка ашыра алмыйлар. Балаларын үстерү, аларны укыту, югары тәрбия бирү, ир балалар белән бергә кызларны да мәктәпкә тарту, мәктәпләр төзү, аларны ашату-эчертү – рус һәм татар педагог-галимнәренең уртак проблемаларына әйләнә (С.А. Рачинский «Заметки о сельских школах» (1883)), Н.И. Ильминский «Казанская центральная крещено-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещеных татар» (1887), В.Д. Сиповский «Чего недостает современной школе», «Чему и как учить» (1895) һ.б.). Болар арасында *«аягыма кияргә юк дип укырга йөрмәүче балага кәвеш алып бир-*

*гән»,* ач-ялангач шартларда, фатир эзли-эзли, шунда дәресләр үткәргән олы җанлы, белемле Каюм Насыйри да бар.

Каюм Насыйриның педагогик һәм методик характердагы мәкаләләрен һәм китапларын тикшереп чыккач, шуны әйтәсе килә: ул – шәкертләрнең психологиясен яхшы белә торган оста педагог, уку-укыту һәм тәрбиягә караган мәсьәләләр белән бик теләп, яратып шөгыльләнгән, методика фәнен яхшы белгән тәҗрибәле укытучы. Аның лингвистика, методика өлкәсенә караган хезмәтләренең тарихи әһәмияте туган телебезгә, татарча укытуга игътибар бермә-бер арткан безнең заманда тагын да ачыграк күренә.

Гомумән алганда, XIX–XX гасырлар чигендә язылган методик хезмәтләр, грамматика китаплары, сүзлекләр, кадими укыту системасын тәнкыйтьләгән, гаилә, тәрбия мәсьәләсен күтәргән әсәрләр татар телен укыту методикасы өлкәсендә кызыклы фикерләр уятты, укытуның эчтәлеген ачыкларга, эш алымнарын эзләргә, яңа дәреслекләр язарга юнәлеш бирде.

## ӘДӘБИЯТ


1. Антология педагогической мысли России второй половины XIX – начала XX в. / Сост. П.А. Лебедев. – М.: Педагогика, 1990.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. – Казан: Таткитнәшр., 1974
3. Татар грамматикасы: Өч томда: Т. 1. – Мәскәү: «Инсан», Казан: «Фикер», 1998.
4. Ханбиков Я.И. История развития педагогической мысли татарского народа. – Казань: КГПИ, 1975.
5. Шакирова Л.З. Обучение русскому языку в татарской школе: теория и практика. – Казань: Магариф, 2002.
6. Шакурова М.М. Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. – 2010. – № 3. – С. 207–214.

# ТАТАРСКОЕ ЗАРУБЕЖЬЕ: ИСТОРИЯ, ЛИЧНОСТИ, НАСЛЕДИЕ / МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАРЛАР: ТАРИХ, ШӘХЕСЛӘР, МИРАС / THE TATARS ABROAD: HISTORY, PERSONALITIES, HERITAGE

УДК:930:910.4(575.2)(04)

## ТАТАРЫ КЫРГЫЗСТАНА В ЧИСЛЕ ЖЕРТВ ПОЛИТИЧЕСКИХ РЕПРЕССИЙ 1920–1953 ГГ.

***А.Р. Бикбулатова***
*КНУ им. Ж. Баласагына, (Бишкек, Кыргызстан)*
***Б.Дж. Абдрахманов***
*Учебный центр СИН МЮ (Бишкек, Кыргызстан)*
***С.Р. Бикбулатова***
*АЗМИ им. С. Тентишева (Кант, Кыргызстан)*

В данной статье рассматриваются этапы и мотивы политических репрессий в Кыргызстане в 1920–1953 гг. Предпринимается попытка проанализировать репрессированных по этническим признакам. Впервые выявлены фамилии 165 татар страны, в числе жертв политических репрессий. Уделяется внимание их социальному статусу.
**Ключевые слова:** татары Кыргызстана, политическая репрессия, тоталитаризм.

This article discusses the stages and motives of political repression in Kyrgyzstan in 1920–1953. An attempt is made to analyze the repressed on ethnic grounds. For the first time, the names of 165 Tatars of the country were revealed, among the victims of political repressions. Attention is paid to their social status.
**Key words:** tatars of Kyrgyzstan, political repression, totalitarianism.

На сегодняшний день одной из самых сложных проблем в изучении истории Кыргызской Республики являются политические репрессии тоталитарного режима в первой половине XX века, которые в истории народа Кыргызстана оставили глубокий трагический след. Репрессии были подвержены представители всех национальностей, конфессий, а также все социальные слои общества.

В национальных республиках, образованных после развала СССР, в большей степени, стали изучать численный состав государствообразующих этносов, в числе репрессированных, например, в Узбекистане – узбеков, в Казахстане – казахов [8], в Кыргызстане – кыргызов [2]. Считаем, что в каждой из этих стран наступила пора активного изучения репрессированных по этническим признакам. Так как все эти республики, а ныне суверенные государства, были и остаются многонациональными.

В данной статье речь пойдет о татарах, Кыргызстана, которые были в числе жертв политических репрессий 1920–1953 гг. Итак, общее количество жертв тоталитарного режима в стране в период с 1920 по 1953 год, согласно данных десяти томов «Книги жертв политических репрессий в Кыргызстане (1920–1953 гг.)», составляет 17134 человек [2]. Среди них лиц кыргызской национальности – 6393 или 37,3 %, русских – 3869 или 22,58 %, уйгуров – 1839 (10,73 %), украинцев – 1358 (7,9 %), узбеков – 1138 (6,6 %), немцев – 782 (4,5 %). **Численность татар 165 человек или они составляли 0,98 %** [1: 232–267] **от общего количества репрессированных.**

В стране численность репрессированных по национальным признакам соответствует процентному соотношению их численности в стране, кроме тех случаев, когда со стороны НКВД проводились «национальные операции». Приведем данные о ко-

